# ЛИТЕРАТУРА И ХУДОЖЕСТВЕННАЯ КУЛЬТУРА ТЮРКСКИХ НАРОДОВ В КОНТЕКСТЕ ВОСТОК-ЗАПАД

# ШӘРЫК ҺӘМ ГАРЕБ КОНТЕКСТЫНДА ТӨРКИ ХАЛЫКЛАРНЫҢ ӘДӘБИЯТЫ ҺӘМ СӘНГАТЕ

# EAST AND WEST: LITERATURE AND ARTISTIC CULTURE OF THE TURKIC PEOPLES

КАЗАНЬ - КАЗАН - KAZAN
2020

КАЗАНСКИЙ ФЕДЕРАЛЬНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ

# ЛИТЕРАТУРА И ХУДОЖЕСТВЕННАЯ КУЛЬТУРА ТЮРКСКИХ НАРОДОВ В КОНТЕКСТЕ ВОСТОК-ЗАПАД

**Материалы Международной научно-практической онлайн-конференции**

**Казань, 22–25 октября 2020 г.**

# ШӘРЫК ҺӘМ ГАРЕБ КОНТЕКСТЫНДА ТӨРКИ ХАЛЫКЛАРНЫҢ ӘДӘБИЯТЫ ҺӘМ СӘНГАТЕ

**Халыкара фәнни-гамәли онлайн-конференция материаллары**

**Казан, 22–25 октябрь, 2020 ел**

# LITERATURE AND ARTISTIC CULTURE OF TURKIC PEOPLES IN THE EAST-WEST CONTEXT

**Materials of the International Scientific and Practical Online Conference**

**Kazan, 22–25 October, 2020**

**КАЗАНЬ**
**2020**

**УДК 80/82**
**ББК 80/84**
**Л64**

**Под общей редакцией**
доктора филологических наук, профессора **Ф.С. Сайфулиной**

**Редакционная коллегия:**
**Т.Ш. Гилазов** (отв. редактор), **Г.Р. Гайнуллина**, **Н.М. Юсупова**

**Under the general editorship of**
Doctor of Philology, Professor **F.S. Sayfulina**

**Editorial board:**
**T.Sh. Gilazov** (responsible editor), **G.R. Gainullina**, **N.M. Yusupova**

**Л64** **Литература и художественная культура тюркских народов в контексте Восток-Запад** [Электронный ресурс]: материалы Международной научно-практической онлайн-конференции (Казань, 22–25 октября 2020 г.) / под ред. Ф.С. Сайфулиной. – Электрон. сетевые данные (1 файл: 3 049,55 КБ ). – Казань: Издательство Казанского университета, 2020. – 370 с. – Систем. требования: Adobe Acrobat Reader. – Режим доступа: https://kpfu.ru/portal/docs/F_14491417/SBORNIK_.Vostok_Zapad_2020.pdf. – Загл. с титул. экрана.

**Шәрык һәм гареб контекстында төрки халыкларның әдәбияты һәм сәнгате**: халыкара фәнни-гамәли онлайн-конференция материаллары (Казан, 22–25 октябрь, 2020 ел) / мөх. Ф.С. Сәйфулина. – Казан: Казан университеты нәшрияты, 2020. – 368 с.

**Literature and Artistic Culture of Turkic Peoples in the East-West Context** [Electronic resource]: Materials of the International Scientific and Practical Online Conference (Kazan, October 22–25, 2020) / ed. by F.S. Sayfulina. – Kazan: Kazan University Publishing House, 2020. – 368 P.

**ISBN 978-5-00130-394-7**

Сборник включает в себя работы участников Международной научно-практической онлайн-конференции «Литература и художественная культура тюркских народов в контексте Восток-Запад», проводимой в Институте филологии и межкультурной коммуникации КФУ 22–25 октября 2020 г. В представленных научных докладах рассматривается широкий круг вопросов, касающихся исследования художественной литературы и культуры тюркских народов и актуальных в научно-теоретическом и историко-литературном аспектах.

**УДК 80/82**
**ББК 80/84**

**ISBN 978-5-00130-394-7**

**© Издательство Казанского университета, 2020**
**© Казан университеты нәшрияты, 2020**
**© Kazan University Publishing House, 2020**

**Д.М. АБДУЛЛИНА**
Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясе
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Казан

# Г. ТУКАЙНЫҢ Ш. МӘРҖАНИНЕҢ ДИНИ РЕФОРМАЦИОН КАРАШЛАРЫНА МӨНӘСӘБӘТЕ

**Д.М. АБДУЛЛИНА**
Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова
Академии наук Республики Татарстан, Казань

# ОТНОШЕНИЕ Г. ТУКАЯ К РЕЛИГИОЗНЫМ РЕФОРМАЦИОННЫМ ВЗГЛЯДАМ Ш. МАРДЖАНИ

**Аннотация.** В статье рассматривается отношение Г. Тукая к религиозным реформационным взглядам Ш. Марджани. Свой идеал он художественно воссоздал в стихотворении «Шигаб хазрет» (1913) в образе религиозного реформатора Шигабутдина Марджани (1818-1889), проявившего пример толерантного религиозного свободомыслия. Поэт высоко ценит Ш. Марджани за независимость рассуждений в религиозных вопросах, за обладание силой воли выступить против налипшей на религию грязи, и слепого следования авторитарной устаревшей религиозной традиции. Просветитель Ш. Марджани дорог Тукаю и защитой приоритета разума в религиоведении, а также раскрытием многих тайн смыслов Корана.

**Abstract.** The article discusses the attitude of the G. Tukai to the religious reformation views of sh. Marjani. Your ideal it artistically recreated in the poem "Shihab Hazrat" (1913) image of the religious reformer after Shigabutdin Mardzhani (1818-1889), who demonstrated an example of tolerant religious freedom. The poet appreciates sh. Mardzhani for independent reasoning in religious matters, for the possession of willpower to act against adhering to the religion of dirt, and blind adherence to outdated authoritarian religious traditions. Enlightener Sh. Marjani is dear to Tukai and the protection of the priority of reason in religious studies, as well as the disclosure of many secrets of the meanings of the Koran.

**Ключевые слова:** Г. Тукай, Коран, Ш. Марджани, религия, религиозное реформаторство.
**Keywords:** G. Tukai, Koran, Sh. Marjani, religion, religious reformism.

Татарлар арасында ислам дине фәлсәфәсенең кайбер якларын яңа иҗтимагый үсеш югарылыгыннан торып аңлату, дингә тиешле реформалар үткәрү юлы белән анны кешелек җәмгыятенең яңа этабына әзерләү эшен XVIII гасыр ахыры – XIX гасыр башларында Габдерәхим Утыз-Имәни, Габденнасыйр Курсавилар башлап җибәрә. Соңгарак ул Каюм Насыйри, Шиһабетдин Мәрҗани һ. б. дини реформаторларыбыз тарафыннан дәвам иттерелә. Алар ислам диненең иҗтимагый прогресс, кеше иреге, акыл эшчәнлеге белән каршылыкка кергән өлешләрен үзләре яшәгән чорның аң дәрәҗәсе югарылыгыннан торып кабул итәргә чакыралар. Ислам дине мөселман халыкларының икътисади, мәдәни, рухи үсешенә, җәмгыятьтә шәхеснең күпкырлы эшчәнлегенә юл ачуга хезмәт итәргә тиеш дип карыйлар. Димәк, ислам диненең кешелек җәмгыяте өчен зур әһәмияткә ия булган өйрәтүләрен кире какмаган хәлдә, аңа заман югарылыгыннан торып шәрехләүләр бирергә дә мөмкин дип саныйлар.

Тормышны үзгәртүдә динне сафландыру, гыйлемлелекне беренче урынга куеп фикер йөрткән шагыйребез Габдулла Тукай җәмгыятьтәге иҗтимагый-сәяси

вакыйгаларның асылын да шул ноктадан торып аңлата. Балалар өчен язылган әсәрләрендә дә шул юлыннан читләшми. Мәсәлән, «Сабыйга» шигырендә «Мәгърифәт нуры ачар күп нәрсәләрнең ялганын» [Тукай, 1985: 74], ди.

Дөньяны үзгәртеп коруны ул мәгрифәтчеләрчә күзаллый. Әмма үгет-нәсыйхәт ярдәмендә камил кеше тәрбияләүне максат итеп куйган XIX йөздәге дидактик мәгърифәтчелектән аермалы буларак, XX гасыр башындагы инкыйлаблар дәверендәге Тукай мәгърифәтчелеге публицистик ялкын белән сугарылган.

Коръәндә дә, хәдисләрдә дә бер үк эчтәлекле әхлакый кануннар: намуслылык, башкаларны рәнҗетмәү, тәкәбберләнмәү, ялганламау, малга табынмау, ата-анага хөрмәт, туганлык кадерен белү, гадел хезмәт белән мал табу, шәфкатьле һәм сабыр булу кебек сыйфатлар да кеше күңеленә бик тәфсилләп төшендерелә, еш кабатлана.

Тукай наданлык тарафдарларын, ашау өчен генә яшәүчеләрне ачыктан-ачык тәнкыйть итә. Аның иҗатының башлангыч чорында язылган төрле жанрга караган чәчмә әсәрләрендәге үзәк тема нәкъ шуннан гыйбарәт. Мәсәлән, «Кыямәт көне», «Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?», «Алай-болай», «Уральск имамнарына ачык хат» һ. б. лар – моның ачык мисалы. Иҗтимагый-сәяси череп таркалуны, көндәлек хезмәт кешесенең хокуксыз, кол дәрәҗәсенә төшүен, әхлак кануннарын саклап, кешеләр арасында изге эшкә чакыручы булырга тиешле дин әһелләренең кайберләре, үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртып, акча, байлык йогынтысына бирелеп бетүләрен, шуның нәтиҗәсендә диннең чын йөзен югалтып, халыкны рухи караңгылыкта тоту, гап-гади изү коралына әйләнүен шагыйрь күңеле күтәрә алмый. Шуңа ул аларга каршы көрәшнең сүз белән генә түгел, ә тагы да катырак булырга тиешлегенә ишарәли. Мәсәлән,

*Күңелдә утлары сүнгән, вә вөҗдан майга капланган;*

*«Әгүзе» дип кенә төшмәс, муенга шайтан атланган,*

*Менә шул чаклы ялкау, шундый хайваннар да рухани!*

*Түбәнлек бу, кабул итмә сүзенә изге рух аны*! – дигән юллар вөҗданын югалткан бу кешеләрне инде «Әгүзе» укып, ягъни сүз белән генә иманга китерү мөмкин түгеллегенә ишарәли. Әлеге идеяне бик ачык яктырткан «Шиһаб хәзрәт» (1913) шигыре аерым игътибарга лаек. Тукай олуг гыйлем иясе, акыллы, Шиһаб хәзрәт (Шиһабетдин Мәрҗани 1818-1889) образын «тамак ягын гына белгүче», надан, үзләре төшенмәгән нәрсәләрне, кемнәндер ишетеп, шуны башкаларга өйрәтүче муллаларга каршы куя. Аны татарлар арасында аңлы, белемле кеше барлыгын күрсәтүче, «мәгарифкә әүвәл башлап адым салган, милләт өчен бәһа җитмәс кыйбат кеше» дип атый. Моның сәбәбе нидән соң? Тукай моңа үзе болай дип җавап бирә:

*Ул итсә дә хәдис, аятьне күп нәкыль,*

*Булып бетми аның гакълы нәкыльгә кол;*

*Инсан дигән шәрәфле бер мәхлукта ул*

*Бар дип белә хәким гакыл вә хөр гакыл.*

Күренә ки, Тукай хәзрәтне хәдис вә аятьләргә гади бер иярүче, аларны сукырларча кабатлаучы, шагыйрьнең үз сүзе белән әйткәндә, «нәкыльгә кол» булучы түгел икәнлеген ассызыклый. Кеше итеп яраткан һәр җан иясендә («мәхлук»та) ул фәлсәфи фикер йөртүче «хәким гакыл вә хөр гакыл» күрергә тели. Коръән сүрәләре һәм аятьләренә мөрәҗәгать итеп ул түбәндәге юлларны яза:

*Дәлил итә «Тәзәккәрү!» аятьләрен,*

*Раушан итә шул аятьнең һәр якларын;*

*«Тәфәккәрү!» аятьләрен таяк итә*
*Тик белгүче муллаларга тамакларын.*
*Аңлагачтын Корьәндәге бик күп серләр,*
*Үзеннән үзе агаралар дини керләр;*
*Бу эшләргә Шиһаб хәзрәт сәбәп диеп,*
*Даһи кулын үбә башлый күп мөнкирләр»* [Тукай, 1985: 260].

Аныңча, Шиһаб хәзрәт – даһиларга тиң галим. Ул Коръән аятьләрен заманга ярашлы рәвештә «раушан итә» – төрле яктан яктырта һәм аңлата. Коръәндә «Тәзәккәрү!» («истә тотыгыз!»), «Тәфәккәрү» («уйлагыз!») дигән эндәшләр Аллаһ тарафыннан җирдә яшәүче кавемнәргә мөрәҗәгать иткәндә кулланыла (2 сурә, 40, 47, 122, 203, 219 аятьләр), ягъни Аллаһы Тәгалә кешеләрне кисәтә, монафикъ булмагыз, үткәннәр тәҗрибәсеннән сабак алырга өйрәнегез, ди. Мәсәлән, «Ий, Ягъкуб балалары! Мин сезгә биргән нигъмәтләрне хәтерләгез, һәм нигъмәт бирүдә сезне бөтен дөнья кешеләреннән артык кылдым, шуны фикерләгез» (2 сурә, 47 аять).

Шиһаб хәзрәт тамак артыннан гына йөрүче муллаларга шул сүзләрне «таяк итә». Тукайның хәзрәтне тасвирлаганда нәкъ бу аятьләр аша тасвирлавының тагын бер сәбәбе шунда: Шиһабетдин Мәрҗани Изге Коръән китабын һәм аның тәфсирләрен тәфсилләп өйрәнеп «Назуратүл-хак» («Хаклыкка күзәтү яки хаклыкка бер караш») китабын язган, ул анда Коръәнне тәфсир итү беркайчан да тыелмаган икәнлекне генә искәртеп калмый, ә бәлки, бөтен ислам дөньясына беренчеләрдән булып, Коръән һәр чорда яңача тәфсир ителергә мөмкин дигән фикерне әйтә. Ислам дөньясы галимнәре Ш. Мәрҗанинең бу фәнни хезмәтенә зур бәя бирәләр. Димәк, Ш. Мәрҗани дини тәгълиматны, шул исәптән Коръәндәге кануннарны да кемнәндер ишетеп, яки сукырларча ятлап түгел, ә аңлап кабул итәргә чакыра. Ул иҗтимагый аңның һәм кеше акылының туктаусыз алга хәрәкәтен күреп, һәр буынның Коръәнне үз акылы югарылыгыннан бәяләргә хакы бар дип уйлый. (Дөрес, ул әле хакимияткә дәһри коммунистлар киләсен үк күздә тотмаган!) «Дингә бәйләнешле мәсьәләләрне хәл иткәндә, – ди ул, – изге чыганакларга – Коръәнгә һәм пәйгамбәрләрнең сөннәтенә таянабыз. Инде фәнни мәсьәләләрне хәл иткәндә гакылга таянырга һәм әйберләрнең фактик хәленнән чыгып эш итәргә кирәк. Шәригать гакыл һәм зарурлык белән исбатланган хөкемне кире какмый. Шәригать белән казыя гакъмия вә әхкам зарурия арасында каршылык булганда да зарурәт вә хаҗәт кадәригә дәлил сәмгыйны тәэвил тиеш буладыр» [Абдуллин, 1974: 154]. Димәк, Ш. Мәрҗани тормышта шәригать кануннарын гына искә алу җитми фәнни караш, акыл таныган дәлилләрне дә искә алырга, ягъни аларның берсен кире кагып, икенчеләренә сүзсез генә ышану юлына басарга ярамый, ди. Диннең катып калган догмалар җыелмасы түгеллеген, ә киресенчә, мәдәниятнең иң хәрәкәтчән өлкәсе икәнлеген «Что такое этика, культура, религия?» китабында И.И. Гарин да күрсәтә: «Высшая религия, хотя и немыслима без догматов веры, тем не менее принципиально адогматична» [Гарин, 2002: 2] Шиһаб Мәрҗанинең бу рәвештә фикерләве, кешенең хөр акылын тануы, Коръән канунарына заманча караш тәкъдим итүе, Тукайның динне сафландырып, кешеләр арасындагы яхшы мөнәсәбәтләргә хезмәт итү коралына әверелдерү турындагы хыялларына бик хуш килгән. Чөнки шагыйрь үзе дә Аллага ышана, шул ук вакытта кеше факторын да күздән ычкындырмый. Һәрнәрсәне Алладан өмет итү, дөнья гаменнән ваз кичү, кешенең үзен рухи яктан бәйле, көчсез итеп тоюы, үзен-үзе тыеп, кимсетеп яшәве аңа ошамый. Халкыбызның гафләт йокысында ятуына, тәрәккыяткә омтылмауларына бик тә борчыла.

## ӘДӘБИЯТ

Абдуллин Я. Дини тәгълиматка һәм суфичылыкка каршы // Казан утлары, 1974. – № 2. – 149 – 158 б. Ш. Мәрҗанидән китерелгән өзекләр шушы мәкаләдән алынды.

Гарин Игорь. Что такое этика, культура, религия? М.: ТЕРРА – Книжный клуб, 2002. – С. 827.

Тукай Габдулла. Әсәрләр. Г. Халит редакциясендә. 5 томда. Т.1. Шигырьләр. Поэмалар (1901 –1908) / Габдулла Тукай. Казан: Тат. кит. нәшр., 1985.– 406 б.



**С.Н. АБДУЛЛАЕВ, Н.О. КАДЫРОВА**

Иссык-Кульский государственный университет, Каракол, Киргизия


# МОДЕЛЬ ЭЛЕМЕНТАРНОГО ПРОСТОГО ПРЕДЛОЖЕНИЯ В ТЮРКСКИХ ЯЗЫКАХ: СТАНОВЛЕНИЕ ПОНЯТИЯ


**Аннотация.** Статья посвящена осмыслению динамики становления понятия модели элементарного простого предложения в тюркских языках как эмической единицы. Эволюция понятия модели предложения интерпретируется на базе достижений новосибирской синтаксической школы. Авторы учитывают перекрестные подходы с позиций моно- и полипредикативного синтаксиса. Это обусловлено изоморфизмом способов синтаксической связи на двух уровнях синтаксиса в тюркских языках.

**Abstract.**The article is devoted to understanding the dynamics of the formation of the concept of elementary simple sentence model in the Turkic languages. The concept of a sentence model is interpreted on the basis of the achievements of scientists of the Novosibirsk syntactic school. The authors take into account the positions of mono-and poly-predicative syntax. This is explained by the isomorphism of the ways of syntactic connection at two levels of syntax in the Turkic languages.



**Ключевые слова:** модель, элементарное простое предложение, эмическая единица, универсальный, изоморфизм.

**Keywords:** model, elementary simple sentence, emic unit, universal, isomorphism.


Своеобразием модельного подхода в синтаксисе тюркских языков по направлению углубления теоретического обобщения можно считать взгляд на предложение без строгого разграничения на традиционные простое и сложное [Abdullayev, 2018]. При таком билатеральном подходе, отвечающем типологическим особенностям тюрко-монгольских языков, уместно допускать, что моделеобразующие синтаксические позиции могут и должны заполняться не только словоформами, но и словесными группами, идиоматическими образованиями, предикативными единицами. Последние могут быть 1) предикативными единицами, субъектно-подлежащня валентность которых ориентирована на субъект главной части и 2) предикативными единицами, члены предикативного узла которых не совпадают с главными членами главной части. Синтаксические позиции в принципе могут заполняться и отдельными предложениями, соединяющимися в связном тексте с другими его конституентами при помощи анафорических местоименно-соотносительных средств синтаксической связи. Другими словами, отталкиваясь от понятия модели элементарного простого предложения, можно смоделировать ряд других синтаксических образований, включая и единицы надфразового уровня. Подобный подход позволит, на наш взгляд. исследователю системно осмыслить сочетаемостные свойства указанных синтаксических объектов на фоне отчетливых границ синтаксического участка языковой системы. Кроме того, это

помогает в интерпретации типологических особенностей языков тюрко-монгольской общности. Результатом этого, как нам представляется, явится выделение глубинно-инвариантных, универсальных моделей элементарных простых предложений (ЭПП), постижение заложенных в них значительных синтагматических потенций.

Моделирование ЭПП с необходимостью детерминирует тесную связь в рамках модели двух его сторон: означающего – структурной схемы и означаемого – пропозиции. Таким образом, моделирование предложений на монопредикативном уровне имеет две ипостаси, ориентированные на план выражения и план содержания моделей. План выражения подразумевает работу исследователя со структурными схемами, включающими минимум облигаторных синтаксических позиций. План содержания имеет в виду пропозиции как мыслительные модели.

Итак, «движение по вертикали» в понимании существа структурно-семантических моделей простого предложения тюрко-монгольских языков применительно, например, к уйгурскому материалу прошло несколько этапов (см. рис. 1), что свидетельствует о том, насколько сложно и трудно постичь грамматическую природу элементарного простого предложения как основной единицы языкового строя, охватить его целиком и учесть все его потенции, исходя из задач адекватного описания синтаксических систем тюрко-монгольских языков. В большинстве современных синтаксических работ, обращающихся к моделям простого предложения, к последним выходят, как правило, оставаясь на уровне, или подуровне, простого предложения, анализируя высказывания «методом отчеркивания» либо при помощи теста на элиминирование. В данном случае для нас важно подчеркнуть, что при этом исследователь мыслит и оперирует понятиями и терминами синтаксиса простого предложения, иначе говоря, замыкается в этой частной области. Однако типологические особенности тюрко-монгольских языков, в частности, например, уйгурского языка, позволяют наряду с этим при описании простого предложения реализовать более широкий взгляд на синтаксические объекты исследования.

Этапы развития понятия модели простого предложения

обобщенный образец

структурная схема

структурно-семантическая модель

универсальная модель ЭПП

Этапы становления понятия модели простого предложения

Выявление моделей простого предложения путем анализа предложений-высказываний, традиционно относящихся к простым, т.е. имеющих один предикативный узел (одну пропозицию) можно назвать взглядом «изнутри», опирающимся на подход «снизу», который исторически идет от исследования словосочетаний, особенно глагольных. Но модели простого предложения могут «проявляться» и при взгляде «сверху», когда исследователь движется от полипредикативных построений, от связного текста путем соотнесения моделеобразующих позиций с зависимыми предикативными единицами и предложениями-конституентами текста (тармақ жүмлиләр). Последний подход характерен для многочисленных работ представителей новосибирской синтаксической школы [Черемисина, 1989], [Черемисина, Скрибник, 1996], [Тыбыкова, 1991].

Таким образом, на практике можно реализовать возможность интерпретации простого предложения с различных позиций. Пересечение, сталкивание этих взглядов,

«высекая искры», вновь и вновь высвечивает грани и контуры системы моделей ЭПП, аккумулирующих в себе значительные синтаксические возможности. Это, по нашему убеждению, повышает надежность и адекватность выявления и описания моделей простого предложения, а также дает возможность верифицировать их в качестве сущностных единиц, обнаруживаемых в точках пересечения различных подходов.

Релевантность модельного синтаксиса для тюрко-монгольского языкознания проявляется в том, что здесь с необходимостью четко проводится различие между моделью предложения как единицей языка и предложением-фразой как единицей речи. Это ставит изучение синтаксического участка системы языка на твердую научную почву и дает возможность работать с конечным закрытым перечнем синтаксических объектов.

Становление понятия модели элементарного простого предложения, как уже отмечалось, в тюркологии прошло несколько этапов. Спецификой синтаксических исследований моделей предложений тюрко-монгольских языков является движение к понятию модели ЭПП «снизу» и «сверху». Такая билатеральная исследовательская практика позволила выйти на центральную единицу синтаксического уровня языка. Она обусловлена изоморфизмом способов синтаксической связи на моно- и полипредикативном уровнях синтаксической системы тюркских языков [Убрятова, 1976].

Таким образом, основной единицей вмодельном синтаксисе является модель элементарного простого предложения. Осознанию данного теоретического конструкта предшествовали ряд этапов лингвистического обобщения. Такое понимание моделей простого предложения получило распространение в разных международных лингвистических традициях, в том числе и среди современных турецких языковедов.

## ЛИТЕРАТУРА

Тыбыкова А.Т. Структурно-семантическая характеристика простого предложения в алтайском языке. Новосибирск, 1991. – 31 с.

Убрятова Е.И. Исследования по синтаксису якутского языка. Ч. 2. Кн. 1, 2. Новосибирск, 1976. – 305 с.

Черемисина М.И. О теоретических вопросах модельного описания предложений // Предложение в языках Сибири. Новосибирск, 1989. – С. 3-18.

Черемисина М.И., Скрибник Е.К. О системе моделей элементарных простых предложений в языках Сибири // Гуманитарные науки в Сибири, 1996. № 4. – С. 43-49.

Abdullayev S. Models of Simple Sentencesin Uyghurand English Languages. Karakol, 2018.

**Д.М. АБДУЛЛИНА, А.Я. ХӨСӘЕНОВА**
Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясе
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Казан

# ПОЛИЛИНГВАЛЬ ДАИРӘДӘ ТУГАН ТЕЛ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ДИАЛЕКТАЛЬ СОМАТИЗМНАРНЫ ӨЙРӘНҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

**Д.М. АБДУЛЛИНА, А. Я.ХУСАИНОВА**
Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова
Академии наук Республики Татарстан, Казань

# ОСОБЕННОСТИ ИЗУЧЕНИЯ ДИАЛЕКТНЫХ СОМАТИЗМОВ НА УРОКАХ РОДНОГО ЯЗЫКА И ЛИТЕРАТУРЫ В ПОЛИЛИНГВАЛЬНОЙ СРЕДЕ

**Аннотация.** В данной статье рассматривается специфика изучения диалектизмов, как части лексики родного языка  в условиях полилингвального образования. Предлагаются виды работ, используемые при изучении диалектных соматизмов на уроках родного языка и литературы.

**Abstract.** This article discusses the specifics of studying dialectisms as part of the vocabulary of the native language in the conditions of multilingual education. The types of works used in the study of dialect somaticisms in the lessons of the native language and literature are offered.

**Ключевые слова:**диалектизмы, соматизмы, диалектная лексика, полилингвальное образование, родной язык, родная литература.

**Keywords:** dialecticisms, somatism, dialect vocabulary, polylingual education, native language, native literature.

Педагогика фәнендә, белем һәм тәрбия бирү процессы бердәм процесс буларак карала. Шәхес тәрбияләү һәм аны даими үстерүне максат иткән дәрес белем бирү белән бергә, һәрвакыт, тәрбия бирүне дә күздә тота. Ә тәрбия милли, мәдәни, рухи мирасны, җирле үзенчәлекләрне исәпкә алып эшләгәндә генә нәтиҗәле була.

Мәктәпләребез билингваль белем бирүдән полилингваль белем бирү системасына күчеп бара. Әмма тел-әдәбият фәне укытучылары өчен бу мөмкинлекләрне тагын да киңәйтә. Бала мәктәптә туган телен, рус телен һәм бер яки берничә чит телне өйрәнә. Әйтик, бүген Башкортстан мәктәпләрендә татар телле укучыларның дәүләт теле буларак башкорт телен, туган телләре буларак татар телен, рус телен һәм чит телләрне өйрәнү мөмкинлеге бар. Бу очракта без тулы хокукта полилингваль белем бирү турында сүз йөртә алабыз.

Туган тел дәресләрендә телнең лексик составын өйрәнү, диалекталь сүзләргә игътибар итеп аларның үзенчәлекләрен ачу, мәктәптә өйрәнелә торган телләр белән чагыштыру бик мөһим санала. Мәсәлән, татар әдәби телендә, диалектларда рус, гарәп, төрек, фарсы алынмаларының кулланылышын караган вакытта алынма сүзләрнең әдәби телдә һәм диалектлардагы  ешлыгы, алардагы фонетик үзгәрешләрне тикшерү укучыны җанлы сөйләм теленә якынайта, кызыксыну уята. Татар әдәби телен диалект белән һәм башка телләр белән чагыштыру укучыларның сүз байлыгын үстерергә ярдәм итә, төрле сүзлекләр белән эш итәргә өйрәтә һәм, гомумән, үз туган теленә, җирле сөйләшкә, туган

төбәк тарихына карата мәхәббәт, кызыксындыру уятуда да зур роль уйный, башка телләрнең үзенчәлеге тирәнтенрәк аңларга да ярдәм итә.

Хәзерге чорда диалекталь лексика сөйләм теленнән югалып бара. Бу халыкның шәһәрләшүе, әдәби телнең йогынтысы зур булу (авылларда да интернет, радио, телевидениенең йогынтысы), икетеллелек шартларында рус теленең киң кулланылышы, тормыштагы аерым күренешләр, предметларның куланылыштан төшеп калуы белән аңлатыла.

Диалекталь сүзләрне өйрәнү укучыга үзенең сөйләмен бәяләргә дә булыша. Ул язма һәм сөйләм телендә әдәби тел һәм диалекталь сүзләрне аерырга өйрәнә, әдәби тел нормаларын үзләштерергә ярдәм итә. Әдәби текста аларны танырга һәм сәнгати яктан вазифаларын аңларга да ярдәм итә.

Дәресләрдә диалекталь сүзләрне өйрәнү ике төрле очракта булырга мөмкин: программа буенча билгеләнгән махсус дәресләрдә һәм башка дәресләрдә ярашлы материалларны үзләштергәндә.

Сүз байлыгын арттыру, әдәби тел нормаларын һәм диалекталь үзенчәлекләрне тел, әдәбият дәресләрендә бәйләнешле рәвештә алып барылганда югары нәтиҗәләр бирә. Тел һәм әдәбият дәресләрендә сүзлек эше барышында укучылар татар теленең лексикасын практик үзләштерәләр. Сүзнең лексик мәгънәсен сөйләм, текст эчендә аңлатуга, аны сөйләмдә кулланырга өйрәтүгә аеруча игътибар бирергә кирәк. Мәсәлән, сүзнең асылына төшенү өчен укучыларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, алар өчен бик таныш булган соматизмнар белән генә дә күп төрле эш төрләрен кулланырга мөмкин.

«Тән» атамасы (грек. soma, somatos- җисем) биологиядә һәм медицинада «кеше җисеме белән бәйле» дигән мәгънәдә кулланыла һәм «психика» төшенчәсенә каршы куела. Тел белемедә ул ХХ йөзнең икенче яртысыннан актив өйрәнелә башлый. Киң кулланылыш аркасында соматик сүзләр телнең төп лексик фондына карый һәм алар арасында бик борынгы чорларда барлыкка килгәннәре дә, соңрак чыганаклы сүзләр бар[Федорова, 2012: 81]. Соматизмнарны һәм алар белән бәйләнгән терминологияне тикшерү турыдан-туры халыкның тормышы, аның матди-көнкүреш мәдәнияте белән бәйләнгән.

Туган тел дәресләрендә лексик берәмлекләр буларак соматизмнар белән таныштыру вакытында татарча-русча сүзлекләреннән тән әгъзалары атамаларына 5 мисал табып язырга, аларны кертеп, җөмләләр төзергә кушып була. Шулай ук укучыларга *каш, күз алмасы, терсәк, иңбаш, тел, сипкел, чәч, танау, бот, тырнак* кебек соматик атамаларын русчага тәрҗемә итү, шулар белән җөмләләр төзү белән бәйле бирем тәкъдим итеп соматизмнарга игътибарны юнәлтәбез, аларның татар әдәби телендәге әйтелешен һәм язылышын билгеләтәбез.

Билгеле, кайбер җирле сөйләшләрдә соматизмнарның үз вариантлары яшәп килә. Бала аларны гаиләдә теле ачылган чорында нәкъ шул әйтелештә үзләштерә башлый, алга таба бу атамалар аның телендә ныгытып хәтердә калдырыла. Башлангыч сыйныфларда тел байлыгын арттыруга юнәлтелгән эш алдагы сыйныфларда лексика бүлеген өйрәнгәндә ныгытыла.

Халык авыз иҗаты әсәрләре дә, әдәби әсәрләр дә укучының телен баетуга зур өлеш кертә. Аларда әдәби тел генә түгел диалекталь сүзләр дә еш очрый. Алар укучыны халык тарихына, гореф-гадәтләренә якынайта. Башка халыклар белән уртак һәм аермалы якларны күрергә ярдәм итә, белем дәрәҗәсен киңәйтә. Мәсәлән, соматик атамаларын халык авыз иҗаты әсәрләрендә еш очратырга мөмкин. Н. Исәнбәтнең 3 томлык “Мәкаль һәм әйтемнәр сүзлеге”ндә соматизмнар булган әйтемнәр аерым күрсәтелә [Исәнбәт, 2010]. Ниһаять, Х. Ш. Мәхмүтов төзегән “Татар халык иҗаты:

Мәкальләр һәм әйтемнәр" дә соматик идиомаларга аерым урын бирелгән [Мәхмүтов,1987].

"Татар халык мәкальләре" китабыннан соматик атамалары кергән мәкальләр сайлап алуны күздә тоткан бирем дә тел һәм әдәбият дәресләренең бәйләнешен билгеләү белән бергә укучыларның бу өлкәдәге белемнәрен киңәйтә.

Өлкәнрәк сыйныфларта туган тел дәресләрендә "Сезнең сөйләштә әдәби телдә кулланылмый торган сүзләр бармы? Шуларны дәфтәрегезгә языгыз", "Татар диалектларында *күз* сүзенең нинди вариантлары очрый? Татар теленең диалектологик сүзлегеннән табып языгыз" дигән биремнәр дә файдалы була ала.

Укучыларның тема белән кызыксынуын, мәсәлән, түбәндәге бирем арттырачак: *баур, бәбәк, кул, илткә, йерәк, күссуwы, мий, колчак, мим, чобарка* кебек сүзләрнең мәгънәләрен аңлатмалы һәм дилектологик сүзлекләрдән табып языгыз. "Сүзләрнең кайсылары сөйләшләрдә кулланыла?". Шулай ук "Соматик атамаларын русчага тәрҗемә итегез. Җөмләләр төзегез", "Соматик атамаларының мәгънәләрен татар телнең аңлатмалы сүзлегеннән табып языгыз: *баш, арка, кул, теш, ирен, бармак, маңгай, ияк, йөрәк, аяк, каш, күз алмасы, терсәк, иңбаш, тел, сипкел, чәч, танау, бот, тырнак*", "Татар теленең диалектологик сүзлегеннән түбәндәге *баш, күз, тубык, иңбаш, колак, чәч* дигән сүзләрнең вариантларын табып языгыз" кебек биремнәр бу эштә ярдәмгә килә ала.

Шулай итеп, диалекталь соматизмнарны өйрәнүнең әһәмияте зур. Бу халкыбызның мәдәни тарихын баетуга, телебезне алга таба үстерүдә йогынтысыннан тыш, полилингваль белем бирү шартларында, телләрне үзләштерүдә киң мөмкинлекләр ача.

## ӘДӘБИЯТ


Рамазанова Д. Б. Татар телендә кешегә бәйләнешле лексика / Д.Б. Рамазанова. Казан, 2013. – 364 б.

Татар теленең зур диалектологик сүзлеге / төз.: Ф.С. Баязитова, Д. Б. Рамазанова, З.Р. Садыйкова, Т.Х. Хәйретдинова. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 839 б.

Федорова М. А., Никонюк М. С. Фразеологические соматизмы как средство вторичной номинации лексикосемантической системы немецкого языка // Журнал Гродненского государственного медицинского университета, 2012. № 3 (39). – С. 81-84.

Исәнбәт Н.. Татар халык мәкальләре: мәкальләр җыелмасы: 3 томда / Нәкый Исәнбәт. – 2-нче басма. Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – 1 том: "Мәкальләребез турында" дигән фәнни хезмәт һәм аңлатмалар белән. – 2010. – 623 б.

Мәхмүтов Х. Ш. Татар халык иҗаты: Мәкальләр һәм әйтемнәр / Х. Ш. Мәхмүтов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. - 592 б.



**Ч.З. АБДУЛЛИНА, Ф.К. СӘГЪДИЕВА**
Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясе
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Казан


## ТАТАР ТЕЛЕ ИНТЕРНЕТ ЧЕЛТӘРЕНДӘ


**Ч.З. АБДУЛЛИНА, Ф.К. САГДЕЕВА**
Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова
Академии наук Республики Татарстан, Казань

# ИСПОЛЬЗОВАНИЕ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА В ИНТЕРНЕТ-ПРОСТРАНСТВЕ

**Аннотация.** В статье рассматривается место татарского языка в сети интернет. Определяется роль интернета в повышении функциональных возможностей языка. Оцениваются роль сайтов на татарском языке в объединении татарского народа. Предоставляется информация о сайтах, которые открывает возможность для изучения истории и языка татарского народа.

**Abstract.** The article considers the place of the Tatar language in the Internet. The role of the Internet in improving the functionality of the language is determined. The role of sites in the Tatar language in uniting the Tatar people is evaluated. Information is provided about sites that provide an opportunity to study the history and language of the Tatar people.

**Ключевые слова:** Татарский язык, интернет, электронные учебники, электронные ресурсы на татарском языке.

**Keywords:** Tatar language, Internet, electronic textbooks, electronic resources in the Tatar language.

Глобальләшү, техник казанышлар нәтиҗәсе буларак туган җәмгыять үсешнең яңа баскычын интернет челтәрннән башка күз алдына да китерә алмыйбыз. Димәк, хаклы рәвештә телнең кулланылышының бер тармагын интернет челтәре тәшкил итә дип әйтеп була. Туган телебезнең хәзерге көндә интернет челтәрендә нинди урын биләп торуын, нинди функция башкаруын ачыклап үтү дә урынлы булыр.

Бөтендөнья интернет челтәрендә татар телле интернет ресурслар, чыганаклар, сайтлар да зур урын алып тора.

Заман таләбен, урта һәм яшь буынның тормышында интернетның роле искиткеч зур булуын, аларның күпчелек мәгълүматны әлеге чыганаклардан эзләвен һәм Татарстаннан читтә яшәүче татарлар өчен дә моның зур әһәмияткә ия булуын испкә алганда, интернетның татар телендә хезмәт күрсәтүе телне саклау, үстерүгә ныклы терәк булуы шиксез. Интернет яссылыгы кешеләрнең иҗтимагый аралашуының аерым төре. Ул аралашуда катнашучылар сан ягыннан чикләнми, әдәбият, кино, театр һәм башка сәнгать әсәрләре кебек бер яки берничә кешенең субъектив карашлары гына хөкимлек итми, интернет тулы дөньяны колачлый ала. Анда катнашучылар кулланучы да, фикер-карашларын тәкъдим итүче дә. Шуңа күрә үз милли интернет мәйданы булмаган халык, бу гаять зур, чиксезлеккә омтылган мәгълүмати дөньяда бөтенләй йотылырга да мөмкин. Татарстан Россия субъектлары арасында Интернеттан кулланучылар саны ягыннан беренче егермелеккә керә 19% кеше файдалана [Атлас “Россия сетевая”, 2006: 102]. Димәк, әгәр Татар интернеты юк дип уйласак бөтен булган бу аралашу безнең туган телебезне читләтеп уза дип нәтиҗә ясарга кала һәм киләчәктә ул тагын яшь буынның күпмесен үзенә җәлеп итәчәген күз алдына китерүе дә бик авыр түгел.

Гомумән, заман тизлеге таләп иткән чара буларак барлыкка килгән Интернет челтәренең аерым халыклар һәм милләт язмышын хәл итүдә роле әһәмиятле булуын безнең тарафтан гына түгел, дөньякүләм таныла һәм бәяләнелә. 2008 елны, әле президентлык вазифаларын башкарган вакытта, Дәүләт советына мөрәҗәгатендә М.Ш. Шәймиев тә шул фикернк бик ачык итеп җиткергән иде. Ул: “Татарстанның глобаль Интернет челтәрендәге урынын, бикрәктә татар сегментының, максатчан киңәйтә брау кирәк. Ул татар диаспораларын тарихи ватан белән бәйли торган иң нәтиҗәле юл” (https://www.tatar-inform.ru/news/official/12-11-2008/mintimer-shaymiev-obratilsya-k-gossovetu-rt-s-poslaniem-5035480 ), – дип мөрәҗәгать итте.

Бу уңайдан, бөтендөнья Интернет челтәрендә татар халкына, аның мәдәниятенә, тарихына һәм теленә мөнәсәбәтле сайтларны ике төркемгә бүлеп карарга була. Аларның беренчесе, төрле телләрдә (татар, рус, инглиз, немец һ. б.) татарларның тарихы, мәдәнияте, халыкның күренекле вәкилләре, хәзерге һәм үткәндәге гореф-гадәтләре, тормыш-көнкүреше һәм башка якларын ачып бирүче – татар дөньясы белән таныштыручы чыганаклар. Алар татар халкының үзенә дә һәм аның белән кызыксынучы башка халыкларга да бу өлкәдә зур мөмкинлекләр ача.

Икенче төркем чыганаклар татар телле, кириллица һәм латин графикасында язмалар урнаштырыла. Алар татар телен белүчеләргә хезмәт күрсәтә һәм татар теленең кулланылыш даирәсен киңәйтә функциональ һәм структур үсешен дә тәэмин итә.

2000 еллардан башлап (1994 елларда беренче татар сайтлары барлыкка килә) телебезнең яңа функциональ мөмкинлегенә юл ачкан бу юнәлеш хәзерге көндә киң колачлы бер өлкә булып тора. Бу юнәлештә үкүп эш алып барылды. Электрон мәгълүмәт чараларында Татарстан Республикасының рәсми серверы (26.02.2003 ел, УП-165 номерлы Татарстан Республикасы президенты указы белән аңа шундый статус бирелгән) моңа ачык мисал. Ул республиканың визит карточкасы булып тора. Биредә татар телендә республиканың дәүләт органнары, административ-территориаль бүленеше, халкы, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары законнары һәм норматив актлары, яңалыклар, телекомпания тапшыруларының видеоматериаллары, республиканың төрле өлкәләргә караган сайтлар катологы һәм башка мәгълүматлар урнашкан.

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы сайтында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының төп норматив хокукый актларының татар телендәге электрон китапханә проекты урнаштырылган.

Барлык министрлык һәм ведомстваларны берләштергән, гражданнарны интернет кабул итүне үз эченә алган Татарстан Республикасының төп порталы Республиканың дәүләт хакимияте органнарының төп сайты булып тора.

Болардан тыш бик күп мәгълүмати яктан бай һәм кызыклы сайтлар бар һәм аларның яңалары да туып тора.

Гомумән, татар теленә өйрәтү һәм татарча белем бирү юлында, Интернет куллану елдан ел киңрәк тарала. Татар телен өйрәнергә теләүчеләргә МТСС (http://www.mtss.ru//page=language ) сайтында татар теленә өйрәнүнең интенсив курсы, телнең морфологик үзенчәлекләре, русча-татарча һәм татарча-русча сүзлекләр, татар телендә эшләүне тәэмин итүче программалар урнаштырылган. Шулай ук «Татарча текстлар» (http://tatarcatext.narod.ru/) сайтында татарча-русча электрон тәрҗемәче – «ТатаРус», «Сәләт» (http://www.selet.biz/) һәм «ТатСофт СЛТ» (http://tatsoft.biz/), http://www.azatliq.ru/dict, http://tugan-tel.com/, «Сузлек» – http://www.suzlek.ru/ сайтлары татар телен өйрәнү мөмкинлеге тудыра, татар телен куллану мөмкинлекләрен киңәйтә.

Татар телендә белем бирүче укытучыларның Бөтендөнья форумы (http://forum.belem.ru), Татар телендә белем бирү интернет үзәге (http://belem.ru), Бөтендөнья Интернет челтәренә урнаштырылган татар теленә өйрәтүче «Ана теле» онлайн проекты. «Ана теле» проекты милли мәдәниятнең асылы булган татар телен тулы канлы аралашу чарасы, татарларны бергә туплау һәм телне өйрәнүне киң җәелдерү максатыннан тормышка ашырыла.

Татар теленең электрон мәгълумати кырга тирәнтенрәк үтеп керүен тәэмин итә торган системалы чаралар күрелгән. Компьютер өчен Microsoft һәм Apple

программалары, смартфоннар өчен Android һәм iOS программалары татарча хезмәт күрсәтә. Яндекс онлайн сүзлеге татар теледә эшли.

«Татар иле» интернет порталында татар теле һәм әдәбиятыннан, татар халкы тарихыннан интерактив дәреслекләр ачык кулланылышка куелган. Федераль белем бирү стандартлары нигезендә тикшерелеп Туган тел (татар теле) һәм әдәбияты дәреслеге буларак Федераль исемлеккә кертелгән дәреслекләрне табарга һәм кулланырга була.

Хәзерге вакытта татар телендә хезмәт күрсәтә торган зур порталларның берничәсенә тукталып үтик. Бу – Татарстан Республикасы массачыл мәгълүмат порталы (http://www.tatmedia.ru/tat/). Биредә бу көндә Татарстан Республикасында чыга торган матбугат исемлеге, теле – һәм радиостанцияләр белән танышырга була. Аларда газета журналларда басылган мәгълүмат белән танышырга, тапшыруларның эчтәлеген карау мөмкин.

Республика матбугат органнарының үзләренең сайтлары да татар телендә укучыга хезмәт күрсәтә. Мәсәлән, «Ватаным Татарстан» (http://www.vatantat.ru), «Татарстан яшьләре» (http://www. tatyash.ru), «Шәһри Казан» (http://shahrikazan. com/) «Азатлык» (http://www.azatlyk.com/), «Шәһри Чаллы» (http:// shahrichalli.narod.ru/), «Безнең юл» (http://beznen-yul.narod.ru/), «Кәеф ничек?» (http://www.kaefnichek.ru/), «Безнең гәҗит» (http:// beznen.ru/), «Сабантуй» (http://sabantuy.net/) һәм «Ялкын» (http://yalqin.ru/) «Казан утлары» (http://kazanutlary.ru/), «Идел» журналларының сайтларында андагы басмалар белән танышырга, архивларына кереп, алдагы елларда басылган язмаларны тулысынча укырга була.

Шулай ук Татарстаннан читтә дә татар телендә чыга торган вакытлы матбугат үзен интернет аша тәкъдим итә: Башкортстанда «Кызыл таң» (латин шрифтында һәм кириллицада) (http:// kiziltan.ru/) «Өмет» (http://www.omet-ufa.ru/), Әстерханда «Идел» (http://www. xacitarxan.narod.ru/gaset.htm). Төмәндә «Себер иле» (http://seberile.ru/tt/), Түбән Новгородта «Мишәр дөньясы» (http://www.nizgar.ru/) газеталары, Германиядә «АлТаБаш» журналы (http://www.altabash.tk/) татар телендә латин шрифтында басыла һәм рус һәм алман телләренә тәрҗемә ителә.

Массачыл матбугат чаралары сайтлары арасында «Матбугат» (http://matbugat.ru/) проекты аерым урын алып тора.

Берничә ел дәвамында Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясе Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан интернет челтәрендә татар теленең кулланылышын зур платформага куйган проектлар тормышка ашырыла. Шуларның беренчесе – Татзет. Монда сүзлекләр урнаштырылган.

Икенче зур проект – XX гасыр башында гарәп графикасында басылган китаплар, газета һәм журналларны интернет челтәренә урнаштыру һәм аның белән танышу мөмкинлеге тудыру. Бу әлеге чыганаклар белән дөньяның теләсә кайсы почмагында танышу һәм файдалану мөмкинлеге тудыра. Бу татар халкының тарихы мәдәнияте, тел үзенчәлекләре белән танышу һәм өйрәнүгә киң мөмкинлекләр ача. Әмма алар белән эшләү өчен гарәп графикасын белү таләп ителә. Бу чыганаклар белән эшләүчеләр, аны куллана алучылар санын бик күпкә чикли. Әлеге каршылыкны исәпкә алып, гарәп шрифтындагы бу чыганакларны траслитерацияләү мәсьәләсе хәл ителә. Бу очракта компьютер өчен махсус программа эшләнә, бүгенге көндә ул инде эшләнгән һәм үз вазифасын башкара. Билгеләнгән текст мөмкин кадәр ачык итеп компьютер тарафыннан танытыла (сканерга алына), икенче баскычта ул аны кирилл хәрефләренә күчерә. Әмма янәшәдә гарәп шрифтындагы сүзләрне дә саклый – чагыштырып уку

мөмкинлеген бирә. Әлеге төзәтү-тикшерү өлешеннән соң әзер текст барлыкка килә. Хәтта гарәп графикасында укып, эш йөртә, компьютер калдырган хаталарны үз төзәтә алмаган кеше дә бу очракта текст белән таныша ала. Төгәллек әлегә 70-80 % тәшкил итә дип белдерә галимнәребез. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының язма һәм музыкаль мирас үзәге тарафыннан тормышка ашырыла торган тагын зур проектларның берсе Татар каберташ язмаларын өйрәнү һәм аны гомум кулланылышка кую юнәлешендә. Бу Татарстан буенча гына түгел, татар телле язмаларның кайда урнашканлыгына бәйсез рәвештә һәммәсен туплап зур каталог булдыру. Аның белән онлайн рәвештә эшләү мөмкинлеге тудыру. Тупланган материал түбәндәгечә эшкәртелә: ташъязманың төрле ракурста алынган сурәте урнаштырыла. Аны зурайту, телэгэн урынны якынайтып карау мөмкинлекләре булдырыла. Ташъязманың тулы тасвирламасы (озынлык, биеклек, киңлек латин графикасына күчермәсе) бирелә. Спутник күрсәтүенчә географик урынын карау мөмкинлеге бар. Ул 1-1,5 м чамасы төгәллек белән күрсәтә.

Интернет челтәрендә татар теле үзенең барлык стильләрен саклап яши. Фән теле һәм гади аралашу теле буларакта иркен кулланыла кулланыла. Бу телебез үсешендә мөһим урын алып тора.

## ӘДӘБИЯТ


Атлас «Россия сетевая». М.: Изд-во Европа, 2006. – 189 с.



**С.Ш. АЙТУҒАНОВА**

Л.Н.Гумилев атындағы Еуразия ұлттық университеті, Нұр-Сұлтан


## Р.НҰРҒАЛИ ПРОЗАСЫНЫҢ ЕРЕКШЕЛІГІ


**С.Ш. АЙТУГАНОВА**

Евразийский национальный унився ситет им.Л.Н. Гумилева, Нур-Султан


## ОСОБЕННОСТИ ПРОЗЫ Р. НУРГАЛИ


**Аннотация.** В статье рассматривается об особенности прозы известного литературоведа Рымгали Нургали. Рассмотрены тематические и содержательные аспекты рассказов писателя, проанализировано его умение передавать реальность жизни. В этом аспекте анализируется произведении и делаюся выводы.

**Abstract.** The article describes the features of the prose of famous literary critic Rymgali Nurgali. The thematic and substantive aspects of the writer’s stories are considered, his ability to convey the reality of life is analyzed. In this case, the work is analyzed and conclusions are drawn.



**Ключевые слова:** Новелла, реалности жизни, художественные особенности, мастерство писателя, трагедия полигона.

**Keywords:** Short story, reality of life, artistic features, writing skill, landfill tragedy.


Зерттеуші, әдебиетші, ғалым ретінде танылған Р. Нұрғалидың жазушылық қыры өз алдына бір төбе деуге болады. Оның қаламынан туған көркем шығармалары өзіндік ерекшелігімен, стилімен дараланады.

Қаламгердің елу новелладан тұратын мазмұны қызықты, бітімі ерекше “Дән” проза кітабын қалың оқырман, әдеби сын ыстық ықыласпен қабылдағаны белгілі. Семей атом полигонының адамдар тағдырына әкелген қасіреттері “Аяқталмаған трагедия” деп

аталатын әңгімелер шоғырында көркем бейнеленді. Қазақ театрының тұңғыш режиссері Жұмат Шанин өміріне арналған “Ай қанатты арғымақ” романы тіл байлығымен, психологиялық талдау шеберлігімен ерекшеленеді. Осы шығармалардың қай қайсысы да Р. Нұрғалидың жазушылық қырын танытатын туындылар.

Қай шығармасын алып қарасақ та, өмірдегі шынайы көкейкесті оқиғалардың арқау болғанын байқаймыз. «Дәнде» тың игеру тақырыбы көтеріледі. Мұндағы әр новелла әртүрлі адамдардың тағдыры туралы баяндап, оқырманды қызықтыра түседі. Адамның бойындағы жағымды, адамгершілік қасиеттерді көрсетуде үлкен шеберлікке жеткен.

Мұнда көзге түсетін бір нәрсе - новеллалардың өн бойында халықтар достығы тақырыбының сыршылдықпен суреттелуі. Шындығында, тыңда еліміздің түпкір-түпкірінен келген әр алуан ұлт өкілдері бір жағадан бас, бір жеңнен қол шығара, толарсақтан саз кешіп жүріп еңбек еткені анық. Ендеше тың туралы айта отырып, осынау жаңа жағдайда, жаңаша қарым-қатынаста қалыптасқан достықты сөз етпеу мүмкін емес. Әсіресе Мәлгаждар мен Константин, Нұрбаев пен Макаров, Довжик пен Байбөрі, Кирсей мен Уәли араларындағы достық ерекше шабытпен суреттелген. Бұлардың достығы - уақытша сипаттағы қарым-қатынас емес, қар жастанып, мұз төсенген қиын-қыстау шақта қалыптасқан, шын мәнісіндегі берік достық. Оған біз осынау кейіпкерлердің іс-әрекетінен көз жеткіземіз. Ұшы-қиыры көрінбейтін қарлы далада қалып қойып, бастарына қатер төнген Тапаловтарды тракторшы Мәлгаждар келіп құтқарады. Байбөрі дүниеден қайтқанда қабырғасы қайысқан Довжиктің бригадасы Целиноградтан мәрмәр ескерткіш алдырып, қимас досқа белгі ретінде бейіт басына қояды. “Молдаван Дмитрий Кирсей боранға кеудесін тосып тұр: жүзінде шаттық, көзінде сенім. Қасында қазақ Уәли Оразаев”, - деп аяқтайды автор бір новелласын. Қазақ досы барда Кирсей өзін алынбайтын қамалдай сезінетін секілді.

Шығарманың сыршылдығын анықтауға  көп жағдайда сезім негіз болады: Отанға деген сүйіспеншілік сезімі, оның алдындағы азаматтық борышты өтеу, туған жерге деген сағыныш сезімі, халықтар арасындағы достық сезімі. Міне, осындай мәселелерді автор өз орнымен шынайы суреттеп жеткізуі шығармаға лирикалық сипат береді. «Дән» новелласы туралы Ә.Нұршайықов: «Лирикалық әуенде, ықшам жазылған бұл кітаптың негізгі ерекшелігі не және оның көркемдік-мазмұндық шешімі тереңдігінің басты сипаты қайсы деген сұраққа–автордың жеке-жеке новеллалардың жүйесін ерекше құрып, формалық құбылту арқылы шығарманың өзіне тән кілтін табуы деп жауап беруге болады» деп жазады [Нұршайықов, 1978: 96].

Тағы бір ерекшелік ретінде новелланың әртүрлі әдіспен жазылуын айтуға болады. Олардың әрқайсысы өзінің көркемдігімен, оқиғасының тартымдылығымен дараланады. Автор өмірмен өзектес шығармадағы деректі кейіпкерлерін тек қана баяндау мен жалаң сурет арқылы ғана суреттеп, цифрды тілге тиек етуді мақсат етпеген.

Қаламгердің өзі басынан өткізіп куә болған өмір шындығын көркем шындыққа айналдыра отырып оқырман жүрегінен орын алған осындай шығарманың қатарынан «Аяқталмаған трагедия» атты әңгімелер циклін көреміз. Мұнда өзі туып-өскен ауылдағы полигон қасіреті туралы толғанады. Ауыл өмірін, ондағы адамдарының мінезі мен болмысын шынайы суреттеген әңгімелерде өз кейіпкерлері арқылы күллі халық басындағы қайғы-қасіретті жеткізеді. Мұнда жеке адамның көңіл-күйі мен сезімі қоғамға тән рухани құндылықтардан ажырамайды.

Р. Нұрғалидың қай әңгімесін алсақ та, ауыл өмірі, ауыл адамдары туралы сөз болады. «Сағыныш» әңгімесінің аты айтып тұрғандай, мұнда автор кейіпкерлері

арқылы өзінің туған жеріне деген сағынышын жеткізеді. Мұндай туындыларда жоғарыда айтып кеткеніміздей, көп жағдайда жазушының ішкі сезім толғаныстары туған жер, өскен орта тіршілігін суреттеумен беріледі. Бұл ыңғаймен келгенде, негізінен ауыл тұрмысы, бір кездегі балалық шағы қалған аяулы мекен жайлы жан-жақты көңіл-күй әуендерін толғайтын қазақ қаламгерлерінің де шеберлігі шексіз. Бір есептен лиризмнің мазмұндық-идеялық төркіні осынау сағыныш, аңсау, адалдық, тазалық, жақсы мұрттарды алыс естеліктерден іздеп, өткенді бағалау сарындарымен тамырлас шыққан сияқты.

Әңгіме кейіпкері Төлеубек жағдайы қанша жақсы болса да қала өмірінен жалығып, бәрін тастап, туған жеріне оралады. Туған жеріне деген ыстық ықыласы мен сезімін оның: «Бірте-бірте апамның жер сағынышы, туған топырақты аңсау ауруы маған ауды. Бұл да бір дерт екен. Бұрын шахтаға түскен соң, бәрін ұмытып кетуші едім, енді бәрі жайына қалды. Есіл-дертім, аңсар-ойым – ауыл, туған жер, Қайнар болды да тұрды», - деген сөздерінен  байқаймыз. Өзге де осы ауылдан шыққан белгілі адамдарды неге ауылға оралмайды деген сауал көтереді. Ауылдың әсемдігін, ерекшелігін ерекше сезіммен жеткізе отырып, әңгіменің соңында мұндағы қасірет туралы бір ауыз сөзбен ғана ой түйеді. «Менің ұлым. Жасы биыл тура он бесте. Қарағандыдан көшіп келген соң, бір жылдан кейін туды. Атын Қуанышбек қойдық. Рейске өзіммен ылғи бірге алып жүруші едім, далаға, өзен-су жағасына талай қондық. Бесінші класта оқып жүргенде, аяқ астынан ауырды. Ылғи айтатыны соғыс әңгімесі: Қыру, Жою. Мұндай сырқаттар, неге екені белгісіз, көбейіп кетті. Асылып өлуші бар. Біреулер жарылыс, сынақтардың әсері дейді, кім білсін» [Нұрғали, 2008: 103], - деп береді де, ойлауды оқырманның өзіне қалдырады. Бұл тек бір адамның, бір ауылдың тағдыры ғана емес, бүкіл халықтың тағдыры екенін білдіреді.  Төлеубек пен баласының өлімі де ауылдағы болашақтың жоғын білдіріп тұрғандай. Бұл жердегі туған жерін ештеңеге айырбастамай, жұмақтай көріп отырған Төлеубек сияқтылардың келешегі қандай болады деген мәселе көтеріп отырғандай.

Осындай қасіреттің кесапаты«Үш аяқты құлын» әңгімесінде де айтылады. Шығармада жас баланың арманы суреттеледі. Қазақ ауылында, қазақы салт-дәстүрді бойына сіңіріп, ертегі тыңдап өскен баланың арманы – тұлпар. Оның атасының тайын жыл сайын сатып алатын Сәспенді жек көруі, Торбиенің құрсағындағы құлынды асыға күтуі, оны жанын салып бағып-қағуы сияқты баланың пәк сезімі шынайы, нанымды етіп берілген. Атасының айтып берген аңызы да әңгімеге сыршылдық дарытып, шынайылығын арттыра түскен.

Осылайша көптен күткен Торбие құлындағанда аспаннан жай түскендей болады. «Қанша күндер бойы үмітпен күткен, немересінің еншісіне беріп, бағып-қағып, үкілеп, түбі – бәйгеге қосам деп дәметкен, текті тұқым Торбиенің нәсілінен жүйрік шығады деп арман еткен еркек құлынның орнына қос құлақтың бармақ басындай ғана нобайы бар, қисық көз, бұзау бастанған, бітеу мойын мақұлық тыпырлап жатыр. Енді аңғарды: алдыңғы екі аяқ қосылып бітеу біткен, туа салып жүріп кететін, төрт аяғы қалт-қалт еткен құлыншақтың орнында үш аяқты, тарбиған ойқы-шойқы бірдеңе жыбыр-жыбыр етеді. Мұндай пәлені кім естіп, кім көрген! Сұмдық-ай!» [Нұрғали, 2008:104]. Кейіпкермен бірге осы сәтті күтіп отырған оқырманның да көңілі су сепкендей басылады.

Автор бұл әңгімесінде де өз ауылының, ондағы адамдардың, сол арқылы халықтың болашағына деген алаңдаушылығын білдіреді. Не болғанын түсінбеген баланың бейнесі арқылы осы жердегі балалардың болашағы туралы мәселе көтереді. Осылайша адам

тағдырына бір алаңдаса, екінші жағынан ұлттық мәселені де көтеріп тұрғандай. Яғни, нағыз қазақылықты сақтаған, ертегі, аңыз тыңдап, жылқыға құмартатын жастардың, сол қазақылықты бойына сіңіретін қазақ ауылдарының жойылып бара жатқандығын айтып, жар салады.

«Үш аяқты құлын» әңгімелер циклінде жарылыстың кесірінен болып жатқан осындай ащы шындықтарды көркем шығармаға айналдыра отырып, көкейкесті мәселе көтереді, ойлануға шақырады. Бұл шындық әр әңгімеде әр қырынан ашылады. Бірін-бірі қайталамайтын кейіпкерлер, олардың тағдырлары арқылы асқан шеберлікпен жазылған әңгімелердің көркемдігі ерекше. Автор өз ойын анық, шынайы жеткізу үшін түрлі штрих, детальдарды да шебер пайдалана білген.

Р.Нұрғали қаламынан туған әңгімелердің әрқайсысы оқырман ойын тербеп, оның санасына сан түрлі сауалдар салады. Жазушыға айтар ойын шынайы жеткізіп, кейіпкерінің ішкі жан дүниесінің иірімдерін аша біледі,өзінің көзқарасы мен шығармашылық ұстанымын дәл жеткізеді. Шығарманың көркемдік мәнділігін арттыратын нәрсе – қаламгердің осындай шеберлігі екені даусыз.

## ӘДӘБИЯТ


Нұрғали Р. 8 томдық шығармалар жинағы. Т.4. Астана: Фолиант, 2008. – 658 б.

Нұршайықов Ә. Деректі кітап дидары. Қазақ әдебиеті. 31. 03. 1978. // Кітапта: Жеті томдық шығармалар жинағы. Қосымша том (8). Астана: Фолиант, 2005. – Б. 98-101.



**В.Р. АМИНЕВА**

Казанский федеральный университет, Казань


# ТРЕХСТИШИЯ Р. ФАЙЗУЛЛИНА: ДИАЛОГ С ЯПОНСКОЙ ЛИТЕРАТУРНОЙ ТРАДИЦИЕЙ


**Аннотация.** В статье рассматриваются структурно-содержательные особенности трехстиший Р. Файзуллина в контексте сопоставления с хокуу как архитектонической формой целого. Выделены два типа трехстиший в творчестве поэта: построенные на двучленном параллелизме и использующие последнуюю строку как композиционный и смысловой ключ к стихотворению. Сделан вывод о трехстишиях и хокку как предмете сопоставительной поэтики жанров.

**Abstract.** Structural and substantial features of R.Fayzullin's three-verses are considered in the article in the context of comparison with hokku as an architectonic form of the whole. Two types of three-verses in the poet's work are distinguished: one is built on two-partparallelism; others usethe last line as a compositional and semantic key to the poem. It was concluded that three-verses and hokku can be the subject of comparative poetics of genres.



**Ключевые слова:** жанр, нациоанльная традиция, сопоставительная поэтика, архитектоника, композиция.

**Keywords:** genre, national tradition, comparative poetics, architectonics, composition.


Р. Файзуллин – признанный лидер поколения поэтов-шестидесятников, стремящихся к обновлению идейно-художественного облика национальной литературы и проводивших эксперименты в области содержания и формы стиха [см.: Равил Фәйзуллин, 2002: 13]. В контексте поиска новых эстетических ориентиров в татарской литературе 1960-1980-х гг. возникает интерес к иным национальным литературно-художественным традициям, в частности – к жанрам японской поэзии. Р. Файзуллин

создает циклы одно-, двух-, трех-, четырех-, пяти-, шести-, семистиший, объединяя их общим определением «кыска шигырьләр» («короткие стихи»). Д.Ф. Загидуллина, сравнивая их структуру с композицией хокку и танка, устанавливает существующие между ними различия: в стихотворных размерах, обусловленных лексико-фонетическими особенностями национальных языков, поэтических приемах, запечатленных в архитектонических формах целого эмоционально-психологических состояниях лирического субъекта [Заһидуллина, 2015: 44-48]. Однако неисследованным в литературоведении остается один из важнейших аспектов поэтики трехстиший Р. Файзуллина, связанный с используемыми в них способами художественного завершения. Они коррелируют с коаном в хокку, жанровым условием которого является неожиданность и непредсказуемость последней строки, призванной стать «мгновенным озарением, в акте которого постигается мир как целое и достигается освобождение» [Бройтман, 2001: 226-227].

В основе значительной части трехстиший Р. Файзуллина – модель двучленного параллелизма. Субъект речи в них как правило грамматически не выражен и предстает как созерцатель, воссоздающий открывающуюся перед ним картину, в которой пластически запечатлено то или иное психологическое состояние, закономерность бытия, новое видение мира и места человека в нем. Так, в миниатюре «Тулайторакта» («В общежитии») спящие девушки и ждущие рассвета цветы оказываются в одном пространственно-смысловом ряду и образуют единую природно-человеческую реальность, в которой синкретичны состояния сна и ожидания рассвета: «Кызлар күптәнйоклый. / Кефир шешәсендәгәлләр / таңныкөтә» [Фәйзуллин, 1981: 223]. («Девушки давно спят. / Цветы, стоящие в бутылке из-под кефира, / ждут рассвета»[1]). Внешняя статичность компенсируется напряженным ожиданием рассвета. Это переживание выступает и в узких, конкретных, индивидуальных рамках, создаваемых локальностью (камерностью) обстановки, единичностью предметных деталей, и в широком, общем, универсальном смысле, который актуализируется отсутствием границы между комнатой и мирозданием. Так устанавливается взаимосвязь микро- и макрокосма, горизонтальных и вертикальных процессов, конечности конкретного быта и бесконечности бытия.

Аналогичная структура возникает в трехстишии «Дөнья» («Жизнь»): устанавливаемое параллелизмом тождество углубляется контрастом человеческого и природного планов, выявляющим противоречивое единство мира и человека: «Пәһлеван кабере өстендә / яфраклары калтыраулы / кәкре, зәгыйфь усак үскән» [Фәйзуллин, 1981: 287]. («На могиле богатыря / выросла кривая, с дрожащими листьями, / слабая осина»). Сравнение богатыря с деревом – традиционный прием в тюркском героическом эпосе [см: Урманче, 2015: 349]. Наделенный множественностью значений, отсылающий к мифу о мировом дереве как универсальном сепаранте «вертикальных» уровней мира, образ дерева в данном случае предельно индивидуализирован и наделен отрицательными коннотациями. Не случайным представляется выбор породы дерева – осины. Обладая богатой мифологической генеалогией, осина символизирует во многих культурах, в том числе и в татарской, страх [Садыкова, Мингазова, 2013]. Дрожащая от страха, чахлая и кривая осина бросает неожиданный отсвет на фигуру умершего богатыря, с одной стороны, актуализируя ряд

---

[1] Здесь и далее подстрочный перевод автора статьи.

оппозиций аксиологического и этического характера: внешнего и внутреннего, явного и сокрытого, истинного и видимого, жизни и смерти, мира потустороннего и посюстороннего, прошлого и настоящего и др., а с другой – устанавливая связь между этими категориями и сферами бытия.

Стихотворение «Очрашкач» («При встрече») начинается зрительным образом, который в лингвистической поэтике называют генетивной метафорой, – «глаза надежды». Очевидно, что эта метафора опирается не на внешнее сходство явлений, а на общую им мифологическую семантику: «Өметемнең күзе / шундый зур! / Керфекләре генә ябылмасын» [Фәйзуллин, 1981: 235]. («У моей надежды / такой большой глаз! / Лишь бы не опустились ресницы»). Экстатическое ожидание исполнения желаемого предстает в качестве широко раскрытого глаза и подобно ему имеет проективную природу. Это душевное состояние, возникающее «при встрече», эмансипировано от пространственно-временных и каузальных связей, от пределов и теологии жизни и поставлено в зависимость от одного обстоятельства – лишь бы не закрылись глаза. Антитеза открытых и закрытых глаз выявляет пульсирующую субстанцию надежды, пребывающей в двух модусах – бытия и небытия, имеющей тотально субъективный характер и не располагающей никакой другой объективируемой идентичностью, кроме открытых глаз.

Другую группу составляют трехстишья, в которых, как и в хокку, последняя строка является композиционным и семантическим ключом к смыслу стихотворения, служит средством универсализации изображаемого и раскрывает в нем новый смысл. Это такие миниатюры, как: «Үҗәтлек» («Упорство»), «Төркем-төркем кошлар күктә!..» («В небе стаи птиц!..»), «Кайту» («Возвращение»), «Көзгеяңгыр» («Осенний дождь»), «Тауларилендә» («В стране гор»), «Ялгызчакта» («Когда один»), «Этюд» и др. Трехстишие «Осенний дождь» –замечательный образец этой группы стихотворений, в котором полная драматизма ситуация прощания переводится в поток зрительных образов: «Торналаркитеп бара. / Кош канатларыорынгач, / Болытларныңкүңелетулды» [Фәйзуллин,1996: 43]. («Журавли улетают. / От прикосновения их крыльев / Облака расчувствовались»). Сложное переплетение природного и душевного планов отразилось в трактовке дождя как слез облаков, провожающих журавлей. Улетающие журавли и плачущие облака – символы не только наступившей осени, но и безостановочного движения времени, далекости душ друг от друга, их разделенности и боли. Это чувство, вызванное расставанием, универсализируется, выражаясь в синкретическом образе дождя-слез. Семантическая эквивалентность дождя и слез открывается в нескольких планах: в их сопричастности стихии воды и в переходе от физических проявлений мира к метафизическим – состояниям души, объединенииприродно-космического, физически-эмоционального и экзистенциального начал.

В миниатюре «Упорство» третья строка функционально сходна с коаном в хокку: «Кырмыска саламын сөйрәп / Түмгәгенең очына менде. / Кояшка тәкия кынайды» [Фәйзуллин, 1981: 223]. («Муравей, неся на себе соломинку, / Поднялся на вершину кочки. / Приблизился-таки к солнцу!»). Упорное стремление к цели, преодоление трудностей и преград трактуется как восхождение вверх – путь к солнцу, равнозначное движению по пространственно-этической траектории. Неожиданный образно-смысловой ход в финале создает границу между поэтической и внехудожественной реальностями, знаменуя озарение, и в то же время размыкает ее, устремляясь в необозримость бытия.

В ряде миниатюр этой группы субъект речи имеет грамматически выраженное лицо и присутствует в тексте как «я», но это предельно обобщенное «я» – носитель самосознания личности, постигающей истины бытия. Так, в трехстишии «Возвращение» непрерывность течения реки-жизни, неизбежность происходящих перемен уравновешиваются памятью отдельной личности о своем прошлом («камне») – о прожитой жизни, о своих корнях, об истории, тем, что защищает человека от разрушительной работы времени, его необратимости: «Инешяңаюлалган. / Иске эздәмиңатаныш / Берташ калган...» [Фәйзуллин, 1981: 289]. («Речка изменила русло. / В старом русле мне знакомый / Камень остался...»). В трехстишии «В небе стаи птиц!..» лирический субъект находит в стае птиц одну, которая говорит на его языке («Төркем-төркемкошларкүктә! / Шуларныңберәрсе / минем телдәсөйләшәдеркүк… [Фәйзуллин, 1981: 290]), а в миниатюре ««Когда один» – среди звезд ту, что светит, понимая его («Төненучакяктымсәхрада... / Күктә, ярый, берсүрәнйолдыз / мине аңлапҗемелдиәле!..» [Фәйзуллин, 1981: 290]).

Трехстишия Р. Файзуллина и японские хокку могут быть предметом сопоставительной поэтики как жанры, обладающие, несмотря на структурно-содержательные различия, функциональной близостью. В произведениях этих жанров сходным образом выстраиваются смысловые границы художественного мира и осуществляется его эстетическое завершение.

## ЛИТЕРАТУРА

Бройтман С. Н. Историческая поэтика. М.: Российск. гос. гуманит. ун-т, 2001. – 320 с.

Заһидуллина Д. Ф. 1960-1980 еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – 383 б.

Равил Фәйзуллин: Заман. Иҗат. Шәхес. Казан: Мәгариф, 2002. – 495 б.

Садыкова А. Г., Мингазова Р. Р. Функционирование фитоморфной метафоры в художественнном дискурсе французского и татарского языков // Современные проблемы науки и образования, 2013. № 6. URL: http://www.science-education.ru/113-11366 (Дата обращения: 01.09.2020).

Урманче Ф.Тюркский героический эпос. Казань: ИЯЛИ, 2015. – 448 с.

Фәйзуллин Р. Кошлар юлы: шигырьләр. Казан: Татар. кит.нәшр., 1981. – 415 б.

Фәйзуллин Р. Җил – вакыт ул... Казан: Мәгариф, 1996. – 287 б.

**А.Г. ӘБРАРОВА**
Казан федераль университеты, Казан

# ТӨРЛЕ МИЛЛӘТ ЯЗУЧЫЛАРЫ ИСЕМ-ФАМИЛИЯЛӘРЕ БЕЛӘН АТАЛГАН КАЗАН ШӘҺӘРЕ УРБАНОНИМНАРЫ

**А.Г. АБРАРОВА**
Казанский федеральный университет, Казань

# УРБАНОНИМЫ ГОРОДА КАЗАНИ, НАЗВАННЫЕ В ЧЕСТЬ ПИСАТЕЛЕЙ РАЗНЫХ НАЦИОНАЛЬНОСТЕЙ

**Аннотация.** Город Казань издавна считается центром, объединяющим и ученых, и литераторов. Особенно ярко это отражается на урбанонимической системе города. Здесь увековечены имена и фамилии многих личностей, связавших свою жизнь с городом Казань. В Казани насчитывается более пятидесяти улиц, названных именами выдающихся писателей татарского народа. Существует более шестидесяти улиц, названных именами писателей разных национальностей. Наличие имен и фамилий представителей разных национальностей на улицах Казани – яркий пример толерантности.

**Abstract.** The city of Kazan has long been considered a center uniting both scientists and writers. This is especially clearly reflected in the urbanonymic system of the city. Here the names and surnames of many personalities who have linked their lives with the city of Kazan are immortalized. In Kazan, there are more than fifty streets named after outstanding writers of the Tatar people. There are more than sixty streets named after writers of different nationalities. The presence of names and surnames of representatives of different nationalities on the streets of Kazan is a vivid example of tolerance.

**Ключевые слова:** город Казань, урбанонимия города Казани, улицы Казани, писатели татарского народа, писатели разных национальностей.

**Keywords:** Kazan city, urbanonymy of the city of Kazan, Kazan streets, writers of the Tatar people, writers of different nationalities.

Мең елдан артык тарихы булган Казан шәһәре белем, әдәбият-сәнгать, фәнни ачышлар, сәнәгать һ.б. өлкәләрдә зур үсешләргә ирешкән борынгы кала. Башкалабызга дөньяның төрле төбәкләреннән алдынгы фикерле зыялыларның тартылуы табигый, чөнки Казан элек-электән фән һәм әдәбият галимнәрен берләштереп торучы үзәк санала.

Казан шәһәре урбанонимнар системасында бу бигрәк тә чагылыш таба. Биредә төрле елларда башкалабызның төрле уку йортларында хезмәт куйган галимнәр, табиблар, татар әдәбияты үсешенә саллы этәргеч ясаган әдипләр һәм мәркәзебез тарихы белән тыгыз бәйләнештә булган шәхесләрнең исем-фамилияләре мәңгеләштерелде.

Казан шәһәре башкарма комитетының «Казан шәһәре атамалар реестры» турында чыгарылган карар нигезләмәсендә татар халкының күренекле язучылар исем-фамилияләре белән аталган урам исемнәре: *Абдулла Алиш, Габдрахман Әпсәләмов, Гадел Кутуй, Әмирхан Еники, Аяз Гыйләҗев, Габдулла Тукай, Галиәсгар Камал, Гариф Ахунов, Гаяз Исхакый, Гөлшат Зәйнашева, Дәрдемәнд, Кави Нәҗми, Каюм Насыйри, Кол Гали, Гафур Коләхмәтов, Мәҗит Гафури, Мирсәй Әмир, Мирхәйдәр Фәйзи, Муса Җәлил, Мөхәммәдьяр, Нәби Дәүли, Нәкый Исәнбәт, Нур Баян, Нурихан Фәттах, Галимҗан Ибраһимов, Сибгат Хәким, Туфан Миңнуллин, Ризаэтдин Фәхретдин, Фатыйх Әмирхан, Фатыйх Кәрим, Һади Атласи, Һади Такташ, Хәсән Туфан, Кәрим Тинчурин, Шәриф Камал, Шиһабетдин Мәрҗани, Җәүдәт Фәйзи, Рәхим Саттар, Гомәр Бәширов* һ.б. [http://docs.cntd.ru/document/446524353].

Казан шәһәре башкарма комитетының «Казан шәһәре атамалар реестры» турында чыгарылган карар нигезләмәсендә төрле милләт галимнәре, язучылары исем-фамилияләре белән аталган 4 дистәгә якын урам бар. Төрле милләт язучылары исем-фамилияләре белән аталган урбанонимнарга түбәндәгеләрне кертергә мөмкин: казах шагыйре – *Абай Кунанбаев*; таҗик язучысы, галим – *Айни Садретдинов;* кыргыз язучысы – *Чыңгыз Айтматов*; үзбәк шагыйре – *Алишер Нәвои*; Украина шагыйре – *Тарас Шевченко*; чех язучысы – *Ярослав Гашек;* латыш шагыйре – *Ян Райнис*; Белоруссиянең халык шагыйре – *Янка Купала* урамнары бар. Рус язучылары арасында – *Сергей Аксаков, Валерий Брюсов, Вероника Тушнова, Аркадий Гайдар, Николай Гоголь, Иван Гончаров, Владимир Короленко, Павел Лукницкий, Гавриил Каменев, Михаил*

*Пришвин, Александр Пушкин, Александр Радищев* һ.б. исем-фамилияләре күп еллар дәвамында Казан шәһәре урамнарына аерым яңгыраш һәм үзенчәлек өсти [http://docs.cntd.ru/document/446524353].

К.Ф. Әмировның “Где эта улица, где этот дом?” (1995) хезмәтендә казах шагыйре *Абай Кунанбаев, Алишер Нәвои, Тарас Шевченко* урамнары турында түбәндәге мәгълүмат бирелә:

*Абай Кунанбаев* урамы – Мәскәү районы (Яңа Каравай бистәсе), Армавир һәм Пришвин урамнары арасында урнашкан; №9 трамвай, №1, №3 троллейбус, №9 автобус йөри, “Ленинград урамы” тукталышына кадәр, (озынлыгы 0,2 км). 420047.

Кунанбаев Абай (1845-1904) – казах мәгърифәтче шагыйре, яңа басма казах әдәбиятына нигез салучы шәхес хөрмәтенә аталган. Лирик һәм сатирик шигырьләре аша иҗтимагый гаделсезлеккә, явызлыкка, белемсезлеккә, иске гадәтләргә каршы чыга. Абайның күп әсәрләре татар теленә тәрҗемә ителгән [Амиров, 1995:138].

*Алишер Нәвои* урамы – (элеккеге *Адмирал Ушаков* урамы), Ленин районы (Каравай бистәсе), Янка Купала һәм Денис Давыдов урамнары арасында урнашкан; №9 трамвай, “Ленинград урамы” тукталышына кадәр №1, №3 троллейбус, “№2 кибет” тукталышына кадәр №9 автобус. 420085.

Нәвои Низаметдин Мир Алишер (1441-1501) – үзбәк шагыйре, акыл иясе, җәмәгать эшлеклесе хөрмәтенә аталган. Башка төрки телле әдәбиятлар үсешенә зур йогынты ясый [Амиров, 1995: 172].

*Шевченко* урамы – Идел буе районы (Яңа Поповка бистәсе), №8 трамвай “ТЭЦ-1” тукталышына кадәр. 420054.

Шевченко Тарас Григорьевич (1814-1861) – украин шагыйре, рәссам һәм сәясәтче хөрмәтенә аталган.

10 елга сузылган авыр сөргеннән соң, 1857 нче елның 5 нче августында балыкчылар көймәсендә Каспий диңгезендә урнашкан Новопетровск фортыннан Әстерханга чыгып китә. Аннан «Князь Пожарский» пароходында Түбән Новгородка кадәр барып җитә. 12 нче сентябрь, кич белән, пароход Казанга килә.

Икенче көнне ул тулысынча шәһәрне карауга багышлый. Шевченконың истәлекләрендә язылганча, “за четвертак” ул татар арбасына утырып, Казанга юнәлә. Казан аңа Мәскәүне хәтерләтә («Казань городок – Москвы уголок»). Шевченко университет белән таныша. 1847 нче елда Казан университетына җибәрелгән, Кирил-Мефодий бердәмлеге аша якын булган көрәштәшләре, киев студентлары – И.Посяде һәм Г.Андрузский турында мәгълүматлар белергә тырыша. Урамда үлем җәзасына дучар ителгән җинаятьчене хөкем итүгә алып барган процессия аңа аеруча тискәре йогынты ясый һәм ул киредән пароходка кайта.

Пароход 14 нче сентябрь, 11:00 сәгатькә кадәр йөкләрне кабул итү сәбәпле, Шевченко ярдан ике каралама эшләргә өлгерә: беренчесе – Казанның гомуми күренеше; икенчесе – Казанга һәм Услон авылына каршы яктан ясалган Идел күренеше.

Аннан соң пароход Түбән Новгородка юлын дәвам итә [Амиров, 1995: 291-292].

Төрки халыклар яшәгән төбәкләрдә шулай ук татар язучылары белән аталган урамнарны очратырга мөмкин. Бу исемлектә, иң беренче чиратта, Муса Җәлил һәм Габдулла Тукай кебек бөек шәхесләребезнең исемнәре еш очрый.

2017 нче елда Казахстанның башкаласы – Астана шәһәрендә *Сөембикә* ханбикә урамы ачыла. Шулай ук биредә татар шагыйре, Советлар Союзы Герое *Муса Җәлил*

исеме белән аталган урам да бар. Алматы шәһәрендә 1962 нче елда һәм Уральск шәһәрендә *Габдулла Тукай* урамнары барлыкка килә.

Кыргызстанның башкаласы – Бишкәк каласында татар шагыйре, Советлар Союзы Герое *Муса Җәлил* урамы бар.

Үзбәкстанның башкаласы Ташкент каласында 1975 нче елда һәм Нукус шәһәрләрендә *Габдулла Тукай, Муса Җәлил, Һади Такташ* урамнары бар.

Төркиянең Әнкара шәһәрендә 2001 нче елда *Габдулла Тукай* урамы, ә 2011 нче елда Тарсус шәһәрендә *Габдулла Тукай* бульвары ачыла.

Казан шәһәренең елдан-ел зураюы яңа урамнар барлыкка килүгә этәргеч ясый. Зыялы һәм укымышлы милләт вәкилләре – татарлар – әдәбият өлкәсендә тирән эз калдырган шәхесләрнең исем-фамилияләрен мәңгеләштерү өстендә зур эш алып бара. Казан урамнарында татар язучылары белән беррәттән, башка милләт язучыларының исем-фамилияләре булу, төрле халык әдәбиятларының, ә бу үз чиратында төрле милләтләрнең, үзара дустанә мөнәсәбәттә яшәүләренә ачык мисал.

## ЛИТЕРАТУРА

Амиров К.Ф. Казань: где эта улица, где этот дом? Казань: Изд-во «Казань», 1995. – 320 с.

О Реестре названий улиц города Казани (с изменениями на 16 апреля 2019 года) // URL: http://docs.cntd.ru/document/446524353 (дата обращения: 20.09.2020).

**А.Д. ӘЛТАЙ**
Л.Н. Гумилев атындағы Еуразия ұлттық университеті, Нұр-Сұлтан

## АБАЙ ИДЕЯСЫ – ЖАҢАША ЖАҢҒЫРУДЫҢ КЛАССИКАЛЫҚ ҮЛГІСІ

**А.Д. АЛТАЙ**
Евразийский национальный университет им. Л.Н.Гумилева, Нур-Султан

## ИДЕЯ АБАЯ – КЛАССИЧЕСКИЙ ПРИМЕР СОВРЕМЕННОЙ МОДЕРНИЗАЦИИ

**Аннотация.** В статье рассматривается просветительское значение стихов великого поэта Абая. Он анализируется на примерах из произведении поэта, где говорится о качествах, необходимых для того, чтобы стать полноценным человеком. Сделаны выводы об актуальности его идеи на сегодняшний день.

**Ключевые слова:** Концепция «полного человека», учитель нации, идея Абая, образование, наука.

**Abstract.** The article examines the educational significance of the poems of the great poet Abai. It is analyzed using examples from the poet’s poems, which speaks of the qualities necessary to become a full-fledged person. Conclusions are drawn about the relevance of his idea to date.

**Keywords:** The concept of«complete man», teacher of the nation, Abai’s idea, education, science.

Ғаламдасу майданында ұлттық болмысымызды жоғалтпай, алтын тамырымызды суалтпай, негізімізді сақтай отырып жаңаша жаңғырудың озық үлгісі – Абай идеясы.

Ұлт ұстазы, адамзаттық ақыл-ойдың заңғары хакім Абайдың сындарлы сындарынан қорытынды шығарып, бой түзеп, еңсе тіктеу – бүгінгі ұрпақ парызы.

Прогрессивті, озық идеяларын іске асыру, мән-мағынасын түсіне білу, әрі қарай дамыта түсу айқын мақсатымыз.

Абай армандаған, мұрат тұтқан интелектуалды ұлт болмысы қандай болмақ?

Біріншіден, білімді болуды, ғылымды игеруді ұсынды. Дүниенің алдыңғы қатарлы, озық елінің бірі болу үшін білімге ұмтылып, ғылымды игеру идеясын ұсынды.

*Ғылым таппай мақтанба,*
*Орын таппай баптанба.*
*Сізге ғылым кім берер,*
*Жанбай жатып сөнсеңіз.*
*Дүние де өзі, мал да өзі,*
*Ғылымға көңіл бөлсеңіз.*
*Пайда ойлама, ар ойла,*
*Талап қыл артық білуге.*

Абайдың толық адам концепциясы:Толық адамға айналу үшін білімді болу жеткіліксіз екендігін түсіндіруге тырысты. Ол үшін ыстық қайрат, нұрлы ақыл, жылы жүрек керек екендігін айқын көрсетіп берді.

Тіпті адам бойындағы қайрат пен ақыл қайырлы болу үшін әділет пен рахым қажет екендігін алға тартты.

*Қайрат пен ақыл жол табар,*
*Әділет, шапқат кімде бар.*
*Сол жарасар туғанға*
*Бастапқы екеу соңғысыз*
*Біте қалса қазаққа*
*Алдың – жалын, артың – мұз,*
*Барар едің қай жаққа,* - *дейді.*

Абай толық адамға, тұлғаға айналу үшін адам бойыдағы мінезге мән береді. Яғни, теріс мінез бен жаман әдеттен көңіл суытып, арылу керек екендігін, жақсы әдеттерден ғибрат алып, ой қазанын молайту керектігін айтады.

*Өсек, өтірік, мақтаншақ,*
*Ерішек, бекер мал шашпақ*
*Бес дұшпаның білсеңіз* - деп, адам бойына кесел боп жабысар «бес дұшпанның» атын атап, түсін түстеп береді.

*Талап, еңбек, терең ой,*
*Қанағат, рахым ойлап қой* – деп адамның ұлық болмысын толықтырып тұратын бес жақсы қасиетті, бес асыл істі бойға қалыптастыруға шақырады.

Балабақшадан, мектеп қабырғасынан бастап жас ұрпақты осы бағытта тәрбиелеуіміз керек.

Абай атамыз сақ болуды, аулақ болуды, бойын аулақ ұстап жиренуге шақырған бес дұшпанның бірі – еріншектік. Масылдықпен, жалқаулықпен күресу арқылы қоғамды сауықтыруға, әлеуетті арттыруға, тұрмысты жақсартуға болатындығын алға тартты. Ол үшін еңбекқорлықты, дүниеге сергек қарауды, талаптылықты ұсынды.

*Болмашы кекшіл,*
*Болсайшы көпшіл,*
*Жан аямай кәсіп қыл.*
*Орынсыз ыржаң,*
*Болымсыз қылжақ,*

*Бола ма, дәулет, нәсіп бұл?*

*Еңбек етсең ерінбей,*

*Тояды қарның тіленбей* – деп толғауы да сондықтан.

Терін сатпай, көзін сатқан, тілемсектіктен, масылдық пиғылдан, жатып ішер жалқаулықтан сақтандырады. Жаңа кәсіп игеруге, еңбектенуге, нәтижеге, дәулетке қол жеткізу үшін аянбай еңбектену керек екенін үлгі етеді.

Абай сынаған қоғамның ауыр дертінің бірі – жемқорлық, сыбайластық, алауыздық дерті. Соның кеселінен қоғамға, оны құрайтын адам факторына залал келетіндігін ашына жырлайды.

*Ондай адамдарға:*

*Сабырсыз, арсыз, еріншек,*

*Көрсеқызар, жалмауыз.*

*Сорлы қазақ сол үшін,*

*Алты бақан, ала ауыз.*

*Өзін-өзі күндейді,*

*Жақынын жаманміндейді – дейді.*

*Ұрлықпен мал таптым деп,*

*Егессе ауыл шабам деп,*

*Сөйтіп құдай атады.*

*Қу нәпсісін тия алмай,*

*Атым шығып жүрсін деп –*

Абай өзі айтқандай, бір ұрты май, бір ұрты қан, нәпсісін тия алмас тойымсыздардан, кеселді пысықтардан, қу тілменен құтыртатын суайттардан, харакетсіз, қайырсыз басшылардан, өзгеге береке ойламайтын оңбаған антұрғандардан сақ болуға шақырады.

Бас-басына би болған өңкей қиқым,

Мінеки кетірді ғой елдің сиқын – деп парадан аузы босамайтын қиқымдардың елге тигізер зиянын ащы сынға алады. Қоғамды алға жылжытпай, артқа тартатын да, ел ішін ала тайдай бүлдіріп іртки салатын да солар екендігін ескертеді.

«Единицаң болмаса, не болады ақшаң нөл?» – деген Абай елді өзі айтқандай «единицалар», яғни толық адамдар, тұлғалар басқару керектігін астын сызып тұрып айтады. Сонда ғана елдіктің туы қисаймайтынын, бірліктің іргесі сөгілмейтінін көрегендікпен пайымдайды.

*Абай – елдіктің алтын туы,*

*Бірліктің – айқын жолы.*

*Біріңді қазақ бірің дос,*

*Көрмесең істің бәрі бос* – деп ұлттық сананың қалыптасуына ықпал еткен пассионарлық тұлға. Рулық тартыстан құтылып, тұтас ұлттық мұрат жолында бірігуге шақырды. Сөйтіп елдік сананың, ұлттық сананың жаңғыруына жол ашты. «Қалың елім, қазағым, қайран жұртым» – деп тұтас ұлттың, елдігі келіскен халықтың арман-мұраты бір арнадан тоғысуы аса маңызды екендігін көре білді. Хакімнің бұл концептуалды ойы, озық идеясы бүгін де, болашақта да аса маңызды бола бермек.

Абай – адамзаттық ой-сананың заңғар биігі, планетарлық ойлаудың өнегелі үлгісі. «Адамзаттың бәрін сүй, жақыным деп» - деген даналық хикметі әлемдік философиядағы теңдесіз пайым болып табылады.

Дүниеге мейірімді көзбен үңілу, адамзат баласына бауырлық сезіммен қарау адамдықтың белгісі екендігін алға тартады. Абайдың әлемге өнеге болар кемеңгерлік келбеті де осында жатыр.

Абай мұраты – тұтас ұлт мұраты!

Абай арманы – қазақ халқының арманы!

Абай мақсаты – жетістікке жеткізер, абыройға бөлентер өркениеттіліктің, елдіктің бақуатты бақыт жолы!

Абай сыны – ұлт тәніндегі теріс кеселдерден сауығуға мүмкіндік беретін сарқылмас ақыл!

Абай идеясы – ұлттық болмысыңды жоғалтпай, тамырыңды суалтпай жаңаша жаңғырудың классикалық үлгісі.

## ӘДӘБИЯТ

Абай. Сен де бір кірпіш дүниеге. Өлеңдер мен қарасөздер. Алматы: Атамұра, 2014. – 288 б.

**С.Е. ӘМИРЛАН**
«Халық даналығы» фольклор клубы, Нөкис

## ШЫРШЫҚ ҲАҚҚЫНДАҒЫ ХАЛЫҚ ЯДНАМАЛАРЫ
### (қарақалпақ фольклоры материаллары бойынша)

**С.Е. АМИРЛАН**
Фольклорный клуб «Народная мудрость», Нукус

## НАРОДНЫЕ ВОСПОМИНАНИЯ О ЧИРЧИКЕ
### (по материалам каракалпакского фольклора)

**Аннотация.** Чирчик – древнее историческое место вокруг Ташкента. Этот регион общая земля многих тюркских народов. Каракалпаки тоже жили здесь с давних времен. Чирчик часто упоминается в каракалпакском фольклоре. В статье представлены материалы по этому поводу.

**Abstract.** Chirchik – is an ancient historical place around Tashkent. This region is the common land of many Turkic peoples. The Karakalpaks also lived here for a long time. Chirchik is often mentioned in Karakalpak folklore. The article presents materials on this matter.

**Ключевые слова:** Народные воспоминания, Чирчик, каракалпакский фольклор, дастан, бадик.

**Keywords:** Folk memories, Chirchik, Karakalpak folklore, dastan, badik.

Орайлық Азияның әййемги ҳәм түпкиликли халқы болған қарақалпақлар тарийхының бир ушы Ташкент қаласы және оның дөгереги, соның ишинде Шыршық алабы менен де ушласып жатыр. Тийкарғы этникалық дүзилиси бойынша *мүйтен, қоңырат, қытай, қыпшақ, кенегес, маңғыт* киби ири алты қәўимлик бирлеспеден ибарат қарақалпақлардың түпки өзеги Аралбойы үлкесинде қәлиплескен болса да, бирнеше мың жыллықлар даўамында бул этнос Евразияның көплеген аймақларына тарқалып, жер-жерлерде өз изин қалдырып отырды. Ата-бабалардың «Ат аўнаған жерде түк қалар, түйе аўнаған жерде жүк қалар» дегениндей, қарақалпақлардың мәкан тутқан жерлеринде олардан көп-көп белгилер, көплеген ядыгерликлер қалды. Солардың

бирпарасы Шыршық алабы менен байланыслы фольклорлық-этнографиялық мағлыўматлар.

Қарақалпақ халық аўызеки дөретиўшилигинде Түркистан үлкесиниң басқа аймақлары сыяқлы Шыршық алабы ҳаққында да есленеди. Қарақалпақтың журтшылық арасына кеңнен танымалы болған «Мәспатша» атлы дәстанының (1934-жылы жазып алынған) Төре жыраў нусқасында усы шығарманың бас қаҳарманы Мәспатшаның өз ғайбана ашығын излеп Шыршық алабына сапар тартып барғанлығы баянланған [Қарақалпақ фольклоры,1982: 8]. Дәстан Бухар журтындағы қарақалпақлардың ўәкили, Кенегес ўәлаятының кәтқудасы Әбдикерим байдың жаратқаннан жалынып-жалбарынып сорап алған жан дегендеги жалғыз улы Мәспатшаның Шыршық дәрьясы бойындағы атақлы байлардың бири Лабақбайдың хан сораса бермеген, қараны көзге илмеген қызы Айпаршаны унатып, айттырыўы ҳәм қалыңлығын әкелиў жолында не-не қыйыншылықларға дус келип, соның бәрин мәртлерше жеңип шығып, сүйген ярына қосылғанлығы туўралы ўақыяларды сөз етеди [Қарақалпақ фольклоры, 2013: 53-70]. Дәстан нусқаларында көплеген жер-суў атамалары менен бирге, Шыршық алабында жасаўшы *арғын, қыпшақ, қурақ, қатаған, қалмақ* сыяқлы ел-елатлардың атлары да атап өтилген. Мәспатшаның қалыңлығы Айпарша Шыршық дәрьясы бойындағы тама урыўының қызы болып, шежире дәреклеринде олар «қурамалардың бир тийреси» деп түсиндирилсе, айырым изертлеўлерде «қыпшақлардың бир шақабы» екенлиги көрсетиледи. Ҳақыйқатында, Шыршық алабындағы қыпшақлар қурамында *тама-қыпшақ, табын-қыпшақ* тәризли этнонимлер ушырасатуғынлығы тиркелген [Қарақалпақ тили бойынша изертлеўлер, 1971: 166]. Қазақ шежиреси бойынша *тама* – кишижүз бирлеспеси ишиндеги алшын улысына киретуғын жетиурыў қәўиминиң бир аталығы сыпатында белгили. «Тама» этноними Орайлық Азия халықларынан тысқары, түрки тұқымынан дөреген башқурт, ноғай ҳәм қырымтатар халқының қурамында да сақланып қалған. «Мәспатша» дәстанында Айпаршаның теги тама екенлиги айтылса да, оның қайсы халыққа тийислилиги айтылмайды. Өйткени, дәстан дөретилген XVII-XVIII әсирлерде де айырым урыў-тайпалар менен ел-елатлардың елеберин жеке-дара жасап атырғанлары бар еди ҳәм олар тарийхта да солай сәўлеленип қалған.

«Шыршық» атамасы ири көлемли эпикалық шығармаларда ғана емес, қарақалпақ фольклорының шағын жанрларында да аталып отырады. Мәселен, қарақалпақ халқында баланы бесикке салыў дәстүри менен байланыслы атқарылатуғын «атшабар» яки «бесикшаппай» деген салт түри бар. Усы салт пайытында ҳәрқыйлы айтымаллар *(арнаў-тилеклер)* айтылады. Онда салтты басқарыўшы «бесикашы» ямаса «бесикапа» нәрестени бесикке салмастан бурын оның иши-тысын түтетки менен тазартып, балаға аталған бул қурылманы «ат» орнында санап, оны бәйгиге қосылған атлар киби шаўдырады. Бесикти атша шаўдырған бесикашы кимниң қасына барса, соған арнап айтымал айтады ҳәм аты аталғанлар атағанларын түйип ылақтырады, алапа *(қәде)* береди. Бесикти арылы-берили алып жүрип шапқылатқан бесикашы болажақ ат ийесиниң тилинен:

*Шымгенли жерде желемен,*
*Шыршыққа жетип келемен,*
*Шап тулпарым, шап, шап,*
*Шын сақыйды саррас тап!*, - деп отырғанлардың арасынан емеўрин танытқанларының бириниң қасына барып, өзлерине буйырған алапасын алады. Қарақалпақ тилиндеги «алапаға шабыў» деген ибараның мәниси де усы салт

пайытындағы алапа алыў үрдиси менен байланысады. Усы айтымалда «шымгенли жер» *(отлақ, майсазар)* уғымының қолланылыўы, Шыршық атамасының тилге алыныўы, қарақалпақлардың сол аймақ пенен әзел-әзелден тығыз байланысы болғанлығынан дәрек береди.

Орайлық Азия халықлары фольклорында денесине бөртпе шыққан балаларды емлеўде қолланылатуғын «бәдик көшириў» салты кең тарқалған. Фольклортаныўшы илимпаз Б. Абылқасымов «бәдик көшириў» салты менен байланыслы үлгилердиң қарақалпақ фолькорында наятый мол сақланғанлығын айрықша келтирип өткен [Абылқасымов,1993: 21]. Усындай бәдик текстлериниң биринде:

*Көш бәдик, көшер болсаң Шыршыққа көш,*
*Қул-қутаннан тараған қулшыққа көш,*
*Көшер жериң таппасаң тағы айтайын,*
*Қуртқалардың*[1] *қолындағы уршыққа көш!*, - деген қатарлар орын алған ҳәм онда да Шыршық ҳаққында еслеп өтиледи. Әдетте, бундай текстлерде көплеген мәканлардың, урыў-тайпалардың, ел-улыслардың атлары аталады. Солар қатарында Шыршықтың да тилге тийек етилиўи, қарақалпақлардың тарийхый жасаў орталықларының мәнзиллерин усылай көрсетип береди.

Халық дәстүринде «бәдик» ямаса «гүлапсан» деп аталған кеселликти көшириўдиң түрлише усыллары бар. Бурын «бәдик көшириў» салтын журт көпшилик болып атқарса, тәреп-тәреп болып «бәдик өлең» айтыў арқалы орынласа, гей-гейде халық арасынан шыққан дарымшылар менен бәдикгөйлер жеке түрде де ҳәрқыйлы ырымларды әмелге асыра отырып:

*Шүў ширкин, көш,*
*Шыршыққа көш,*
*Шубалып көш,*
*Шыршықтағы шыршаға,*
*Шырмалып көш, көш-ә, көш!*, - деп оны қуўған болады ҳәм усы текстте де Шыршықтың атының аталыўы, бул аймақтың қарақалпақлар тарийхында әдеўир терең из қалдырғанлығын тағы бир мәрте еске салады.

Қарақалпақлардың Ташкент әтирапы ҳәм Шыршық алабы менен узақ әсирлик байланысы барлығын тарийх илими де қуўатлайды. ХХ әсирдиң екинши ярымындағы археологиялық изертлеўлердиң жуўмағына көре, Орайлық Азиядағы дәслепки тиришилик орынларының бири – Арал теңизиниң түслигиндеги «Келтеминар мәденияты» ўәкиллериниң бир бөлегиниң өз өрисин кеңейтип, буннан бирер мың жыл бурын ҳәзирги Ташкент ўәлаяты аймағына қоныс аўдарғанлығын ҳәм сол жерлердеги жаңа мәдений ошақларды қәлиплестириўге үлес қосқанлығын дәлилледи. Бул мәденият ўәкиллериниң баслы өзгешелиги, олар аңшылық, шарўашылық пенен қатар, дийқаншылық ҳәм балықшылық кәсиби менен де шуғылланып, хожалық жүргизиўдиң жәмлеспели түрин жүзеге келтирген [Ртвеладзе, 2005: 8]. Қарақалпақлар – усы мәденияттың бирден-бир даўам еттириўшилери саналады.

Қарақалпақлардың Шыршық алабына қарай көшип өтиўи бир емес, бирнеше дүркин тәкирарланған. Оның базыбири, қарақалпақ төрелериниң Ташкент қаласына ҳүкимдарлық етиўи менен байланыслы болса, базыбиреўлери, халықтың тиришилик жағдайлары ҳәм

[1] ***қуртқа*** *– бул жерде: кәйўаны ана, мама.*

сырткы жаўлардан қорғаныў ҳәрекетлери себебинен жүзеге асқан. Бул бойынша Л. Толстованың «Жоқарғы қарақалпақлар» атлы монографиясында тийислисинше баянланған. Қарақалпақ аңызлары да Шыршық ҳаққында қызықлы мағлыўматларды алға тартады. Әлбетте, булар өз алдына бир темаға өзек боларлық мәселе.

Улыўма, Шыршық алабы халқы менен қарақалпақлардың қарым-қатнасықлары кеше жақында басланған емес. Бул байланыслардың сағасы оғада тереңнен тамыр тартқан. Оларды дәўирлерге бөлип изертлеў – келешектиң иси. Бизиң бул усынған дәреклеримиз болса, соған тийкар боларлық тамызықтың бир ушлығы ғана...

## ӘДЕБИЯТ


Абылқасымов Б. Телқоңыр. Алматы: Атамұра-Қазақстан, 1993.

Қарақалпақ тили бойынша изертлеўлер. Нөкис: Қарақалпақстан, 1971.

Қарақалпақ фольклоры: Мәспатша. Х том. Нөкис: Қарақалпақстан, 1982.

Қарақалпақ фольклоры: Мәспатша. 58-том. Нөкис: Илим, 2013.

Ртвеладзе Э. Цивилизации, государства, культуры Центральной Азии. Ташкент: УМЭД, 2005.



**Й.Р. ӘХМӘДИЕВА**

Казан федераль университеты, Казан


## ЧИТ ТӨБӘКЛӘРДӘҺӘМ ЧИТ ИЛЛӘРДӘ ТУКАЙҺӘЙКӘЛЛӘРЕ


**Ю.Р.АХМАДИЕВА**

Казанский федеральный университет, Казань


## ПАМЯТНИКИ ТУКАЮ В РОССИИ И ЗАРУБЕЖНЫХ СТРАНАХ


**Аннотация.** В статье рассмотран вопроссоздания образа народного поэта Г. Тукая в искусстве скульптуры. Памятники известному татарскому поэту Г. Тукаю были открыты в различных регионах России и за рубежом, они отражают значимые события, связанные с именем поэта. Памятники воссоздают образ поэта, помогают восприятию жизни и богатоготворческого наследия великого татарского поэта Г. Тукая.

**Abstract.** The article examines the reflection of the image of the national poet G. Tukay in the art of sculpture.  Monuments to G. Tukai were opened in various regions of Russia and abroad, including they reflect significant events associated with the name of the poet.  Monuments help to get acquainted with life, with the rich creative heritage of the great Tatar poet G. Tukay.



**Ключевые слова:** Г. Тукай, татарский народный поэт, памятники, скульптура

**Keywords:** G. Tukay, Tatar folk poet, monuments, sculpture.


Тарихи һәм сәяси сәбәпләр аркасында Җир шарының төрле өлкәләренә сибелгән күпмиллионлы татар милләтенең борынгыдан килгән бай тарихы бар. Гасырлар буе аның үзаңы, дине, әдәбияты, фәне һәм мәдәнияте формалашкан. Көнбатыш һәм Көнчыгыш Европада, Урал аръягында, Урта Азиядә, Казахстанда яшәүче күпсанлы татар халкы үзенең милли үзенчәлеген, телен һәм гореф-гадәтләрен саклаган. Бер яктан, татарның этник төркемнәре күп һәм төрлечә таралган булса да, аларның барсы өчен дә матди һәм рухи мәдәният уртак.

Халкыбызның бөек улы – Габдулла Тукай иҗаты татар милләтен, тарихын, шулай ук милли үзенчәлекләрен танытуда зур әһәмияткә ия. Шагыйрь үзенең әсәрләрендә татар халкының мәдәниятын, туган якка мәхәббәтен, халыкның рухи көч-куәтен, дөньяга карашларын чагылдыра. Шул сәбәпле Тукай иҗаты – бөтен дөньяга сибелгән татарлар өчен рухи кыйбла, халкыбызны берләштерүче үзәк булып тора. Төрки халыклар Тукайны үзләренең шагыйре итеп кабул итәләр. Әдипнең шигърияте, әсәрләренең жанр төрлелеге, сурәтләү чаралары төрки халык язучылары өчен үрнәк, яңа әсәрләр иҗат итү өчен юнәлеш тә булы тора.

Халкыбызның бөек шагыйре, татар поэзиясен төрки дөньяга танытучы шәхес – Габдулла Тукай исемен мәңгеләштерү – шагыйрьнең вафаты көненнән үк башлана. Татарстанның авыл-шәһәрләрендә, шагыйрь туган, яшәгән яки булган төбәкләрдә аның исеме белән урам, сквер, парк исемнәрен атау, музейлар ачу, картиналар язу – шушы юнәлештәге эшләрнең бер юнәлеше.

Әлеге мәкаләдә безне Г. Тукай образын сынлы сәнгатьтә чагылдыру – Тукай һәйкәлләре кызыксындыра. Әлбәттә, шагыйрь исемен мәңгеләштерү, киләчәк буыннарга да җиткерү, иҗаты белән кызыксындыру тудыру эшендә һәйкәлләр эшләү һәм урнаштыру да кирәкле, файдалы эш.

Әлеге эзләнү барышында без бөек татар шагыйренә куелган һәйкәлләрнең чит илләрдә – Казахстан, Төркия җирләрендә дә булуына игътибар иттек.

Казан шәһәре белән шагыйрь ятимлек язмышына тартылган чакларда ук “очраша”. Биш яше тулган җәйдә аны Казанга алып бары асрамага бирәләр. Тукай шәһәр тормышының матур якларын: байлар йортларын, ишек алдындагы тавис кошларын, Ташаяк базары күренешләрен күрә, тамагы тук, өсте дә бөтен була... Җаек шәһәреннән Казанга Тукай Казанның Печән базарында асрамага бирелгән ятим бала сыйфатында түгел, ә танылган шагыйрь, публицист-журналист буларак кайтып кергән. Казан чорында әдипнең иҗаты яңа биеклекләргә күтәрелә. Нәширләр аның шагыйрь китабын бастырырга атлыгып торлар: 1907-1914 елларда Тукайның 33 китапбы Казан матбагаларында дөнья күрә.

Шагыйрь Габдулла Тукай вафатыннан соң 45 ел үткәч, Казанның Куйбышев мәйданында, шәһәр үзәгендәге бакчада, кеше иң күп йөри торган урында һәйкәлнең беренчеләрдән булып ачылуы очраклы түгел. 1993 ел азагыннан Кубышев мәйданы исеме үзгәртелеп, Тукай мәйданы исемен йөртә. Кулына китап тотып баскан мәгърур карашлы шагыйрь һәйкәлен скульпторлар С.С. Ахунов, Л.П. Писаревский, Л.С. Кербель һәм Л.М. Павловлар эшләгән [5].

1894 елның ахыры яки 1895 елның башында Тукайны Казаннан Алты-биш Сапый чанасында Җаекка алып китә [2: 250]. Монда ул башта җизнәсе Галиәсгар Госмановның югары өенда үзе белән бертуган Газизә апасы янында тора. Җизнәсе аны “Мотыйгия” мәдрәсәсенә укырга бирә. “Мотыйгыя”дә иң әүвәлге хәлфәсе Фәтхетдин Рәхмәтуллин була. Ул Тукайны гарәп әдәбияты, Коръән, “Тәгълиме-с-салат” исемле гарәпчә китаплар укыта. Укуга сәләтен күргәч, җизнәсе Тукайны русс классына бирә. Булачак шагыйрь бер үк вакытта мәдрәсәдә дә укый. Әхмәтша Сиражетдинов – рус классындагы беренче укытучы, Тукайга рус теле, рус әдәбияты, математика, география кебек дөньяви фәннәрдән башлангыч белем бирә. Тукай көзен, җизнәсе Галиәсгар Госманов үлгәч, “Мотыйгыя” мәдрәсәсенә торып укырга күчә. Мәдрәсәдә яшәгәндә, матбугат, әдәбият һәм театр белән таныша, шигырь яза башлый, язучылык эшенә керешә. Шулай ук, Т.Нуриәхмәт хәлфә белән бергәләп, 4 ай чамасы мәктәп балаларын җәдитчә укыта.

Җаекка кунакка килгән шагыйрь Мирхәйдәр Чулпаный белән танышып, аннан шигырь төзелешен, "Мотыйгыя" дә укып киткән төрек шәкерте Габделвшли Әмрулладан төрек әдәбиятын өйрәнү дә Тукайны әдәбиятка тартып кертә.

Тукай шәкертләр белән бергә Җаек һәм Чаган елгаларының кушылган урынына ял итәргә чыккалый. Анда балык тотып, төрле уеннар уйнап, җырлап күңел ачалар. Тукай шунда үзенең шигырьләреннән өзекләр дә укый. Шуны әйтергә кирәк, Тукайның беренче шигъри тезмәләре 1902 елда бөреләнә башлый. Бу вакытта Камил Мотыгый этисе мәдрәсәсендә укыта башлый, әдәби түгәрәк оештыра һәм "Мәгариф" исемле стена газетасы, "Әлгасрелҗәдид" исемле кулъязма журнал чыгара. Тукайның беренче иҗат җимешләре шунда урын ала.

Г. Тукай Җаекта 12 ел яши. Нәкъ менә шушында Казаннан килгән кечкенә Апуш инде зуп–зур Тукай була, иң беренче шигъри тезмәләре дөнья күрә, Җаекта чыга торган газета-журналларда каләмен чарлый, шагыйрь булып җитлегә.

Бүгенге көндә Уральск шәһәре Казахстан Республикасына керә. Тукай беренче адымнар атлаган, иҗатына җирлек булдырылган Җаекта (Уральск) шәһәрендә 2001 елның 30 октябрендә Габдулла Тукайга һәйкәл куела. Бюсты авторлары:сынчы – М. Гасыймов, архитекторлар – С.Айдаров, А.Галиев, Р.Вафеев эшләгән.

Истанбул – Төркиянең Босфор бугазында урнашкан шәһәр. Күңелендә Истанбулга бару уе булса да, Тукай бервакытта да анда булмаган. 1911 елның 4 марттында дусты С. Сүнчәләйгә язган хатында җитәрлек акча таба алса, Әстерханга С.Рәмиевкә кунаккабарырга җыенуын, аннан аның белән кыргыз арасына кымызга чыгу, мөмкин булса, Истанбулга да бер-ике атнага барырга теләге барлыгын белдерә [2: 302].

Шагыйрьнең Истанбулга мөнәсәбәте үзенчәлекле. Уральскида мәдрәсәдә укыганда дуслашкан Төркиядән Габделхәмид режимыннан качып килгән Истанбул университеты студенты Габделвәли Әмрулла тәэсирендә башта шигырьләрен дә төрекчәрәк яза. Төркиянең әдәбиятына, сәнгатенә, мәдәниятенә күңел бирә. Ләкин үз ватанындагы хәлләр һәм чит ил матбугаты белән яхшы таныш булган зирәк, акыллы шагыйрь бик тиз икенче төрле нәтиҗәгә килә. Халкың аң-белемле булсын, артта калмасын дисәң, алдынгы карашларга ияреpгә, яңача белем алырга кирәк икән [2: 302].

Мәдрәсәдә укыганда ук, Тукай төрек телен белгән. «Мөхәммәдия» кебек дини-суфыйчыл әсәр белән танышкан. Тукай төрек әдәбиятының классиклары: Зыя Паша, Гәбделхак Хәмид, Нәмык Кемал, Мәхмүт Әкрам кебек язучыларның иҗатлары белән таныш булган. Көнчыгыш әдәбиятның яңалыклары белән таныш булса да, Тукай Төркиягә бара алмый кала. Шуңа да карамастан, төрки дөньяда аның әсәрләре күп тәрҗемә ителә. Тукайның исеме бөтен дөньяга билгеле, чөнки шигырьләренең гарәп, инглиз, француз, итальян, испан, алман, удмурт, кытай, фарсы телләренә тәрҗемәләре бар.

Төркия башкаласы Әнкара шәһәрендә татар шагыйре Габдулла Тукайга һәйкәл 2011 елның 26 маенда ачылды. Ул Анкараның 2000нче еллар башында Габдулла Тукай исеме бирелгән урамында куелды. Төркия башкаласы үзәгендә Габдулла Тукай бюстын ачу тантанасын ТӨРЕКСОЙ халыкара оешмасы ярдәме белән шәһәр мэриясе оештырган иде [4].

Рәсәйнең төрле төбәкләрендә ачылган Тукай һәйкәлләре, әдипнең иҗаты белән бергә аның шул төбәк белән бәйле тормышындагы мөһим вакыйганы ачарга ярдәм итә. Тукай һәйкәлләре – яшь буынга Тукайның тормыш юлын, иҗатын язмышын, образларга бай дөньясын өйрәнергә бер этәргеч булып тора.

**ӘДӘБИЯТ**

Антонова Б.Ф., Вәлиева Л.Г. Габдулла Тукайның әдәбт-мемориаль музее. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – 64 б.

Габдулла Тукай. Энциклопедия/ [баш мөх. З.З.Рәмиев]. Казан: Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2016. – 864 б., илл. ю-н.

Фәйзуллин Р.Г. Тукайга чәчәкләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. – 132 б.

http://gabdullatukay.ru/bez-tukay/monuments/ankarada-tukaj-hejkele/

https://www.hobbysalon.ru/russia/respublika-tatarstan/kazan/pamyatnik-gabdulle-tukayu-kazan

**А.З. БАРИЕВА**
Казан федераль университеты, Казан

## Ч.АЙТМАТОВ ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ ТАТАРЧАГА ТӘРҖЕМӘЛӘРЕНДӘ ӘДӘБИ ТӘРҖЕМӘ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

**А.З. БАРИЕВА**
Казанский федеральный университет, Казань

## ОСОБЕННОСТИ ЛИТЕРАТУРНОГО ПЕРЕВОДА ПРОИЗВЕДЕНИЙ Ч. АЙТМАТОВА НА ТАТАРСКИЙ ЯЗЫК

**Аннотация.** В статье определены особенности перевода произведений Ч. Айтматова на татарский язык. Также на примере произведений рассмотрены общие черты киргизской и татарской литературы. Особое внимание уделено на двуязычное творчество Ч.Айтматова. Сделаны выводы о качестве переводных произведений. Показана глобальная важность переводов произведений тюркских языков.

**Abstract.** The article defines the features of translation of C. Aitmatov's works into the Tatar language. Also, the common features of Kyrgyz and Tatar literature are considered on the example of works. Special attention is paid to the bilingual creativity of C. Aitmatov. Conclusions are drawn about the quality of translated works. The global importance of translations of works of Turkic languages is shown.

**Ключевые слова:** перевод, советский классик, киргизская литература, проза, литература.

**Keywords:** translation, Soviet classic, Kyrgyz literature, prose, literature.

Соңгы бер гасырдан аз гына артык вакыт эчендә төрки сүз сәнгате барлык юнәлешләрдә һәм жанрларда гаять зур уңышлар казана, дөнья әдәбиятлары арасында лаеклы алдынгы урынын алды. Һәм бу һич тә очраклы түгел. Төрки әдәбиятларның болай югары күтәрелүе бихисап талантлы әдипләрнең армый-талмый иҗади эшчәнлек алып барулары сәбәпле мөмкин булды. Төрки телле әдипләр арасында бигрәк тә атаклы кыргыз язучысы Чыңгыз Айтматов аерылып тора.

Ч. Айтматовның интеллектуаль, тирән фәлсәфи мәгънәләргә бай, аһәңле прозасыннан башка бүгенге көн дөнья әдәбияты, мәдәниятен күз алдына китерү мөмкин түгел. Аның һәр иҗат иткән әсәре сүз сәнгатендә генә түгел, ә иҗтимагый-сәяси, әхлакый-фәлсәфи тормышта да күренекле вакыйга булып торган [Миңнуллин, 2018: 65]

Чыңгыз Айтматов, нигездә рус телендә язуына карамастан, чын мәгънәсендә милли, кыргыз язучысы. Әдип үзе дә һәрвакытта тамырларын, килеп чыгышын

онытмаган. Әдип күңеленең чагылышы буларак, Айтматов иҗатында кыргыз теле, милли күзаллавы, халыкның йолалары, гореф-гадәтләре зур урын алып тора.

Ч. Айтматов – милли язучы. Ул әсәрләрендә милләт тормышының күп якларын яктыртып кына калмый, иҗатының әдәби кыйммәте югары булуы сәбәпле, яулап алган дөнья әдәбияты мәйданын җәмәгатьчелекне кыргыз халкының кыйммәтләре, тарихы, көнкүреше, бай традицияләре белән таныштыру өчен файдалана. Гомумкешелек кыйммәтләрен, яшәешкә карашларын Айтматов шәхси, милли сурәтләр аша яктырта алган.

Чыңгыз Айтматов безгә данлы төрки эпосның, төрки мифологиянең мәңгелеген, табигать белән гармониядә яшәү зарурлыгы хакындагы әхлакый кануннарны чагылдырган Найман-Ана, Ак бүре яки кола бия Гөлсарыны бүген дә хәтердә яңарта, рухи ныклыгыбыз һәм безгә кадәрге буыннар нигезләгән кыйммәтләребез һәм традицияләребез сагында тора. Ч.Айтматов тарафыннан тудырылган дөнья сурәте татарларга үзләренең хайваннар дөньясы белән бердәмлектә яшәгән дәверләрен хәтерләтә. Мәсәлән «Бәхил бул, Гөлсары» повестенда Танабай Бакасов белән аның юргасы Гөлсары, «Гасырдан да озын көн» романында Идегәй Жангельдин белән Каранар-дөя, «Ахырзаман» да Авдий белән Акбар образлары аша кеше белән хайван арасында параллельлекләр уздырып, язучы кешенең асылы, аның психологиясе, киләчәк язмышы турында уйланырга мәҗбүр итә. «Ахырзаман», «Гасырдан да озын көн» әсәрләрендә кеше гармонияле һәм бербөтен табигый дөньяга, гомумән галәмгә каршы баручы җимергеч көч итеп тасвирлана. Ч. Айтматовның фикер һәм концепцияләрен, кичерешләрен без күңелебезгә якын кабул итәбез, алар безнең уй-карашларыбызга аваздаш. Шул ук вакытта аның күп кенә мотивлары татар әдәбиятына, бигрәк тә тарихи ядкарьләребез проблемасына кагылган әсәрләргә, аеруча якын тора. [Хабутдинова, 2013: 270]

Чыңгыз Айтматов иҗаты өчен хас булган, аны сыйфатлы, төпле иҗат итеп таныткан барлык үзенчәлекләр (актив гражданлык карашлары, художестволык, фәлсәфи тирәнлек, заманның иң катлаулы мәсьәләләрен яктырту, гади кеше һәм дөнья арасындагы диалектик бәйләнешләр) аның кыргызча язган (нигездә алар әдипнең башлангыч чоры иҗатына карыйлар) әсәрләрендә үк чагылыш табалар.

Гәрчә Ч.Айтматовның русча язылган әсәрләре күбрәк танылу алган, киңрәк таралган булса да, кыргыз телендә иҗат ителгәннәре бөтенләй игътибарсыз кала дигән сүз түгел. Алар шулай ук дөньяның төрле телләренә тәрҗемә ителгәннәр.

Совет чорында әдәби тәрҗемә яңа үрләр яулый. Бер яктан бу яңа туган илдә бер-берсеннән нык аерылып торган халыкларның күплеге, төрлелеге белән аңлатылса, икенче яктан хакимиятнең әлеге этнослар традицияләрен Совет казанына салып, бердәм совет әдәбиятын калыплаштыру теләге белән нигезләнгән.

Ч. Айтматовның кыргызча язылган әсәрләренең татар теленә тәрҗемә ителү үзенчәлекләрен билгеләү өчен 2018 елда туплап чыгарылган «Сайланма әсәрләр»дәге әсәрләр версиясеннән (әлеге җыентыкта әдипнең биш повесте һәм бер романы урын алган. “Бер көн – бер гомер” (“И дольше века длится день”) романын Рим Шириязданов, “Дөя күзе” (“Верблюжий глаз”), “Анам кыры” (“Материнское поле”) һәм “Бәхил бул, Гөлсары” (“Прощай, Гульсары”) повестьларын Яхъя Халитов, “Җәмилә” (“Джамиля”) повестен Миркасыйм Госманов һәм “Чыңгызханның ак болыты” (“Белое облако Чингисхана”, татар телендә беренче тапкыр бирелә) повестен Мөдәррис Вәлиев тәрҗемә иткән), ә Ч.Айтматовның «Кызыл яулыклы тирәгем минем» әсәренең татарның талантлы язучысы Хәсән Сарьян тәрҗемә кылган «Гүзәлем Әсәл» әсәре текстлары кулланылды.

Тәрҗемәләрнең сыйфатлары төрле, әмма тәрҗемәчеләрнең берсе дә турыдан-туры тәрҗемә белән шөгыльләнми, иҗади якын килергә тырыша. Әйтик, М. Госманов кыргыз телендәге чыганак тексттан файдалануына да карамастан, әсәрне татар җирлеге, татар мәдәнияте, татар укучысы өчен адаптацияли, яраклаштыра. Яхъя Халитов тәрҗемәсе шактый каршылыклы фикердә калдыра. Бер яктан, ул чыганакка саклык белән карый, язучы үзенчәлекләрен мөмкин кадәр тулы калдырырга тырыша (“Саманчы юлы” – тәрҗемәченең уңышы), икенче яктан аерым бер моментларда турыдан-туры тәрҗемә итәргә тырышу урынсыз дип бәяләнергә мөмкин күренешләргә китерә (текст белән ирекле эш итү, әсәрнең исемен тәрҗемә иткәндә үзенчәлекле карар).

Шулай булуга да карамастан, бер өлеш тәрҗемәләрдә чәчмә әсәрләрнең структур-композицион элементлары сакланып калган, эчтәлекләре дә сизелерлек үзгәрмәгән. Әйтик, Р.Ширияздaнов (“Бер көн – бер гомер” (“И дольше века длится день”)), Я.Халитов башкарган тәрҗемәнең кайбер мисаллары (“Бәхил бул, Гөлсары” (“Прощай, Гульсары”)) – шундыйлардан.

Әмма киресенчә очраклар да бар – идея-мәгънәви яктан оригиналны үзгәрткән тәрҗемәләр дә байтак. Әйтик, М.Госманов текстка шактый ирекле мөнәсәбәттә – композицион үзенчәлекләр, лексик берәмлекләрне турыдан-туры эквивалентлары белән тәрҗемә итмәү күзгә ташлана. Мөдәррис Вәлиев исә әсәр композициясен (“Белое облако Чингисхана”) бөтенләй үзгәртә, русча вариантта булмаган күп өлешләрне кертә.

Кыргыз телендәге сүзләр белән тәрҗемәчеләр төрлечә эш итә. Аерым берләре тулысынча татар теле чаралары белән белдерелеп килсә, башкалары чыганак телдәге калдырылган. Әйтик, М.Госманов “Җәмилә”нең тәрҗемәсендә аларны кулланмый диярлек. Ялгызлык исемнәренең нигездә кыргыз телендәгечә вариантлары кулланылган – бу тәрҗемә әсәрләренең аһәңлеген саклап калып, аутентиклыгын, кыйммәтен арттыра (Мөдәррис Вәлиев, Рим Ширияздaнов башкаруындагы тәрҗемәләрдә). Шунысы да бар кыргыз исемнәрен фонетик яктан татарчалаштырып, төркиләштереп тәкъдим итү отышлырак та, чөнки алар – төрки нигезле сүзләр, һәм русчалаштырылган рәвешләрендә мәгънәви асылын, матурлыгын югалталар.

Мифологик катлаулар әсәрләрдә бик зур әһәмияткә ия. “Чыңгызханның ак болыты”, “Бәхил бул, Гөлсары!”, “Анам кыры” – шундыйлардан. Әсәрнең исеменнән башлап, сюжет сызыгы, мәгънәви катламына кадәр мифологик детальләргә бай, мифларга корылган. Мифлар нигездә үзгәрешсез сакланып калган.

Гомумән алганда, татарча тәрҗемәләр күп очракта рус вариантларына караганда отышлырак, чөнки татар һәм кыргыз телләре якынлыгы тәрҗемәне җайлыландыра, күп лексик формаларны отышлырак вариантта бирергә мөмкинлек бирә.

Тәрҗемәләрнең глобаль һәм төп проблемасы – кыргызча язылган әсәрләрнең исемнәрен тәрҗемә итү. Бик сирәк очракларда гына әсәр исемнәре метафорик байлылыгын, тирән символик мәгънәләрен югалтмыйча күчкәннәр. Исемнәре уңышлы тәрҗемә ителгән әсәрләр арасында “Кыямәт”, “Бәхил бул, Гөлсары!” кебекләрне күрсәтергә мөмкин. Исемен тәрҗемә иткәндә автор күздә тоткан тирән мәгънә югалу очраклары күпкә күбрәк: “Гүзәлем Әсәл”, “Анам кыры”, “Дөя күзе” һ.б.

Татар укучысына бөтенләй аңлашылмаган төшенчәләрне кайбер тәрҗемәчеләр астөшермәләр ярдәмендә аңлатып төшендерә.

Ч.Айтматов шәхесе өчен кыргыз һәм татар әдәбияты, мәдәнияте генә түгел, совет әдәбияты кысалары да “тар”. Ул – дөньякүләм масштабтагы әдип. Моңа ачык дәлил – аның әсәрләре дөньяның йөзләрчә телләренә тәрҗемә ителгән булуы.

**ӘДӘБИЯТ**

Миңнуллин К.М. XX гасырның икенче яртысы татар әдәбиятын өйрәнү контекстында Чыңгыз Айтматов иҗаты // Фәнни Татарстан, 2018. № 4. – Б.79-82.

Сәйфулина Ф.С. Чыңгыз Айтматов иҗатының татар теленә тәрҗемәләре // Туган телләрне һәм әдәбиятларны саклау һәм үстерү Халыкара фәнни-гамәли форумы кысаларында уздырылган конференция материаллары. Казан, 2010. – Б. 126-131.

Хабутдинова М.М. Личность и творчество Чингиза Айтматова в оценке татарского писателя Аяза Гилязова // Филология и культура. Philology And Culture, 2013. №2 (32). – Б. 270-276.

**А.Д. БАТТАЛОВА**
Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясе, Казан

## ЧИСТАЙ ТӨБӘГЕН ӨЙРӘНҮДӘ ЯҢА ЧЫГАНАК БУЛАРАК С.Е. МАЛОВ ИҖАТЫ

**А.Д. БАТТАЛОВА**
Академия наук Республики Татарстан, Казань

## ТВОРЧЕСТВО С.Е. МАЛОВА КАК НОВЫЙ ИСТОЧНИК В ИЗУЧЕНИИ ЧИСТОПОЛЬСКОГО КРАЯ

**Аннотация.** В статье работа С.Е. Малова «Изъ поездки къ мишарям», опубликованная в 1904 году, рассматривается как фольклорный источник.

**Annotation.** In the article, the work of S. E. Malov "Two trips to the Mishars", published in 1904, is considered as a folklore source.

**Ключевые слова.** Чистополь, фольклор, жанр, песня, загадка, пословица.

**Keywords.** Chistopol, folklore, genre, song, riddle, proverb.

Чистай төбәге – гуманитар фәннәр өлкәсендә эзләнүләр алып бару өчен шактый кызыклы төбәкләрнең берсе. Ул тарихчыларны, археологларны, антропологларны, социологларны, тел галимнәрен, әдәбият белгечләрен әле дә булса үзенә тартып тора. Моның сәбәпләрен төбәкнең географик яктан үзенчәлекле урында булуына нисбәтле бик борынгы заманнардан бирле төрле кавемнәрнең үзара кисешеп, аралашып яшәүләрендә күрергә кирәктер.

Бүгенге мәкаләдә без игътибарны әлеге төбәкне XX гасыр башында өйрәнүчеләрнең берсе – Сергей Ефимович Малов иҗатына юнәлтербез. Мәгълүм булганча, Сергей Ефимович Малов - күренекле галим-тюрколог, шәрык белгече, дистәдән артык күләмле китап, йөздән артык мәкалә авторы. Аның хезмәтләре Себер һәм Идел буе, Үзәк һәм Көнбатыш Кытай, Монголия, Урта Азия һәм Казакъстан җирләрендә яшәүче төрки халыкларның телен, фольклорын, тарихын һәм этнографиясен тикшерүгә багышланганнар. Шулар арасында Чистай төбәгендә яшәүче милләтәшләребезнең XX гасыр башына хас сөйләм үрнәкләрен, халык иҗаты әсәрләрен туплаган, бүгенге көндә дә актуальлеген югалтмаган җыентык та бар. Тюркологлар өчен С.Е. Малов төрки телләрнең фәнни тасвирламаларын беренче тапкыр тәкъдим

итүче буларак билгеле, чөнки ул күп кенә борынгы төрки язма истәлекләрен тикшереп фәнни әйләнешкә керткән шәхес. Шунлыктан аның эшчәнлеген бәяләгәндә төп игътибар тюрколог һәм шәрык белгече булуына [И.В. Кормушин, Д.М. Насилов, 1978; С.Д.Милибанд, 1995; Е.И. Убрятова, 1970] бирелә. Кайбер галимнәр исә, мәсәлән, С.М. Абрамзон [Абрамзон С.М., 1975: 12-25] аны төрки халыкларның этнографиясен өйрәнүче буларак та танылар.

С.Е. Малов төрки халыклар теле, этнографиясе белгече буларак очраклы рәвештә формалашмый. Ул 1880 елның 16 гыйнварында Казанда протоиерея дигән мактаулы исеме булган, Казан руханилар академиясе профессоры Евфимия Александрович Малов гаиләсендә туа. Төрки телләрне шактый белгән Евфимия Александрович улына үзе үк төрки телләр дәресләре бирә башлый. Күрәсең, ул улын татар теле, этнография кафедрасына һәм «алар арасында христиан мәгърифәте» кафедрасына әзерләүне максат итеп куйган булса кирәк. Шулай итеп С.Е.Малов 5 нче класстан алып (ягъни 1898 елдан), 1900-1904 елларда белем алган югары рухи уку йорты – Дини академиядә белем алу дәверләрендә татар телен өйрәнүен дәвам итә һәм Академиядә укуының соңгы ике елында Император университеты профессоры Н.Ф. Катанов лекцияләрен тыңлый, әтисе белән Казан университеты каршында оешкан Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте утырышларында даими катнаша. Җәйге каникуллары вакытында С.Е. Малов Казан губернасының Зөя һәм Чистай өязләренә мишәрләр сөйләшен өйрәнү максатларыннан сәфәргә чыга [И.В. Кормушин, Д.М. Насилов, 1978: 5]. Сәфәр нәтиҗәсе буларак ул “Изъ поездки къ мишарямъ” дигән җыентык әзерләп бастыра. Әлеге мәкаләдә без шушы җыентыкка тукталып, анда урын алган XX гасыр башында Чистай өязендә яшәгән мишәрләргә хас фольклор үрнәкләре турында сүз йөртербез. С.Е. Малов җыентыгының сүз башында, В.А.Казаринов һәм профессор Е.А. Маловның мишәрләр турындагы мәкаләләреннән соң бу як мишәрләре белән кызыксынуы артуын һәм мишәр сөйләше белән якыннанрак танышу максатыннан Чистай өязе авылларына баруын аңлата. Җыентыкта бирелгән мәгълүматта гыйлъми сәфәрнең 1902 нче елның 5-14 нче июнь аралыгында оештырылуы һәм галимнең Каргалы һәм Дүртөйле авылларында тукталуы турында әйтелә [С.Е. Малов, 1904: 3]. Автор Чистай мишәрләре сөйләшенең фонетик үзенчәлекләрен санап үткәннән соң, үзе туплаган фольклор үрнәкләрен дә китерә. Тупланмада 20 кыска җыр тексты (аларны автор мишәр җырлары дип атый) һәм аларның рус теленә тәрҗемәсе китерелә. Әлеге җыр текстларын фольклорчы М.Х. Бакиров бүленешенә таянып [Бакиров, 2008: 160] классификацияләсәк, аларның барысын да лирик һәм көнкүреш җырлары дип атый алабыз. Бер төркеме– мәхәббәт җырлары:

*Тубылгы урман зур булмас,*
*Аның уртасында юл булмас;*
*Кашың да кара, буең зифа,*
*Сине сөйгән җегет хур булмас* [С.Е. Малов, 1904: 10].
*Урам буйлап син киләсең*
*Аягыңда Казан калушы;*
*Тауышың былбыл тауышы,*
*Зифа буйың диңгез камышы* [С.Е. Малов, 1904: 12].
*Өстәл өстендә шәм яна,*
*Тармак-тармак май тама;*
*Сиксән керпек ука бөртек*

*Нурлы йөзеңне яба* [С.Е. Малов, 1904: 12].

Бу типтагы җырларда хатын-кызның матурлыгы, чибәрлеге, яшьлеге макталса, бер төркемендә егетләрнең булганлыгы, егетлегенә дан җырлана.

*Абзый синең мыегың –*
*Сәмрух кош канаты;*
*Синең кебек булса булыр*
*Патшаның санаты* [С.Е. Малов, 1904: 13].
*Биек тауның башында*
*Күренәдер бер авыл;*
*Ике егет бергә булгач*
*Дөнья җиңел узадыр* [С.Е. Малов, 1904: 13].

Бер төркем җырларда егет белән кызның пар килүе, бер-берсенә тиң булуы турында сүз бара, нәселнең дәрәҗәсе, заты югалмауга сөенү хисләре чагыла. Текст эчтәлегенә, алардагы мөрәҗәгать объектына бәйле сүз йөртсәк, аларны туй йоласы җырлары дип тә атап була.

*Ак  Иделгә сал килгән*
*Чыгар башы тар килгән;*
*Казанда түгел Мәскәүдә юк*
*Сезнең кебек пар килгән* [С.Е. Малов, 1904: 14].
*Ике дә була атыбыз,*
*Өч тә була атыбыз;*
*Сезнең белән бергә булгач,*
*Югалмыйдыр затыбыз* [С.Е. Малов, 1904: 13].

Җыентыкта беркадәр урынны мәкаль әйтемнәр дә алып тора. Фольклор галиме М.Х. Бакиров халык иҗатының үзенчәлекле жанры мәкаль әйтемнәр турында: “халыкның менталитеты, этник характеры һәм этник аңы аның культурасында да чагылыш таба. Шул исәптән тел һәм образлы-хикмәтле сүз берәмлекләре булган мәкаль-әйтемнәр дә культура билгеләре яки кодлары буларак характерланалар. Чөнки алар, милләтара һәм гомумкешелек кыйммәтләрен саклау һәм тапшыру чарасы булу белән беррәттән, аерым бер халыкның яшәү рәвешен, милли рухын һәм этник культурасын теге яки бу дәрәҗәдә чагылдыручы калыплашкан модель-берәмлекләр дә”, ди [Бакиров, 2008: 95]. Әлеге афористик жанр әсәрләрен М.Х. Бакиров фикерләренә таянып күзәтсәк, алар аркылы XX гасыр башына хас татар тормышын, үзара мөнәсәбәтләрне беркадәр бәяләргә була. Мәсәлән,*“Бирмәсә дә бай яхшы, ашамасаң да май яхшы”, “Байның бозавы, ярлының баласы”* [С.Е. Малов, 1904: 16]. Күренгәнчә, биредә халык арасында яшәп килгән социаль тигезсезлеккә мөнәсәбәт белдерелә. Бер ишләрендә халык акылында формалашкан яшәү тәртипләре урын алган. Мәсәлән, *“Яхшы сүз җан азыгы, яман сүз баш казыгы”, Яхшы белән йөрерсең, җитәрсең муратка, яман белән йөрерсең, калырсың оятка”* [С.Е. Малов, 1904: 16]. Композицион яктан бәяләсәкалар,башлыча, ике объектның яки күренешнең янәшә бирелүенә нигезләнгәннәр. Шул ук вакытта күренеш яисә сыйфатларның үзара капма-каршы куелуына корылганнары да бар.

Югарыда атап үтелгән җыентыкта табышмаклар да теркәлгән. Төзелешләренә нисбәтле сүз йөртсәк, алар нигездә метафорик табышмаклар: *“Кечкенә генә бөкере, бөтен кырны бетерде” (урак), “Кечкенә үзе, мең күзе” (уймак), “Сары бия чаптырып сия”(самовар)* [С.Е. Малов, 1904:18]. Әлбәттә, әлеге әсәрләрдән дә XX гасыр башында

Чистай өязендә яшәгән татарларның теле белән беррәттән көнкүрешләрен дә шактый чамалап була. Шуңа күрә С.Е. Маловның 1904 нче елда Казан университеты типографиясендә басылып чыккан «Изъ поездки къ мишарям» җыентыгында теркәлгән фольклор үрнәкләрен әлеге төбәктә яшәүчеләрнең дөньяга карашын, яшәү рәвешен, рухи кичерешләрен бәяләүдә хаклы рәвештә мөһим бер чыганак буларак бәяли алабыз.

## ӘДӘБИЯТ


Абрамзон С.М. Этнографические исследования С.Е. Малова // Тюркологический сборник 1975. М.: Наука (ГРВЛ), 1978. – С. 12-25.

Бакиров М.Х. Татар фольклоры югары уку йортлары өчен дәреслек. Казан: Мәгариф, 2008. – 359 б.

Кормушин И.В., Насилов Д.М. О жизни и творчестве С.Е. Малова // Тюркологический сборник. 1975. М., 1978.

Малов С.Е. «Изъ поездки къ мишарям» (О наречии мишарей Чистопольского уезда). Казань: Типо-литография Императорского Университета, 1904. – 24 с.

Милибанд С.Д. Биобиблиографический словарь отечественных востоковедов с 1917 г. М., 1995.

Убрятова Е.И. С.Е. Малов – крупнейший исследователь тюркских языков // Календарь знаменательных и памятных дат на 1970 г. Якутск, 1970.



**А.Ә. БӘДРТДИНОВА**
Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясе
Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Казан


## ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ МИНЗӘЛӘ СӨЙЛӘШЕНДӘ [А] АВАЗЫНЫҢ ФАРИНГАЛИЗАЦИЯСЕ


**А.А. БАДРТДИНОВА**
Институт языка, литературы и искусства им. Г.Ибрагимова
Академии наук Республики Татарстан, Казань


## ФАРИНГАЛИЗАЦИЯ ЗВУКА [А] В МИНЗЕЛИНСКОМ ГОВОРЕ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА


**Аннотация.** При изучении мензелинского говора среднего диалекта татарского языка инструментами программ Audacity, Speech Analyzer у нас появился фарингализованный звук [ɑˤ]. Фарингализация гласных в среднем диалекте татарского языка еще не была описана и изучена. Фарингализованный звук [ɑˤ] в мензелинском говоре среднего диалекта татарского языка не является самостоятельной фонемой, является аллофоном звука [а].

**Abstract.** When studying the Menzelin dialect of the middle dialect of the Tatar language with the tools of the Audacity and Speech Analyzer programs, we have a pharyngealized sound [ɑˤ] with the instrumental methods of dialect. Pharyngalization of vowels in the middle dialect of the Tatar language has not yet been described and studied. The pharyngealized sound [ɑˤ] in the Menzelin dialect of the middle dialect of the Tatar language is not an independent phoneme, it is an allophone of the sound [a].



**Ключевые слова:** татарский язык, средний диалект, мензелинский говор, фонема, аллофон, фарингализация.

**Keywords:** Tatar language, the middle dialect, Menzelinsky dialect, the phoneme, allophone, pharyngealization.

Телнең фонетикасын инструменталь ысуллар кулланып өйрәнү бүгенге көндә актуаль юнәлешләрнең берсе булып тора.

Эксперименталь фонетика – тел белеменең мөһим тармагы. Бер үк фонеманың комбинатор-позицион шартларга бәйле берничә варианты булырга, авазлар чиратлашырга яки редукцияләнергә мөмкин. Авазларны артикуляцион һәм акустик яктан хәзерге заман методлары (УЗИ, МРТ, компьютер) белән өйрәнү фонетистларның бурычы булып тора.

Татар телендә эксперименталь тикшеренүләр алып барган галимнәр күп түгел: Ш.Н. Асылгараев, У.Ш. Байчура, М.Х. Бакиров, Р.М. Балтаева, В. Богородицкий, Т.И. Ибраһимов, М.Р. Сәйхунов, Х.Х. Сәлимов, Җ.Ш. Сөләйманов, Г.М. Сөнгатов, Г.Ш. Шәрәф һ.б.

Г.Т. Гобәйдуллина татар тел гыйлемендә эксперименталь фонетиканың тарихы, үсеше буенча диссертация яклый. Ул үзенең гыйльми эшендә фәнни хезмәтләрне системалаштыра, хронологик этапларга бүлә. Г.Т. Гобәйдуллина хезмәте – татар теле гыйлеменең эксперименталь фонетика юнәлешендә кыйммәтле материал һәм хезмәт булып тора.

Без Азнакай районы авылларында яздырып кайткан записьләрне Audacity программасында кисеп, Speech Analyzer программасында тикшердек. Азнакай районында күбесенчә урта диалектның минзәлә сөйләшендә аралашалар.

Әлеге тикшерүнеләр вакытында бәхәсле һәм кызыклы күренешләргә очрадык. Шуларның берсе [а] авазының фарингализациясе.

Фарингализация – йоткылык резонаторының өстәмә рәвештә эшләве, соматик билгеләре: телнең тамыры артка тартылган вакытта йоткылыкның кысылып, фаринксның арткы стенасы телнең тамырына таба тартылуыһәм ларинксның төшүе [Селютина, 2008: 35].

Фарингализация – артикуляцион аппаратның көчәнүе аркасында фаринксның арткы стенасына һаваның көчле ышкылуы һәм фаринксның кысылуы [Щербак, 1970: 42].

Фарингализация – йоткылык стеналарының өстәмә рәвештә кысылуы [Словарь лингвистических т-в, 2016: 191].

Фарингаль сузыклар тува телендә [Байыр-оол], тофалар (карагас) телләрендә [Щербак, 1970: 42], шор телендә [Уртегешев, 2012: 41], хант теленең сургут диалектында [Кошкарева, Уртегешев, 2017: 1], башкорт телендә [Хисәметдинова, 1986: 46] очрый.

Татар теленең урта диалекты минзәлә сөйләшендәге фарингаль авазга мисаллар түбәндәге рәсемнәрдә бирелә: [xɑˤβˤɐˤr̥ˤθɣʷʷɣʰθʰ] (хәбәрсез) (1 рәс.), [ɦǯʲiwʷɜrɐɐˤˤlɣʰʰ] (җибәр әле) (2 рәс.), [ʔʌʷˤˤndʌˤw̥ˤɔˤʌˤʷʒ̥ʃtʰʌˤʌʰ] (анда аш та) (3 рәс.), [oɦolʲˤʷɑˤv̌ʷθ̥θɣjnɑɑˤˤɑʰ] 'ул абзыйны' (4 рәс.), [sɔʁ̥ʷɔʃtʌˤʌʡʡnɯʷðteʷɛʷɛʷʰ] 'сугышта нитте' (5 рәс.)



*1рәс. хәбәрсез*



*2рәс. җибәр әле*



*3рәс. анда аш та*



*4рәс. ул абзыйны*




*5 рәс. сугышта нитте*

Спектограммаларда күренгәнчә монда [а] авазының ике вариантында фарингализация күзәтелә: [ʌˤ] - уртача ачык, [ɑˤ] – ачык авазлар.

Башкорт телендәге фарингализация турында Ф.Г. Хисаметдинова болай яза: фарингаль [ɑˤ] аллофон характерында һәм [q], [ɣ] авазлары әйтелеше белән бәйле [Хисаметдинова, 1986: 46-47]. Татар телендә дә аллофон рәвешендә очрый, кавказ һәм семит телләрендәге кебек мәгънә аермый, омофоннар [Хакимзянов, 2009: 82] юк. Татар телендә авазларның фарингализациясе ирекле, күрше авазларның әйтелешеннән тормый, төрле иҗектә очрый. Бәлки артикуляцион аппаратның үзенчәлегенә: [а°] авазын әйткәндә иреннәр түгәрәкләнә [Сагдеева, Хусайнова, Бадртдинова, 2018: 78] һәм шуңа өстәп фаринкс та кысыла; басым яки интонациягә бәйле булырга мөмкин. Моның өчен тикшеренуләрне дәвам итәргә кирәк.

Фарингаль сузыклар – катлаулы күренеш. Фарингализация килеп чыгышы, тон, озынлык һәм регистр буенча классификацияләнергә мөмкин.

Шулай итеп, эксперименталь ысуллар куллану татар тел гыйлемендә фәнни эзләнү һәм тикшеренүләргә яңа мөмкинлекләр ача. Эксперименталь методлар куллану бүгенге көндә авазлар өйрәнгәндә мөһим шартларның берсе [Хөсәинова, 2018: 248].

Автор мәкалә азагында информантларга: Хәкимова Мәгыйдә Ибраһим кызына – 1936 нчы елгы, Азнакай районы, Мөслим авылы; Шакирова Җәмилә Хәким кызына – 1929 нчы елгы, Азнакай районы, Сәпәй авылы рәхмәтен белдерә.

## ӘДӘБИЯТ

Байыр-оол А.В. Тувинская фарингализация под рентгеновскими лучами. [Электрон чыганак] // Керү режимы: https://www.tuva.asia/journal/issue_24/7573-bayyr-ool.html. (мөрәҗәгать итү вакыты: 02.02.2019).

Губайдуллина Г.Т. Татарская экспериментальная фонетика: истоки и этапы её развития: автореф. ...канд. филол. наук: 10.02.02. – Казан, 2011. – 27 с.

Кошкарева Н.Б., Уртегешев Н.С. Система кратких гласных звуков первого слога в сургутском диалекте хантыйского языка // Вестник угроведения, 2017. №4. Т. 7. – С. 1-16.

Русско-татарский толковый словарь лингвистических терминов / под ред. Ф.И. Тагировой, Ф.Ф. Гаффаровой. Казань: ИЯЛИ, 2016. – 248 с.

Сагдеева Ф.К., Хусайнова А.Я., Бадртдинова А.А.Фонетическая интерференция в условиях двуязычия (на примере гласных) // Казанская наука, 2018. № 3. – С. 77-79.

Селютина И.Я. Введение в общую фонетику. – Новосибирск: Изд-во Новосибирского национального исследовательского государственного ун-та, 2008. – 66 с.

Уртегешев Н.С. Шорский язык: фарингализация гласных. – Материалы Международной научной конференции. Тюрко-монгольские народы Центральной Азии: язык, этническая история и фольклор (к 100-летию со дня рождения В.М. Наделяева). Кызыл: 2012 – С. 41-43.

Хакимзянов Ф.С. Изучение омонимии в татарском языкознании // Российская тюркология, 2009. № 1 (1). – С. 75-83.

Хисамутдинова Ф.Г. О фарингализованном заднеязычном гласном а в башкирском языке. – Фонетика языков Сибири и сопредельных регионов. Новосибирск: Наука. Сиб. отд.-е, 1986. – С. 46-49.

Хусаинова А.Я. Изучение консонантизма в татарской диалектологии – Научное наследие В.А. Богородицкого и современный вектор исследований Казанской лингвистической школы. Труды и материалы международной конференции. / Под общей редакцией К.Р. Галиуллина, Е.А. Горобец, Э.А. Исламовой. Казань: 2018. – С. 246-249.

Щербак А.М.Сравнительная фонетика тюркских языков. Л.: Наука. Ленингр. отд-ние, 1970 – Ч. 1. – 1970. – 206 с.

**М.Д. БЕКБЕРГЕНОВА**
Әжинияз атындағы Нөкис мәмлекетлик педагогикалық институты, Нөкис

## XX ӘСИР ҚАРАҚАЛПАҚ ПРОЗАСЫНДА ТИПОЛОГИЯ МӘСЕЛЕЛЕРИ

**М.Д. БЕКБЕРГЕНОВА**
Нукусский государственный педагогический институт им. Ажинияза, Нукус

## ВОПРОСЫ ТИПОЛОГИИ В КАРАКАЛПАКСКОЙ ПРОЗЕ XX ВЕКА

**Аннотация.** В данной статье рассматриваются вопросы типологии в каракалпакской прозе XX века. Изучаются рассказы, повести и романы ведущего прозаика Т.Кайыпбергенова. В историко – сравнительном аспекте изучается типологические связи эпического жанра каракалпакской прозы XX века. В частности, рассматриваются типологические связи произведений С. Мажитова, Т. Кайыпбергенова, Г.Есемуратовой, Ш.Сейтова.

**Abstract. T**his article examines the issues of typology in the Karakalpak prose of the 20th century. The stories, novellas and novels of the leading prose writer T.Kayipbergenov are studied. In the historical - comparative aspect, the typological connections of the epic genre of the Karakalpak prose of the 20th century are studied. In particular, the typological connections of the works of S. Mazhitov, T. Kaypbergenov, G. Esemuratova, Sh. Seitov are considered.

**Ключевые слова:** типология, рассказ, повесть, роман, басня, эпос, жанр.

**Keywords:** typology, story, story, novel, fable, epic, genre.

Өзбекстан Қаҳарманы, Өзбекстан ҳәм Қарақалпақстан халық жазыўшысы Т. Қайыпбергенов XX әсир қарақалпақ әдебиятында жетекши жазыўшы, қарақалпақ прозасын тереңлестирип, кеңейтип раўажландырған, эпикалық жанрдың ҳәр қыйлы формаларын дөреткен көркем сөз шебери. Жазыўшының қарақалпақ прозасында ең дәслепки адымы болып есапланған 1961-жылы баспадан шыққан «Блокнот сөйлейди» гүрриңлер топламы. Бул топламға «Алжасықтың ақыры», «Арза», «Тракторшы»,

«Жолдағы жәнжел», «Исиң сөзиңдей емес» ҳ.т.б. гүрриңлери киреди. [Қайыпбергенов, 1980: 5 том]

Жазыўшы ана әдебиятының миллий дәстүрлериниң тийкарында өз шығармаларын дөретеди. Қарақалпақ халқының ерте дәўирлерден баслап пайда болып қәлиплескен, раўажланған халық аўызеки дөретиўшилигинде эпикалық баянлаўшы жанр қәлиплесип келген. Олар жырлар, толғаўлар, әпсаналар, рәўиятлар, ертеклер, дәстанлар миллий жазба әдебиятының эпикалық жанрының раўажланыўына тийкар салды.

«Тарийхый-әдебий мәнисинде эпос деп халық поэмаларын ҳәм ертеклерин атайды. Теориялық мәнисинде эпос деген бул жанр, оның тийкарғы белгиси адам характерлериниң кең түрде ашылып сүўретлениўи»,-деп белгилейди әдебиятшы алым Л.И.Тимофеев. [Тимофеев, 1971: 357]

Эпикалық жанрдың тарийхый-әдебий раўажланыў жолы жәҳән әдебияты тарийхында аты белгили Эзоптың тымсалларынан басланады. Оның тымсалларының көпшилиги тәрбиялық әҳмийетке ийе. Мәселен, Эзоптың «Ҳайўанлар ҳәм чума» атлы тымсалы белгили. Бул тымсалда үлкен жаўызлықлар мойынланбай, кишкене қылмысы ушын ешектиң жазаға тартылғаны сөз етиледи. [Все знаменитые сказки народов мира, 2014: 472]

Көркем әдебиятта инсан характериниң ашылыўы турмыс жөнелисиниң сүўретлениў типлерине қарай үш формаға бөлинеди. Олар: киши, орта ҳәм үлкен форма деп бөлинеди. Булар: гүрриң, повесть, роман. Жанрлық формалардың пайда болыўы ҳәм қәлиплесиўиниң өз алдына тарийхы ҳәм классификациялық белгилери бар. Эпостың тийкарғы белгиси: ол баянлаўшы жанр. Адамның өмирлик жолы, оның ис-ҳәрекетлери, ишки кеширмелери, жәмийетте жасайтуғын басқа адамлар менен қарым-қатнасы, ол қатнасқан ўақыялар баян етиледи. Баянлаўшы жанрдың дәстүри аўызеки әдебиятта пайда болған. Қарақалпақ халқының тарийхый жырларында, әпсана-аңызларда, толғаўларда ўақыялар баян етиледи. Көпшилик жағдайда эпикалық жанрдың бул формаларында қаҳарманлық ўақыялар сөз етиледи.

«Толғаўлар қарақалпақ халқының көркем аўызеки дөретпелериниң белгили бир жанры. Толғаўлар түркий халықлардың көркем аўызеки дөретпелеринде өз алдына жанр болып қәлиплескен.» [Мақсетов, 1996: 218]

Көркем әдебияттың раўажланыў тарийхында уқсас жанрлар болады, бирақ ҳәр бир дәўирдиң өзиниң өзгешелиги тийкарында жанрлардың мазмуны ҳәм характери өзгерип барады. XX әсир қарақалпақ әдебиятында проза жанрының пайда болыўына ҳәм қәлиплесиўине үлес қосқан жазыўшы С.Мажитов. Оның «Еки пазна», «Дослық», «Мийрас» ҳ.т.б. гүрриңлеринде әдеп-икрамлық мәселеси, тәрбия темасы сөз етиледи. [Мажитов, 1992: 30]

С.Мажитовтың гүрриңлериндеги тәрбиялық мәселелерди сөз етиў дәстүри Т.Қайыпбергеновтың дәслепки гүрриңлеринде мийраслылық форманың раўажланыў сыпатында көринеди. Мәселен, С.Мажитовтың «Мийрас» гүрриңинде бир үйдиң еки улы ҳаққында сөз етиледи. Үлкен баласы әкесинен қалған байлыққа исенип қалады. Генже баласы әке мийрасынан үмит етпей, өз мийнети менен турмыстан орын алады. Бул гүрриңдеги тийкарғы идея мийнет пенен өмирде өз бахтына ерисиў.

Т.Қайыпбергеновтың «Исиң сөзиңдей емес» гүрриңинде Төребай жасы үлкенлерди ҳүрметлеў ҳаққында мектепте класс мәжилисинде дурыс сөйлеген менен, турмыста автобуста болған ўақыяда өзиниң анасына орынды бериўди умытып кетеди [Қайыпбергенов, 1980: 437-440].

Баянлаўшы жанрдың бул киши формасында инсанның өмирлик жолына характерли болған бир эпизод ғана сүўретленген. Ал, баянлаўшы жанрдың орта формасы болып есапланатуғын повесть формасында белгили бир дәўир, инсан өмириниң белгили бир басқышы бир қатар эпизодлар қамтылған ҳалда инсан турмысы сүўретленеди. Көркем шығарма бул жәмийетлик турмыстың раўажланыў барысындағы белгили бир тарийхый мәўритлердиң сүўретлениўи болып табылады. Қарақалпақ прозасы тарийхында повесть эпикалық жанрдың орта формасы сыпатында ХХ әсирдиң 30-жылларындағы М.Дәрибаевтың «Мыңлардың бири» дөретпеси менен басланады. Қарақалпақ повестиның буннан соңғы раўажланыў басқышы ХХ әсирдиң 60-70-жыллары менен белгиленеди. Қарақалпақ әдебиятының белгили жазыўшылары Ж.Аймурзаевтың «Жетимниң жүреги», Ш.Сейтовтың «Қашқын», «Көп еди кеткен тырналар», Т.Қайыпбергеновтың «Секретарь», «Мүғаллимге рахмет», «Сууық тамшы», «Уйқысыз түнлер», С.Баҳадырованың «Ҳаяллар», Г.Есемуратованың «Жийрен» х.т.б. повестлери баянлаўшы жанрдың ҳәр қыйлы түрлерде раўажланыўын тапты. Соның ишинде, жазыўшы Т.Қайыпбергеновтың «Секретарь», «Муғаллимге рахмет», «Сууық тамшы», «Уйқысыз түнлер» повестлери қарақалпақ миллий прозасының тарийхында жаңа әдебий қубылыс болды ҳәм эпикалық баянлаўшы жанрының қарақалпақ әдебияты тарийхында жаңа көркем шығармалардың пайда болыўын белгиледи.

## ӘДӘБИЯТ

Қайыпбергенов Т. Шығармалары. 5 томлық. 5 том. Нөкис. Қарақалпақстан. 1980.

Мақсетов Қ. Қарақалпақ халқының көркем аўызеки дөретпелери. Нөкис. Билим. 1996.

Мажитов С. Шығармалары. Нөкис. Қарақалпақстан. 1992.

Все знаменитые сказки народов мира. Москва. АСТ. 2014.

Тимофеев Л.И. Основы теории литературы. Москва. Просвещение. 1971.

**Ә.К. БУЛАТОВА**

Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясе

Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Казан

## ТАТАР ДИАЛЕКТОЛОГИЯСЕН ФӘННИ КИҢЛЕККӘ ЧЫГАРУЧЫ ГАЛИМ (Л.Т. МӘХМҮТОВА ЭШЧӘНЛЕГЕ)

**А.К. БУЛАТОВА**

Институт языка, литературы и искусства им. Г.Ибрагимова

Академии наук Республики Татарстан, Казань

## УЧЁНЫЙ, ВНЁСШИЙ ОГРОМНОЙ ВКЛАД В ТАТАРСКУЮ ДИАЛЕКТОЛОГИЮ (ДЕЯТЕЛЬНОСТЬ Л.Т. МАХМУТОВОЙ)

**Аннотация.** В статье рассматривается научно-исследовательская деятельность известного тюрколога и диалектолога Махмутовой Ляйлы Тагировны. Научные труды учёного посвящены диалектологии, лексикографии, лексикологии и истории татарского языка.

**Abstract.**The article examines the research activity of the famous specialist in Turkic Philology and dialectology of Mahmutovoy Laily. Scientific works of the scientist are devoted to dialectology, lexicography, lexicology and history of the Tatar language.

**Ключевые слова:** Л.Т. Махмутова, тюркология, диалектология, татарский язык, мишарский диалект татарского языка.

**Keywords:** L.T. Makhmutova, Turkology, dialectology, Tatar language, Mishar dialect of the Tatar language.

Мәхмүтова Ләйлә Таһир кызы 1925 елның 15 августындаУльяновск өлкәсе Иске Кулаткы районының Муса (Мосеевка) авылында укытучы гаиләсендә дөньяга килә. Булачак галимәнең әти-әнисе алдынгы карашлы кешеләр була, балаларын белемле үтү өчен күп көч куялар. Л. МәхмүтоваЛенинград дәүләт университеты Көнчыгыш факультетының тюркология кафедрасына укырга керә, 1948 елда аны кызыл диплом белән тәмамлый.1948-1950 елларда Көнчыгыш факультетында татар теле укыта, аспирантурага кабул ителә. 1952 елда «Татар теле касыйм сөйләшенең үзенчәлекләре» темасына кандидатлык диссертациясе яклый.

1952 елда Ләйлә Таһир кызы Казан шәһәренә күченеп килә һәм Тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү институтында (хәзер – Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты) фәнни хезмәткәр булып эшли башлый. Тырыш һәм югары әзерлекле хезмәткәрне тиз күреп алалар, аңа тел секторы мөдире вазифасын ышынып тапшыралар: Ләйлә Мәхмүтова 25 ел дәвамында тел бүлеген җитәкли.

Ләйлә Таһир кызының фәнни эшчәнлеге гаять күп тармаклы. Галимә барыннан да элек диалектолог буларак таныла. Л. Мәхмүтова татар тел гыйлеменең мөһим бер бүлеген тәшкил иткән диалектологияне фән киңлегенә чыгара.Аның җитәкчелегендә татар диалектологиясе аерым мөсткыйль тел белеме тармагы буларак формалаша.

Ләйлә Мәхмүтова җиде–сигез кешедән торган диалектологик группа җыя, һәм аның җитәкчелегендә татарлар яшәгән Идел буе һәм Урал төбәкләренә, җирле сөйләшләрне тикшерү-өйрәнү өчен, күпсанлы экспедицияләр оештырыла, күп кенә фәнни сәфәрләрдә галимә үзе дә катнаша. Лингвогеография ысулын кулланып, уналты төбәкнең татар сөйләшләре җентекле өйрәнелеп чыгыла, 200 артык фәнни диалектологик экспедиция уздырыла. Барлыгы 900 гә якын торак пункт өйрәнелә, сөйләш үрнәкләре язылып алынып, тәфсилле анализлана, магнитофон язмаларына нигезләнеп фонотека төзелә. Яңа сөйләшләр һәм сөйләш урынчалыклары ачыклана, классификация тәгаенләнә һәм сөйләшләрнең таралыш ареалы билгеләнә, бай һәм фәнни тикшеренү өчен мөһим тел материалы туплана.Әлеге кыр практикасы эшләренең нәтиҗәсе буларак диалектологик материал «Татар теленең диалектологик сүзлек»ләренең нигезенә салына (1969, 1993).

Ләйлә Мәхмүтова җитәкләгән диалектологлар төркеме төрки дөньяда беренчеләрдән булып диалектологик атлас төзү эшенә керешә, зур күләмле фактик материал фәнни әйләнешкә кертелә. Сөйләшләр халык авыз иҗаты, этнография, материаллары, тарихи фактларны истә тотып комплекслы өйрәнелә. Шулай ук татар диалектологиясенең теоретик төшенчәләр системасы булдырыла. 1989 елда «Урта Идел һәм Урал төбәге татар халык сөйләшләре атласы»ике томда басылып чыга, соңыннан галимәнең шәкертләре тарафыннан «Татар сөйләшләренең атласы» (2015) эшләнеп дөнья күрә.

1978 елда Мәскәүдә Л. Мәхмүтованың «Опыт исследования тюркских диалектов (мишарский диалект татарского языка)» монографиясе басылып чыга. Галимә мишәр диалектын эзлекле рәвештә бөтен киңлеге һәм тирәнлеге белән комплекслы өйрәнә. Бай тел материалы туплый, аны төркемләп чыга, татар диалектларының өйрәнелү тарихын, көнбатыш диалектка караган сөйләш һәм урынчалыкларның классификациясе бирелә һәм диалектның төп үзенчәлекләре ачыклана. Мишәр диалектының фонетикасы һәм морфологиясе татар теленең әдәби теле белән чагыштырылап карала, шулай ук башка төрки һәм фин-угор телләре белән уртак һәм аермалыклы яклары күрсәтелә.

Галимәнең тел гыйлеменең башка мөһим мәсьәләләренә карата язылган хезмәтләре дә байтак, ул татар теленең диалектларын тел тарихы, әдәби тел формалашу этаплары белән тыгыз бәйләнештә тикшерә. Шулай ук икетеллелек мәсьәләләренә кагылышлы фәнни мәкаләләрендә дә мөһим фикерләр әйтелә.

Ләйлә Таһир кызы Мәхмүтова шулай ук сүзлекләр төзүче, редакцияләүче буларак та билгеле. Ул «Русча-тартарча фразеологик сүзлеге»нең (1959), «Татар теленең фразеологиясе, мәкаль, әйтемнәр» (1957) сүзлекләренең төзүче авторларның берсе, шулай ук дүрт томлык «Русча-татарча сүзлек» (1956–1958), «Татарча-русча сүзлек» (1966), «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» (1977–1981) төзүдә дә катнаша.

Ләйлә Таһир кызы үзеннән соң дәвамчылары булган, фәндә үз урыннарын табып, төрки дөньяда танылган бер төркем диалектологлар – Зилә Садыйкова, Леонид Арсланов, Фәрит Юсупов, Дөррия Рамазанова, Тәнзилә Хәйретдинова, Флера Баязитова һ.б. әзерләүгә зур өлеш кертә.

Алда әйтелгәннәрдән мәгълүм булганча, Л. Мәхмүтова гыйльми эшчәнлегенә тематик төрлелек, киң колачлылык һәм фикер тирәнлеге хас. Җитди фәнни мәсьәләләрне хәл итәргә алынган, төрле өлкәләрдә бердәй мәгълүматлы, энциклодепик белемгә ия, эрудит галимә бай рухи мирас калдыра, ул барыннан да элек татар диалектология фән буларак дөньяга таныта.

Олы галимә, күренекле тюрколог Ләйлә Мәхмүтова 2002 елның 10 февралендә вафат була. Быел тууына 95 ел тулу уңае белән тюркология дөньясында танылган, татар диалектология фәнен формалаштырган галим филология фәннәре кандидаты Ләйлә Таһир кызы Мәхмүтованы тирән ихтирам белән искә алабыз.

## ӘДӘБИЯТ


Баязитова Ф.С., Рамазанова Д.Б. Опыт исследования тюркских диалектов // Советская тюркология, 1978. №6. – С. 75–77.

Бәширова И.Б. Остазым истәлегенә // Фәнни Татарстан, 2005. №3. – Б. 89–90.

Махмутова Ляйла Тагировна // Казанская лингвистическая школа. Книга первая: Казанская тюркская лингвистическая школа / сост. М.З. Закиев. Казань: Татар. кн. изд-во, 2008. – С. 218-221.

Махмутова Л. Опыт исследования тюркских диалектов (мишарский диалект татарсткого языка) . М.: Наука, 1978. – 272 с.

Насипов И.С. Татар диалектологиясе: библиографик белешмә. Стәрлетамак, 2004. – Б. 121-124.

Рамазанова Д.Б. Достижения и задачах татарской диалектологии // Научный Татарстан, 2000. №3. – С. 80-83.

Рамазанова Д.Б. Во имя науки // Актуальные вопросы татарского языкознания. – Казань, 2002. – С. 3-6.

Рамазанова Д. Фәнгә багыфшланган гомер // Фән һәм тел, 2009. – № 1. Б. 3-7.
Рамазанова Д. Ул үзе зен халыкка багышлады // Ватаным Татарстан, 2005. – 243 сентябрь.
Рамазанова Д. Сүзләр дөнясында йөзгән Ләйлә // Ватаным Татанстан, 2000. – 19 август.
Хәйретдинова Т. Озтазым турында // Фән һәм тел, 2009. №1. – Б.7–9.

**М.З. ВӘЛИЕВА**
Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясе
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Казан

## XVII – XVIII ГАСЫР ЯЗМА ИСТӘЛЕКЛӘРЕНДӘ ЧАГЫЛЫШЫ ТАПКАН ТАРИХИ ШӘХЕСЛӘРНЕҢ ИСЕМНӘРЕ

**М.З. ВАЛИЕВА**
Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова
Академии наук Республики Татарстан, Казань

## ИМЕНА СОБСТВЕННЫЕ ИСТОРИЧЕСКИХ ЛИЧНОСТЕЙ В ТАТАРСКИХ ПИСЬМЕННЫХ ИСТОЧНИКАХ XVII – XVIII ВВ.

**Аннотация.** В статье рассматривается имена собственные исторических личностей. Данные имена зафиксированы в письменных источниках XVII – XVIII вв.

**Annotation**. The article deals with onymas, which are recorded in the written source of the XVII– XVIII century.

**Ключевые слова**. Письменный источник, имена собственные, исторические личности.

**Keywords**. Written source, onyms, historical figures

Борынгы чорда халык исемнең кеше язмышына тэсире итә алуына, ягъни кеше белән аның исеме арасында ниндидер рухи бәйләнеш барлыгына ышанган, кеше исеменә зур вазыйфа йөкләгән [Саттаров, 1989: 25]. Шул исәптән әдәби әсәр авторлары да персонаж, лирик герой исемнәренә зур әһәмият бирә. Әдәби әсәрләрдә гадәттә автор, жанрга карап, тарихи исемнәрне дә, чынбарлыкка очрый торган кеше исемнәрен дә, хәтта үзе иҗат иткәннәрне дә кулланырга мөмкин. Боларның үзара бәйләнеше, кайсының ни дәрәҗәдә бирелүе, әлбәттә, әсәрнең темасына, җанрына, авторның дөньяга карашына, куйган максатына һәм әдәби осталыгына бәйле. XVII-XVIII язма истәлекләрендә кеше исеме, беренче чиратта, Мөслиминең “Тәварихе Болгария” һәм “Дәфтәре Чыңгызнамә” әсәрләрендә күп очрый. Белгәнебезчә, бу язма истәлекләрдә тарихи вакыйгалар яктыртыла. Шул сәбәпле биредә төрки-татар халкы тормышында эз калдырган тарихи шәхесләрнең исемнәре төп урынны алып тора. Тарихи исемнәрне яктыртканда, беренче чиратта, аларның кайсы чорда, ханлыкта кулланылышына игътибар итәргә тырыштык, чөнки Мәүлә Колый иҗатында, аеруча “Тәварихе Болгария” белән “Дәфтәре Чыңгызнамә”дә төрки-татар тарихы, ханлыклары белән бәйле булган бик күп күренекле шәхесләрнең исемнәре телгә алына. Нәтиҗәдә, без “Татар ханлыкларына бәйле тарихи шәхес исемнәрен” инвариант итеп алып, аның түбәдәге вариантларын аерып күрсәтергә булдык:

**а) Болгар дәүләте белән бәйле кеше исемнәре.** Язма истәлектә шәһре Болгар ханы буларак *Габдулла* исеме телгә алына: Ошда анлар мондаг чиру белән килмәкдә, әмма ул дәүердә, ул заманда Болгар шәһәрендә ханлары *Габдулла хан* дигән ирде [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011: 85]. Габдулланың *Алтынбик* һәм *Галимбик* исемле ике улы булуы да искәртелә: Габдулла ханның ике углы бар ирде, бере *Алтынбик*, бере *Галимбик* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011: 91]. Бу шәхесләр хакында конкрет һәм тулы мәгълүматлар булмаса да, алар тарихи чыганакларда, риваять-дастаннарда теркәлеп калган. Бу исемнәр, беренче чиратта, Болгар ханлыгы, һәм Иске Казанга бәйле телгә алына [Галлям 2017: 3-12].

Шәһре Болгарның дәрәҗәле кешеләре – бикләре хакында да азмы-күпме сүз бар: Берсе *Икали бик*, бере *Гали бик,* нә бере *Хаши бик*, һәнә бере *Миркаши бик* дийерләр ирде [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011: 85]. Мисалдан телгә алынган Кол Гали – һәммәбезгә яхшы таныш булган тарихи шәхес, Галим бикне Габдулла ханның кече угълы дип фаразларга мөмкин, чөнки язма чыганакларда Галимбик еш кына Гали бик буларак телгә алына [Галлям, 2017: 8].

**ә) Алтын урда чоры белән бәйле кеше исемнәре. Чыңгыз хан нәселе.** Кеше исемнәренең иң күп өлеше “Дәфтәре Чыңгызнамә» әсәрендә телгә алына. Автор Чыңгыз ханың нәсел шәҗәрәсен язуга зур урын бирә. Әсәрдән күренгәнчә, автор Чыңгыз ханнын нәсел башын Нух пәйгамбәр белән бәйли. Алга таба түбәндәге тарихи шәхесләрнең исемнәрен китерә: *Әбүлҗа хан* углы *Бакыр* хан, аның углы *Ужҗан*, аның углы *Аваз* хан, аның углы *Күк* хан, аның углы *Әбү Гара хан*, аның углы *Кара хан,* аның углы *Күнү Мәргән*, аның углы *Уҗам Буйыл*, аның углы *Сам Савучы*, аның углы *Сар Савучы*, аның углы *Сәнга Борун*, аның углы *Качу Мәргән*, аның углы *Качумән*, аның углы *Кара Даман*, ның углы *Турымтай Чәчән*, аның углы *Тумавыл Мәргән*, аның углы *Дуйын Бәйан*, аның углы *Чыңгыз хан*, аның углы аның углы *Саин хан*, аның углы *Сартак хан*, аның углы *Пәртак хан*, аның углы *Тугали Йучи хан*, хан, аның углы *Тук Тәгый хан*, аның углы *Үзбәк хан*, аның углы *Җанибәк хан*, аның углы *Пәрдик Солтан хан*, аның углы *Шәбәк хан*, аның углы *Мортаза хан*, аның углы *Күчем хан*, аның углы *Арслан хан*, аның углы *Борһан солтан*, әмма Борһан солтан урыс кулында хибес булып мөртәд булды [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011: 69]. Әлеге шәҗәрәдә күп кенә тарихи исемнәр телгә алынуга карамастан, аны һич кенә дә тарихи мәгълүмат итеп кабул итергә ярамый. Дөрес, аның күпмедер дәрәҗәдә тарихи чынбарлык белән туры килүен дә кире кагырга ярамый. Мәсәлән, “Борһан ханнын урыс кулында хибес булуы”, ягъни диненнән язуы тарихта исбатланган күренеш. Ул 1653 елда христианлыкка күчә һәм Василий исеме астында Касыйм ханлыгы белән үлгәнче идарә итә [Усманов, 1972: 106]. Шулай ук Чыңгыз ханның улларының исемнәрен санаганда да, эзлеклек югалган, күп ялгышлыклар киткән. Әмма автор Чыңгыз ханның уллары хакында чагыштырмача дөрес мәгълүмат бирә, дүрт улы булуын искәртә, исемнәрен саный: Олуг углы – *Йуҗи хан*, икенче – *Җәдай хан*, өченче – *Герай* хан, дүртенче – *Тули хан* дигән ирде [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011: 78]. Тарихи чыганакларда, икенче һәм өченче улларының исемнәре Чегатай һәм Үгедәй дип бирелә [Сафаргалиев, 1996: 520]. Гәрчә аларны ялгышлыклар дип әйтү дөрес түгелдер, чөнки “Дәфтәре Чыңгызнамә” әсәренең тарихи чыганак түгел, ә дастан булуын искәртергә кирәк.

**Алтын урда ханнары**. Язма истәлектә телгә алынган исемнәр арасында Алтын Урда дәүләте оешуга, идарә итүгә катнашы булган атаклы ханнар бар. Мәгълүм булганча, аларның да байтагы нәсел җепләре белән Чыңгыз ханга барып тоташа:.

Мәсәлән, *Йуҗи хан, Тули хан, Сартак хан, Үзбәк хан, Җанибәк хан, Бирдебәк хан* һ.б.: Аның углы Сартак хан булды... Аның углы *Үзбәк хан* булды... [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011: 69]. *Җанибәк ханның* бичәсе Тайдулы ханшаның ай-көне иңгән ирде. Кызны үлтермәде, *Бирдебәккә* йибәрде [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011: 88]. Мәгълүм булганча, Йуҗи /Җучи хан Хәрәзм, Дәшт-и-Кыпчак далаларында идарә итә.Алтын урда дәүләте ханлык буларак Узбәк хан идарә иткән чорда икътисади, сәяси һәм дини яктан көчле үсешкә ирешә. Аны урынына улы Җанибәк хан утыра, Җанибәктә соң идарә эше аның улы Бирдебәккә күчә [Фахрутдинов, 1995: 109]. "Дәфтәре Чыңгызнамә" авторы исә Җанибәк һәм Бирдебәк хан исемнәрен маҗаралы вакыйгаларга бәйле генә телгә ала.

Язма истәлекләрдә урын алган төп геройларның берсе Аксак Тимернең исеме төрле вариантларда кулланыла. Мәсәлән, түбәндәге мисалда исеменең сәбәбе аңлатыла: Бер айагы аксак ирде, угланның атын ул сәбәбдин *Аксак Тимер* куйдылар [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011: 82]. Әмир Тимер, Мир Тимер исемнәре дә Аксак Тимерне атау өчен файдаланылган: Ул кырмыскадин хәзрәте *Әмир Тимер* гыйбрәт алды [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011: 82]. Хәзрәте *Мир Тимер* үзе ләшкәре белән Истанбул шәһәрен алырга йарагланды [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 84]. Мисаллардан күренгәнчә, биредә Аксак Тимер исеме *хәзрәте* сүзе белән телгә алына, ягъни зурлап, хөрмәт белән тасвирлана. Үз чорының идеологиясенә туры китереп язылган кайбер риваятьләрдә дә Аксак Тимер изге хәзрәт итеп югары чөелә [Дәүләтшин, 1999: 159]. "Дәфтәре Чыңгызнамә" әсәренең авторы да шундый риваятьләргә таянып эш иткән булырга мөмкин. "Тәварихе Болгария" әсәрендә дә Аксак Тимерне зурлау-олылау сизелә, шулай ук Хәзрәте Аксак Тимер яисә Аксак Тимер хәзрәтләре дип телгә алына: *Хәзрәте Аксак Тимерне* Аллаһы Тәгалә хәзрәте мөсәлләт итеб... Ул *Аксак Тимер хәзрәтләре* Хытайның шәркый сәрхәдден. *Хәзрәте Мир Тимер* Хытай йортындан гаскәре илән чыкды [Мөслими, 1999: 35]. Шул рәвешчә, *Аксак Тимер, Мир Тимер, Әмир Тимер* – барысы да Аксак Тимерны атый.

**б) Казан ханнары.** "Дәфтәре Чыңгызнамә" әсәрендә Казан ханнары хакында да кыска гына мәгълүмт бирелә, кемнәрнең хан булып торуы билгеле бер эзлеклелектә санала: Андин соң *Мәхмүд хан,* андин соң *Мәмнәк хан*, андин соң *Хәлил хан*, андин соң *Ибраһим хан*, андин соң *Илһам хан*, андин соң *Габделлатыйф хан*, андин соң *Сахиб Гәрәй хан*, андин соң *Сафа Гәрәй хан*, андин соң *Гали хан*, андин соң *Үтәш хан*, андин соң *Йәдгәр хан*. Андин соңа *Шәгали хан*, андин соң кяфер урыс алды [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011: 91]. Әлеге ханнарның исемнәре тарихи чыганакларда теркәлгән, алар тарихчылар тарафыннан өйрәнелгән, ягъни "Дәфтәре Чыңгызнамә" авторы бу тарихи шәхесләр хакында мәгълүматлы булган, белеп тасвирлаган.

**в) Рус ханнарының исемнәре.** "Дәфтәре Чыңгызнамә" әсәрендә рус халкы тарихында эз калдырган патша һәм кенәз исемнәре дә телгә алына. Алар, нигездә, *хан* һәм *кенәз* кебек лексик берәмлекләр белән кулланыла: Берсенең аты *Иван,* икенчесенең аты *Петр* ирде [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011: 92]. *Хәзрәте Аксак Тимер* барган вакытда кяфер урысның *ханы Михайла* иде [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011: 87]. Андин соң тарих мең дә илле өч тә ирде, *кенәз Михайла Фидорович* хан булды, куй йылы ирде [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011: 91]. Әлеге мисалларда сүз Петр I, аның туганы Иван Алексеевич, Романовлар династиясендәге беренче патша Михаил Федорович Романов телгә алына. Рус исемнәре күпмедер дәрәҗәдә фонетик яктан үзгәреш кичергәннәр: Михайла, Митрий, Фидор һ.б. Андин соң тарих мең дә унйидедә ирде, *кенәз Митрий* йагый булды, тавык йылы ирде. Ул йаман киңәшне кыйлган Фидор атлиг хан иде [Дәфтәре

Чыңгызнамә, 2011: 92]. Арада тулысынча диярлек татарча әйтелешкә яраклаштырылган рус исемнәре очрап куя. Мәсәлән, Иван Калита язма истәлектә Калталы Җәвал, кенәз Алексей исә Әләкчәй дип аталган: *Калталы Җәван* ирде, йиде йылгача орыш-кырыш кыйлды, мөселманларны ала алмады... Икесе дә Әләкчәй хан угланнары ирде [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011: 92].

Шул рәвешчә,кеше исемнәрендә татар халкы тарихы, милли мәдәнияте, гореф-гадәтләре үз эзен калдырган. Алтын Урда, Казан ханлыгы чоры мәдәни традицияләре, идеологиясе ислам дине кеше исемнәре системасына да үтеп кергән [Галиуллина, 2008: 120]. XVII – XVIII гасыр татар язма чыганакларында теркәлеп калган кеше исемнәрендә бу үзенчәлекнең тагын да ачыграк чагылыш табуы күренә.

## ӘДӘБИЯТ


Галиуллина Г.Р. Татарские личные имена в контексте лингвокультурных традиций. Казань: Изд-во Казан.ун-та, 2008. – 349 с.

Галлям Р. Абдуллах-хан и его сыновья. Казань: Тат. кн. изд-во, 2917. – 15 с.

Дәүләтшин Г.М. Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. – 512.

Дәфтәре Чыңгызнамә (транскрипция) // Мирастан биш сәхифә: XVII – XIX гасырлар әдәби-тарихи ядкярләре. Казан: Тат.кит.нәшр., 2011. – 38-96 б.

Мөслими Тәварихы Болгария. Казан: иман, 1999. – 101 б.

Саттаров Г.Ф. исемең матур, кемнәр куйган? Казан: Тат.кит.нәшр.,1989. – 276 б.

Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды // На стыке континентов и цивилизаций. Казань: Инсан. – 280-524 с.

Усманов М.А. Татарские исторические источники XVII – XVIII вв. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1971. – 222 с.

Фахрутдинов Р.Г. История татарского народа и Татарстана. Казан: Мәгариф, 1995. – 255 б.



**Р.Р. ГАБДУЛЛИН, Г.Р. ГАЙНУЛЛИНА**
Казан федераль университеты, Казан


## Г.САБИТОВ ХИКӘЯЛӘРЕНДӘ ОБРАЗ ТУДЫРУ АЛЫМНАРЫ


**Р.Р. ГАБДУЛЛИН, Г.Р. ГАЙНУЛЛИНА**
Казанский федеральный университет, Казань


## ОБРАЗНАЯ СИСТЕМА В РАССКАЗАХ Г. САБИТОВА


**Аннотация.** В данной статье проанализированы особенности образного мышления писателя Габделхая Сабитова на примере его рассказов, которые не были ранее обьектом исследования литературоведов. Выводом является то, что проза Г. Сабитова является неотьемлимиой частью сентиментальной прозы 1960-1980-годов XX века.

**Abstract.** This article analyzes the features of imaginative thinking of the writer Gabdelkhay Sabitov on the example of his stories, which were not previously the object of research of literary critics. The conclusion is that G. Sabitov's prose is an integral part of the sentimental prose of the 1960-1980s of the twentieth century.



**Ключевые слова.** рассказ, проза, образ, литература

**Keyword.** short story, prose, image, literature

Г. Сабитов хикәяләрендә обоаз тудыру алымнары гаҗәеп бай. Язучы милли нигеләргә кайту дәвере прозасында лирик-сентименталь катламны батуга үзеннән гаҗәеп зур өлеш кертә. «Габделхәй Сабитовның хикәяләрендә күбесенчә гап-гади хәлләр сабыр, салмак кына сөйләнеп барыла. Берәүнең яртылаш кына язып ташланган дәфтәре җирдә аунап ята, икенче бер авылга ерак шәһәрдән герой кайтып төшә. Ә бер өйнең стенасындагы поши мөгезенә уенчык чиләк элеп куелган. Искитәрлек берние юк кебек тә бит, ә менә язучы күзенә эләккәч, шушы гади генә эшләр дә укучыны дулкынландырырлык хикәягә әйләнгәннәр» [Ихсанова, 2003: 150].

Бөек Ватан сугышы темасын яктырткан «Чын дәфтәр» (1975) хикәясенә игътибар итик. Әсәр Хәлим исемле малай исеменнән бәян ителә. Хикәя башында укучының игътибары «койма буенда зәңгәр тышлы дәфтәр аунап ятуын»на юнәлтелә. Әлеге күренеш хикәяләүче «мин»нең уйларын «ерак елларга, бала чакларга» кайтара. Көзге пейзаж хикәя дәвамында кабатланып, хикәяләүченең эчке кичерешләрен аңларга ярдәм итә: «Әлегедәй сытык чырайлы көзге көн. Күктә салынкы соры болытлар агыла. Юлбасар җил урман читендәге куакларның соңгы яфракларын талап йөри, игене урылган арыш кырындагы камылларда сызгыра» [Сабитов, 2010: 130].

Дәфтәр аунап ята. Хикәя барышында ике төрле дәфтәр сурәтләнә: койма буенда аунап ятучы һәм сугыш елларында Өлфәт тарафыннан күз карасыдай кадерләп сакланылган дәфтәр. Хикәядә без әлеге ике детальне чагыштыру аша автор фикерен ачыклыйбыз.

Әсәрдә беренче дәфтәргә икенче дәфтәр образы капма-каршы тасвирлана: «Дөрестән дә, чын дәфтәр! Ялтырап торган кәгазьле егерме дүрт битле фабричный дәфтәр!» [Сабитов, 2010: 132]. Кечкенә баланың прәннекнең ни икәнен белмичә, аның белән уйнарга тотынуы Өлфәтнең әтисе Җәмил абзыйга көчле тәэсир ясый, аның эчке халәте – сызлануы атала: «Ул тагын бер уч прәннек алып чыгып безгә өләшә дә кинәт борчыла, ашыга-ашыга ишектән чыгып китә» [Сабитов, 2010: 133].

Дәфтәр детале ярдәмендә Өлфәтнең кешелек сыйфатлары күрсәтелә. Миңзаһитның әтисе үлүе турында хәбәр килгәч, Өлфәт дустын юатыр өчен юл таба: «Әтисе алып кайткан, моңарчы алтын хәзинәдәй сакланган әлеге дәфтәре аның кулында иде» [Сабитов, 2010: 133]. Дәфтәр детале кадерле «хәзинә» генә түгел, ә ике дусның хисләре чагылышы да. Шушы ноктада без хәзерге «урам читендә аунап яткан» дәфтәргә кире әйләнеп кайтабыз. Дәфтәрнең хуҗасы да ачыклана: «Гатин Фәритнең татар теленнән өйгә эш дәфтәре» дип язылган. Карасана! Өлфәт малаеныкы икән бит» [Сабитов, 2010: 134]. Бу урында автор буыннар арасында бәйләнеш темасын һәм проблемасын калкыта, яшь буынга әхлакый кыйммәтләрне җуймасыннар, дигән фикер әйтә, теләк-өметләрен белдерә.

Шулай итеп, хикәяләүдә мәктәп балалары Өлфәт, Миңзаһит һәм хикәяләүче үзе Хәлил, укытучы һәм телгә алынган берничә кыз бала катнаша. «Ана казга ияргән бәбкәләр» чагыштыруы балаларның ярдәмгә мохтаҗлыгын искәртә. Өлфәтнең дә, Миңзаһитның да үзенчәлекле бер сыйфаты да аталмый. Әмма хикәяне укыганда күз алдына гел сабыйлык билгеләре чыкмаган яшь бала йөзе һәм җитди, моңсу күзләр килә. «Күшеккән бәбкәләр» чагыштыруы текстта кабат-кабат яңгырый.

«Дәфтәр хуҗасы» образын хикәяләүче геройның тышкы кыяфәте тудырган хис-тойгыны сурәтләү аша, ягъни тойгы төрендәге портрет детале ярдәмендә бәяли: «...бу дәфтәр хужасының тырыш, пөхтә укучы булуы турында кычкырып тора» [Сабитов, 2010: 130]. Укучының эш-гамәленә бәя бирү дәфтәр детален сурәтләү ярдәмендә

башкарыла: «Икенче бите исә яртылаш кына язылган. Әлеге укучы, үзенең ниндидер ялгышын күреп, эшли башлаган эшен аркылы-торкылы сызгалаган да дәфтәрне урамга, җилләр иркенә ташлап калдырган» [Сабитов, 2010: 130].

Төп герой Хәлим үзенең балачагын исенә төшерә. «Сугыш еллары... авыр чаклар. ...бер төркем мәктәп балалары – ана казга ияргән бәбкәләр кебек, укытучы апабыз белән басуда чүпләнәбез, коелып калган башакларны җыябыз» [Сабитов, 2010: 130]. Ач булганга, Өлфәт үз кесәсенә дә җыя, ләкин Мирзаһитның «үтемле сүзләреннән» соң («Фронтта солдатларга ипи өләшкәндә безнең этиләргә җитми калса?!» [Сабитов, 2010: 131]) бишмәт кесәсендәге башакларны ашыга-ашыга капчыгына бушата. Күренешләр кабатлана. Укытучы апалары басуда җыйган ашлыкларын үзләренә алып кайтырга рөхсәт биргәч, балаларның шатлыгы эчләренә сыймый: «Күшеккән бәбкәләр төркеменә шунда ук җан керә. Без дәррәү ура кычкырабыз. Җир дымыннан бүртенгән тук башаклы капчыкларыбыз, шактый саллы булса да, җиңел генә иңсәләребезгә чөелә» [Сабитов, 2010: 131].

Иртәгесе көнне укытучы диктант язуны әйткәч, «минем иске китаптан ясалган дәфтәрем дә тулды» [Сабитов, 2010: 131] дигән сүзләр фаҗигане көчәйтә: «... Кызганыч, бик кызганыч иде безгә китапларны тураклау. Нишлисең бит. Сугыш мәҗбүр итте...» [Сабитов, 2010: 132]. Сугыш афәте фаҗигасе иҗтимагый проблема буларак күтәрелә.

Һәрбер дәфтәр бите алтынга тиң булган вакытта Өлфәтнең этисе аңа егерме дүрт битлек «чын дәфтәр» алып кайта. Әлеге дәфтәр – Өлфәтнең этисеннән калган бердәнбер истәлеге, ләкин Мирзаһитның этисе үлү хәбәре килгәч Өлфәт үзенең «алтын хәзинәдәй» саклаган әлеге дәфтәрен аңа (Мирзаһитка) бүләк итә. Өлфәт дустына әлеге адымы белән ярдәм итәргә тели. «Миңа тагын шундый ук дәфтәр... егерме дәфтәр җибәрә» [Сабитов, 2010: 134] – дип әйтсә дә, соңыннан юри әйткәне аңлашыла. Өлфәтнең һәм төп герой «мин»нең этиләре хәбәрсез югала.

Өлфәтнең этисе – эпизодик образ Җәмил абзыйның әйткән сүзләре малайларда өмет уята: «Сез, балалар, түзегез бераз. Озак калмады инде. Тәгәри башлады фашист. Менә тиздән, немецны җиңеп, этиләрегез белән бергәләп кайтырбыз. Сезгә прәннекләр, кәнфитләр төяп, күчтәнәчләр белән кайтырбыз» [Сабитов, 2010: 133].

Хәлим белән Миңзаһитның этиләре исә – аталучы образлар. Алар хикәядә турыдан-туры чыгыш ясамыйча, бары тик шул вакыттагы тормыш моделен булдыруда гына катнашалар. Хикәядә табигать күренешләре геройларның психологик халәтен ачып бирә. Әсәрдә кабатланучы мотивлар хикәяләү башында һәм ахырында урын алганнар. «Көзге ваемсыз һәм юлбасар җил» лейтмотив функциясендә килә.

Пейзажны тулыландырып килеп кергән «бар эше тузгыту да очыру» булган ясалма образ – җил образы автор-хикәяләүченең бәясен – шуңа бәйле психологик халәтен ачу вазифасын башкара: «Көзге ачы җил, кемгәдер ачу иткәндәй фырылдатып, аның битләрен актара» [Сабитов, 2010: 130]. Җил монда «юлбасар» сыйфатына ия, дип гәүдәләндерелә. Ул «соңгы яфракларны талап йөри, игене урылган арыш кырындагы камылларда сызгыра» [Сабитов, 2010: 130]. «Ачы», «ачулы», «ваемсыз» җил образы, хикәяләүченең хисләрен, димәк, бәясен дә гәүдәләндерә. Хикәяләүче дәфтәрнең җирдә аунап ятуы өчен борчыла, сызлана: «...бер хатасыз, җепкә тезелгән төймә кебек тигез, матур язу. Тик беренче битнең азагында соңгы ике юл гына яңгыр суы тиеп бераз буялган. Кызыл кара белән укытучы куйган «бишле»ле билгесе кып-кызыл булып җәелеп киткән» [Сабитов, 2010: 130].

Еш кына хикәяләү лирик чигенешләр белән өзелә: «Авыл урамнары мәет чыккан йорт кебек буп-буш. Җимерек йортлар, сугыштан гарипләнеп, култык таягына таянып кайкан солдатлар кебек, як-яктан терәүле йортлар...» [Сабитов, 2010: 133]. «Сугыш безне, суга болгатып, кара сыман нәрсә юнәтергә дә, борынгы бабайлар үрнәгендә каурый каләм ясарга да, китап юллары арасына диктант язарга да өйрәтте» [Сабитов, 2010:132]. Әсәрдә билгеләнгән кеше һәм сугыш каршылыгы хикәядәге иҗтимагый проблеманы булдыра.

Хикәя әлеге койма янында аунап ятучы дәфтәрнең хуҗасы табылуы турындагы чигенеш белән тәмамлана. Хикәяләүче чын күңеленнән аның ялгышлык белән төшеп калуына өметләнә: «Бәлки... бәлки, ул аны ялгыш кына төшереп калдыргандыр» [Сабитов, 2010: 134]. Әдип әлеге хикәясендә сугышның нәтиҗәләрен күрсәтә. Аерым бер детальләр ярдәмендә күренешләрне күңелгә үтеп керерлек итеп сурәтли.

Нәтиҗә ясап, түбәндәге фикерләрне билгеләп үтәргә кирәк:

Г.Сабитов иҗтимагый проблемаларны әхлакый проблематикага төреп бирә. Сугыш темасын үзәккә алып, аның нәтиҗәсендә барлыкка килгән ачлык афәтен тасвирлый. Хикәяләрдә Кыяметдин карт, Өлфәт, Хәлим, Миңзаһит образлары аша укучыга шул дәвер михнәтләрен бәян итә. Туган җир, туган як образы Г.Сабитовның һәр хикәясендә урын ала. Автор иҗтимагый проблемаларны калкыткан әсәрләрендә дә намуслылык, гаделлек, явызлык һ.б. проблемаларны да чагылдыра.

## ӘДӘБИЯТ


Сабитов Г. Чын дәфтәр / Ай сукмагы. Казан: Тат. кит. нәшр. 2010. - 335 б.

Ихсанова Л. Гүзәллекнең бер мизгеле // Мәйдан. 2003. № 6. – Б. 150-151



**Э.И. ГАБИДУЛЛИНА**

Казан федераль университеты, Казан


## И. ЮЗЕЕВНЫҢ “ГАШЫЙКЛАР ТАВЫ” ПОЭМАСЫНДА СИМВОЛИК ОБРАЗЛАР


**Э.И. ГАБИДУЛЛИНА**

Казанский федеральный университет, Казань


## СИМВОЛИЧЕСКИЕ ОБРАЗЫ В ПОЭМЕ И.ЮЗЕЕВА “ГАШЫЙКЛАР ТАВЫ”


**Аннотация.** В данной статье исследуются симолические образы в поэме известного поэта И. Юзиева “Гашыйклар тавы”. Изучается смысловая нагрузка мифологического сюжета.

**Abstract.** His article examines the symbolic images of the famous poet I. Yuziev in the poem "Gashyiklar tava". The semantic load of the mythological plot is studied.



**Ключевые слова.** Татарская поэзия, поэма, символ, мифология.

**Keyword.** Tatar poetry, poem, symbol, mythology.


И. Юзеевның «Гашыйклар тавы» повесть-поэмасы фәлсәфи фикерләргә багышлаган (1985-1986). Поэма Серле үрдәк хакындагы риваять сюжетына мөрәҗәгать итеп язылган.

Романтик эчтәлек Мөнирә һәм Сәет мәхәббәте хакында сөйли. Гашыйклар тавында бер-берсенә тугрылыклы калырга вәгъдәләшкән геройларның тормыш юллары төрле якка сибелә. Мөнирә, үзвәгъдәсенә тугрылыклы калып, соңгы сулышына кадәр Сәетнең сугыштан кайтуын көтеп яши. Сәет исә яшьлектә ясаган хатасы аркасында гомере буена сагышлы, аянычлы язмышка дучар була [Юзеев, 1991: 27].

И. Юзеев әсәргә борынгы риваятьтне эпиграф итеп кертеп җибәрә. Мифологик материал әсәрне ачып җибәрә, аны мәгънәви яктан тагын да киңәйтә, тирәнәйтә.

Әсәрне аңлауга ачкыч хезмәтен үтәп килгән әлеге сюжет фәлсәфәне җиткерүче символ дәрәҗәсенә күтәрелә. Саф мәхәббәтне югалту, саф мәхәббәт турындагы хыялдан баш тарту тормыштагы гармонияне югалта, дигән фикер әсәрне үтәли кисеп үтә, мәхәббәт фәлсәфәсенең үзегендә тора. Хыял юкка чыгу романтик концепциядә гомумән яшәешнең бетүе белән тәнгәлләшә (Гашыйклар тавының фаҗигасе). Әсәр материалында бу фикер Сәет образы мисалында яңгыраш таба [Заһидуллина, Йосыпова, 2011: 74].

Әлеге сюжетка бәйле Гашыйклар тавы сакраль үзәк кебек кабул ителә, әсәр тукымасында ул галәмне тоя алу мөмкинлеген ачкан мәхәббәт югарылыгын символлаштыра. Галәмне борчыган мәсьәләләр турында уйлану өчен билгеле бер рухи биеклеккә күтәрелергә кирәк. Ул рухи югарылык кеше күңелендә туган мәхәббәт хисенең бөеклеге белән билгеләнә. И.Юзеев фикеренчә, шәхеснең рухи бөтенлеген саклап калучы көч - идеаль, илаһи мәхәббәт, аның сакральлеге, изгелеге дә шуның белән бәйләп аңлатыла.

Автор символлар ярдәмендә мәхәббәтнең бөеклегенә төшенү аша гына рухи югарылыккакүтәрелү, шуның ярдәмендә үз-үзе белән гармониягә ирешүмөмкин икәнлегенәйтеп чыга. И.Юзеевукучыны, җан һәлакате мәңгелек кыйммәтләрне юкка чыгара, аларның әһәмиятен җуя, дигән фикергә алып килә.

Моннан тыш, әсәр тукымасында ул гади җир белән каршылыкта сурәтләнә, сакраль – профан оппозициясен формалаштыра. Субъектив эчтәлектә матурлык – ямьсезлек, яхшылык – явызлык каршылыгы булып та төгәлләшә. Мөнирәнең Гашыйклар тавын юкка чыгарырга теләүчеләрдән сакларга омтылышы аша туган җирне ярату хисен теләсә нинди көчне дә җиңәрлек кыйммәт дәрәҗәсенә күтәрә[Заһидуллина, Йосыпова, 2011: 76].

Риваять сюжетының үзәгендә торган кош әсәрнең композицион бөтенлеген тәшкил итә. Ул риваятьтә дә, Мөнирәнең нәселе исемендә дә күзәтелә, Сәет язмышына бәйле вакыйгаларда да кабатлана. Шагырь әсәрдә символлар аша Мөнирәнең булган хисләрен, тойгыларын ачып бирә.Тылсымлы үрдәк – Мөнирә янәшәлеге аша автор Мөнирәне саф мәхәббәткә ирешә алган тугрылыклы кеше югарылыгына куя. Серле үрдәк – Мөнирәнең мәхәббәт хакында могҗиза дәрәҗәсендәге хыялы, сере.

Романтик шагыйрь хыялый мәхәббәтне рухи бөеклек, җан сафлыгын саклаучы бер идеал итеп күрсәтә. Романтик концепция раслаганча, яшәү мәгънәсен, бәхетне мәхәббәт белән бәйләп аңлату әсәрне сызып үтә. Сәет тарафыннан үрдәкнең үтерелүе укучыны бер фикергә алып килә: үрдәкне аткан Сәет, сугышка китеп, мәхәббәтеннән аерыла, гомер буе үз күңелендәге мәхәббәтне, саф мәхәббәт турындагы хыялын «үтереп яшәргә» мәҗбүр була [Даутов, 2002: 121]. Бу ике образ әсәр ахырында, хикәяләүче-мин тарафыннан чынбарлык буларак сурәтләнгән тормышта да тәңгәлләштерелә. Әнә шулай мәхәббәт бөеклегенә тугрылык саклаган Мөнирә әсәр ахырында үзе үк саф мәхәббәт билгесенә – тән һәм җан берлегенә ирешкән илаһи хатын-кызга, идеалга әверелә [Заһидуллина, Йосыпова, 2011: 76].

И. Юзеев шулай ук әсәрдә табигатьнең пычрануы, сак караш бетү, гореф-гадәтләрнең юкка чыгуы, эчкечелек, әхлаксызлык, сугыш афәте, авылларны эреләндерү проблемаларынада тукталып китә. Автор риваять, образлар, символлар аша фәлсәфи фикерләрен яшь буынга җиткерегә тели.


## ӘДӘБИЯТ

Даутов А. И. Илдар Юзеев шигърияте ндә романтизм. Казан: “ИНТЕЛПРЕСС”, 2002. – 152 б.

Заһидуллина Д.Ф., Йосыпова Н.М. XX гасыр татар әдәбияты тарихы. Казан: Казан ун-ты нәшр., 2011. – Т.2. – 198 б.

Татар әдәбияты тарихы: 8 томда. Т. 6: 1960-80 нче еллар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. – 775 б.

Юзеев И.Гашыйклар тавы: поэмалар, шигырьләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. – 144 б.



**Ф.И. ГАБИДУЛЛИНА**

Казан федераль университетының Алабуга институты, Алабуга


## С. ХӘКИМНЕҢ “КЫРЫГЫНЧЫ БҮЛМӘ” ПОЭМАСЫНДА ХАЛЫК ИҖАТЫ ТРАДИЦИЯЛӘРЕ


**Ф.И. ГАБИДУЛЛИНА**

Елабужский институт КФУ, Елабуга


## ТРАДИЦИИ НАРОДНОГО ТВОРЧЕСТВА В ПОЭМЕ С. ХАКИМА «40 НОМЕР»


ПУБЛИКАЦИЯ ОСУЩЕСТВЛЕНА В РАМКАХ МЕРОПРИЯТИЯ 3.5.4 ГОСУДАРСТВЕННОЙ ПРОГРАММЫ «СОХРАНЕНИЕ, ИЗУЧЕНИЕ И РАЗВИТИЕ ГОСУДАРСТВЕННЫХ ЯЗЫКОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН И ДРУГИХ ЯЗЫКОВ В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН НА 2014-2020 ГОДЫ



**Аннотация**. В статье исследуется отражение традиций народного творчества в поэме известного татарского поэта Сибгата Хакима «40 номер». Автор анализирует особенности сюжетно-композиционной структуры поэмы, выявляется особенности лирического героя. В поэме поэт раскрывает жизненные противоречия с помощью учения, литературных деталей и символов, которые исходят из народного творчества, создает изображение мира, в котором люди живут со своей мечтой.

**Annotation.** The article examines the reflection of folk art traditions in the poem "number 40"by the famous Tatar poet Sibgat Hakim. The author analyzes the features of the plot and compositional structure of the poem, reveals the features of the lyrical hero. In the poem, the poet reveals life's contradictions with the help of teaching, literary details, symbols that come from folk art, creates an image of the world in which people live with their dreams.



**Ключевые слова:** поэзия, Сибгат Хаким, поэма, структура, герой, традиция.

**Keywords:** poetry, Sibgat Hakim, poem, structure, hero, tradition.


Татар әдәбияты тарихында С. Хәкимнең (1911 – 1986) кабатланмас урыны бар. Аның тормыш юлы ил-халык тарихының гаять катлаулы, каршылыклы дәверләренә

туры килеп, әлеге хәл-күренешләр еш кына тема-мотивлар, әдәби сурәтләр булып әсәрләренә килеп керә. Казан артындагы Күлле-Киме авылында туып үскән әдип кечкенәдән халык җырларын, такмак-әкиятләрен күңеленә сеңдерә, телнең матурлыгын, эчке аһәңен тоеп яши.

Г. Тукай иҗаты С. Хәким өчен буй җитмәс биеклек, соклангыч иҗат үрнәге булып тора. Ул бөек шагыйрьнең әдәби образына 1930 еллар ахырында ук мөрәҗәгать итә. “Пар ат” (1938-39), “Шагыйрьнең бала чагы” (1940) поэмаларында Тукай биографиясенә бәйле уйланулары аша аның иҗатына килә, бу мирасның үзе өчен кыйммәте, халык рухына тәэсире турында уйлана. С. Хәким шул еллардан башлап Тукайны үзенең остазы итә, әсәрләреннән образлар, әдәби детальләр ала, үзе язганча – “Тукай аша карыйм дөньяга”. Бу темага соңрак тагын әйләнеп кайта һәм нәтиҗәдә “Тукай һәйкәле алдында” (1960), “Тукай дәфтәреннән” (цикл, 1971), “Кырыгынчы бүлмә” (1971), “Тукай белән очраштырды заман...” (1975), “Тукайга” (1984) кебек шигырь-поэмалары языла. Р. Вәлиев билгеләп үткәнчә, “Тукай иҗаты Сибгат Хәким өчен гомер буена рухи юл күрсәткеч, шигъри кыйбла булды. Аның һәр көне, һәр кылган гамәле Тукай бисмилласы белән башлана иде. Шуңа күрәдерме, еллар үткән саен, Сибгат аганың шигъри сурәтләре һич тә тоныкланмый, төсләре уңмый, фикерләре искерми” [Вәлиев, 2011: 7]. Алар арасында сәнгати эшләнеше, Тукайның шәхесен, иҗатын үз чоры һәм автор яшәгән чорга нисбәтле сурәтләү ягыннан “Кырыгынчы бүлмә” поэмасы аерым игътибарга лаек. Әлеге әсәрдә С. Хәкимнең сәнгати эзләнүләре, фикерләү үзенчәлеге тулы чагылыш табып, аның бөтен иҗатына хас сыйфатларны ачыклауга да уңышлы җирлек булып тора.

С. Хәким иҗаты, шул исәптән әлеге поэма шактый өйрәнелгән. Әдип әсәрләре Н. Юзеев, Х.Хәйри, Т. Галиуллин, Р.Мостафин, З.Рәмиев, М. Вәлиев, Д. Заһидуллина, Ф. Миңнуллин, Н. Йосыпова һ.б. тарафыннан тикшерелеп, тема-проблематика, сәнгати эшләнеш ягыннан бәяләнә.

С. Хәкимнең “Кырыгынчы бүлмә” поэмасы бөек Тукайның әдәби образын чагылдырып, эш-гамәләренә, әдәби мирасына үз чоры һәм автор яшәгән чорга нисбәтле бәя бирүне максат итә. Автор “шагыйрь образын сурәтләүне эпик әсәр мөмкинлекләрен файдаланып тирәнәйтә һәм аны төрле катламнарның синтезында тасвирлый” [Йосыпова, 2018: 288]. Әсәрне халык иҗаты традицияләре кысасында өйрәнү, аның халыкчанлыгын, милли асылын тирәнрәк аңлау мөмкинлеге бирә. Әлеге мәсьәлә исә ике яссылыкта карала. Берсе – вакыйгалар һәм образлар катламы аша халыкның яшәү рәвешен, аны борчыган, уйландырган мәсьәләрне ачу, икенчесе – халык иҗатыннан килүче шигъри алымнарга, гади-гадәти күренешләргә, халыкчан тәгъбирләргә мөрәҗәгать итү. Поэмада төрле катламнар үзара керешеп, бөтенлекле күзаллауны барлыкка китерә. Әсәр лирик геройның хатирәләре, әтисенең Әтнә базарыннан кайту күренеше белән башлана. Ат чанасындагы печән-салам арасыннан бик тә кирәкле ике әйбер чыга – күмәч һәм Тукай китабы. Әнә шул рәвешле герой тормышына “әкиятләре белән, кар белән...” Тукай керә һәм китмәскә дип шунда кала.

Поэмада үткән һәм бүгенге бәйләнеше үзара бәйләнеп, үрелеп бара. Аңа автор образы, аның Тукайга караш-мөнәсәбәте дә кушылып китә. Шуңа нисбәтле әдәби катлам аерымлана. Автор өчен Тукай яшәеш таянычы, хыял чыганагы, киләчәккә юл күрсәтүче: “илаһи рух – Тукай рухыннан”. Тукай иҗатының кыйммәтен ачу аша ул әдәби иҗатның кеше тормышындагы урыны турында уйланырга этәрә. Бөтен күңеле белән иҗатка тартылучы лирик герой остазы әсәрләрен үзе өчен маяк итә. Әнә шул аны

сугыш фронтыннан исән-имин алып чыга һәм күңелендәге иҗат хисен баетып, үстереп җибәрә – “Фронтта да бары бер генә чир – / Тукай чире белән чирләдем”. Бөтен барлыгы белән шигърияткә тартылган, әдәби иҗат белән яшәгән автор гомере буе Пушкин, Лермонтов,Тукайлардан көч-илһам алып яши. Әлеге өч бөекнең янәшә килүе юкка түгел. Автор үзенең Тукаен дөньякүләм танылган рус шагыйрьләре белән янәшә куя, иҗат биеклеген шулар белән чагыштырып бәяли.

Поэмада мөһим урынны иҗтимагый катлам алып тора һәм ул Тукайны үз чоры белән бәйләнештә аңларга ярдәм итә. Тукайдан көч алып яшәгән лирик герой өчен бөек шагыйрь белән бәйле һәрбер әйбер кадерле. Шуңа ул һәр татар өчен изге урынга – Тукай торган йортка – “Болгар” номерларына килә. Әлеге иске йортны ул үзе өчен “сихерле”, “изге” дип саный. Ул исә Тукай яшәгән чор, мәдәни-иҗитмагый мохит, шагыйрьнең әйләнә-тирәсе белән аерылгысыз бәйле. Тукай яшәгән чор символы булып Печән базары, аның янындагы мәчет (әсәр язылган вакытта айсыз-манарасыз) тора. Печән базары – татар өчен дөнья үзәге. Бу сату-алу урыны гына түгел, монда татарның борынгы тарихы да, бүгенгесе дә саклана – “халык монда җанын бушатты”. Дөнья буйлап сибелгән татарлар өчен Казан мәркәз булган кебек, Печән базарында һәр татарның бару һәм кайту юлы кисешә. Язмыш Тукайны да Кырлай һәм Җаек аша Казанга – Печән базары чатындагы “Болгар” номерларына алып килә. Әмма ул монда иске дөнья каршылыклары белән очраша. Барыннан да бигрәк зур тарихлы үткәнебезнең моң, сагыш, фаҗига белән тулы сәхифәләре үкенү хисе белән җанны яралый.

Поэмадагы фәлсәфи катлам халык язмышыннан аерылгысыз Тукай язмышы аша ачылган яшәү һәм үлем, фани һәм бакый, үткән һәм хәзерге, хакыйкать һәм ялган кебек мәсьәләләргә барып тоташа. Автор нинди генә кыенлыклар алдында да башын имәгән халкы алдында баш ия. Авыр вакытларда мәйданга Ш. Мәрҗани, Тукай, Х. Ямашев кебек бөек шәхесләр чыккан һәм “җан богавын, фикер богауларын” өзеп, халыкка юл күрсәткән. Автор шагыйрьлекнең төп вазифасын да халкына хезмәт итүдә күрә:

*“Иң бәхетле хис, дим, халкым белән*
*Горурланып язган чагымны;*
*Шул хис икән – җиз кыңгырау җанда,*
*Шул яшәтә икән шагыйрьне”.*

Халкың белән горурлану... Никадәр якын һәм кадерле төшенчә. Ә бит поэма язылган еллар – интернационализм идеяләре көчәеп, татар теле, мәдәнияте кысрыкланган вакыт. Шагыйрь шундый шартларда да киләчәккә өмет белән карый. Шуңа да аның өчен алыштыргысыз хакыйкать булып халык акылы, рухы тора: “Сыен аңа, таян аңа һәрчак”. Татар халкы тарихы фаҗигале һәм данлы сәхифәләргә бай булып, кызганыч ки, югалтулар күбрәк. Кан саркып торган яра – дәүләтчелекне югалту. Әмма халкыбызның эчке потенциалы зур. Ул гаять кыен шартларда да үз-үзен саклап калу мөмкинлеген тапкан. Шуңа да әлеге халыкка хөрмәт, аның белән горурланудан башлана.

Лирик геройның халык турындагы уйланулары яңадан Тукай, Әмирхан (Фатих), Рәмиләргә (Сәгыйть) барып тоташа. Автор үз чоры белән әлеге бөекләр яшәгән елларны чагыштыра һәм җанына тынычлык таба алмый:

*Чорны чорга якын куеп карыйм,*
*Вөҗданына аның – вөҗданым.*
*Өч гомерен аның яшәп җирдә*
*Чагыштырыр эшем бармы соң?*

Автор Тукайны татар халкына Аллаһыдан җибәрелгән дип кабул итә, шуңа да татарны Тукайдан аерып булмаган кебек, Тукайны да татардан аерып булмый. “Намус, вөҗдан, хакыйкать турында уйланулар аркылы лирик герой, Тукайда әлеге хасиятләрне барлап, изгелеккә ия шагыйрьне вөҗдан, намус һәм хаклык символы итеп күтәрә...” [Йосыпова, 2016: 230]

Поэмада җитди бер катламны Тукайның эш-гамәлләренә, иҗатына бирелгән бәя, аларның тарихи, милли әһәмиятен ачу алып тора. Бөек шагыйрь үзенең иҗаты белән халыкны “йокы”дан уята, күңеленә өмет хисе сала, хокуклары өчен көрәшкә чакыра – “Язганнары безгә бүләге”. Бу исә “Болгар” номерларындагы Тукай яшәгән кырыгынчы бүлмә белән бәйләнештә ачыла. Әлеге бүлмә тар, кечкенә, салкын булса да, рухы белән зур, иркле, “бердәнбер бәйсез дәүләт”. Монда Тукай рухы, Тукай моңы, Тукай җаны калган. С. Хәким төрле сурәт чаралары аша әлеге хөрлекне, Тукайга хас үзенчәлекләрне ача. Йозагы-ачкычы да булмаган бүлмәгә ярты “дөнья” сыйган. Дуслары аңа Казан, Уфа, Җаек яңалыкларын алып килгән. Бу булмәдә Пушкин, Лермонтов шигырьләре дә, Байронның шашкын хисле поэмалары да яңгыраган. Әлеге бүлмә уты Тукай иҗатыннан нур алып, татар халкының киләчәген яктырткан, төрки халыкларга барып җиткән. Әмма чорның салкын җилләре кырыгынчы бүлмәгә үтеп кереп, Тукайны өшетә. У җылы эзләп туган ягына кайта, казах далаларына бара, Петербургны урый, язмыш исә “Һаман да шул салкын номерга...” озата. Автор күңелендә әрнү, үкенү хисе:

*“Тырыш та син, ярлы да син, халкым,*
*Күршеләрең нинди бай бар да!*
*Берүзенә утыз өч бүлмәле*
*Йорт биләгән Гете Веймарда”.*

Ул риторик сорау белән үткәнгә карый: “Нигә Тукайны сакла кала алмадык?” Шагыйрьнең ачы язмышы һәрберебезгә сабак булып, бөекләребезнең кадерен белсәк иде, дип киләчәккә эндәшә автор: “Халкым, алда улларыңны сакла, / Авыр чорлар кичерә улларың...”

Поэманың соңгы өлешендә автор яңадан үз чорына әйләнеп кайта һәм Тукайның урыны турында уйлана. Иҗатында халык җаны, халык идеаллары чагылган Тукай милләт яшәеше символы булып тора:

“*Мәктәбем дә, телем дә ул Тукай,*
*Тукайдагы кебек тел кайда?*
*Мең елдан соң да бер синең, илем,*
*Кайтасыңны беләм Тукайга”.*

Автор горурлыгын яшерми, әнә Тукайга һәйкәлләр салына, аның исеме белән урамнар, уку йортлары атала, “Туган тел”е гимн буларак яңгырый. Поэма өмет-ышаныч хисләре белән тәмамлана.

Шул рәвешле, әлеге поэмада Тукайның үлемсез образы торгызыла. Автор халык җырларыннан килә торган хис-кичерешләр байлыгыннан, халыкчан афоризмнардан файдаланып, ике чор бәйләнешендә халык шагыйренең тормыш сәхифәләрен, теләк-омтылышларын һәм халыкның рухи дөньясына тәэсир итү көчен сурәтли. С. Хәким халык иҗатыннан килә торган тәгъбирләр, әдәби детальләр, символлар ярдәмендә яшәеш каршылыкларын ача, халыкның хыялында яшәгән дөнья сурәте тудыра. Шул нигездә Тукай иҗатының үз чорындагы, автор яшәгән дәвердәге һәм киләчәк буыннарга барачак кыйммәтен билгели.

**ӘДӘБИЯТ**

Вәлиев Р. Сезгә баш ияр көннәр // Хәким С. Сусау: шигырьләр, җырлар, поэмалар [кереш сүз авт. Р. Вәлиев]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. Б. 5-10.

Йосыпова Н., Мозаффаров Р. Сибгат Хәким // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда: 6 т.: 1960-1980 еллар [фәнни мөх.: Д.Ф. Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. Б. 272-291.

Йосыпова Н.М. XX гасырның икенче яртысы татар поэмаларында Тукай образы (С.Хәкимнең “Кырыгынчы бүлмә” һәм М.Әгъләмовның “Тукайдан хатлар” поэмалары мисалында) // Габдулла Тукай и тюркский мир: материалы международной конференции, посвященной 130-летию со дня рождения Г. Тукая. Казань: ИЯЛИ, 2016. Б. 229-233.

Хәким С. Тукай // Үз тавышың белән. Казан: Татар. кит. нәшр., 1969. Б. 128-145.

**Л.Р. ГАЗИЗОВА**

Университет Эрджиэс, Кайсери, Турция

## ПЕРЕВОД СТИХОТВОРЕНИЯ ГАБДУЛЛЫ ТУКАЯ «РОДНОЙ ЯЗЫК» НА РУССКИЙ ЯЗЫК: СТРАТЕГИИ ПЕРЕВОДЧИКОВ

**Аннотация.** Актуальность и научная новизна работы состоит в исследовании самых известных переводов программного стихотворения Габдуллы Тукая «Родной язык»на русский язык. Рассматриваются стратегии переводчиков в контектсе традиций русской и татарской культур, а также существующих методологических подходов к переводу национальной поэзии в целом.

**Annotation.** The relevance and scientific novelty of the work consists in the study of the most famous translations of Gabdulla Tukai's program poem "Native language" into Russian. The strategies of translators are considered in the context of the traditions of Russian and Tatar cultures, as well as existing methodological approaches to the translation of national poetry in general.

**Ключевые слова**: татарская поэзия, Габдулла Тукай, «Родной язык», стратегия переводчика.

**Keywords**: Tatar poetry, Gabdulla Tukai, "Native language", translator's strategy.

Стихотворение «Родной язык» принадлежит к лучшим образцам национальной поэзииРоссии. Созданное в 1910-м году молодым поэтом, произведение стало неофициальным гимном татар всего мира.

Приведем полностью оригинал стихотворения:

***Туган тел***

*И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!*
*Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.*
*Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән,*
*Аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән.*
*И туган тел! Һәрвакытта ярдәмең белән синең,*
*Кечкенәдән аңлашылган шатлыгым, кайгым минем.*
*И туган тел! Синдә булган иң элек кыйлган догам:*
*Ярлыкагыл, дип, үзем һәм әткәм-әнкәмне, ходам!*
[Тукай, 1986:1]

Нами выполнен подстрочный перевод стихотворения:

***Родной язык***

*О родной язык, о красивый язык, отца-матери язык!*

*Много чего о мире узнал через тебя.*

*Качая мою колыбель, пела на этом языке моя мать.*

*А потом ночами бабушка читала мне сказки.*

*О родной язык! Всегда чувствую твою опору,*

*С младенчества понимаешь и радость мою, и печаль мою.*

*О Родной язык! Я молился в детстве:*

*И просил у творца: защити моих маму-папу!*

На сегодняшний день каноническими считаются переводы стихотворения, выполненные Семёном Липкиным (1911-2003) и Равилем Бухараевым (1951-2012).

Как известно, художественный перевод может быть буквальным и вольным. Сторонником вольного перевода был Цицерон, который одним из первых в европейской культуре начал разрабатывать теорию художественного перевода. В своём сочинении «О пределах добра и зла» он писал: «...нет необходимости переводить слово в слово по обычаю плохих переводчиков, если существует более употребительное слово с тем же значением»[Цицерон, 2000: 2].

Стихотворение написано от первого лица. Для лирического героя стихотворения родной язык – живая субстанция, точнее говоря, самостоятельный субъект, к которому он обращается с вдохновенным монологом.

Для стихотворения характерны доверительная интонация, простота слога, безыскусность имелодичность. Это негромкое по своему накалу, но эмоциональное стихотворение. Эмоции эти – глубинные, сущностные.

В большинствеизданий советского периода опубликован перевод Семёна Липкина.

***Родной язык (Пер. С. Липкина)***

*Родной язык — святой язык, отца и матери язык,*

*Как ты прекрасен! Целый мир в твоем богатстве я постиг!*

*Качая колыбель, тебя мне в песне открывала мать,*

*А сказки бабушки потом я научился понимать.*

*Родной язык, родной язык, с тобою смело шел я вдаль,*

*Ты радость возвышал мою, ты просветлял мою печаль.*

*Родной язык, с тобой вдвоём я в первый раз молил творца:*

- *О боже, мать мою прости, прости меня, прости отца.*

[Тукай, 1957: 3]

В 90-е годы двадцатого века появился перевод этого стихотворения, выполненный известным российским поэтом Равилем Бухараевым, который вырос в татароязычной среде.

***Родной язык (Пер. Р.Бухараева)***

*О язык родной, певучий, о родительская речь!*

*Что еще на свете знал я, что сумел я уберечь?*

*Колыбель мою качая, тихо-тихо пела мать.*

*Подрастая, сказки бабушки я начал понимать.*

*О язык мой, мы навечно неразлучные друзья,*

*с детства стала мне понятна радость и печаль твоя.*

*О язык мой, как сердечно я молился в первый раз:*

*«Боже, – я шептал, – помилуй мать, отца, помилуй нас.»* [Тукай, 2006: 4]

Рассмотрим первое двустишие. В оригинале содержится междометие «И», которым начинается стихотворение и которое можно перевести на русский язык как «О». В татарских народных баитах, а также в прямой речи татар оно часто встречается. Здесь же это восклицание сразу в двух местах первой строки задаёт высокий стиль и торжественность. Равиль Бухараев, который хорошо знал татарскую литературу и культуру, сохраняет это междометие. Семён Липкин опустил это восклицание, считая, что оно не несёт большого смыслового значения.

Тукай называет свой язык языком «отца-матери»(«әткәм-әнкәмнең теле»). Семён Липкин переноситэто понятие в свой перевод, точно интерпретируя идею автора. Равиль Бухараев заменяет его «родительским» языком, применяя лексическую трансформацию. Налицо снижение доверительности.

При переводе большой задачей становится введение в ткань стиха специфических понятий и вещественных деталей, свойственных бытованию этого народа. В стихотворении Тукая есть архаизмы. Например, *бишек* (подвесная люлька), *кыйлган догам* (произнесённая молитва), *ярлыкагыл* (помилуй или отпусти грехи). Переводчики дали современный перевод этих понятий, не сохранив устаревшие их значения.Данная стратегия оправдывает себя: благодаря этому, переводы имеют современное звучание.

Вторая строфа носит повествовательный характер. Переводы Липкинаи Бухараева носят почти дословный характер, сохраняя все оттенки оригинального произведения.

Оба переводатретьей строфы выглядят поэтично: «Ты радость возвышал мою, ты просветлял мою печаль» (Липкин) и «С детства стала мне понятна радость и печаль твоя» (Бухараев). При этом образ *опоры* в первой строке строфы не вошёл в их переводы. Возможно предположить, переводчики решили, что смысл языка как опоры растворён в самом стихотворении.

В последней строке автор обращается к Богу, просит защитить отца-мать. Таким образом, повторное упоминание обоих родителей словно замыкает это стихотворение, придаёт ему личный оттенок, хотя говорится о важнейшей для каждого народа проблеме родного языкап. Бухараев, как и Липкин, упоминает обоих родителей. Возможно, что переводчик тем самым акцентировал внимание читателя на отце-матери, упомянув их лишь в последней строфе.

В поэтических переводах сохранился темперамент лирического героя и его активная позиция. И это свидетельство большого мастерства переводчиков, поскольку они уловили и сохранили важное свой ство текста Тукая, проявляющееся в преобладании объективного начала над субъективным в структуре художественного образа» [Аминева, 2013: 5].

Таким образом, оба переводчики воссоздали не только формальные признаки стихотворного произведения, но и «дух» оригинала. Им удалось сохранить ключевые образы и понятия программного стихотворения татарской поэзии. Некоторые отклонения от оригинала были оправданы, поскольку потери при художественном переводе неизбежны. Но Липкину и Бухараеву удалось свести их к минимуму. Это пример того, что масштаб таланта переводчиков в данном случае сопоставим с талантом автора переводимого произведения. Их переводы и сегодня звучат современно и актуально.

Семён Липкин и Равиль Бухараев внесли посильный вклад в художественный перевод поэзии великого татарского поэта на русский язык.

## ЛИТЕРАТУРА

Тукай Г. Әсәрләр: 5 томда. Казань: Татар. кн. изд-во, 1986. Т.2. – 399 с.

Марк Туллий Цицерон. О пределах блага и зла. Парадоксы стоиков / Пер. Н.А. Федорова. М., 2000. – 133 с.

Тукай Г.Антология татарской поэзии: Стихи. Казань: Таткнигоиздат, 1957. – 146.

Тукай Г. Избранное: Стихи и поэмы / Габдулла Тукай; Сост. Г.М.Хасанова, С.В.Малышев. Казань: Татар. кн. изд-во. – 2006. – 192 .

Аминева В.Р. Межлитературные текстовые образования: закономерности формирования и фунционирования // Знание. Понимание. Умение, 2013. № 2.

**Г.Р. ГАЙНУЛЛИНА, Л.Р. ФӘЕЗОВА**

Казан федераль университеты, Казан

## Р.ТУФИТУЛЛОВАНЫҢ “ЯЗМЫШ ҖИЛЕ” РОМАНЫНДА ТАТАР ХАТЫН-КЫЗЫ ИДЕАЛЫ БИРЕЛЕШЕ

**Г.Р. ГАЙНУЛЛИНА, Л.Р. ФАЕЗОВА**

Казанский федеральный университет, Казань

## ИДЕАЛ ТАТАРСКОЙ ЖЕНЩИНЫ В РОМАНЕ РОЗЫ ТУФИТУЛЛОВОЙ “ВЕТЕР СУДЬБЫ”

**Аннотация.** В татарской прозе образ идеальной женщины воссоздавался в течение всего XX века. Образ великой женщины Уммугульсум Камаловой-Акчуриной, воссозданной в новом романе Розы Туфитулловой “Ветер судьбы” примечателен тем, что отсылает к национальному идеалу и прозы начала XX века, и второй половины. Биографический материал, обогащенный историческим материалом, приравнивает произведение к прозе Г.Исхаки, Ф.Амирхан, А.Гилязова, А.Еники. В статье впервые дан филологический анализ произведению в аспекте изображения идеала татарской женщины.

**Abstract.** In Tatar prose, the image of the ideal woman was recreated throughout the twentieth century. The image of the great woman Ummugulsum Kamalova-Akchurina, recreated in the new novel by Roza Tufitulova “Wind of fate " is notable for the fact that it refers to the national ideal of prose of the early twentieth century and the second half. Biographical material, enriched with historical material, equates the work to the prose of G. Iskhaki, F. Amirkhan, A. Gilyazov, A. Eniki. The article provides the first philological analysis of the work in the aspect of the image of the Tatar woman.

**Ключевые слова**: роман, хронотоп, национальный идеал.

**Keywords:** novel, chronotope, national ideal.

Мәкаләдә сүз Роза Туфитуллованың 2019 елны дөнья күргән “Язмыш җиле” дигән романындагы Гөлсем образы, узган гасыр башында татарның музасы, XX йөз башында формалашкан татар хатын-кызы идеалы, Чистай кызы Өммегөлсем Камалова-Акчурина турында бара.

Романның хронотобы бу образның әдәби эшләнүендә хәлиткеч рольне уйный. Автор укучысын XX гасыр башындагы татар мохитенең, шул ук вакытта тулаем Россия җәмгыятенең рухи атмосферасына күмә. Гөлсем Россия империясенең төньяк башкаласы Петербургта, Бестужев югары курсларында (Россиядә хатын-кызлар өчен иң беренче югары уку йорты) белем ала. Мәгълүм булганча, Петербург – ул вакытта татар

дөньясы өчен дә мәдәни үзәкләрнең берсе. Биредә беренче татар газетасы – “Нур” чыга, ахун Гатаулла Баязитов, дин галиме Муса Бигиев яши. Татар милләтенең идеологы Исхакый әледән-әле төньяк башкалага килеп чыга, аның һәм Садри Максудиның мәкаләләре өзлексез рәвештә “Нур”да басылып бара. Һәм менә шушындый мәдәни тормышның таҗы – Петербургка Тукай килә. Гөлсем образының төп билгеләмәсе Тукай белән бәйле эпизодларда бары тик романтик ноталарда яңгыраш ала: ул – “кара төннең ак фәрештәсе”.

Икенче яклап, Петербург – рус мәдәниятенең көмеш гасыры дип аталачак тектоник үзгәрешләр барган урын да. Д.Мережковский, К.Бальмонт, А.Блок, А.Ахматова, О.Мандельштам кебек шагыйрьләрнең исемнәре, хәтта ки “Бродячая собака” арт-кафесы Бестужев курсисткаларына таныш булмый калмагандыр. Романда моңа дәлил дә бар: «1911 елның ноябрь башында Гөлсем укыган институтка курсисткалар белән очрашуга бер төркем шагыйрьләр чакырыла. Алар арасында бердәнбер хатын-кыз шагыйрә Анна Ахматова да була» [Туфитлулова, 2019: 28]. Шәһәрнең, гомумән, иҗади мохитнең шигырь белән генә яшәгән чагы әле. Шигырь, ягъни акыл белән хис квинтэссенциясе атмосферада ялангач нерв кебек зыңлап тора. Роза Туфитуллова әсәрендә шигырьләрне шуның өчен дә мулдан бирә. Гөлсемгә Джоконда дип дәшүләренең тамырын әнә шул үзгәрешләрдән эзләргә кирәк. Аның да мотивлары көнбатышка барып тоташа.

XIX гасырның икенче яртысында Франциядә башланып киткән позитивистик, хәтта ки антиклерикаль мәдәният Флоренция даһие Леонардо да Винчиның иҗатына кызыксыну уята. Аның моңа кадәр әллә ни билгеле булмаган “Джоконда”сында символистлар (мәсәлән, Шарль Бодлер) өр-яңа чалымнар күреп ала: Мона Лизаның серле елмаюы символ дәрәҗәсенә җиткерелә, шул рәвешле портрет сәнгать тарихындагы иң зур табышмакка әйләнә [Альберто Анджело]. Джоконда мифы 1911 елда – портретны Луврдан урлап алып чыккач формалашып бетә. Аны 1913 елга кадәр эзлиләр. Әлбәттә, бу турыда Россиядә дә иҗади мохит хәбәрдар булып торган. Әлбәттә, югалган матурлыкны эзләгәннәр: Исхакый белән Анна Ахматова аны татар кызы Гөлсем Камаловада тапкан. Автор Роза ханым XX гасыр башы татар музасының әлеге исем белән аталып йөртүенә кат-кат басым ясый: «Институт белән танышып йөргәндә, кунаклар баскыч янында серле елмаюга төренеп берьялгызы басып торган зифа буйлы кызга игътибар итми калмыйлар.

– Бу кызыгыз Джоконданы хәтерләтә. Итальян кызы түгелдер бит? – дип сорый Анна Ахматова.

– Юк, юк, – ди кунакларны озатып йөрүче олы яшьтәге мөлаем ханым. – Ул – мөселман кызы. Эмма, якынрак кил әле. Кунаклар синең белән танышырга тели, – дип, кызны үзләре янына чакырып ала.

– Мин – Чистайдан. Кама елгасы ярындагы иң гүзәл шәһәрләрнең берсеннән. Татар кызымын.

– Сез бик тә Джокондага охшагансыз. Аның хакында ишеткәнегез бармы? – ди Ахматова, әңгәмәне дәвам итеп.

– Ул бөек Леонардо да Винчиның иң данлыклы портретларыннан берсе дип беләм. Әлеге портрет Парижда, Луврда саклана, – дип җавап бирә Гөлсем, аз гына да икеләнмичә»[Туфитуллова, 2019: 28].

Татар кызына Джоконда исеменең чынлап торып ябышмый калуы Тукай белән бәйле:

«Ә нигә сез аңа «Джоконда» дип эндәшәсез? – дип сорады Тукай, кыз чыгып киткәч.

«Өммегөлсем», дип, эчтән генә өзелгән, үзе дә хыялый елмайган егетләрнең берсе җавапны озакка сузмады.

–Нигә дип... Серле елмаюы өчендер. Гаяз ага Исхакый Петербургта чагында аңа һәрчак «Джоконда», дип эндәшә иде. Ул: «Мәшһүр итальян рәссамының атаклы портретын хәтерләтә», – дигән иде.

– Аның үз исеме тагын да килешлерәк, минемчә, – диде Тукай, егетләргә карамаска тырышып» [Туфитуллова, 2019: 28].

Тукай хаклы: да Винчиның Джокондасы, белгечләр фикеренчә, үзендә фәрештә белән иблис башлангычларын берләштергән тәкъдири хатын-кыз архетибын гәүдәләндерсә, Роза Туфитуллова Гөлсем образында аның фәрештәлеген ассызыклап бара. Автор аңа карата “ак фәрештә” эпитетын мулдан куллана. Илһамландыручы муза буларак, Гөлсем образында фәрештә башлангычы сюжетта Габдулла Тукай, Гаяз Исхакый, Мәгъҗан Җомабаев сызыклары аша гамәлгә ашырыла. Гәрчә Гөлсем-Джоконда бу шәхесләргә язмыш җиле булып кагылып узса да, фәрештә канаты сыйпаган кебек кенә итеп, аларның тормышларын бизәп кенә үтә, ә аларның һәлакәтенә сәбәпче булмый. Әсәрнең исеменә үк чыгарылган “язмыш җиле” метафорасының семантик яктан бер вазифасы шушы. (Бу урында искәрмә ясап, шуны әйтергә кирәк: Роза Туфитуллованың “Язмыш җиле” романы 2019 елда “Гөлсем” исеме белән Төркиядә төрек телендә китап булып  басылып чыкты).

Икенчедән (автор үзе дә метафораның шушы вазифасына өстенлек бирә кебек), язмыш җиле – татар милләте тарихының кыска, әмма хәлиткеч олы бер дәверенең җил искәндәй кебек кенә итеп юкка чыгуына, Россия җәмгыятендәге катаклизмнарга ишарә ул.

Гомумән, әсәрдә “мәхәббәт сакчысы”, “ак фәрештә”, “язмыш җиле”, “шәфкать туташы” кебек тропларның күплеге әсәрнең эмоциональ катламын көйли, шуның бәрабәренә аның экспрессивлыгын тәэмин итә. Шул ук вакытта аларның һәркайсының тирәндәрәк яткан эчке мәгънәсе бар. Әсәргә аерым бүлек булып кергән “Шәфкать туташы”н да туры һәм күчерелмә мәгънәдә аңларга була. Гөлсемнең Балкан сугышы вакытында, укуын калдырып, Төркиягә шәфкать туташы булып китәргә алынуы, гомумән, рухи яктан үзен югары идеалларга корбан итәргә әзерлеге янә шул чорның мәдәни логикасы белән аңлатыла. Белүебезчә, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында татар дөньясы көнбатыш мәдәнияте контекстына йөз тота башлый. Л.Гумилевның пассионар шәхес концепциясе нәкъ шушы вакыттагы шәхес тибы алышыну вакытында барлыкка килә. Моңа кадәр обывательлек дәрәҗәсендә тормыш куып яшәгән кешеләр тибына алмашка югары максатлар белән илһамланган романтик шәхесләр тибы килә. Татар дөньясында ул югары максат – милләт була. Гөлсем – әнә шундый пассионар шәхес тибы, ул үзен башкалар бәхете хакына корбан итәргә әзер. Аның Истанбул университетында алты мең төрек хатын-кызы катнашында зур җыенда ясаган чыгышы гына да моңа дәлил булып тора. Ул гүя татар әдәбиятындагы мәгърифәтчелек реализмы әсәрләреннән реальләшкән зат. Нәкъ менә либераль карашлар белән дә коралланган мәгърифәтчеләр беренче булып хатын-кызларны укымышлы, зыялы, ир-атлар белән иңгә-иң яшәргә хокуклы зат, ирекле шәхес итеп күрергә теләгән иде бит. Мәгърифәтчеләрнең хатын-кыз идеалында шәфкатьлелек, игелеклелек сыйфатлары да гыйлемлелек белән бер дәрәҗәдә хуплана, алай гына да түгел идеаллаштырыла. Бу җәһәттән Гөлсем теләк-омтылышлары белән Гаяз Исхакыйның “Мөгаллимә” (1913) драмасындагы Фатыйма образына да якын. Исхакыйның җәмгатьчелектә шактый бәхәс уяткан “Мөгаллимә” драмасының герое  пассионарий белән обыватель

арасындагы дилемманы гәүдәләндерүе белән җәмгыять каршына зур сорау куя: “Адәм баласы өчен шәхси бәхет өстенрәкме, әллә милләт, халык бәхете өчен көрәшме?” Исхакыйның музасы Гөлсем Камалова чынбарлык тормышта бу дилемманы бер якка да хилафлык китермичә хәл итә: 1913 елда ул Сембер фабриканты Абдулла Акчуринга кияүгә чыга, мөгаллимлеген ташламый, киресенчә, матди ягы яхшыру сәбәпле, милләтенә, халкына тагын да күбрәк хезмәт итү мөмкинлегенә ия була. Хәтта инкыйлабтан соң, бөтен байлыклары тартып алынгач та, Гөлсем хыялына тугры кала. Әмма Исхакый үзенең илһам чыганагы булган туташының бай сәүдәгәр хатыны булып китүен хупламаган булса кирәк: шактый еллар узып, Кызылъярда (Петропавловск) очрашкач, Гөлсемнең күңелен яралардай сүзләр дә әйтә: «Бай хатыны булдым, диген инде, Гөлсем?! Байлыкка чумасым килде, диген... Хыялыма хыянәт иттем, диген...» [Туфитуллова, 2019: 9]. Кем белә, бәлки, “Мөгаллимә” драмасы Гөлсемнең туй хәбәре Гаяз абыйсына килеп ирешкәч язылгандыр? Әсәрдә Исхакый – Гөлсем сызыгы Пигмалион турындагы миф сюжетындагыча төгәлләнә. Исхакый Төркиядә мөһаҗирлектә үзенеке генә булган Гөлсемне - мөгаллимә-шәфкать туташын таба: «Әнә, башкалардан чак кына аерылыбрак торганы – Гөлсем ич моның! Гөлсем! Тукта, нәкъ шул картинаның алдында ап-ак мәрмәрдән ясалган сылу кыз да Гөлсем ләбаса! Әйе, әйе, ак гүзәл сын астына «Гөлсем» дип язып та куелган. Исхакый түзмәде, таш сынны кочаклап ук алды. Билгеле, шул минутта ук күзәтеп торучы музей хезмәткәре дә килеп җитте.

– Пәһале бәй, экспонатларга кул белән кагылырга рөхсәт ителми.

Исхакый, гафу үтенеп, тиз-тиз эшнең нәрсәдә икәнлеген аңлатырга тотынды. Үзе һаман «Гөлсем»нән күзен ала алмады. Еларлык яшьләре кипте дип уйлаган иде дә, үзеннән-үзе бите буйлап кайнар яшь акты»[Туфитуллова, 2019: 85]. Димәк ки, Роза Туфитуллованың Гөлсем образы шәхси бәхеткә тиенүе белән (яратып кияүгә чыга, өч тапкыр ана булу бәхетенә ирешә) XX гасыр башындагы хатын-кыз идеалыннан күпмедер дәрәҗәдә аерыла да. Әмма барыбер төрле сословие, төрле карашлы кешеләр өчен үз вакытында ук чын мәгънәсендә идеалга әверелә. Гөлсем кебекләр күп була ул заманда: автор аның белән бергә Төркиягә шәфкать туташлары булып киткән Петербург кызы Рокыя Юнусова, Ташкенттан Мәрьям Якупова, Ростовтан Мәрьям Поташеваны, Чистай кызлары Зәйтүнәне, Сания Гыйффәтне шулай ук бары тик романтик рухта сурәтли.

Инкыйлабтан соңгы авыр елларда да, репрессияләр чорында да, Бөек Ватан сугышы чорында да, аннан соңгы каршылыклы заманда да Гөлсем Камалова-Акчурина үз йөзен, үз мәсләген югалтмый.

Әсәрнең XXI гасырда барлыкка килүе – әнә шул татар хатын-кызы идеалын сагыну ул.

Автор Роза Туфитуллова Гөлсем образын эшләгәндә, аның эчке дөньясына, кичерешләренең, эш-гамәлләренең мотивларына үтеп керүне, аларны тирән анализлап шәрехләүне максат итеп куймый, монысын ул әзерлекле укучының үзенә калдыра. Роза Рәхмәтулла кызы эзтабар логикасына таянып, музаның биографиясен сәнгати алымнар кулланып торгыза, художестволы алымнар белән документальлекне кирәк кадәрле генә баланста тотып, һәр яклап камил булган матурлык эталонын, яңа хатын-кыз образын тудыра.

## ӘДӘБИЯТ

Туфитуллова Р.Р. Язмыш җиле. Роман // Казан утлары, 2019. № 4, 5.

Альберто Анджело. Глаз “Джоконды. Секреты Моны Лизы // https://knizhnik.org/alberto-andzhela/glaza-dzhokondy-sekrety-mony-lizy/1 (мөрәҗәгать итү вакыты 23.09.2020)

**Г.Р. ГАЛИУЛЛИНА**
Казан федераль университеты, Казан

## ТАТАР ХАЛЫК ТАБЫШМАКЛАРЫНДА СИНОНИМНАР

**Г.Р. ГАЛИУЛЛИНА**
Казанский федеральный университет, Казань

## СИНОНИМЫ В ТАТАРСКИХ НАРОДНЫХ ЗАГАДКАХ

**Аннотация.** В статье рассматривается функционирование синонимов в составе татарских народных загадок. Внимание уделяется идеографическим и стилистическим синонимам. Как показывает анализ, синонимы в текстах загадок способствуют раскрытию свойств загаданного объекта. Синонимический ряд текстов охватывает не только общеупортебительную лексику. Наблюдается широкое использование диалектной, просторечной и архаичной лексики.

**Abstract.** The article discusses the functioning of synonyms in the composition of Tatar folk riddles. Attention is paid to ideographic and stylistic synonyms. As the analysis shows, synonyms in the texts of riddles contribute to the disclosure of the properties of the hidden object. The synonymous series of texts covers not only the general reputable vocabulary. There is a wide use of dialectal, vernacular and archaic vocabulary.

**Ключевые слова:** татарский язык, синонимы, загадки, татарский фольклор

**Keywords:** Tatar language, synonyms, riddles, Tatar folklore

Табышмаклар – халык авыз иҗатының бик борынгыдан килә торган, үзендә халыкның күпгасырлык мирасын чагылдырган кыска, тотрыклы, ритмик характердагы төре. Мәкаль-әйтемнәрдә кебек үк, аларда борынгы мәҗүсилек ышанулары, сүзнең илаһи көченә инану күзгә күренә. Үзенең эчтәлегендә читләтеп әйтү, күчерелмә мәгънәлелек күзгә ташланган халык авыз иҗатының бу төре халык тормышын, тарихи чынбарлыкны төрле яклап чагылдыруда гаять әһәмиятле роль уйный. Борынгы чорларда ук барлыкка килеп, шактый үсешкә ирешкән, өлкәннәр һәм балалар телендә бик яратып кулланыла торган табышмакларда телнең бөтен байлыгы тулысынча чагылыш таба. Татар табышмакларының тагын бер үзенчәлекле ягы – халыкның гореф-гадәтләре, йола-уеннарында да табышмаклар төрле функция башкарганнар. Халкыбыз үз уй-фикерен табышмаклар аша җиткерүне кулай күргән. Күренекле галим М.Х. Бакиров билгеләвенчә, “табышмак ул – табыла торган предмет яки күренешне атамыйча яки шартлы исем белән атап, аның урынына төп үзенчәлекләрнең тасвирламасы бирелә торган поэтик әсәр” [Бакиров, 2012: 111].

Табышмакның җавабын табучы төрле яклап макталса, тапмаучы кешегә тискәре караш булган. Бу гадәт төрле туй йолаларында, яшьләр уеннарында, җыр текстларында сакланып калган. Табышмак жанрының, алда әйтелгәнчә, татар халкы арасында электән популяр булуы, теле ягыннан бик үзгәреш кичермичә, хәзерге телгә килеп җитүе табышмакларда тел-сурәтләү чараларының бик төрле кулланылуына ишарә итә. Әлеге мәкалә кысаларында без барлык тел чараларының да кулланылыш үзенчәлекләрен

күзәтүне максат итеп куймыйча, табышмакларда еш очрый торган синонимнарның кулланылыш үзенчәлекләренә тукталырга булдык[1].

Синонимнар татар теленең байлыгын гына күрсәтеп калмыйлар, бәлки халыкның, телнең тарихына үтеп керү өчен дә ярдәмче чара саналалар. Синонимнарның төп вазифасы – сөйләмне тәэсирле, үтемле итү, мәгънәнең нечкә төсмерләрен мөмкин кадәр төгәл бирү, охшаш, әмма бер-берсеннән аерылып торган чынбарлык күренешләрен атау [Татар лексикологиясе, 2015: 166]. Синонимнар татар халык табышмакларында кулланылып, фикерне ачыкларга ярдәм итәләр.

Табышмаклар тыңлаучылар алдына асылы читләтеп әйтү аша белдерелгән билгесез әйберне эзләп табу бурычы куялар. Жанр табигате таләп иткәнчә, табышмакта әйбер хакында беркайчан да турыдан-туры әйтелми, бәлки ул сурәтләп, тасвирлап кына күрсәтелә. Сурәтләү чараларын барлыкка китерүдә синонимнар төп таяныч, терәк булып торалар да инде. Синонимнар ярдәмендә әйләнә-тирә мөхиттәге күренеш, предмет һәм процесслар чагылыш табалар. Халыкның образлы фикер йөртү осталыгы, тапкырлыгы, зирәклеге тел чаралары ярдәмендә гаять төгәл, ачык итеп формалаша. Табышмаклар нигезенә салынган эчтәлекне төгәл, дөрес бирүдә синонимнар алыштыргысыз роль уйныйлар. Табышмакта исә фикер конкрет, ачык бирә алу төп таләп санала, шунсыз халык авыз иҗатының бу төре әһәмиятен тулысынча югалтыр иде. Бу максатны гына күздә тотып та, әлеге жанрда мәгънәдәш сүзләрнең ни дәрәҗәдә кирәкле булуын күзаллау кыен түгел.

Татар халык табышмакларында синонимнарның телдә киң таралыш тапкан идеографик һәм стилистик төрләрен күпләп очратып була. Алар төрле синонимик оялар барлыкка китереп, шактый уңышлы кулланылалар.

Фикер төгәллегенә ирешүдә бары мәгънә төсмерләре белән генә аерыла торган идеографик синонимнар зур роль уйныйлар. Татар халык табышмакларында алар бик киң таралган, мәсәлән: *Ялмак уты ялтырык, **тавышы**, **тыны** юк. (Аҗаган); **Чакырдылар, дәштеләр**, барган идем – качтылар. (Яңгыр); Минем белән уйныйлар, кулларыннан куймыйлар. **Иркәлиләр, сөяләр**, йокла, иркәм, диләр. (Курчак)*

Мисаллардан күренгәнчә, биредә идеографик синонимнар кулланылыш даирәсе ягыннан гомумхалык сүзләрен тәшкил итәләр. Табышмаклар әйләнә-тирә чынбарлыктагы предметларны, күренешләрне төрле яклап тасвирлауда телнең барлык катламнарын, җанлы сөйләм теленең барлык үзенчәлекләрен эшкә җигәләр. Аларда диалекталь сүзләр, гади сөйләм лексикасы, искергән сүзләр, гомумкулланылыш сүзләре белән бергә килеп, халыкның сөйләм теле үрнәкләрен бирәләр. Табышмаклар телендә татар халкының милли күзаллавы, яшәеш кануннары синонимнар аша ачык бәян ителә. Табышмаклар составында төрле даирә сүзләре очрау аларның телен бозмый, киресенчә, халыкның аралашу теленә якынайта гына. Бу, үз чиратында, гаять дәрәҗәдә табигый яңгырый: *Ишеккә килде **сөмсәеп**, туктап торды **турсаеп**, Ишектән керде **иңкәеп**, түргә менде **туңкаеп**. (Суык); Яндагысы **янтайган**, саздагысы **чүңкәйгән**, Агалары туры утырган, түрдәгесе **түңкәйгән**. (Түмгәкләр)*

Табышмакларның борынгыдан ук телебездә киң кулланылганлыгын алар составында очраган синонимнарның искергән вариантлары да исбатлый. Мәсәлән: *Бер картның өч улы бар: Өчесе сары **көпе** кия, Өчесе сары **чикмән** кия, Өчесе яшел күлмәк кия, Өчесе ак тун кия (Ел фасыллары).* Әлеге мисалларда *көпе, чикмән* сүзләре, өс

---

[1] Мисаллар Татар халык иҗаты. Табышмаклар. Казан, 1977. – 271 б. җыентыгыннан алынды.

киеменең төрләрен белдереп, *күлмәк, тун* сүзләре белән гомуми бер синонимик парадигма барлыкка китерә.

Табышмакларның диалекталь вариантлары белән әдәби телгә нигезләнгәннәре янәшә шактый киң кулланылалар: ***Бәләкәй** генә бөкре бөтен кырны бетерде.* ***Кечкенә** генә бөкре ни бар кырны бетерде. (Урак, иген уру); Кечкенә казанның ашы тәмле. Кечкенә генә бакрач, эче тулы тәмле аш. (Чикләвек);* ***Такта сарай** эченә кара башлы мал яптым. Бер **пайыт** астында илле егет (Каплы шырпы).* Пайыт – лапас, лапас түбәсе [Татар теленең …, 2009: 516].

Стилистик синонимнарнарның табышмакларда күп таралыш табуы ачыкланды. Табышмаклар – халыкның иҗат җимеше, аларда яшәү, тормыш итү үзенчәлекләре, холык-фигыль, фикер йөртү ачыктан-ачык күренә. Шунлыктан, төрле эмоциональ-эспрессив төсмерле сүзләр ярдәмендә фикер аныклыгына, төгәллегенә ирешү, аларга билгеле бер дәрәҗәдә хис-тойгы салу табышмаклар теле өчен гадәти. *Котыра да үкерә, бөтен җирне тутыра. (Буран)* табышмагында *котыра, үкерә* синонимнары аша җавапта бирелгән сүзнең үзлекләрен, аның характерлы билгеләрен бирергә тырышу күзгә ташланса, *Кара җиргә казан астым, кайнамыйча пеште. Бер акыллыга әйттем, – аңлады да белде, Бер җүләргә әйттем, –* ***хыхылдады, көлде**. (җир җиләге)* табышмагында исә тыңлаучыга киная дә сизелә.

Табышмакларның югарыда караган төрләре милли үзенчәлекләргә бәйле, аларның чишелешен тулаем аңлау өчен татар халкының милли күзаллауларын, үткән тарихи юлын белү дә сорала. Мисал өчен, *Чулпан да ул, Зөһрә дә, Венера да кайчакта. Шундый матур балкып тора Кояш уянган чакта (йолдыз)* табышмагында татар телендә төрле чорларда үтеп кергән *Зөһрә, Венера* атамалары белән бергә, төрки-татар чыгышлы *Чулпан* атамасы кулланылып, телебез үсеше этапларын дөрес күзаллаган хәлдә, җавап эзләүчегә объектны дөрес табарга юл күрсәтелә.

Гомумән алганда, синонимнар татар халык иҗатының бер төре булган табышмакларда фикерне ачыкларга, төгәлрәк әйтергә ярдәм итәләр. Табышмаклар составында идеографик һәм стилистик синонимнар белән бергә, абсолют һәм контекстуаль синонимнар да куланыла, әмма аларның таралышы зур түгел. Синонимнар ярдәмендә кабатлаулардан котылырга омтылу, жанр таләбенә туры китереп фикерне кыска, әмма төгәл бирү күзәтелә. Табышмакларның зур күпчелеге кешеләрнең көндәлек гамәлләре, тормыш тәҗрибәсе нигезендә иҗат ителәләр. Аларның байтагы хезмәткә, эш коралларына, тормыш-көнкүреш әйберләренә бәйләнгән булулары, шуның белән бергә, табышмакларда кешеләрнең табигать күренешләренә мөнәсәбәтләре, аларны үзенчә бәяләве, андагы әйберләрне һәм аларның үзгәрешләрен реаль тормышта булган әйбер-күренешләр, кешеләрнең гореф-гадәтләре, тормышы белән чагыштырып күз алдына китерергә омтылу сизелә. Бу эштә синонимнар гаять зур булышлык итәләр.

## ӘДӘБИЯТ

Бакиров М Х. Татарский фольклор. Казань: Ихлас, 2012. 400 с.

Мәхмүтов Х.Ш. Борынгылар әйткән сүзләр. Казан, 2002. 256 б.

Татар лексикологиясе: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р. Галиуллина. Казан: ТӘһСИ, 2015. Т. I. 352 б.

Татар теленең зур диалектологик сүзлеге. Казан: Татар. кит. кәшр. 2009. 839 б.

Татар халык иҗаты. Табышмаклар. Казан, 1977. 271б.

**Ф.Г. ГАЛИМУЛЛИН**
Казан федераль университеты, Казан

## ТАҖИ ГЫЙЗЗӘТ ИҖАТЫНДА ТАТАР ХАЛКЫ МӘНФӘГАТЬЛӘРЕ ЧАГЫЛЫШЫ (ТАҖИ ГЫЙЗЗӘТКӘ 125 ЕЛ)

**Ф.Г. ГАЛИМУЛЛИН**
Казанский федеральный университет, Казань

## ВОПЛОЩЕНИЕ ИНТЕРЕСОВ ТАТАРСКОГО НАРОДА В ТВОРЧЕСТВЕ ТАЗИ ГИЗЗАТА (К 125-ЛЕТИЮ СО ДНЯ РОЖДЕНИЯ)

**Аннотация.** В статье раскрываются особенности творчества Т. Гиззата, отражающие специфику татарского литературного процесса 1930-40-х годов, представлен обзор жизни и творчества писателя. Творчество татарского писателя рассматривается в контексте его взаимосвязей с известными деятелями татарской культуры первой половины XX века: с К. Тинчуриным, С. Сайдашевым, А.Ключаревым и др. В произведениях Т. Гиззата отражались черты национального характера, быта и интересов татарского народа, что было большой смелостью писателя для его времени.

**Abstract.** The article reveals the features of T. Gizzat's creativity, reflecting the specifics of the Tatar literary process of the 1930s-1940s, provides an overview of the life and work of the writer. The work of the Tatar writer is considered in the context of his relationship with famous figures of Tatar culture of the first half of the twentieth century: with K. Tinchurin, S. Saydashev, A. Klyucharev and others. The works of T. Gizzat reflected the features of the national character, life and interests of the Tatar people it was a great courage of a writer for his time.

**Ключевые слова**: Тази Гиззат, татарская литература, татарская драматургия, народность, интересы татарского народа

**Keywords:** Tazi Gizzat, Tatar literature, Tatar drama, nationality, interests of the Tatar people

*Җилкәне юк тал каек*
*Җилгә каршы баралмас.*
*Калканы юк ир-егет*
*Яуга каршы торалмас.*

Дастаннардагыча тирән мәгънәле сүзләр. Аларны атаклы драматургыбыз Таҗи Гыйззәтнең “Алсук таң” әсәрендә гәүдәләндерелгән умартачы карт Гозәер улларына әйтә. Акыл иясе карт моның белән бик үткен фикер үткәрә: Тормыш дулкыннарының халәте бертөрле генә тормый. Беренче карашка тыныч кына булып тоелганнарының да эченә биниһая зур көч яшерелгәнлеге сер түгел. Аларны ниндидер бер сәбәп хәрәкәткә китерергә, бөтен нәрсәнең астын-өчкә китерерлек көчкә әверелдерергә мөмкин. Андый гарасатлар вакытында чыдамлы җилкәнле, ягъни ныклы иманы булганнар гына юлларыннан тайпылмаска мөмкин. Киеренке хәлләрдә иңендә калкан барлыгын тою ышанычлылык, түземлек бирә. Тудырган герое авызыннан мондый сүзләр әйттергән Таҗи Гыйззәт үзе дә социаль чолганышта әнә шундый зилзиләләр аша узды, аңа да шул хәтәр хәлләрдә шактый югалтулар бәрабәренә исән-имин калу насыйп булды. Аның каравы ул бу юлда үзенә көчле корал алды – каләм көче белән халкыбызның ничә гасырлар буена газап чигүенең сәхифәләрен образлы итеп күрсәтеп баруга иреште. Без

бу очракта аның яшәешендәге хәл-әхвәлләрнең иҗат юнәлешен билгеләүдә билгеле бер нигез булганлыгын искәртәбез.

Кайчакта матбугатта илебездәге 1917 елга кадәрге тормышны сагыну, алай гына да түгел өстенлекле итеп бәяләп әйтелгән фикерләргә юлыгырга туры килә. Сүз дә юк, аерым кешеләр өчен ул шулай да булгандыр. Әмма милләтебезнең ул вакыттагы гомуми хәленнән чыгып караганда, болай раслау хакыйкатькә хилафлык итүдән, патша хакимияте сәясәтенең асылын белеп бетермәүдән гайре нәрсә түгел. Патшаның егерменче йөз башындагы иң төп терәкләреннән берсе П. Столыпинның татарларга каршы сәясәтнең тулы бер нигезен чагылдырган чыгышларын гына искә алу да моның шулай икәнлеген ачып бирә. Бу җәмгыятьтә күп нәрсә кешенең иң мөкатдәс хокукларына каршы юнәлдерелгән иде.

Әйтик, җир мәсьәләсе егерменче йөз башында иң үзәктә торган, крестьянның җан авазы белән ыңгырашуына китергән нәрсәләрнең берсе иде. Таҗеттиннең этисе кебек хөрлеккә омтылучы, туган туфрагында иркенрәк яшәргә теләгән гаярь егетләр вакыт-вакыт Әгерҗе, Алабуга якларындагы Стахеев, Халитов кебек җир биләүчеләргә каршы көрәшкә күтәрелергә мәҗбүр булалар. Әмма көчләр тигез түгел, аерым төбәкләрдәге күтәрелешләр генә мәсьәләне тамырыннан хәл итүгә китерә алмый. Кәлимулла агайны да дәвамлы вакытка тоткынлыкка дучар итәләр.

Кешенең дөньяга карашы калыплануга балалык чорында күргәннәре-кичергәннәре бик нык тәэсир итә. Алар бигрәк тә киләчәктә иҗатчы булып китәчәк кешеләр күңелендә тирән эз калдыра. Без моны Таҗеттин мисалында да күрәбез. Аның иҗтимагый аңы калыплану вакыты инкыйлаби давыллы елларга туры килүе дә билгеле юнәлештә тәэсир итә. Үзедәй кешеләрнең өстенә кояш төшермичә, иңнәренә басып килгән патша хакимиятен какшату көннәрендә Таҗеттин күңелендә дә зур өметләр барлыкка килә. Ул да яшәешне матур итеп үзгәртергә омтылучылар арасында. Халыкка шушы якты максатларны аңлатып бирергә, аның күңелендә киләчәккә өмет уятырга кирәк. Моның юллары бихисап. Үтемлеләренең берсе – тамашалар күрсәтү ярдәмендә кешеләрнең иҗтимагый аңнарына, күңел дөньяларына йогынты ясау. Таҗеттин дә шундый хыяллар белән рухланучы зыялылар мохитенә тап була. Һәвәскәр артист, суфлер сыйфатында, алар белән спектакльләр куюда катнашып китә. Очраклы гына башланган бу юлның яшәү максатына әйләнеп китәчәге турында әле уйлап та карамый.

Әмма тәкъдир дигән нәрсә аны да тиешле юлга чыгара. 1920 елда Самара каласында татар галәмендә тәүге тапкыр сәнгать укуйорты – театр студиясеачыла. Аңа, театр сәнгатемохитендә Габдулла Кариев җитәкчелегендәдистәелгаякынкайнап, шактый тәҗрибә туплаган Кәрим Тинчурин һәм Әстерхан якларында шулай ук сәнгатьнең бу өлкәсендә халыкка танылган Зәйни Солтанов җитәкчелек итәләр. Татар телендә театр булдыру юлында төрле төбәкләрдә аеруча күзгә ташланган талантлы яшьләрне әлеге бер еллык курсларга җыялар. Иж каласы һәвәскәрләре Таҗеттинне шушында җибәреп укытып кайтаруны максат иткән икән, димәк, ул биредәге мохиттә аеруча сәләтлесе һәм өметлесе булган дигән сүз. Шул рәвешле, Таҗеттин Гыйззәтуллин (алга таба – Таҗи Гыйззәт) үз язмышын тулысынча театр сәнгате һәм драматургия белән бәйли.

Самарада укуны тәмамлагач, К. Тинчурин әлеге шәкертен кире Ижауга җибәрми, үзе белән ул вакыттагагы Казахстанның башкаласы Оренбургка барырга кодалый. Анда студияне тәмамлаучылардан татар театры оештыралар. Әйбәт кенә эшләп тә китәләр. Әмма 1921 елда, коточкыч ачлык башлангач, алар алдына да исән калу мәсьәләсе килеп

баса. Байтагы “икмәкле” Ташкентка таба кузгала. Чөнки анда ачлыктан котылып калуга өметләнәләр. Тажеттин монда да үз урынын таба. Үзен генә түгел, аңа биредә йөзләрчә ятим балаларны үлемнән алып калу вазифасын үтәргә дә туры килә. Ничек дигәндә, егеткә язмыш бер интернатта мөдир ярдәмчесе булуны насыйп иткән икән. 1922 елда исә Казанда дәүләт тарафыннан беренче татар драма театры оештырыла. Бу эшне җитәкләүнеК. Тинчуринга тапшыралар. Ул үз чиратында Т. Гыйззәтне дә Татарстан башкаласына кайтырга өнди. Шулай итеп, Т. Гыйззәт 27 яшендә Казан туфрагына аяк баса.Сүз уңаенда әйтергә кирәк, игелекле үзбәк җире нәкъ шушы елда халкыбызның талантлы шагыйре Һади Такташны да туган халкы тарафына озатып кала. Анда кышлаган елда Т. Гыйззәт “Җир уллары трагедиясе” авторы белән аралашкан икән, биредә, ягъни Казанда аны иҗади мохиткә кертеп җибәрүчеләрнең берсе дә Т. Гыйззәт була. Ике талантның  эшчәнлекләре инде Идел буенда дәвам итә. Дөрес, аңа, төрле сәбәпләр аркасында, берничә ел Сембер (Ульяновск), Алабуга, Мәскәү шәһәрләрендә яшәп алырга да туры килә. Әмма 1929 елдан соң, К. Тинчурин янәшәсендә булуга өстенлек биреп, ул инде бөтенләйгә күңелен шушында беркетә.

Бу ике сәнгатькяребезне тагын да якынайта, берләштерә торган янә бер шәхес бар, ул – Салих Сәйдәшев. К. Тинчурин әсәрләренең сәхнә язмышын С. Сәйдәшев музыкасыннан башка күз алдына китерә алмаганыбыз кебек, шушындый ук бәйләнеш Т. Гыйззәткә дә карый. Аларның замандашы, режиссерһәм драматург Риза Ишморат бер вакыт композитордан сорый:

– Салих дус, синең халык яраткан көйләрең күп, бик күп. Син үзең шуларның кайсысын иң яхшысы дип саныйсың?

С. Сәйдәшев нык итеп әйтеп бирә:

– “Наемщик” спектакленә язган музыкамны!

Шулайдыр, Т. Гыйззәтнең шушы драмасы буенча куелган спектакльдә яңгыраган музыкаль әсәрләр, үзләренең халык моңнарыннан үсеп чыгулары белән генә түгел, профессиональ камиллек җәһәтеннән дә композиторның зур иҗади үсешен раслый иде. Увертюра, арияләр, дуэтлар, хорлар – барысы бергә ул тудырган музыканы опера сәнгатенә якынайталар. Дөресендә дә С. Сәйдәшев аны тулы канлы опера әсәре итеп эшләп бетерү белән илһамлана, ләкин моңа гомере җитми. Дусты, олы композиторыбыз Александр Ключарев, аның бу омтылышын тормышка ашырып, әсәрне опера театры сәхнәсенә күтәрде. Шуңа тагын Т. Гыйззәтнең “Бишбүләк”, “Башмагым” (Җ. Фәйзи белән), “Кыю кызлар”  кебек әсәрләрнең музыкаль драма жанрында иҗат ителгәнлекләрен өстәсәк, аның каләменең бу хасияте тагын да киңрәк булып ачыла.Атаклы “Ташкыннар” трилогиясе дә халкыбыз моңнарын кулланудан башка шактый төссез булып туган булыр иде.Ул бу җәһәттән дә Г. Исхакый, К. Тинчурин салган юнәлешне дәвам иттерде. Дөрес, аңа Г. Исхакый иҗаты белән азыклану мөмкинлеге чикләнде. Аның каравы егерменче йөз башында “Зөләйха” драмасы авторының иҗат мәктәбен К. Тинчурин шактый нигезле үткән иде. Аның бу яктан да Т. Гыйззәткә йогынтысы булмады түгел.

Ике зур драматургны янәшә куеп сүз алып барып та, алар арасындагы аермалыклар булуын да күрсәтмәү мантыйкка туры килмәс иде. Гадәттә андый шәхесләрнең үзләренә генә хас сыйфатлары һәрвакыт була, әйтергә кирәк, еш кына ачык ярылып ята. Киресенчә булганда, классик булып танылу мөмкин дә түгел.

К. Тинчуриннан аермалы буларак, Т. Гыйззәт иҗатының бер юнәлеше аның драма хасиятләренә өстенлек бирүендә. К. Тинчуринны исә без иң әүвәл комедиограф буларак

беләбез. Т. Гыйззәт исә драманың зур остасы. Моның гыйбрәтле мисалы “Наемщик” әсәре. Башта ул аның сюжетын көлкеле вакыйгаларга нигезләгән иде. Әмма тора-бара драматург, әлеге хәлләргә халык мәнфәгатьләреннән карап, шактый катлаулы тормыш чынбарлыгын күрсәтеп бирүне максат итте, варианттан-вариантка аларны әсәр тукымасына тыгызрак урнаштыра барды. Шул рәвешле, әсәр бер татар авылы кысаларыннан илкүләм мәйдандагы вәзгыяткә аваздаш булган карашларны үткәрерлек үткенлеккә иреште. Коллыкның бер гәүдәләнеше булган крепостнойлыкның Росссиядә 1861 елга кадәр яши алуы мәсьәләсенең дә килеп кертелүе шулай дияргә мөмкинлек бирә.

Т. Гыйззәт иҗатының тагын бер үзенчәлеге – аның әсәрләрдә әнә шул унтугызынчы гасыр урталарыннан алып егерменче йөзнең илленче елларына кадәрге халык тормышының эзлекле күрсәтелеп килүе. Бездә әле бер генә драматургның да мондый бурычны куйганы һәм тормышка ашырганы булмады. Шунысын да игътибарсыз калдырып булмый, ул шулай да әсәрләрендә милли мәсьәләне үзәккә куя алмады (куеп кара, шунда ук яманаты чыккан илле сигезенче маддәгә эләгүеңне сизми дә калырсың!). Аның каравы халыкның сыйнфый изелүен бөтен аянычлылыгы белән күрсәтүгә ирешә. Т. Гыйззәтнең утызынчы еллар хәвеф-хәтәрләреннән исән калуы шуның белән бәйле дип тә әйтергә мөмкиндер. Сугыш вакытының ике елында язучылар оешмасы җитәкчелеген тапшырулары да аңа карата булган карашның уңай булганлыгы турында сөйли.

Әсәрләрдә милли үзенчәлекләрне күрсәтүне өнәмәгән рәсми сәясәткә яраштырып, ул заманда хакимлек иткән карашларга эстетика теориясен дә буйсындырулары аеруча гыйбрәтле хәл. Имеш, милли үзенчәлекләрне күрсәтү натурализм була. Әмма бу очракта Т. Гыйззәтнең кыюлыгын да икрар итәргә кирәк. Ул халкыбыз яшәешенә, тормыш-көнкүрешенә хас сыйфатларны гәүдәләндерүдән беркайчан да тайпылмады. Илгә билгеле булган драматург А. Корнейчук илленче елларда Т. Гыйззәт каләменең бу хасиятен язучылар съездында уңай яктан билгеләп үтте.

Менә шушы сыйфатлар аның әсәрләренең яшәүчәнлеген тәэмин итте. Берничә дистә еллар театрлар репертуарын тотып тору өчен, әнә шундый осталык, үзенә хас маһирлек, тамашачыларның зәвыгын һәм таләпләрен истә тоту, заман белән бергә сулау, театр сәнгате үзенчәлекләрен тирән белү кирәк иде. Аның илһамлы рухи җилкәне туган халкына, аның сәнгатенә хезмәт итү булды. Шушы затлы кыйбла аның әсәрләренең халык күңеле белән аваздашлыгын тәэмин итте. Тууына 125 ел тулган көннәрдә без боларны тагын бер тапкыр бәялибез һәм сирәк талантка ия элгәребезне ихласлылык белән хөрмәт итеп искә алабыз.

**А.Ф. ГАЛИМУЛЛИНА**
Казанский федеральный университет, Казань

## РОЛЬ ХУДОЖЕСТВЕННОГО ПЕРЕВОДА В СОВРЕМЕННОМ ЛИТЕРАТУРНОМ ПРОЦЕССЕ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**Аннотация:** В статье рассматривается современное состояние и поэтика художественных переводов произведений русских и татарских поэтов. На примере переводческой практики Рената Хариса, Дж. Сулеймана, Николая Переяслова, Алины Каримовой определяются основные тенденции в области художественного перевода. В татарско-русских литературных

взаимосвязях XX – XXI веков большую роль выполняет художественный перевод, способствовавший взаимообогащению литератур.

**Abstract:** The article examines the current state and poetics of literary translations of the works of Russian and Tatar poets. On the example of the translation practice of Renat Kharis, J. Suleiman, Nikolai Pereyaslov, Alina Karimova, the main trends in the field of literary translation are determined. In the Tatar-Russian literary relationships of the 20th - 21st centuries, literary translation plays an important role, contributing to the mutual enrichment of literatures.

**Ключевые слова:** Художественный перевод, татарская литература, русская литература, литературные взаимосвязи, Ренат Харис, Дж. Сулейман, Николай Переяслов, Алена Каримова

**Keywords:** Literary translation, Tatar literature, Russian literature, literary relationships, Renat Kharis, J. Suleiman, Nikolay Pereyaslov, Alena Karimova

Художественный перевод вносит большой вклад в развитие межкультурных связей и оказывает влияние на формирование интернациональной культуры, взаимообогащение литератур народов России и зарубежья.

Проблема перевода представляет собой одну из самых трудных и по сути неразрешимых проблем литературоведения потому, что в принципе невозможно дать окончательный ответ на вопрос, что лучше: как можно более точная, адекватная передача семантической и лексико-семантической стороны оригинала или же такой же перевод, который как бы утрачивает признаки «иностранности» и начинает восприниматься как часть национальной культуры языка-реципиента. Конечно, в идеале должно быть и то, и другое…

В мире ни одна литература не существует без взаимного обогащения и участия в творческом процессе переводной литературы. В качестве перспектив совершенствования художественного перевода с использованием татарского языка и дальнейшего исследования истории и поэтики переводов, следует отметить, что назрела необходимость создания уже библиографического указателя по художественному переводу, который продолжил бы работу Абрара Каримуллина и Энгеля Нигматуллина [Каримуллин 1962, Нигматуллин 2002].

В современной татарской литературе перевод занимает значительное место. Однако в большей мере носит частный, индивидуальный характер. В 1980-е – 2020-е годы в русско-татарских литературных взаимосвязях появляется больше переводов творческого характера, выявляются талантливые переводчики: Киям Миннибаев, Т.Нурмухамедов, Нури Арслан, Ренат Харис, Зульфат, Лерон Хамидуллин, Гариф Ахунов, Рашид Ахунов, Алена Каримова, Наиль Ишмухаметов, Вера Хамидуллина, Ахат Мушинский, Гаухар Хасанова, Борис Вайнери др.

По сравнению с предшествующими десятилетиями, количество переводов с русского языка на татарский и с татарского языка на русский резко сократилось. Сейчас выбор художественного перевода основывается на художественном вкусе и личных предпочтениях переводчиков. На татарский язык переведены многие произведения писателей второй половины XX века: Чингиза Айтматова, Юрия Бондарева, Мустая Карима, Валентина Распутина, Василия Аксенова и др.

Одним из последних достижений в области переводов русской литературы на татарский язык можно назвать книгу переводов выдающихся русских поэтов:поэта XVIIIвека Гавриила Державина (переводчик – Ренат Харис) (2016) и поэта XX века – А. Ахматовой (2013, коллектив переводчиков: Радиф Гаташ, Рифа Рахман, Рамис Аймет, Луиза Янсур и др.).

Следует отметить, что высокое художественное мастерство переводчиков получило общественное признание, так 2014 году переводчик Гаухар Хасанова вместе с автором получила премию им. Г.Р. Державина за перевод книги Марселя Галиева «Рух-Поэзия духа» (Тат. кн. изд-во, 2014), а в 2016 году Первую Республиканскую премию им. Г.Р. Державина получил народный поэт РТ Ренат Харис за переводы стихотворений Гавриила Державина.

Книга «Кизләү» (Казань, 2016) является первым изданием произведений великого русского поэта, выдающегося нашего земляка Гаврилы Романовича Державина на татарском языке.Книга высокохудожественно исполненных переводов сложнейших произведений всемирно признанного мастера оды и тончайших лирических стихов является существенным вкладом как в культуру татарского народа, так и в многонациональную отечественную литературу и пропаганду высоких образцов поэзии. Многие произведения классика мировой литературы и по сей день звучат актуально, злободневно.

В сборнике «Кизляу» включены поэтические переводы 29 од и стихотворений, отражающих широкий диапазон творчества Г.Р. Державина: гражданская, философская тематика, размышления о судьбе поэта («Кизләү», «Аллаһ», «Фелица», «Тончию,» «Давыл», «Балаларын үзетәрбияләүче анага», «Вакыт дәрьясы», «Хушлашу» и др.).

Показательно, что татарский поэт обратился к переводу программного стихотворения «Тончию» (1801), в котором Г.Р. Державин утверждает превосходство звания философа, «человека» над вельможей: «*Потомков поздных удивляло;/ В сединах лысиной сияло,/ И в нем бы зрелся человек*». Р. Харис стремится точно передать форму и содержание оригинала. Во вступлении, вслед за Державиным, обращаясь к Тончию, он перечисляет античные имена, ассоциирующиеся с различными видами деятельности: с Гомером, с полководцем Аристидом, с мудрым Сократом и принципиальным Катоном. Однако в татарский перевод автор включает оценочные эпитеты, отсутствующие в русском оригинале: *«Батыр Аристидны»* (храбрый), *«гакыллы Сократны»* (мудрый), *«кырыс Катонны»* (суровый), которые помогают создать точные, лаконичные характеристики античным образам и способствуют контекстуальной конкретизации. В 3 строфе подчеркивая интонацию размышления, свойственную всему стихотворению, поэт-переводчик изменяет порядок слов в предложении: *«...сурэтемне Терле сэер киемнэрдэ ясап ал бер,/ Белгэненчэ...»* (У Державина: «Пиши меня в уборах чудных,/ Как знаешь ты...»). Интересно контекстуальное звучание слова «саер», которое используется для перевода слова «чудный»: поэт-переводчик актуализирует и другие звучания татарского слова: «загадочный», «чудный».

Перевод произведений Г.Р. Державина на другие языки, особенно – на татарский – является сложным явлением. Оно требует от переводчика как отличного владения русским и татарским языками, высокой культуры стихосложения так и энциклопедических знаний, так как каждая строфа державинских од или анакреонтических стихов содержит аллюзии на известные исторические события, древние обычаи, обряды. Адекватная передача переводчиком философических и космогонических мыслей Державина демонстрирует огромные поэтические возможности татарского языка.

Специфику художественного мира Сулеймана исследователи рассматривают в контексте татарского постмодернизма.

В данной статье остановимся подробнее на анализе стихотворения «Чи-керт-ка-стан» [Сөләймән, 1999: 46 – 47], его переводе на русский язык «Куз-не-чик-стан» (перевод Алены Каримовой) [Сулейман, 2014: 18]), которое было прочитано 12 мая 1997 года на вечере Г. Айги в Чебоксарах.

Все же отметим и некоторые отличия в переводе на русский язык, которые не учитывают эмоциональные оттенки оригинала. У Сулеймана «Шәлперәйгән болын», дословный перевод: «расслабленный, увянувший луг», что соответствует символическому образу «Поле» из стихотворения Г. Айги. И хотя русский перевод этой строчки без сопоставления со стихотворением Г. Айги звучит органично, в нем есть метафорический образ «…Трав увянувшие космы», фигура «умолчания», добавленная переводчиком в начало строки, представляется органичной для структуры стиха татарского поэта. Вторая строчка третьей строфы также отличается от оригинала. У Сулеймана: «Әлсерәгән көтү» – собирательный образ стадо коров, которое измотано –«әлсерәгән» (этот глагол переводится как «изматываться, измотаться, изнуряться, изнуриться, изнемогать, изнемочь, уставать, устать; выбиваться (выбиться) из сил»), в переводе А. Каримова использует более нейтральный образ «утомленные коровы». Сулейман этой усталой, увядающей природе, земному миру противопоставляет активных, деятельных, жизнерадостных кузнечиков. Его стих лаконичный, емкий, основывается на звукоподражании (как у В. Хлебникова) и на зрительном образе скачущих кузнечиков (как у Э. Каммингса):

*Сикергәли*
*Чикерт-чикерт –*
*Чикерт-кәләр*
*Сикер-гәли...*

Безусловно, отдавая должное почти невозможности перевода такого сложно организованного текста без потерь, заметим, что русский перевод теряет эту лаконичность, в нем появляется, отсутствующая в оригинале описательность: «Лишь кузнечики мелькают», «Скок – куз-не-чик – без учета…». В то же время в русском переводе сохраняется главное: деятельный оптимизм, свободолюбие кузнечиков, противопоставленные утомленной природе. Образ кузнечиков передается через звукоподражания («скок и скок их, / сколько-сколько…») и зрительный образ.

Завершается стихотворение Сулеймана емким многозначным образом:

*Эңгер йота*
*Саркып чыккан*
*Кара сыер сөтен...*
[Сөләймән, 1999: 47]

Дословно этот образ переводится, как «Сумерки глотают просочившееся молоко черной коровы». Заметим, что в татарском тексте «Эңгер» дается в единственном числе, поэтому представляется, что эквивалентом точному переводу было бы: «Тьма (Ночь) глотает). Глагол «сарку» переводится как «сочиться, просочиться».

Татарский текст Сулеймана лаконичен, он закольцован ночными образами: «эңгер – тьма» и черная корова, которые уравновешивают активность и подвижность третьей строфы. Создается экзистенциальная, космическая картина разлитой в мире тишины, вбирающей в себя и небо, и землю. Этот образ возвращает нас и к первой строфе, где представлен сельский мир, в то же время возносит и к небу, где пролегает Млечный путь.

Этот образ укоренен как в традициях татарской литературы, так и легко воссоздает в сознании читателей и образы русской литературы. Например, его можно соотнести с лермонтовскими строчками: «*Выхожу один я на дорогу; / Сквозь туман кремнистый путь блестит; / Ночь тиха. Пустыня внемлет богу, / И звезда с звездою говорит. / В небесах торжественно и чудно! / Спит земля в сияньи голубом... / Что же мне так больно и так трудно? / Жду ль чего? жалею ли о чём?*» или даже с ломоносовскими: «*Открылась бездна звезд полна; / Звездам числа нет, бездне дна*».

И хотя Сулейман не проводит параллель с внутренним состоянием лирического героя, однако многоточие в конце стихотворения приглашает самого читателя к сотворчеству, к сопереживанию, к философским размышлениям.

Алена Каримова – замечательный переводчик, которая перевела и другие стихотворения Сулеймана, в целом бережно отнеслась к татарскому стихотворению, однако проявила стремление к завершенности, закольцевав финал по-своему, на центральном образе стихотворения – кузнечике:

*Молоко коровы черной*
*Вниз по вымени стекает –*
*Сумерки его глотают…*
*Че-керт-стан…*
[Сулейман 2014: 19].

Переводчик добавляет дополнительную строчку в финальную строфу стихотворения, вынеся на нее только одно слово: «Че-керт-стан…», так в оригинале звучит название стихотворения Сулеймана, сохранив слоговую разбивку оригинального текста, такое написание слов продолжает традицию В. Хлебникова, Э. Каммингса и Г. Айги, таким образом, переводчик возвращается нас к началу стихотворения, к его заголовку – Куз-не-чик-стан, то есть страна кузнечиков.

Таким образом, отметим, что финал стихотворения Сулеймана на татарском языке звучит более монументально, чем финал перевода, хотя в целом в переводе на русский язык почти полностью воспроизводятся лексические и стилистические особенности оригинала, при этом не всегда сохраняется синтаксис, особенно фигура «умолчания», которая в произведениях поэтов-авангардистов (В. Хлебникова, Г. Айги, Э. Каммингса и Сулеймана) заключает в себе смысловую функцию.

К числу адекватных переводов можем отнести и переводы произведений современного татарского поэта Рамиса Аймета, сделанные поэтами Николаем Переясловым и Сергеем Малышевым, – «Свобода в неволе» (2016) [Айметов, 2016].

Поэзия известного татарского поэта Рамиса Аймета отличается философской глубиной. В своих стихотворениях татарский поэт размышляет о смысле жизни, о смерти, о бессмертии души. Экзистенциальные проблемы бытия преодолеваются бесконечной верой поэта в доброе и светлое начало в человеке и во всеобщую гармонию во Вселенной («Пора», «Во мне поют мгновенья», «В поисках улыбки», «Автопортрет», «В дождь», «Проходит все…», «В предчувствии рожденья», «Настроение», «Праздник первых луж», «Сошел я наземь», «Качество души», «Судный день», «Я здесь», «В поисках смысла», «свобода», «Белый корабль», «Молитва к сердцу», «Без меня», «Последний праздник сирени», «Одиночество»).

Наиболее сложно поддается переводу форма поэтического текста, особенно следует отметить, что в отличие от русского стихосложения, в котором преобладает силлабо-тонический стих, в татарской поэзии до сих пор превалирует силлабический

стих. Это тоже создает определенные трудности для создания адекватных переводов. Приведем удачный пример сотворчества поэта и переводчика, когда в переводе произведения на русский язык сохранятся содержание и форма оригинала. Стихотворение «Акростих» Р. Аймета в переводе Н. Переяслова представлено следующим образом:

*__Р__учьем журчит душа во мне, звеня.*
*__А__ может, это – льется песнь во мгле?*
*__М__ерцая, светит тайна из меня*
*__И__ тает теплым отсветом огня,*
*__С__лед в небесах рисуя на крыле.*

*__А__ если в стебле, где копилась мощь,*
*__Й__од вдруг иссякнет, как усопший сок,*
*__М__не вместо сил оставив в сердце – дрожь?*
*__Е__го собой – в ночи разбудит дождь,*
*__Т__ебя согрев, как с неба голосок…* [4, 138].

Таким образом, следует отметить, что не ослабевает интерес к переводам художественных текстов с языков народов России (в том числе и татарского) на русский язык и с русского языка на языки народов России, а это предполагает решение насущных задач: специальной подготовки специалистов, которые могли бы профессионально осуществлять переводы технических, научных, художественных и т.д. текстов на русский язык с языков народов России и с русского – на языки народов России. Необходимо готовить двуязычные кадры, способных осуществлять высоко профессиональные переводы. Сейчас за небольшим исключением переводчики, как правило, работают через подстрочники. Н. Переяслов, С.Малышев и А.Каримова свои переводы делают по подстрочникам, а Ренат Харис и Дң.Сулейман, свободно владея русским и татарским языками, свои переводы осуществляют напрямую с оригинала.

## ЛИТЕРАТУРА


Айметов Р.К. Свобода в неволе: Стихотворения / Рамис Аймет: Пер. с татар. Н.В. Переяслова, С.В. Малышева. Казань: Магариф – Вакыт, 2016. – 183 с.

Ахматова А.А. Избранные произведения: Анна Ахматова. Казань. Магариф – Вакыт, 2013. – 168 с.

Державин Г.Р. Кизляу: Одалар, шигырьләр: перевод Рената Хариса / Г.Р. Державин. Казан. Мәгариф – Вакыт, 2016. – 139 с.

Елисеев И.А. Поэзия в переводе // Идель, 2018. – № 8. – С.76.

Каримуллин А.Г. Татарская литература в переводах на русский язык (библиографический указатель. 1917 – 1960). Казань: Казан. ун-т, 1962. – 88 с.

Лирика А.С.Пушкина в татарских переводах / Сост. Г.Ф.Сафина. Казань: Казан. гос. ун-т, 2005. – 135 с.

Миннибаев К.С. Перевод – это искусство: Золотой век. Казань, 2004. – 196 с.

Нигматуллин Э.Г. Диалог литератур: Указатель переводов произведений русской литературы на татарский язык. Казань: «Унипресс», 2002. – 176 с.

Сулейман Знаки времени: поэма и стихи / Д.Ш. Сулейманов. Казань: Мәгәриф-Вакыт, 2014. – 127 с.

Сөләймән Минсез дөньяда. Казан: Мәгариф, 1999. – 127 б.

**А.Ф. ГАНИЕВА**
Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясе
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Казан

# ТАТАР ШАРТЛЫ-МЕТАФОРИК ПРОЗАСЫ (БАТУЛЛА ИҖАТЫ МИСАЛЫНДА)

**А.Ф. ГАНИЕВА**
Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова
Академии наук Республики Татарстан, Казань

# ТАТАРСКАЯ УСЛОВНО-МЕТАФОРИЧЕСКАЯ ПРОЗА (НА ПРИМЕРЕ ТВОРЧЕСТВА РАБИТА БАТУЛЛЫ)

**Аннотация.** Условно-метафорическая проза возникла в национальных литературах в середине XX века в результате стремления выйти из идеологических рамок общественной формации. Рабит Батулла является одним из зачинателей этого направления в татарской литературе. Писатели данного течения основывают художественный мир на трех типах условности: сказочном, фантастическом и мифологическом. Автор статьи отмечает, что в творчестве Р. Батуллы используются все три вида. С одной стороны, они приводят к разнообразию стилей и жанров искусства, с другой стороны, содержание, поданное читателю в вымышленной обёртке, позволяет писателю косвенно донести до него реальную жизнь и связанные с ней размышления.

**Annotation.** Conditional-metaphorical prose appeared in national literatures in the middle of the XX century as a result of the desire to get out of the ideological framework of the social formation. Rabit Batulla is one of the initiators of this trend in Tatar literature. Writers of this trend base the artistic world on three types of conventions: fairy-tale, fantastic, and mythological. The author of the article notes that all three types are used in the works of R. Batulla. On the one hand, they lead to a variety of styles and genres of art, on the other hand, the content presented to the reader in a fictional wrapper allows the writer to indirectly convey to him real life and related thoughts.

**Ключевые слова:** Татарская литература, проза, Роберт Батулла, образ, герой.
**Keyword:** Tatar literature, prose, Robert Batulla, image, hero.

Шартлы-метафорик проза рус һәм башка милли әдәбиятларда XX йөз урталарында илдәге идеологик цензурага реакция буларак барлыкка килә. Тормыш-чынбарлыкка үз мөнәсәбәтләрен турыдан-туры белдерә алмаган язучылар замандашлары таныррлык шартлы-әкияти, фантастик дөнья сурәтләре тудыра башлыйлар. «Шартлылыкның төрле төрләрен файдаланып, шартлы-метафорик проза шартлы шәкел һәм алымнар пәрдәсе артына яшерелгән реаль чынбарлыкның асылын тагы да ачыграк күрсәтергә ярдәм итә» [Нефагина, 1997: 75]

1960 елларда башланган әдәбияттагы яңарыш эчтәлеккә генә түгел, жанр һәм форма ягына да тәэсир итә. Тормыштан канәгатьсезлек, ризасызлык, җәмгыятьтәге гаделсезлекләр, әйләнә-тирәгә, табигатькә салган зыян язучыларны яшәеш турында тирәнрәк уйланырга, үткән тамырларны барларга этәрә. Реализмның (бигрәк тә социалистик реализмның) хыял дөньясын чикләве, хис-кичерешләрне, уй-фикерләрне тулы иркендә сурәтләргә юл бирмәве аңлашыла. Бүгенге белән үткәнне янәшә сурәтләү, әсәрләрдә риваять, миф, легенда, әкият сюжетларын иркен файдалану, сихер, әверелеш

кебек алымнарга еш мөрәҗәгать итә башлау әдәбиятта шартлы-метафорик прозаның үсеш алуына китерә. Әлеге күренеш рус һәм милли әдәбият белгечләренең өйрәнү объектына әверелә [Гараева, 2015], [Загидуллина, 2017], [Нефагина, 1997], [Чушникова, 2014].

Рабит Батулла татар әдәбиятында шартлы-метафорик юнәлешне башлап җибәрүчеләрнең берсе булып тора. Бу агымдагы язучылар сәнгати дөньяны өч тип шартлылыкка нигезлиләр: әкияти, фантастик һәм мифологик. Р. Батулла үз иҗатында өч төрне дә куллана. Бер яктан, шартлы-метафорик сурәт сәнгать төрлелегенә китерә, икенче яктан, әкияти эчтәлеккә төрелеп, укучыга чын тормыш һәм аның белән бәйле уй-фикерләрне җиткерергә мөмкинлек бирә.

Язучы беренче «Исемем минем Дүрткүз» (1966) повесте белән үк яшь укучы күңелен җәлеп итә: анда кечкенә генә көчекнең ферма казларын көткән җирдән чыгып китеп, төрле шәһәрләрдә, илләрдә булуы, батырлыклар эшләп туган авылына әйләнеп кайтуы мавыктыргыч маҗаралар белән сурәтләнә. Маэмай күзлегеннән дөньяга караш бала психологиясенә туры килә, тормыштагы күренешләр гадиләштереп бирелә. Өйрәнчек кулдан язылган тәүге әсәрләрендә үк әкиятилек һәм реальлекне кушып бирүе, гадәттән тыш маҗаралыкка коруы белән Батулла үзенең язу манерасын ачыклый. Ә инде Дүрткүзнең чираттагы бер төрек хуҗасы «Мин бүген үз милләтемә каршы үлем җибәрәчәкмен. Шаһ Кипрга һөҗүм итә. Без җибәргән снарядлар гаепсез сабыйлар, абый-апаларга үлем алып киләчәк» [Батуллин, 1966: 68] дип уфтануы язучының иҗат позициясен, гуманист һәм милләтпәрвәр булачагын хәбәр итә.

Батулла әкиятләрен ниндидер принциптан чыгып классификацияләү кыен. Аларны традицион рәвештә җәнлекләр турында, тылсымлы һәм маҗаралыларга да аерып куеп булмый, чөнки күп кенә әкиятләрдә боларның өчесенә дә хас билгеләрне очратырга мөмкин. Укучының яшь үзенчәлекләренә бәйле бүлеп караганда кызык кына күренеш күзгә ташлана: балаларга нисбәтләнгән әкиятләрдә дә олыларга гыйбрәт алырлык мәгънә була. Мисал өчен, «Колакчын Тафи» (1966) әсәрендә аучылар көчеккә охшаш бер төлке баласын, атмыйча калдырып, үзләре белән алалар. Төлке эткә әверелә: ау вакытында токымдашларының ояларын табып бирә башлый. Кешеләр моның өчен Тафи муенына медаль-калай асып куялар. Тик ахырдан аучы аның үзен дә атып, колакчынлы бүрек тегеп кия. Әсәр яшь укучыга үз туганын сатканнарның үзен дә шул язмыш көткәнлеген кисәтү кебек аңлашылса, киңрәк фикерләүчегә җәмгыятькә, иҗтимагый стройга бәя буларак кабул ителә. Шулай ук аны милли күзлектән дә бәяләргә мөмкин.

Батулла – иҗатының башлангыч чорыннан ук коммунистик идеологияне инкарь итеп килгән язучы. 1960-1970 елларда моны турыдан-туры язып булмаганлыктан, әдип күчерелмә, текст асты мәгънәләре белән эш итә. Р. Фәйзуллин «Батулланың бөтен хикәяләре дә диярлек кинаяле, аларның һәрберсендә дә тел төбенә яшеренгән бер сер ята» [Фәйзуллин, 1998: 156] дип язуы белән хаклы. Мисалга, үз чорында күпләрне аптырашта калдырган «Монар» (Мираж) (1966) хикәясен алыйк. Исәнгол һәм Рәүф исемле ике ир, кыска юлдан барабыз дип, машиналары белән чүлгә кереп адаша. Өстәвенә, бензин бакларын да алырга онытканнар икән. Язучы оста психологик детальләр белән чүлдә калган кешенең чарасыз халәтен тасвирлап бирә. Сусызлык, билгесезлек, котылгысыз үлем куркынычы геройларны чыгырыннан чыгара. Тора-бара Исәнголның күзенә ерак түгел генә шәһәр күренә башлый. Рәүф юлдашын акылга китерергә омтыла, тик аны ишетергә дә теләмәгән Исәнгол шул билгесезлеккә таба юл тота. Моның мираж гына булуын белсә дә, Рәүф иптәше артыннан китәргә мәҗбүр

була. Әсәр тулысынча яшерен эчтәлеккә корылган, аны хикәя-метафора дип атарга мөмкин. Берәүләрнең коммунизм идеясенә ихластан ышануын, алдануын, икенчеләрнең хакыйкатьне аңлый торып та, башкаларга иярергә мәҗбүр булуын яшь Батулла «коммунизм чәчәк аткан» дәвердә үк шартлы рәвештә әйтеп бирә.

«Баш-аягым белән әдәбиятка чумган кеше буларак, мин хикәяләр язучы Батулла турында ишетеп белсәм дә, ул язган хикәяләрне укып, аңлый алмыйча интегә идем» [Әшрәфҗанов, 2008] дип яза Х. Әшрәфҗанов. Чыннан да, тормыш-чынбарлыкны реалистик һәм романтик ысулда яктыртуны гына кабул итәргә күнектерелгән укучыга Батулла иҗаты сәеррәк тоелырга мөмкин. Халыкның образлы күзаллавын сабый чактан ук сеңдереп үсү, әкият, миф, риваятьләргә аерым бер мәхәббәт белән тәрбияләнү алга таба Батулланың сәнгати дөньясына нык тәэсир ясый. Балалар өчен әкиятләр дигәнендә сәясәт чагылуы, өлкәннәргә нисбәтләнгән повесть-романнарына әкияти мотивлар кертеп җибәрүе дә аның моңарчы яшәп килгән әдәби стандартларга сыешмавын күрсәтә.

«Акбүре» повесте Буй-Турай авылының табигый яшәеше, бүреләрнең дә урманда үз тормышлары белән көн итүләре белән башланып китә. Көннәрдән бер көнне бүре аулау осталыгы белән дан алган Сыртак каршына башкалардан төсе белән дә, зурлыгы белән дә аерылып торган бүре чыга. Шул көннән башлап атаклы сунарчы Акбүрене тоту хыялы белән яши башлый. Батулла төрки халыкларның бүре турындагы риваятьләреннән уңышлы файдалана. Авыл тарихы да, Сыртакның нәсел башлангычы да турыдан-туры бүреләргә барып тоташкан икән. Акбүрене ату тыелганын белсә дә, сунарчы аучылык үҗәтлеген тыя алмый. Бөтен бәла да шуннан башлана. Кешеләр арасында да, бүреләр өерендә дә табигый баланс югала. Бүреләр белән мөнәсәбәттә халык тарихы яктыртыла: каһәрле утызынчы елларны, Бөек Ватан сугышы фаҗигаләрен, табигатькә китерелгән зыянны сурәтләп, автор бүреләр тормышы белән җәмгыять арасында янәшәлекләр уздыра. Бүре тешеннән һәлак булган Сыртак улы Котлыйга Акбүрене ауларга васыять итеп калдырса да, Котлый әтисеннән акыллырак булып чыга. Акбүренең тарих укытучысы Дивангәри булуын, аны үтерү бетүгә илтәчәген аңлый ул. Батулла укучы аңына тәэсир итү максатында халыкның мифик күзаллауларын яңарта. Шулай итеп, магик реализм авторга сурәтлелеккә һәм фикергә киңәергә мөмкинлекләр бирә. Әсәрдә кешенең киләчәге табигать белән гармоник мөнәсәбәттә яшәгәндә генә булачагы ассызыклана.

Р. Батулла прозасында реаль булган көнкүреш белән хыялый дөньяның кушылып китүе еш очрый. Аларның күбесе халык әкиятләрендәге кебек схематик калыпка салынган: канун бозу һәм аның өчен җәзага тару. Кылынган ялгышлык гафу ителә («Җыланнар» (2011), кайбер очракта җинаять өчен гомерлек җәза да бирелергә мөмкин («Фәрсия-пәризат» (2010), «Еш кызлары» (2010) һ.б. хикәяләре).

Шулай итеп, әлеге күзәтүләр күренекле язучы Рабит Батулланың сәнгати алымнарының индивидуаль-авторлык билгеләрен ачыкларга, аның уңышлы иҗади тәҗрибәләре татар әдәбиятын эчтәлеге ягыннан да, форма ягыннан да яңа баскычка күтәрүе турында нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә.

## ӘДӘБИЯТ


Әшрәфҗанов Х. «Өстебездә каргыш, рәнҗеш ятмасын» // Шәһри Казан, 2008. – 22 март.

Батуллин Р. Исемем минем Дүрткүз: повесть // Роберт Батуллин. Казан: Татар. кит. нәшр., 1966. – 84 б.

Гараева Г.Н. Развитие башкирской условно-метафорической прозы // Инновационная наука, 2015. №3. – С. 199–200.

Загидуллина Д.Ф. Условно-метафорическая проза // Современная татарская проза (1986-2016 гг.) основные тенденции историко-литературного процесса. Казань: Изд-во Академии наук РТ, 2017.– С. 175-186.

Нефагина Г.Л. Русская проза второй половины 80-х начала 90-х гг. XX века. Минск: НПЖ «Финансы, учет, аудит», «Экономпресс», 1997. – 231 с.

Фәйзуллин Р. Бар шундый бер Батулла // Равил Фәйзуллин. Сайланма әсәрләр. 5 томда. 4 т. : әдәби-публицистик мәкаләләр, иҗат портретлары, эссе уйланулар. Казан: Татар кит. нәшр., 1998. – 156 б.

Чушникова Н.В. Условно-метафорическая проза Мордовии: стилевые особенности // Филология и культурология: современные проблемы и перстективы развития: сборник материалов 6-й международной научно-практической конференции. Махачкала: «Апробация», 2014. – С. 63-75.

**А.Р. ГАРАЕВА**
Казанский федеральный университет, Казань

## МЕЖЛИТЕРАТУРНЫЕ ДИАЛОГИ В ТВОРЧЕСТВЕ Г.ТУКАЯ

**Аннотация.** В данной статье рассматривается влияние на творчество Г.Тукая произведения русских поэтов. На материале анализа вольных переводов татарского поэта доказывается, что Г.Тукай в обращениях к лучшим образцам русской поэзии, остается сугубо национальным поэтом. Сравниваются «Просыпайся, мужик…» Г.Тукая и «Что ты спишь, мужичок?» А.В. Кольцова. Доказывается, что его переводы вольные. А также приводятся примеры переводов произведений из творчества М.Лермонтова.

**Ключевые слова:** межлитературный диалог, вольный перевод, связь творчества, национальная литература, сопоставление.

**Annotation**. This article examines the influence Of works by Russian poets on the work of G. Tukai.Based on the analysis of free translations of the Tatar poet, it is proved that G.Tukay in his appeals to the best examples of Russian poetry, remains a purely national poet. Compared "Wake up, man..." G. Tukaya and "What are you sleeping, man?" A.V. Koltsov. It is proved that its translations are free. Examples of translations of works from the works Of M. Lermontov are also given.

**Keywords:** inter-literary dialogue, free translation, connection of creativity, national literature, comparison.

«Ни одна великая национальная литература не развивалась вне творческого взаимодействия с литературами других народов» – писал В.М. Жирмунский [Жирмунский, 1979: 71]. И действительно, развитие татарской литературы происходит за счет межлитературного диалога. Если в начале развития это были восточные формы, мотивы, образы и т.д., то к началу XX века татарская литература стала обогащаться идеями русской литературы. В истории многих национальных литератур выделяются периоды, когда межлитературный диалог становится причиной невероятного скачка. «В татарской литературе начала XX века, например, мощным стимулом, оказавшим серьезное влияние на идейно-эстетическое содержание и поэтику, явился синтез многовековых традиций Востока с достижениями словесного искусства Запада» – отмечает Т.Н. Галиуллин [Галиуллин, 2014: 105]. На творчества русских поэтов

опирались такие представители татарской литературы начала XX века как Г.Тукай, Дардменд, С.Рамиев, С.Сунчелей и т.д.

С точки зрения обогащения национальной литературы Г. Тукай в своем творчестве часто обращался к русским поэтам. «Продуктивностью, смелостью и поэтической отточенностью выделялись его авторские переводы и переложения» [Галиуллин, 2014: 105].

Первое поэтическое произведение опубликованное в прессе – это «Мужик йокысы» / «Просыпайся, мужик…» (1905).

Это произведение является вольным переводом стихотворения А.В.Кольцова «Что ты спишь, мужичок?». У Кольцова стихотворение состоит из 13 строк, а у Тукая – 19. Таким образом, следует принять тот факт, что татарский поэт не просто перевел, а также развил и обогатил данную тему. Также хочется отметить, что у Тукая объектом является не только «мужик», но и его семья: жена и ребенок. Как известно, А.Кольцов писал свои произведения на понятном языке, не используя сложные, непонятные, заимствованные слова. Тукай также при переводе использовал простые слова, здесь нет архаизмов, заимствованных слов и т.д. Поэтому стихотворение «Мужик йокысы» очень сильно отличается от его других произведений.

Приведем несколько строк, которые добавил Г.Тукай:

*Тик яткач, Ходаем*
*Бирми мал сәбәпсез:*
*Бишмәтең таланган,*
*Күлмәгең сәдәпсез.*
*Үзеңдә ялкаулык,*
*Хатныңда аңкаулык;*
*Кайда кышка азык*
*Ачлыктан сакларлык?(“Мужик йокысы”).*
*Оглянись на себя:*
*Гол как будто сокол.*
*На дворе ни кола,*
*На гумне ни зерна,*
*Пажить сгнила в полях,*
*Лошадёнка одна,*
*Ей цена три рубля.*
*Хлеба нет на полях,*
*Нет соломы в стогах,*
*Сам лентяй, и жена*
*Ни на что не годна (Перевод В.С.Думаевой-Валиевой).*

Как мы видим, тяжелое материальное положение крестьян молодой поэт объясняет их ленивостью, не желанием и не умением работать.

А в произведении Кольцова не акцентируются причины сложной жизни крестьян. Для него самое главное – точно и детально изобразить тяжелую жизнь обычного мужика.

Г. Тукай в 1905-1907 гг. написал около 75 стихотворений. 15 из них – переводы с русского или европейской литературы. В этот период Тукай очень часто обращается к Пушкину и Лермонтову. В одном из своих произведений Тукай приводит следующие строчки:

*Хочу быть Пушкина и Лермонтова близь.*
*Карабкаюсь за ними потихоньку ввысь (Перевод В.С. Думаевой-Валиевой)*
*Пушкин илә Лермонтовтан үрнәк алам,*

*Әкрен-әкрен югарыга үрләп барам(“Бер татар шагыйренең сүзләре”).*

Г.Тукай знакомится с творчествами этих поэтов в Уральске. Он их называет своими наставниками. Конечно, мы видим, что татарский поэт не слепо им поклоняется, а идет своей дорогой, однако, есть дорога, по которой им «по пути». Здесь совпадают их идей, мотивы.

Г.Тукай перевел на татарский язык очень много стихотворений М.Лермонтова. Например: «Г[ну] Павлову (Как вас зовут?..)» – «Шагыйрьгә», «Опасение» – «Вәгазь», «Пророк» – «Пәйгамбәр», «К *** (Я не унижусь перед тобою…) – «Алдандым», «К*** (Из Шиллера)» – «Шиллердән», «К деве небесной» – «Хур кызына», «К*** (Глядися чаще в зеркала...)» – «...га (И матур!иренмәче...)», «Молитва» – «Тәэссер», «Ответ» – «Соңра», «Эпиграмма» – «Охшату», «Дитя в люльке» – «Бишектәге бала», «В альбом» – «Байроннан», «Звезда» – «Кичке азан», «Три пальмы» – «Кадер кич», «Ангел» – «Шыер».

Связь творчества Тукая с Лермонтовым каждый литературовед, исследователь видел по-своему. Например, по мнению В.Р. Аминевой, «в лирике Г.Тукая, выделяется ряд мотивов и образов с явным параллелизмом их соответствия поэтике М.Ю.Лермонтова. В данном случае субъект межлитературной дискурсии – читатель, актуализируя релевантный смысловой потенциал вступающих в диалог текстов, выполняет функцию их модально-смысловой центрации. Так, уход от несовершенной действительности нередко принимает в творчестве русского и татарского поэтов форму замкнутости во внутреннем мире личности, в жизни души. Например, в стихотворении «Күңел йолдызы» («Моя звезда», 1909) противопоставляются и уравниваются два мира –пространство вселенной и сфера человеческой души, характеризуемые оппозициями света и тьмы, легкости и тяжести, временного и вечного» [Аминева, 2012: 7].

Мы не можем не согласиться с тем, что «хотя в творчестве Тукая достаточно большое место занимают вольные переводы, он ни одно инонациональное произведение в буквальном смысле не переводил, а развивал мотивы, и определяющим в текстах оставалось тукаевское – сугубо национальное – мировоззрение и мышление» [Галиуллин, 2014: 106].

Конечно, Тукай переводил, однако, их он называл «иярү», т.е. «следовать». Мы же видим, что даже названия некоторых произведений не совпадают. Например: «В альбом» – «Байроннан», «Звезда» – «Кичке азан», «Три пальмы» – «Кадер кич», «Ангел» – «Шыер» и др.

Люди, которые близко знакомы с творчеством Тукая и Лермонтова не могут заметить тот факт, что в творчестве Тукая есть те стихотворения, которые не являются переводами или «иярү» Лермонтова, однако у них одни и те же мотивы, темы, образы. Например: мотив поиска счастья, одиночества и т.д. Это связано и с историческим временем, в котором они проживали, и условиями, и тем, как к их творчеству относились коллеги, читатели.

По мнению Хабибуллиной А.З., «черты арабо-мусульманской философии, отразившей идею «метафизического атомизма», можно найти в восприятии Тукая лирики Лермонтова, и в частности, его переводе стихотворения Лермонтова «Ответ». Внешнее сходство между татарским переводом и убеждениями арабо-мусульманских философов позволяет понять, почему доминирующим здесь стало не выражение чувств лирического героя, подобно вспышке, а их описание, своего рода развертывание с помощью других дополнительных сравнений и художественных образов таких, как душа, мученик, дервиш» [Хабибуллина, 2009: 144].

Итак, мы утверждаем, что связь творчества Тукая и русских поэтов существуют. Однако стихотворения Тукая в переводе, обработке обретают особую систему ценностей, которые указывают на национальный склад мировидения.

## ЛИТЕРАТУРА

Аминева В.Р. М.Ю. Лермонтов и Г.Тукай: к вопросу о структурно-содержательных особенностях межлитературных текстовых образований // Филология и культура, 2012. № 2. – С. 7-10.

Галиуллин Т.Н. Диалог национальных литератур (на примере творчества г. Тукая) // Филология и культура, 2014. №2. – С.105-107.

Жирмунский В.М. Сравнительное литературоведение. Восток и Запад. Л.: Наука, 1979. – 500 с.

Тукай Г.М. Әсәрләр. 1 т. Шигъри әсәрләр (1904-1908). – Академик басма. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – 407 б.

Тукай Г. Стихотворения: пер. с татар. Л.: Сов. писатель, 1988. – 432 с.

Хабибуллина А.З. Из истории переводов произведений М.Ю. Лермонтова в тюркоязычных литературах // Ученые записки Казанского университета. Серия Гуманитарные науки. Т.151., 2009. №3. – С. 144-152.

**Э.Ф. ГАРИФУЛЛИНА**
Казан федераль университеты, Казан

## Х.ТУФАН ИҖАТЫНДА ГРАЖДАНЛЫК ЛИРИКАСЫ

**Э.Ф. ГАРИФУЛЛИНА**
Казанский федеральный университет, Казань

## ГРАЖДАНСКАЯ ЛИРИКА В ТВОРЧЕСТВЕ Х.ТУФАНА

**Аннотация.** Статья посвящена изучению особенностей гражданской лирики в творчестве Х.Туфана. В его гражданской лирике важное место занимает тяготение к метафорическому или символическому мышлению, сочетание условности с напряженными лирико-эмоциональными моментами. В ходе исследования установлено, что традиционные для татарской поэзии образы-символы в гражданской лирике поэта выступают «выразителями» «противоидеологической» авторской позиции, становятся номинациями субъективного отношения татарских поэтов к происходящим событиям.

Татар халкының туй йоласы иҗаты фольклорчылар, этнографлар тарафыннан шактый өйрәнелгән өлкә. Соңгы берничә дистә елда бу юнәлештә фольклор һәм әдәбият галимнәре Р.Мөхәммәтҗанов [Мөхәммәтҗанов, 1977], М.Бакиров [2008], Традицион мәдәниятне үстерү үзәге белгече З.Арикеева-Брусько [2009] һ.б. кызыклы хезмәтләре дөнья күрде.

Чыннан да, туй йоласы үзенең тирән эчтәлеге, матурлыгы белән тикшеренүчеләр игътибарын даими җәлеп итүче өлкә. Кайсы чорда һәм кайсы халыкта булуына карамастан, никах туе белән бәйле йолаларның төп мәгънәсе яңа гаиләне булдыру, аны рәсмиләштерү һәм тануга кайтып кала. Р.Мөхәммәтҗанов билгеләвенчә: "Туй йолаларының төп юнәлеше һәм составы бер йорттан икенче йортка кыз (кәләш) тапшыру, булачак ирнең йортына озатудан тора. Калган бөтен эшләр (башта, озатканда, соңыннан булган чаралар) һәммәсе дә әлеге үзәк акт – ярәшелгән кызны күчерү – тирәсенә тупланган [Мөхәммәтҗанов, 1977: 11]". Бу процесс күпчелек халыкларда һәм татарларда да шулай булган һәм берничә көнгә яки айга сузылган. Шул рәвешле ул катлаулы фольклор-этнографик комплексы барлыкка китергән.

Соңгы елларда Казан федераль университеты студентлары тарафыннан җыелган фольклор материаллары арасында туй йолалары турында шактый кызыклы мәгълүматлар бар. Әмма аларда аермалар бик аз. Туй йоласының этаплары, детальләре

күп очракта кабатлана. Соңгы елларда рус һәм башка милләтләрнең традицияләренә, заман үзенчәлекләренә иярү дә сизелә. Кызганыч, чит йогынтыга иярү милли йолаларның онытылуына, югалуына китерә.

Ә менә Россиядәге иң зур татар авылларының берсе булып саналган Мордовия республикасының Белозерье авылында туй йолаларын саклауга хәзер дә бик зур игътибар бирелә икән. Әлеге авылда уздырылучы туй йоласы түбәндәге ритуалларны берләштерә.

1) *Яучылау (кодалау).* Яучылау өчен биредә иң уңышлы көн дип чәршәмбе һәм җомга көн санала. Яучы булып егетнең әти-әнисе яки берәр якын туганы килергә мөмкин. Кыз бу егеткә барырга риза булса, аның әти-әнисе чәй өстәле артында яучыларга хәбәрне әйтәләр һәм кул билгесе көнен билгелиләр.

2) *Ярәшү яки кул билгесе көне.* Бу көнне кыз йортына егетнең әти-әнисе зур бүләкләр белән килә. Алар булачак кодагыйлар белән калым хакын (хәзерге вакытта мәһәр якынча йөз мең сум тирәсе), кызга нинди киемнәр алырга кирәклекне (елның дүрт фасылына да яраклы баш, өс, аяк киемнәре, туй, туй арты көне өчен киемнәр һ.б.) сөйләшәләр. Аларны тәмле ризыклар белән сыйлап, кызның ризалык билгесе буларак берәр бүләк, мәсәлән сөлге биреп озаталар. Кияүнең нинди вакытка килергә мөмкин икәнен әйтеп җибәрәләр. Билгеләнгән вакытка кияү үзенең бертуган абыйсы яки энесе, я берәр якын дусты белән килә. Кызга бүләк итеп алтын бизәнү әйбере һәм чәчәк алып килә.

3*) Сүз бетерү.* Бу көнне егетнең әти-әнисе һәм якын туганнары җыелышып кыз йортына баралар. Алар барысы да яшь киленгә һәм аның әнисенә бүләкләр алып киләләр. Кияүнең әнисе кәләшкә алтын бизәнү әйберсе бүләк итә. Кодагыйлар да бер-берсенә зур бүләкләр бирешәләр.

4) *Туй.* Сүз бетергән көнне кичен кыз өенә ике яктан да яшьләр җыела. Менә шул көнге табынны туй дип йөртәләр. Элегрәк кызлар һәм егетләр бер өстәлләр артына утырганнар. Шушында танышып өйләнешүчеләр дә шактый булган. Әмма хәзер, авылда ислам дине йогынтысында кызлар һәм егетләр аерым өстәлләргә утыралар. Бу көнне кунакка килгән яшьләрнең барысына да кызның әнисе бүләк биреп җибәрә.

5*) Никах* - туйның иң әһәмиятле өлеше. Белозерьеда аны Фатия дип атыйлар. Монда инде ислам, шәригать кануннары өстенлек итә. Никах кыз өендә укыла. Никахка өлкәнрәк кешеләр килә. Кияү үзе белән мулла алып килә. Мулла никах укыр алдыннан кыздан өч тапкыр рөхсәт сорый. Кызның җавабыннан соң гына никах укыла. Кияүнең этисе мәһәрне кәләшнең кулына тапшыра. Фатия вакытында өстәлгә савыт белән су куела. Аны “фатия суы” (Ләбәжәдә) дип атыйлар. Никахтан соң бу су белән яшьләр кулларын, битләрен юалар, аннан агач төбенә түгәләр. Ә юынган сабын белән себеренгән (сөртенгән) сөлгене яшьләр үзләренә генә тоталар. Ә менә Торбеев районында никах суы белән яшь парлар мунчада юынырга тиеш икән.

6) *Фатия көнендә үк*, өлкәннәр таралгач, 30-35 егет белән кияү кызны алырга килә. Шау-гөр килеп, бик күңелле итеп киләләр. Мылтыктан аталар. Мылтыктан ату күренеше Казан арты авылларында сакланмаган. Белозерьедагы информантлар да “мылтыктан ату нигә кирәк?” дигән сорауга җавап бирә алмадылар. Әмма туй йоласына караган фәнни хезмәтләрдә бу сорауга бик кызыклы җавап бар. Р.Мөхәммәтҗанов кияү килгәндә мылтыктан атуны борынгыдан калган йола элементы дип күрсәтә һәм борынгы кеше карашынча, усал, явыз көчләргә каршы тору чарасы, ягъни апоторопик магиянең бүгенге көнгә килеп җиткән күрсәткече дип саный [Мөхәммәтҗанов, 1977: 28].

Кияү егетләрен ишек төбендә кечкенә малайлар көтеп тора. Алар кияүне акча түләгәч кенә кертәләр. Кыз өендә ашап-эчкәч, кияү, әти-әнисеннән рөхсәт сорап, кызны

алып китә. Машиналарның сигналларын кычкыртып һәр урамны әйләнәләр һәм егет ягы әзерләгән табынга туй мәҗлесенә – кодага кайталар.

7*) Ко(ы)да.* Кодада кеше бик күп була (250-300 ләп кеше). Зурлап уйнала. Кодада өч-дүрт сәгать дәвам итә. Ирләр һәм хатын-кызлар аерым өстәлләр артына утыра. Яшь парлар да иң якын туганнары белән аерым утыралар. Кунаклар бераз ашап-эчкәч, яшь кәләш белән кияүне хатын-кызлар ягына "тау итәргә" ягъни, күренергә чакыралар. Күренекле галим М.Бакиров "Туй табыны җырларының беришe, мәҗлес ахырында җырлана торганнары, тау итү җырлары дип атала. Тау итү кыпчаклардан килгән борынгы гыйбарә, рәхмәт белдерү мәгънәсендә. Мондый җырлар мишәрләрдә һәм керәшен татарлары арасында күбрәк сакланган" – дип яза. [Бакиров, 2008: 79]. Белозерьеда "тау итү" җырлары бүген дә сакланган. Ике як уздырышка кияү һәм кәләшне мактап җырлый. Алар чыгып киткәч тә, ике як кодагый-кодачалар арасында кара-каршы җырлашу дәвам итә. Җыр текстлары шактый күп. Чөнки туй табыны җырларының тематикасы, эчтәлеге шактый киң. Иң характерлы һәм киң таралган җырлар яшьләрне, ике якның да нәсел-нәсәбен һәм бер-берләрен макташуга корылган. Шуларның кайберләренә генә булса да игътибар итик. Җырларның кайберләрендә яшьләрне мактау, аларга бәхетле тормыш теләү күзәтелә:

1) Йе(ө)злереңә йе(ө)з карадым,
Йе(ө)з карап та туймадым.
Нурдан яралгансың диеп,
Син маемны уйладым.
2) Карагызчы киленемә,
Каршысында ае бар.
Җир шарында рәхәт яшә,
Йерәгемнең маеман (мае белән).
3) Э(ө)сләрегезгә килешә
Костюм күгелчемнәре
Пар килдегез, шат яшәгез,
Бохар күгәрченнәре.
4) Ке(ө)згегәме багыштыгыз,
Куллармы алыштыгыз?
Сахра былбыллары кебек
Сез каян табыштыгыз?

Кайбер текстларда кунакларны кыстап ашату, хөрмәтләү, аларның мөнәсәбәте өчен борчылу сизелә:

Магазиннан сатып алдым,
Ике тәңкәгә бер каз.
Ашамыйсыз да эчмисез,
Әллә хөрмәтебез аз?

Җырлар кода-кодагыйларга рәхмәт әйтеп, өйгә кайтыр вакыт җиткәнне белдерү белән тәмамлана:

Ары да ефәк эләбез,
Бире дә ефәк эләбез.
Кодагыйга рәхмәт әйтеп,
Давай өйгә китәбез.

Җырлашу бетү белән, кодалар мәҗлесе дә ахырына якынлаша. Кунаклар тарала, ә яшь киленнең туганнары кияү йортына “урны түшәргә” китәләр. Урынны кәләшнең иң якын җиңгәләре түши һәм кодагыйда кунак булгач, кайтып китәләр. [Иск.: Салихова Ә.]

Икенче көнне тагын кунаклар җыела. Монысы инде “урны кыртлау”, ягъни, урынны котлау дип атала. Бу көнне якын туганнар гына җыела. Монда кеше саны азрак (100-150) була.

Ә менә Мордовиядәге Торбеев районында туйның төп өлеше җиде көн үткәрелә:

1 көн- яраш туй (кыз ягында);

2 көн – алыр туй (егет ягында);

3 көн – еңәләр (җиңгиләр) Кызны кияү йортына төшерүче җиңгиләр белән кияү ягында була;

4 көн – кодачалар (ике якта да);

5 көн – кияүләр (кыз ягында);

6 көн – кодагыйлар (ике якта да);

7 көн – ике якта да Коръән укытыла. [Иск.:Агишева Ә.]

Замана туйларын оештыруны артистларга тапшырып, халык үзенең табигый күңел ачуын оныта барган вакытта, Мордовиядә яшәүче кардәшләребезнең гаилә йолаларының иң матуры – никах туе йоласын бүгенге көнгә кадәр шактый тулы формада саклап үткәрәләре һәм киләчәк буынга җиткерүләре бик матур күренеш.

## ӘДӘБИЯТ

Бакиров М. Гаилә-көнкүреш йолалары һәм аларның поэзиясе / Татар фольклоры: Югары уку йортлары өчен дәреслек. Казан: Мәгариф, 2008. – Б. 65-88.

Мөхәмәтҗанов Р. Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты (Туй поэзиясе) “Татар халык иҗаты” курсы буенча читтән торып укучы студентлар өчен уку әсбабы. Уфа, 1977.

Брусько З. К вопросу комплексного изучения фольклора (на примере семейно-бытовых обрядов татар) // Актуальные проблемы современной фольклористики: материалы международной научно-практической конференции (Казань, 29 июня 2009 г.) ИЯЛИ им. Г.Ибрагимова АН РТ. Казань: Алма-Лит, 2009. – С. 88-89.

Искәрмәләр:

Агишева А., 1973 елгы, татар, Мордовия Республикасы, Торбеев районы Тат. Юнки авылында туган. Язып алучы Җамалиева Л.Ф. 17 сентябрь 2010.

Салихова Ә.А., 1941 елгы, татар, Мордовия Республикасы, Ромадан районы Белозерье авылында туган. Язып алучы Җамалиева Л.Ф. 18 декабрь, 2010.

**Г.Ә. ҖӘЛӘЛЕТДИНОВА**
КФУ каршындагы Ш.Мәрҗани исемендәге 2 нче татар гимназиясе, Казан
**Н.М. ЙОСЫПОВА**
Казан федераль университеты, Казан

# М.ҖӘЛИЛНЕҢ «МОАБИТ ДӘФТӘРЛӘРЕ» ЦИКЛЫНДА МОТИВЛАР ТӨРЛЕЛЕГЕ

**Г.А. ЗАЛЯЛЕТДИНОВА**
МБОУ «Татарская гимназия №2 имени Шигабутдина Марджани
при Казанском федеральном университете», Казань
**Н.М. ЮСУПОВА**
Казанский федеральный университет

# МОТИВЫ В ЦИКЛЕ «МОАБИТСКИЕ ТЕТРАДИ» М.ДЖАЛИЛЯ

**Аннотация.** Статья посвящена изучению мотивов в «Моабитских тетрадях» Мусы Джалиля. Его лирика характеризуетсяразнообразием мотивов, сочетанием условности с напряженными лирико-эмоциональными моментами. В ходе исследования установлено, что в исследуемый период поэзия Джалиля становится источником универсальных обобщений: раскрываются роль и взаимоотношения поэта и поэзии, поэта и Родины, поэта и вселенной, где переплетаются реалистические, романтические, фольклорные традиции и философские мотивы.

**Abstract.**The article is devoted to the study of motifs in Moabit notebooks by Musa Jalil. His lyrics are characterized by a variety of motives, a combination of Convention with tense lyrical and emotional moments. The study found that during the study period poetry Jalil becomes the source of universal generalizations: describes the role and relationship of the poet and poetry poet and the Motherland, the poet and the universe, intertwined with the realistic, romantic, folk traditions and philosophical motives..

**Ключевые слова:** лирика, образ, мотив, лирический герой, М.Джалиль.
**Keywords:** lyrics, image, motif, lyric hero, M. Jalil.

Тоткынлыкта язылган шигырьләрендә Җәлил фәлсәфи яктан да, форма җәһәтеннән дә башка югарылыкка күтәрелә. Шигырьләрен төзүдә төп композицион алымнар булган кабатлаулар, көчәйтүләр хиснең дәрәҗәсен арттыруга хезмәт итә («Ышанма», 1943; «Җырларым», 1943; һ.б.), интонация үзгәреше (салмак интонация үлемгә тыныч мөнәсәбәт булдыруга юнәлтелә: «Дуска», 1943), сүз-сурәт фәлсәфи эчтәлекне тирәнәйтү максатында кулланыла («Җырларым», 1943; «Чәчәкләр», 1943), якты хыял, якты гомер, ал таң, акбүз ат, зәңгәр томан, ак дулкыннар кебек төсне белдерүче эпитетлар фәлсәфи мотивларны җиткерүдә, лирик герой күңеленең матурлыгын, керсезлеген ачуда терәккә әйләнә. Җәлил милли поэзиянең күптөрле традицияләренә – классик әдәбият һәм халык иҗатында чарланган формаларга таяна. Аның әсәрләрендә халык авыз иҗатының әкият-дастаннарындагы сурәтләр, шартлы алымнар һәм тел чаралары күзәтелә [Мостафин, Йосыпова, 2017: 325]. Болар барысы да аның поэзиясенә көчле романтик рух бирә.

Бу чорда иҗат ителгән шигырьләрдә төп мотивлар буларак илгә тугрылыкны раслау, җиңүгә ышаныч, батырлыкка дан җырлау, илне сагыну, тоткынлык аерылып чыга.

Туган илгә тугрылыкны раслау мотивы ант һәм ышаныч образлары, үлем-үлемсезлек төшенчәләре белән тыгыз бәйләнештә бирелә, алар шагыйрь шәхесе белән

Туган ил арасындагы мөнәсәбәтне ачуда төп чарага әверелә. Моңа кадәрге иҗатында шагыйрь үлемне үлемсезлеккә, мәңгелек яшәешкә юлның башлангыч ноктасы дип расласа, хәзер инде коллыктан котылу чарасы итеп карый башлый.Яшәү-үлем оппозициясенә таянып язылган «Дуска» (1943) шигырендә батырларча үлү һәм хыянәтче булып үлү каршылыгы үлемне коллыктан котылу һәм Ватанына керсез мәхәббәтен дәлилләүче чара дәрәҗәсенә күтәрә:

*Юк, теләмим мин бу «исәнлекне»,*
*Йөрәк минем моңа үчекмәс.*
*Кешеме мин илем үги иткәч,*
*Җирдә миңа эчәр су беткәч?!*[Җәлил, 1976: 192].

Үлем темасына язылган шигырьдә, читкәрәк китеп, илнең уңышлары турында сөйләү дә аңа үз үлемен аклау, үлемнең бу очракта бердәнбер дөрес юл булуына инандыру өчен хезмәт итә.

«Моабит дәфтәрләре»нең дә, Җәлил иҗатының да программ әсәре дәрәҗәсенә күтәрелгән «Җырларым» (1943) шигырендә туган илгә тугрылыкны раслау мотивы җыр символик образы аша ачыла.

Илне сагыну мотивлары белән сугарылган шигырьләрдә Туган ил чит җиргәкаршы куела:

*Туган илем, үксез улың булып*
*Үләм инде читтә тилмереп.*
*Яшем барсын синә елга булып,*
*Каным шытсын кызыл гөл булып* («Соңгы үпкә», 1943)[Җәлил, 1976: 163].

Тоткынлык мотивы «Бүреләр» (1943), «Таш капчык» (1943), «Алман илендә» (1944) кебек шигырьләрдә алга чыга, мондый әсәрләрдә фаҗигалелек көчле.

Бер төркем шигырьләрдә тоткынлыкта яшәп, палач балтасы астында гомере өзеләчәген белгән, илендә әсирләр, ягъни дошманнар исемлегендә йөргән шагыйрь язмышы фаҗига буларак ачыла[Заһидуллина, Йосыпова, 2011: 221]. Мәсәлән, «Соңгы үпкә» (1943) әсәрендә төп хиснең сәбәбен тоткын геройның әсирлектә үлемгә әзерләнүе, үлемнең аны яшәеш матурлыгыннан аерачагын уйлап газаплануы тәшкил итә. Чит җирдәге үлем фаҗигасе белән янәшә туган илдәге хаксыз мөнәсәбәтне фаразлау, шуның өчен язмышка үпкә тоемлана.

Кайбер шигырьләрдә («Алман илендә» (1944), «Катыйльгә» (1943), «Вәхшәт» (1943), «Бүреләр» (1943), «Кол» (1943), «Хөкем алдыннан» (1943), «Таш капчык» (1943) һ.б.) дошман образы фашист дип аталып, югары мәдәниятле, акыллы алман халкының фашизм колына әверелү фаҗигасенә кагылына. Мәсәлән, «Бүреләр» (1943) шигырендә бүре метафорасы фашистларның бүреләрдән дә ерткычрак булуы турындагы фикерне ассызыклый:

*Кешеләр сугыша, кан коя,*
*Киселә меңнәрчә гомерләр.*
*Төн буе улашып якында*
*Иснәнеп йөриләр бүреләр.*
*Бүреләр,*
*Аһ, ләкин бүреләр*
*Бу кадәр үк ерткыч түгелләр* [Җәлил, 1976: 123].

«Вәхшәт» (1943) шигырендә фашистларның, аналарны, балаларны кырга куып, атып үтерүләре кичерешләр сәбәбе булып килә:

*Ул сарыла шашкан анасына,*
*Нәни күңеле сизә, күрәсең!*
*– Аталар бит, әнием, яшер мине,*
*Әнием, бәгърем, килми үләсем!..* [Җәлил, 1976: 181].

Көннең яңгырлы булуы, болытларның җиргә иелүе, елгаларның үкереп агуы, бу вәхшәткә «түзә алмаган җир-ананың, тешләрен кысып, үксеп җылавы, көзге урманның шашып шаулавы, җил сызгыруы» кебек әдәби детальләр, «үзем күрдем» гыйбарәсен кабатлау эмоциональ тәэсирлелекне көчәйтүгә хезмәт итә. Ил өчен үлем шушы вәхшилекне җиңә алырдай көч югарылыгына күтәрелә. Дошманга нәфрәт белән сугарылган мондый әсәрләрдә фашизмга бәя бирү һәм лирик геройга үз кичерешләрен тирәнрәк ачу максатыннан катыйль («Катыйльгә»), шакшы куллар, канга туймас Гитлер, фашист этләре («Дошманга каршы»), кызыл күзле, юеш танаулы җәллад («Хөкем алдыннан»), зур борынлы, ямьсез бакыр күзле («Вәхшәт») кебек натуралистик образлар, эпитетлар өстенлек ала; болар «Моабит дәфтәрләре»нең үзенчәлекле лексик сурәт катламын тәшкил итә.

Батырлык мотивы шигырьләрдә еш кына мифологик мотивлар, образлылык ярдәмендә белдерелә. Мәсәлән, «Ана бәйрәме» (1943) балладасында экияттәгечә өч ул, аларның икесе яуда башын салу, «алмаз кылычлы» өченче улның җиңеп кайтуы, хәбәр китерүче җил һәм күгәрчен, кайгыдан сукырайган ананың күзләре ачылу кебек мотивлар ил өчен көрәшне данлауга хезмәт итә. «Сандугач һәм чишмә» (1942) балладасында аллегорик образлылык шулай ук ил өчен үлү фикерен калкыта, табигать матурлыгы үлемнең ямьсезлеген көчәйтүгә юнәлдерелә. «Кызыл ромашка» (1942) балладасында батырлык иң югары кыйммәт дәрәҗәсенә куела, илгә тугрылык, батырларча ныклык ромашка образы аркылы җиткерелә.

Җәлилнең легионда вакытта язылган бер цикл шигырьләре юмористик эчтәлекле һәм нейтраль темага иҗат ителә. Конспирация таләпләреннән чыгып, шагыйрь монда үзен бик сак тота, фикерен яшерергә мәҗбүр була («Сыра залында», 1942; «Шагыйрь», 1942; «Аерылу», 1942; «Дару», 1942; «Ишек төбендә», 1942; «Хәдичә», 1943; «Томаулы гыйшык», 1943; һ.б.).

Шулай итеп, М.Җәлилнең тоткынлык чоры иҗаты мотивлар төрлелеге белән билгеләнә, ул үзенең иҗатын мотивлар ягыннан баета, катлауландыра. Мондый шигырьләре белән герой-шагыйрь Муса Җәлилнең исеме «тарихларда укып ятларлык» булып халык күңелендә уелып кала.

## ӘДӘБИЯТ


Җәлил М. Әсәрләр: дүрт томда. Т.2. Казан: Тат.кит.нәшр., 1976. – 495 б.

Заһидуллина Д.Ф., Йосыпова Н.М. XX гасыр татар әдәбияты тарихы. I кисәк (XX гасырның беренче яртысында татар әдәбияты): Югары уку йортлары өчен дәреслек. Казан: Казан ун-ты нәшр., 2011. – 235 б.

Мостафин Р., Йосыпова Н. М.Җәлил / Татар әдәбияты тарихы: 8 томда. Т.5: 1917-1956 нчы еллар). Казан: Татар. кит. нәшр., 2017. – Б. 315-345.

**Э.А. ИСЛАМОВА, Р.М. БОЛГАРОВА**
Казанский федеральный университет, Казань

# ЛЕКСИКА МАТЕРИАЛЬНОЙ КУЛЬТУРЫ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА В РУССКОЯЗЫЧНЫХ СЛОВАРЯХ

**Аннотация.** Язык, являясь неотъемлемой частью культуры народа, хранит в себе и передает от поколения к поколению бесценные сокровища культуры. Лексика любого языка отражает материальную культуру народа, в ней аккумулируются сведения об окружающем мире, об условиях жизни, быте и т.п. Изучение такой лексики предоставляет ценный материал о лексико-семантическом и структурном развитии лексических единиц языка, способствует раскрытию различных сторон хозяйственной деятельности этноса, выявлению его экономических и культурных связей с другими народами.

Статья посвящена исследованию наименований предметов одежды тюркского происхождения в русскоязычных лексикографических источниках.

**Abstract.** Language is an integral part of people's culture. It stores priceless treasures of culture and transmits them from generation to generation. The vocabulary of any language reflects the material culture of the people, it accumulates information about the world, living conditions, life, etc. The study of such vocabulary provides valuable material on the lexical, semantic and structural development of the lexical units of the language, it contributes to the disclosure of various aspects of the economic activity of the ethnic group, the identification of its economic and cultural ties with other peoples.

The article focuses on the study of clothing terminology of Turkic origin in Russian-language dictionaries.

**Ключевые слова:** лексика материальной культуры, тюркизмы, наименования одежды.

**Keywords:** vocabulary of material culture, Turkisms, clothing names.

В отечественной лингвистике активно развивается лингвокультурология, которая рассматривает язык не только как средство общения и познания, но и в качестве выразителя национально-культурного своеобразия народного духа.

Лингвокультурологические исследования призваны выявлять специфику отражения культуры в языке. Объектом изучения может стать материальная или духовная культура. Лексика материальной культуры занимает особое место в лексическом составе любого языка. Исследуя названия жилищ, одежды, обуви, посуды, домашней утвари и пр., исследователи обращаются к внеязыковой действительности, к этнографическим данным.

Одежда любого народа является важной составной частью культуры народа в целом. В ней отражаются традиции, социальные отношения, эстетические нормы. Лексика этой тематической группы теснейшим образом связана с историей народа, реагирует на изменения в жизни этноса, связанные с условиями среды обитания, климата, духовной жизни.

Задачей данной статьи является изучение лексики материальной культуры татарского языка в аспекте тюркско-русских языковых контактов, а именно лексем-тюркизмов в русскоязычных словарях.

Разработка вопросов взаимовлияния языков является одной из важнейших задач современной лингвистики. История русского народа тесно связана с судьбами тюркоязычных народов. Результатом языковых контактов тюрков и славян является

многочисленные заимствования из различных тюркских языков (или посредством тюркских языков).

Как показали результаты исследования, в исторических словарях русского языка зафиксировано большое количество названий предметов одежды тюркского происхождения, в том числе ушедших из активного употребления. Среди них наименования предметов верхней и нательной одежды, обуви, головных уборов, а также их элементов, названия тканей и т.д.

В меньшей степени известны специалистам исторические словари, составленные по региональным памятникам русской письменности. Например, в издании «Казанский край: Словарь памятников XVI века» отмечены использованные в «Писцовой книге города Казани, его острога, посада и слобод и церковных, городских и посадских выгонных земель» 1565-1568 гг. лексемы: *бахрома, кушак* “пояс”, *камка* “шелковая узорчатая ткань”, *мухояр* “старинная бумажная ткань с примесью шерсти или шелка”, тафта “тонкая и плотная шелковая ткань” и др. [Исламова, 2000].

Зафиксированы не только апеллятивы, но и собственные имена, которые позволяют судить о существовании нарицательных имен. Например, в списке жителей Казани XVI века встречаются Иванка *Башмаков* (от слова *башмак* “низкая обувь, преимущественно кожаная, женская или детская; ботинок”); Порыга *колпачник* (от слова *колпак* “вид головного убора”); Иванко *тафейник* (от слова *тафья* “небольшая шапочка: ермолка, тюбетейка или скуфейка”) и др. [Исламова, 2000].

«Тюркизмы в русской литературе» Р.А.Юналеевой (2005) – богатейший словарь с текстовыми иллюстрациями, составленный на материале произведений восемнадцати русских классиков XIX столетия. В этом издании зарегистрировано более пятидесяти лексем изучаемой группы. Это наименования предметов одежды, обуви, головных уборов, а также их элементов: *башлык, башмак, бешмет, бурка, ичиги, казакин, кайма, кафтан, колпак, кушак, папаха, тулуп, тюбетейка, халат, чалма, чоботы, чувяки, шаль, шаровары* и др. [Юналеева, 2005]. По материалам данного словаря можно судить об употребительности того или иного слова, об изменениях в его семантике, о производных и др.

Рассмотрим пример с последней лексемой из данного списка слов.

«Большой толковый словарь русского языка» раскрывает значение, происхождение слова *шаровары*: «От тюрк. шалвар из перс. Длинные широкие штаны свободного покроя, заправленные в голенища» [Большой толковый словарь, 1998: 1491]. Среди других примеров употребления есть любопытные: «*Татарские шаровары* (собранные в сборки у щиколоток)»; производное слово *шароварчики* отмечено стилистически как уменьшительно-ласкательное, это подтверждает свойственную некоторым тюркизмам способность к развитию значений эмоционально-оценочной характеристики.

«Этимологический словарь русского языка» М.Фасмера также указывает на персидское происхождение слова *шаровары* «через тюркское посредство», приводит много параллелей из тюркских, финно-угорских языков [Фасмер, 2004: 410].

По данным словаря Р.А. Юналеевой «Тюркизмы в русской литературе», в произведениях шестнадцати из восемнадцати классиков русской литературы XIX века употребляется лексема *шаровары* в значении “широкие штаны особого покроя, обычно заправляемые в сапоги”, например: «Передо мной стоял великан необыкновенной толщины; в нем было двенадцать вершков роста и двенадцать пуд веса, как я после

узнал; он был одет в казакин и в широчайшие плисовые шаровары; на макушке толстой головы чуть держалась вышитая золотом запачканная тюбетейка…» [Юналеева, 2005: 43]. Цитата дает представление о высокой частоте и типичном контексте употребления нескольких тюркизмов. Словарь также указывает на словообразовательную активность слова *шаровары* в виде производного *зашароварить* "заправить в брюки" в произведениях Н.С.Лескова.

Лексема *шальвары* отмечена в творчестве М.Ю. Лермонтова, И.С. Тургенева и А.Ф. Писемского в значении «широкие восточные шаровары», например, у последнего автора: «Одет он в серенький, домашний, с красною оторочкой пиджак и в широкие клетчатые шальвары» [Юналеева, 2005: 326].

В своей монографии «Тюркизмы русского языка (проблемы полиаспектного исследования)» Р.А. Юналеева указывает на параллелизм форм *шаровары, шальвары,* уточняет их этимологию и время заимствования (со ссылкой на труды П.Я.Черных и И.С.Козырева): «Форма *шальвары…* книжного характера и более всего отражает дальний персидский прототип šalvar через турецкое посредство и хронологически связывается с послевоенными событиями 1826 года. Форма *шаровары* была заимствована, очевидно, не раньше XVI в. На поздний факт усвоения русским языком указывает то, что еще в XVII в. она была малоупотребительна: при переводе польского слова *szarowary* переводчики, хотя и пользовались им, но считали необходимым комментировать его – "шаровары, то есть портки"» [Юналеева, 2000: 54].

Таким образом, языковеды располагают богатой словарной базой для исследования функционирования лексики тюркского происхождения в русском языке. Названия предметов одежды, ее деталей и т.п. зафиксированы в словарях различных типов – толковых, исторических, этимологических, созданных на материале памятников деловой письменности, художественных произведений и др. Эти материалы иллюстрируют все этапы освоения тюркизмов, развития ими переносных значений, приобретения стилистической окраски и т.д. В уже исчезнувшей лексике, зафиксированной словарями, содержится ценная информация об особенностях материальной культуры контактировавших народов.

## ЛИТЕРАТУРА

Большой толковый словарь русского языка / Сост. и гл. ред. С.А. Кузнецов. СПб.: «Норинт», 1998. – 1536 с.

Исламова Э.А., Галиуллин К.Р. Казанский край: Словарь памятников XVI века [Текст]. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2000.– 286 с.

Фасмер М. Этимологический словарь русского языка: В 4 т. Т. 4 / М.Фасмер; Пер. с нем. и доп. О.Н.Трубачева. 4-е изд., стер. М.: ООО «Издательство АСТ», 2004. – 860 с.

Юналеева Р.А. Тюркизмы русского языка (проблемы полиаспектного исследования). Казань: Изд-во «Таглимат» Института экономики, управления и права, 2000. – 172 с.

Юналеева Р.А. Тюркизмы в русской литературе. Словарь с текстовыми иллюстрациями. Казань: Изд-во «Таглимат» Института экономики, управления и права, 2005. – 752 с.

**Д.И. КАМАЛОВА, А.Ф. ЮСУПОВ**
Казан федераль университеты, Казан

# ПОЭТИК ТЕКСТНЫ ОЕШТЫРУДА ГРАММАТИК ЧАРАЛАР

**Д.И. КАМАЛОВА, А.Ф. ЮСУПОВ**
Казанский федеральный университет, Казань

# ГРАММАТИЧЕСКИЕ СРЕДСТВА В ОРГАНИЗАЦИИ ПОЭТИЧЕСКОГО ТЕКСТА

**Аннотация.** Статья посвящена проблеме функционирования грамматических средств в организации поэтических текстов в татарском языке. Актуальность исследования связана необходимостью рассмотрения художественного текста как грамматически организованного целого. Использование лингвистического анализа позволило представить способы репрезентации различных грамматических средств. В ходе исследования утверждается, что грамматические средства функционируют в поэтических текстах не только для формирования отдельных предикативных единиц, но и для создания общей синтаксической композиции, воплощая и единство замысла автора, и целостность действительности.

**Abstract.**The article is devoted to the problem of functioning of grammatical means in the organization of poetic texts in the Tatar language. The relevance of the research is related to the need to consider a literary text as a grammatically organized whole. The use of linguistic analysis allowed us to present ways of representing various grammatical means. The research asserts that grammatical means function in poetic texts not only to form separate predicative units, but also to create a common syntactic composition, embodying both the unity of the author's idea and the integrity of reality.

**Ключевые слова:** поэтический текст, грамматические средства, организация, язык поэзии.

**Keywords:** poetic text, grammatical means, organization, language of poetry.

Хәзерге тел белеме өлкәсендәге тикшеренүләрдә текст һәм аңа бәйле булган лингвистик проблемалар актуаль мәсьәләләрнең берсен тәшкил итә. Текст – сөйләмнең бөтен үзенчәлекләрен үзендә туплаган сөйләм берәмлеге [Сафиуллина, 1993: 7], аның мәгънәви, логик, коммуникатив, структур-грамматик, интонацион яктан оешкан иң зур берәмлеге, мөстәкыйль җөмләләрнең билгеле бер рәвештә оешуы [Сәлимов, 2005: 109].

Текст белән кызыксыну, иң беренче чиратта, лингвистик тикшеренүләр парадигмасын алыштыру һәм коммуникациянең реаль процессында эшли торган зур тел берәмлеген текст буларак тану белән бәйле башлана. Алга таба бу юнәлештәге эзләнүләр текст грамматикасы, текст стилистикасы, текст лингвистиксы һ.б. өлкәләр белән керешеп китә.

Текстның грамматик бөтенлеге турында сүз барганда тексттагы мөстәкыйль җөмләләрнең, абзацларның грамматик чаралар белән бәйләнүе күз алдында тотыла. Текст оештыра торган чараларны 3 төргә бүлеп карыйлар:

1. Текст оештыра торган лексик чаралар: мәгънәдәш сүзләр (синонимнар), бер тематик группага караган сүзләр (тематик лексика), кабатлаулар (лексик кабатлаулар, деривацион кабатлаулар, тамырдаш кабатлаулар, кумуляция).

2. Текст оештыра торган лексик-грамматик чаралар: алмашлыклар һәм аның төрләре, исем, фигыль, сыйфат сүз төркемнәре.

3. Текст оештыра торган грамматик чаралар: теркәгечләр, мөнәсәбәтле сүзләр, көттерү паузасы, грамматик формаларның кабатлануы, заман формаларының ярашуы, җөмләләр арасындагы логик бәйләнешләрне билгеләүче хәлләр һәм аерымланган хәлләр, модаль сүзләр (кереш һәм эндәш сүзләр), тиңдәш кисәкләр, ким җөмләләр һәм эллипсис.

Әлеге мәкалә чикләрендә без текст оештыруда аерым грамматик чаралар хакында сөйләшү белән чикләнәбез.

Беренчедән,татар телендә поэтик текст эчендәге җөмләләрне бәйләп килүдә мөнәсәбәтле сүзләраеруча актив кулланылалар. Алар җөмләләрне оештырып килү, аларны мәгънәви бөтенлек итеп оештыру сәләтенә ия. Мәсәлән:

*«Шул заманнан бирле кем алтын, көмеш*
*Күл төбендә һич хисапсыз күп, имеш.*
*“Бер заманда, шөбһәсез, бу күл кибәр”,—*
*Дип гакыллы зур хәкимнәр сөйлиләр» (Г.Тукай)* [Шигърият.ру].

Икенче яктан, текст эчендәге логик бәйләнешләрне барлыкка китерүдә хәлләр һәм аерымланган хәлләр,җөмләләр мөһим роль уйный:

*«Бармакларыңны, җанашым,*
*Күмәч белән саласың,*
*«Шалт» иттереп саласың да,*
*«Ялт» иттереп аласың* [Шигърият.ру].

Өченчедән, текст структурасында фикер тәртибен, чыганагын, логик эзлеклелекне, гомуми бәяне белдерү юлында кереш сүзләр актуаль санала. Алар җөмләләрне чагыштыралар, каршы куялар, нәтиҗә ясыйлар, фикер тәртибен урнаштыралар, аларның чыганагын теркиләр, сөйләмнең экспрессив-эмоциональ мөнәсәбәтен, фикерләрнең төгәл яки төгәл түгеллеген белдерәләр. Җөмләләр арасындагы структур бәйләнешне көчәйтеп киләләр, мәгънәви бәйләнешләрне ассызыклыйлар, фикер күчешләрен тәэмин итәләр:

*«Кара аны, яшь Ләйләңне этеп,*
*Бер әкият тагын тумасын! » (К.Булатова )*[Шигърият.ру].

Дүртенчедән, поэтик текстны җыйнак итүдә, кабатлаулардан коткаруда ким җөмләләр актив кулланыла. Бу очракта башта герой атала, аннан соң ким җөмләләр белән кыска-кыска гына аның тормышы, халәте, эше сурәтләнә. Текстны болай төзү монотонлыктан коткара, текстны мәгънәви һәм логик яктан бер бөтен итә, ритм һәм интонация ягыннан бердәм итеп оештыра:

*«Соңладым...» дип, әллә уйнап инде,*
*Әллә чынлап әйтеп куясың... » (К.Булатова)*[Шигърият.ру].

Моннан тыш, татар телендәтекст эчендәге җөмләләрне бәйләүдә көттерү паузасы актив кулланылышка ия:

*Хас иткәндә (Маннур әйткән иде):*
*«Без беләбез аның хәйләсен:*
*Теләгәндә каратырга була*
*Ходайның һәртөрле бәндәсен» (К.Булатова)*[Шигърият.ру].

Поэтик текстлар телендә аһәңлелеккәтиңдәш кисәкләрне уңышлы куллану нәтиҗәсендә ирешелә:

*Алдагы михнәтнең, урнын әллә истикъбаль ала?*
*Тормыш инде яктырадыр, кузгала һәм җанлана» (Г.Тукай)*[Шигърият.ру].

Шигъри текстларда җөмләләрне бәйләүдә, синтаксик бөтеннең бетем өлешен оештыруда, тематик күчешләрдә өстәлмәләр мөһим роль уйныйлар. Мондый төзелмәләр өстәмә хәбәр алып киләләр, җөмләләр бәйләнешен экспрессив-эмоциональ итүдә катнашалар:

*Әмма мине (син беләсең инде)*
*Яшьләр аермасы беркайчан*
*Шагыйрьләрдән аерып сакламады,*
*Әгәр үзем киртә куймасам(К.Булатова)*[Шигърият.ру].

Кыскалыкка омтылган поэтик текстлардафигыль заманнары аерым әһәмияткә ия. Алар вакыйгаларны бер вакытка беркетәләр, хикәяләүдә үзенчәлекле интонация барлыкка китерәләр:

*Иләсләнгән җанны гаепләмим –*
*Озын кышлар аны тилмертте.*
*Сыешалмый дөньям бер йөрәккә –*
*Әрем исе мине тилертте(С.Әхмәтҗанова)*[Шигърият.ру].

Бер үк грамматик формаларның кабатлануы да шигъри текст телендә тәэсир көчен арттыра, текст оештыруның мөһим чарасы булып тора:

| | |
|---|---|
| *Кеше кайчан матур була?*<br>*Кеше матур шул чакта —*<br>*башкаларны чакырганда*<br>*үзе яккан учакка;*<br>*ятлар белән танышканда*<br>*күзләре җылынганда;*<br>*шул җылылыкның рәхәтен*<br>*җаның белән тойганда.*<br>*Кеше кайчан матур була?*<br>*Кеше матур шул чакта —*<br>*ерак дусын очраткачтын,*<br>*елаганда кочаклап;* | *җырлаган чакта җырының*<br>*моңында эрегәндә;*<br>*бәхеткә таба чапканда,*<br>*күршеңә юл биргәндә.*<br>*Кеше матур шул вакыт —*<br>*иле өчен, халкы өчен*<br>*яшәгәндә җан атып;*<br>*замананың авырлыгын*<br>*җилкәсенә алганда;*<br>*олы данга ирешеп тә,*<br>*кече булып*<br>*калганда(Р.Харис)*[Шигърият.ру]. |

Шул рәвешле, поэтик текстта грамматик бөтенлек аның үзәген тәшкил итә, грамматик чаралар аша тел чараларының барлык эстетик фунцияләре чагыла. Шигъри текстларның бөтенлеген тудыру юлында грамматик чаралар аһәңне көчәйтә, структураны бөтенлекле итә, фикерне, асыл мәгънәне төгәл җиткерүдә зур роль уйный.

## ӘДӘБИЯТ

Сафиуллина Ф.С. Текст төзелеше / Югары уку йортлары өчен дәреслек-кулланма. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1993. – 263 б.

Сәлимов Х.Х. Тел гыйлеме терминнары сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 144 б.

Шигърият.ру. Интернетта татар сәнгате һәм мәдәнияте белән таныштыру [Электрон ресурс] // URL: https://shigriyat.ru/ (мөрәҗәгать итү вакыты: 20.09.2020)

**Е.Е. ҚАНААТОВ**
Әжинияз атындағы Нөкис мәмлекетлик педагогикалық институты, Нөкис

# ҚАРАҚАЛПАҚ ХАЛЫҚ ТАРИЙХЫЙ ҚОСЫҚЛАРЫ КЛАССИФИКАЦИЯСЫНЫҢ ӨЗГЕШЕЛИГИ

**Е.Е. КАНААТОВ**
Нукусский государственный педагогический институт им. Ажинияза, Нукус

# ОСОБЕННОСТИ КЛАССИФИКАЦИИ КАРАКАЛПАКСКИХ НАРОДНЫХ ИСТОРИЧЕСКИХ ПЕСНЕН

**Аннотация.** В статье рассматривается классификация каракалпакских народных исторических песен. Проведено сравнительное изучение классификации исторических песен в фольклоре некоторых других тюркских народов. Автор сравнивает каракалпакские народные песни с классификацией исторических песен татарских, ногайских, алтайских, казахских, узбекских народов. В классификации каракалпакских народных исторических песен выбрано периодическое и тематическое направление. В статье анализируются исторические песни, созданные в связи с историческими событиями, произошедшими в жизни каракалпаков в XIII - начале XX веков.

**Abstract.** The article deals with the classification of the Karakalpak folk historical songs. A comparative study of the classification of historical songs in the folklore of some other Turkic peoples has been carried out. The author compares the Karakalpak folk songs with the classification of historical songs of the Tatar, Nogai, Altai, Kazakh, Uzbek peoples. In the classification of the Karakalpak folk historical songs, a periodic and thematic direction is chosen. The article analyzes the historical songs created in connection with the historical events that occurred in the life of the Karakalpaks in the 13th - early 20th centuries.

**Ключевые слова:** каракалпаки, исторические песни, классификация, жанр, тематика.
**Keywords:** karakalpaks, historical songs, classification, genre, subject.

Қарақалпақ халық тарийхый қосықларының классификациясы мәселесин үйренгенимизде оны халық қосықларының классификациясы ишинде қараймыз. Улыўма қосық жанрын түрлерге бөлип системалаў, классификациялаў мәселесинде ҳәрқыйлы көзқараслар ҳүким сүрип келеди.

Басқа халықларда да халық қосықларын классификациялаўда түрлише қатнас жасаўлар көзге тасланады. Бир илимпазлар халық қосықларын классификациялаў ушын оның мазмуны менен тематикасын тийкар етип алса, базылары атқарылыў орталығына, биреўлери жанрлық сыпатына қарайды. Тағы бирлери қосықтың қай жерде, қайсы аймақта дөретилгенине итибар қаратады. Сондай-ақ қосықты белгили бир социаллық топарға байланыстырып яки белгили бир кәсип түрлерине қарай классификациялаў усыллары да бар.

Мәселен, қарақалпақ фольклоры менен қазақ, ноғай, өзбек халықлары фольклоры бир-бирине жақын. Деген менен усы халықлардың халық қосықларын классификациялаўда өзине тән өзиншеликлери, айырмашылықлары бар екенлигин көриўге болады. Қазақ халық өлеңлери (қосықлары) бойынша кең изертлеген илимпаз Б.Уахатов қазақ халық қосықларын үлкен 2 топарға бөледи: биринши топар – турмыс-салт қосықлары, екинши топар – лирикалық қосықлары.

Турмыс-салт қосықлары үш топарға бөлинеди:

1) Мийнет-кәсип қосықлары. Буған аңшылық ҳаққындағы, төрт түлик туўралы ҳәм Наўрыз қосықлары;

2) Халықтың ески исениминен туўылған қосықлары. Буған порханлар айтымы менен арбаў-байлаў қосықларын киргизген;

3) Үрп-әдет қосықлары: балалар қосықлары, үйлениў салт қосықлары, муң-шер қосықлары.

Лирикалық қосықларға қара қосықлар ҳәм тарийхый қосықларды киргизеди. Қазақ халық қосықларын классификациялаўда илимпаз жанрлық белгилерин ҳәм қосықтың халық турмысынан алатуғын орнын, оның турмысқа, салтқа қатнасын есапқа алған.

Илимпаз қазақ халық тарийхый қосықларының тийкарын қазақ пенен қалмақ арасындағы шапқыншылықты, Хийўа, Бухар ханлықларының қазақ гедейлерине жасаған зулымлық ҳәрекетлери ҳәм қалың елдиң басына түскен жутшылық сыяқлы ўақыялар қурайды, деп есаплайды [Уахатов, 1974: 75-76].

Қазақ фольклорындағы тарийхый қосықлар бойынша изертлеў жүргизген Ж.Ахметжанова тарийхый қосықларды тематикалық жақтан «Тарийхый қосықлардың ески дәўирдеги хатқа түскен үлгилери», «Қазақ ханлығы дәўирине байланыслы тарийхый қосықлар», «Ақтабан шубырынды» ўақыясына байланыслы тарийхый қосықлар», «XIX әсир тарийхый қосықлары», «1916-жылғы миллий-азатлық көтерилис қосықлары» деп топарларға бөледи[Ахметжанова, 2007: 58].

Ноғай халық йырларын (қосықларын) топлап, белгили бир системаға салып дүзген С.А. Калмыкова революцияға шекемги ноғай қосықларын өзиниң мәнисине, жырланыў өзгешелигине қарай бурынғы йырлар (лиро-эпикалық йырлар), казак йырлары, яшав йырлары (бизиңше турмыс-салт қосықлары – Е.Қ.) деп топарларға бөлген.

Лиро-эпикалық йырларға Айсылдың улы Әмет батыр, Қарайдар менен Қызыл гүл, Бозйигит, Шора батыр, Әдил Солтан сыяқлы батырлық жырларды киргизеди.

Өзбек халық қосықлары жанрлық тийислилиги, жаратылыў дәўири, атқарылыў орны ҳәм түри сыяқлы тәреплери менен рәң-бәрәңликке ийе. Кейинги изертлеўлер нәтийжесине бола, өзбек халық қосықлары төмендегише классификацияланады:

1. Мийнет қосықлары;
2. Мәўсим-мәресим қосықлары;
3. Лирикалық (ашықлық) қосықлар;
4. Тарийхый қосықлар [Мадаев, Сабитова, 2001: 208].

Өзбек халық тарийхый қосықларын арнаўлы түрде изертлеген илимпаз У.Жуманазаров басқа халықлар фольклористлериниң жанрлық классификациясын үйрене отырып, тарийхый қосықларды төмендегише классификациялаўды усыныс еткен:

1) Тарийхый-қаҳарманлық қосықлар; 2) тарийхый-революциялық қосықлар; 3) тарийхый-мобилизациялық қосықлар; 4) реал шахсларға бағышланған қосықлар; 5) белгили тарийхый ўақыяларға бағышланған қосықлар [Жуманазаров, 1982: 17].

Басқа түркий халықларда халық қосықларын тәртиплестирип бөлиўде түрлише қатнаслар жасалғанын көриў мүмкин. Мәселен, алтай халық қожон (қосық)ларын Т.Тюхтенев малдас қурып айтатуғын қосық, түрегелип айтатуғын қосық, дизерлеп айтатуғын қосық, ат үстинде киятырып айтатуғын қосық дер түрлерге бөлген [Тюхтенев, 1970].

Татар халық жырларын болса белгили фольклорист И.Надиров йола (салт) жырлары ҳәм лирикалық қосықлар деп еки топарға бөледи. Йола жырларына түрли исеним, үрп-әдетке, турмыс-салтқа байланыслы қосықлар киреди. Лирикалық

қосықларға болса ойын, мийнет, солдат, турмыс-күнкөрис жырлары болып, бирде атқарылыў мәнисине, бирде дөретиўшилер орталығына, гейде мазмунына, тематикасына қарап классификациялайды. Сондай-ақ, И.Надиров татар халық қосықларын жасалыў формасына қарап: узын сюжетли жырлар, төрт қатарлы жырлар, қарама-қарсы жырланатуғын жырлар ҳәм ойын жырлар деп те төртке бөледи [Надиров, 1965: 455].

Қарақалпақ халық қосықларының классификациясы Н.А.Баскаков, Қ.Айымбетов, О.Кожуров, Н.Дәўқараев, Қ.Мақсетов, Ә.Тәжимуратов, Н.Камалов, М.Низаматдинов, С.Баўетдиновалардың мийнетлеринде сөз етиледи.

Н.А.Баскаков қарақалпақ фольклорын мазмуны ҳәм жанрлары бойынша шәртли түрде шаңарақлық-турмыс, дәстүр фольклоры ҳәм тарийхый-эпикалық жанрлар деп еки тараўға бөлди.Тарийхый-эпикалық жанрлар тараўы да екиге бөлинеди, яғный биринshisи, тарийхый қосықлар ҳәм аңызлар, екиншиси, қаҳарманлық дәстанлар. Тарийхый қосықлар ҳәм аңызлар бөлимине тарийхый қосықлар, толғаў ҳәм термелер кирсе, тарийхый дәстанларға дуўтарда айтылатуғын ҳәм қобызда айтылатуғын тарийхый эпикалық жырларды киргизген [Баскаков, 1951: 7].

Әлбетте, бул классификация ең алды менен диалектологиялық мийнетке байланыслы ислеп шығылған, сонлықтан илимпаз онда тек формалық өзгешеликлери ғана есапқа алған. Деген менен, бул классификация мол дәлийл ҳәм материалларға сүйенип исленген.

Қ.Айымбетов пенен О.Кожуров 1939-жылы “Қарақалпақстан әдебияты ҳәм искусствосы” журналында жәриялаған мақаласында қарақалпақ фольклоры жанрларын төмендегише бөледи: 1) Ертек; 2) Нақыл (термелер де усының ишинде); 3. Жумбақ (ишинде айтыс түри де бар); 4) Жаңылтпаш; 5) Жуўап; 6) Өтирик өлең; 7) Бет ашар; 8) Жоқлаў; 9) Толғаў; 10) Бәдик, Гүләпсан; 11) Жайдары қосықлар; 12) Ярамазан; 13) Дәстанлар [Айымбетов, Кожуров, 1939: 79-80]. Бул бөлистириўде халық қосықларына киретуғын жанрлар шашыранды, биринши «жайдары қосықлар» болып бөлистирилсе, екиншисинде дәстүр қосықларының ишине кирип кеткен [Баўетдинова, 2019: 21].

Қарақалпақ фольклорын классификациялаўда Н.Дәўқараевтың ислеген мийнети айрықша. Қарақалпақ фольклорының өзгешелигин жақсы түсинген илимпаз классификация мәселесинде бирқанша тужырымлы бағдар бере алды.

Ол қарақалпақ халық аўызеки дөретиўшилигин үлкен еки жанрға бөлди: 1) Лирикалық; 2) Эпикалық.

Лирикалық жанрды қосықлар, салт әдебияты ҳәм аталар сөзи деп үшке бөлди. Қосықларға жайдары қосықларды, айтыс ҳәм жуўапты, бәйтти, балалар қосықларын, жаңылтпаш ҳәм жумбақты, диний фольклорды киргизсе, салт әдебиятына ҳәйийўди, той дәстүрлериниң қосықларын (сыңсыў, бет ашар, ҳәўжар), жоқлаўды киргизеди. Ал, аталар сөзине нақыл-мақалларды, пәтия, толғаў ҳәм термелерди жатқарады [Дәўқараев, 1977: 127-160].

Қосықлардың намаға алып айтылыў тәреплерин итибарға алып, орыс композиторы В.Шафранников 1959-жылы қарақалпақ халық қосықларының әдебий текстин жыйнап, оны нотаға түсирип, “Қарақалпақ халық қосықлары” деген атама менен китап етип шығарып, онда халық қосықларын төмендегише жанрлық бөлимлерге бөлип қарады:

1. Лирикалық қосық; 2. Дәлкек ҳәм сатиралық қосықлар; 3. Ойланыў, ойлаў қосықлары; 4. Тарийхый қосықлар; 5. Социаллық қарама-қарсы идеядағы қосықлар; 6. Эпикалық баянлаў (тәрип) қосықлары [Шафранников, 1959].

Қарақалпақ халық қосықларын классификациялаўда илимпаз Ә.Тәжимуратов белгили дәрежеде табысларға ерискен. Ол тарийхый қосықларды биринши мәрте өз алдына алып қарады. Ол халық қосықларын төмендегише классификациялады:

1. Турмыс-салт қосықлары (Ҳәўжар, Той баслар, Бәдик, Бәйит, Баяз, Айтыс, Беташар); 2. Бесик жыры ҳәм балалар қосықлары; 3. Қызлар қосықлары; 4. Муң-шер қосықлары (ҳаял-қызлардын муҳаббатқа, турмыстың қыйыншылығына байланыслы наразылық қосықлары; жәмийетлик тәртиптиң әдилсизлигине налыў қосықлары); 5. Нәсият қосықлары; 6. Ойын-дәлкек қосықлары; 7. Динди әшкаралаўшы қосықлар; 8. Муҳаббат қосықлары; 9. толғаўлар ҳәм термелер; 10. Тарийхый қосықлар [Тәжимуратов, 1965: 18-19].

Улыўмаластырып айтқанда, қарақалпақ халық тарийхый қосықлары өз алдына классификация етилмеди. Тарийхый қосықларды классификация етиўде дәўирлик ҳәм тематикалық жақтан бөлген мақул. Қарақалпақ тарийхый қосықлардың ең дәслепкилери XIII әсирде Шыңғыс хан шапқыншылығынан кейин қарақалпақлардың Хорезмнен бүлип көшиў дәўиринен басланған. Соған бола, тарийхый қосықлар дәўирин:

1) Хорезм журтынан бүлип көшиў дәўири; 2) Ноғайлы дәўири; 3) Түркистан дәўири; 4) Жаңадәрья дәўири; ҳәм 5) Аралбойына қайта айланып келген дәўир.

Тематикалық жақтан: 1) Ел-журт сағынышы; 2) Батырлықты тәрийплеў; 3) Қыз салығы; 4) Қазыўға байланыслы; 5) Мәрдикарлық қосықлары деп бөлиўди мақул таптық.

## ӘДЕБИЯТ


Татар халық жырлары. Лирик жырлары, йола жырлары. Топлаған, таярлаған, алғы сөзин ҳәм түсиндирмелерин жазған И.Надиров. Казань: Татар. кн. изд-во, 1965. – 455 с.

Айымбетов Қ. Кожуров О. Қарақалпақ әдебиятының түрлери // «Қарақалпақстан әдебияты ҳәм искусствосы», 1939. №7. – Б. 79-80.

Ахметжанова Ж. Қазақ фольклорындағы тарихи өлеңдер. (филология илимлери кандидаты илимийдәрежесиушын автореферат). Алма-Ата, 2007. – 58 б.

Баскаков Н.А. Каракалпакский язык. Том 1, М., 1951. – 7 с.

Баўетдинова С. Қарақалпақхалыққосықлары. Нөкис: Қарақалпақстан, 2019. – 21 б.

Дәўқараев Н. Шығармаларыныңтолықжыйнағы. 2-том. Нөкис: Қарақалпақстан, 1977. – Б. 127-160.

Қарақалпақ халық қосықлары (Баспаға таярлаған Ә.Тәжимуратов). Нөкис: Қарақалпақстан, 1965. – 18-19 бб.

Мадаев О. Сабитова Т. Халқоғзаки поэтик ижоди. Тошкент: Шарқ, 2001. – 208 б.

Уахатов Б. Қазақ халық өлеңдері. Алматы: Ғылым, 1974. – Б. 75-76.

Шафранников В. Каракалпакские народные песни. М.: Музгиз, 1959

**Г.О. ҚАНААТОВА,**
Әжинияз атындағы Нөкис мәмлекетлик педагогикалық институты, Нөкис

# ҚАРАҚАЛПАҚ ТИЛИНДЕГИ ТАРИЙХЫЙ ЕСТЕЛИКЛЕР МЕНЕН БАЙЛАНЫСЛЫ БАЗЫБИР ТЕРМИНЛЕР
## (Аралбойы ҳәм Бухара қарақалпақлары материаллары бойынша)

**Г.О. КАНААТОВА,**
Нукусский государственный педагогический институт, Нукус

# НЕКОТОРЫЕ ТЕРМИНЫ, СВЯЗАННЫЕ С СТОРИЧЕСКИМИ ТЕРМИНАМИ В КАРАКАЛПАКСКОМ ЯЗЫКЕ
## (по материалам каракалпаков Приоралья и Бухары)

**Аннотация.** В тезисе приведены примеры различных терминов каракалпаксого языка, имеющих историческое значение и их использование в говорах. А также показано их омонимичное значение.

**Abstract.** In the thesis, various terms are taken as an example which is of historical importance used in the Karakalpak language and its local speech.

**Ключевые слова:** Приаралье, Бухара, каракалпак, святые места, термин.

**Keywords:** Aral region, Bukhara, karakalpak, holy places, term.

Қарақалпақ тили – сөзлик қоры бай тиллердиң бири. Ҳәзирге шекем қарақалпақ тилши илимпазлары тәрепинен қаншама сөзликлер дүзилсе де, олар еле де халық тилинде бар сөзлердиң ҳәммесин толық өз ишине қамтып ала алған жоқ. Бул бағдарда ҳәр тараўға байланыслы көплеп сөзликлердиң дөретилиўи зәрүр екенлиги байқалады. Келешекте дүзилиўи тийис болған усындай сөзликлер қатарына тарийхый естеликлер менен байланыслы атамалар да киргизилсе, қарақалпақ тилиниң сөз байлығы және де артар еди ҳәм ҳәзирги ўақытта умытылып баратырған көплеген термин сөзлерди қайта жаңғыртыўдың итималы туўылар еди. Қарақалпақ халқының қәдириятларының бири усындай өтмиштен жеткен мийраслар [Андрианов, 1958: 7-132].

Бул жерде биз Аралбойы ҳәм Бухара қарақалпақлары тилинде тарийхый естеликлерге, тийкарынан зиярат орынларына байланыслы қолланылатуғын (сөзликлерге енген ҳәм сөзликлерде болмаған) гейпара терминлердиң қысқаша дизимин ислеп шықтық ҳәм оларға түсиндирме берип өтиўге ҳәрекет еттик.

1. **АЙҚАЛ**. Бурынғы заманларда адам тулғасына уқсатып жасалған тас мүсинлер **«айқал»** деп аталған. Ҳәзирги ўақытта бул сөз Бухара қарақалпақлары сөйлесимлеринде ҳәм қубла диалект ўәкиллериниң тилинде қолланылады. Д.Насыров ҳәм О.Доспанов авторлығындағы «Қарақалпақ диалектологиясы» атлы мийнетте: «**айқал** – биреўдиң естелигине арнап қойылған монумент, мүсин», - деп түсиник берилген [Насыров: 1995, 104]. Ески түрки тилинде «айқал» уғымы орнына «балбал» сөзи қолланылған. Ислам дининиң күшейиўи менен Орта Азия далаларында сақланған адам көринисиндеги бундай естеликлер шетинен бузып тасланған.

2. **ӘЎЛИЙЕ**. Халық арасында «әўлийе» мәниси биринshiден «кәраматлы инсан», «көзашық» деген түсиникти, екинshiден «зиярат орны» *(«әўлийежай»)* дегенди

аңлатады. Терминниң екинши мәниси қарақалпақ тилинде кең пайдаланылады ҳәм тарийхый орынларды, тийкарынан қойымшылықты аңлатады [ҚТТС_1: 1982, 152].

3. **БАЛБАЛ**. Халқымыз ертеде саўаш пайытында қазаланған атақлы батырларына балбаллар турғызған. Әскер тулғасын сәўлелендириўши бундай балбаллар Қарақалпақстанның Үстирт кеңислигинен де табылған [Есбергенов: 1993, 22].

4. **БЕЙИТ**. Ҳәрқыйлы көринистеги саздан, тастан ҳәм ағаштан турғызылған мазарлардың улыўма атамасы. Бундай атамадағы орынлар нәзермииздеги регионда да сақланған. Мысалы: *Тасбейит, Қосбейит*.

5. **БЕСИКТАС**. Марқумның басына салынған бесик тәризли естелик. Этнограф Х.Есбергеновтың бул туўралы пикири төмендегише: *«Қулпытас, қойтас, бесиктас ҳәм тағы басқалар халқымыздың тарийхын, мәдениятын, өнерин, руўхый байлығын изертлеўде баслы дәреклердиң бири болып есапланады»* [Есбергенов: 1993, 68].

6. **БИЙНЕТАС**. Таўелибай *(Арқа Бухара)* қарақалпақларында таў жартасларына салынған ҳәрқыйлы сүўретлерди «бийнетас» деп атайды. Бундай бийнетаслар Сармышсай мәканында, Бухантаў жанбаўырларында ҳәзирге шекем сақланған [ИДЖ: 2011, 12].

7. **ДИҢ**. Халықтың сөйлеў тилинде «диң» сөзиниң еки мәниси бар: 1) бийиклик, төбелик; 2) бийик жерге соппас тәризли салынған қурылыс. Диңлер белги сыпатында қойымшылықларға да қойылады. Диң – бийик болғанлықтан айрықша оқшаўланып алыстан көринеди. Сонлықтан геўдели узын адамлар диң менен салыстырылады. «Курттай тайға диңдей молла» деген сөз усыған байланыслы қолланылады [ҚТТС_2: 1984, 78]. Мысалы: *Қусхана диңи*.

8. **ДИҢГЕК**. Сөздиң биринши мәниси – қазық тәризли қурылма, екинши мәниси – қараўыл дүмпешик,  үшиншиси – геўректиң жемиси, төртиншиси – тас сүдин *(өре)*. Диңгеклер қәбирстанларда да сақланып қалған. Сөзликте жергиликли мәнилери толық берилмеген [ҚТТС_2: 1984, 78].

9. **КЕСЕН**. Дәслеп тек ғана қурылыс мәнисинде түсинилген «кесен» кейин ала қойымшылық басына салынған естеликлерге байланыслы қолланылған. Бухара қарақалпақлары тилинде бул сөз «кешен» түринде де қолланылады ҳәм тийкарынан қойымшылықтағы тутас қурылысларды аңлатады.

10. **КЕСЕНЕ**. «Кесен» сөзи менен түбирлес болған «кесене» *(«кешене»)* түсиниги «мақбара» мәнисин билдирген. Мысалы: *Аққесене, Көккесене*.

11. **ҚАЗЫҚТАС**. Қәбир басына қойылатуғын тийкарғы тас белги. Онда марқумның шыққан тегине байланыслы мағлыўматлар, тамғалар түсириледи.

12. **ҚАЛМАҚЫ**. Қәбир үстине қамыстан өрип исленген үш мүйешли қурылма. Гейде оны «қалмақы ҳәрем» деп те атайды.

13. **ҚӘБИР**. Өли жерленген орын. *«Қәбирди изертлеп көргенде, оның арқа батыстан қубла батысқа қарай туўры төртмүйешли терең шуқыр етип қазылғанлығы, оған марқум менен қоса оның қурал-жарақлары, безениў буйымлары көмилгенлиги анықланды»* [Хожаниязов: 1994, 5].

14. **ҚӘБИРСТАН**. Қарақалпақ тилинде бул атама орнына «қойымшылық», «әўлийе» терминлери көбирек қолланылады. Нурата зияратханасы әтирапында «Қарақалпақ қәбирстаны», Кенимық жеринде «Кенегес қәбирстаны», Ғыждуўанда «Ғайып ата қәбирстаны» деген үлкен зиярат орынлары бар. *«Бул орында б.э.ш. IV әсирлерде тикленген қала ҳәзирги пайтахт қәбирстаны болған Шорша қойымшылығы ишинде қалып кеткен»* [Хожаниязов: 1994, 34].

15. **ҚӘБИРТАС**. Қәбир басына қойылатуғын ҳәрқыйлы тас белгилердиң *(қазықтас, қулпытас, бесиктас, қойтас ҳәм т.б.)* жәмлеўши атамасы.

16. **ҚӘДЕМЖАЙ**. Халық көп зияратлайтуғын кийели жер, муқаддес орын. Әўлийели жерлерден тысқары, мәдений орынлар да «қәдемжай» есапланады.

17. **ҚОЙТАС**. Зиярат орынларында белгили адамларға қойылған тас белгилердиң бир түри. *«**Қойтас** дәслепки дәўирлерде қой көринисин елеслеткен. Қойтастың бундай түрлерин С.П.Толстов та өз мийнетинде келтиреди»* [Есбергенов: 1993, 60].

18. **ҚОЙЫМШЫЛЫҚ**. Марқумларды жерлеў орны. Халық тилинде оны «қойымгершилик» деп те атайды. *«**Қойымшылық** елден аўлақ бийикликте, кеңислик ҳәм қурғақ жерде орналасып, алыстан көринип турған»* [Есбергенов: 1993, 78].

19. **ҚОРҒАН**. Қарақалпақ тилинде «қорған» сөзиниң тийкарынан «қала» *(«бекинис», «қамал»)* ҳәм «жайдың сыртын қоршаған ағаш яки тас дийўал» мәнилери белгили. Булардан тысқары, таслар менен қоршалған ески обалар турған жерди де усылай атайды. Оның шағын түрлери «қорғанша» деп аталады.

20. **ҚОРЫМ**. Қәбирстан мәнисинде қолланылыўшы сөз. Мысалы: «Қырыққыз» қорымы. Тас қоршаўларға байланыслы да «қорым» атамасы қолланылады [ҚФ: 2014, 556].

21. **МАЗАР**. Бул сөз қәбир басына салынған жайды да, қойымшылықты да аңлатады. Мысалы: *Қосмазар, Кәттемазар*.

22. **МАЗАРАТ**. Қәбир көп түскен қойымшылық «мазарат» делинеди. Сөйлесимлерде «мазарлық», «мазарстан» деген сыңарлары да бар [ҚТТС_3: 1988, 256].

23. **МОЛА**. «Мола» сөзи тийкарынан саз кесектен турғызылған қойымшылық иморатларына байланыслы қолланылады. Молалар шөл аймақларда усындай атамаларда сақланған. Мысалы: *Ақмола, Тасмола, Молалы*.

24. **МЫҚ**. Ертедеги отпаразлар орны. Бундай орынлар Бухара қарақалпақлары қонысланған аймақларда бирнеше жерде бар болып, оны «Мықтың үйи» деп те атайды. Қарақалпақ фольклоры үлгилеринде «мық» атамасы менен байланыслы мысаллар сақланып қалынған [ҚФ: 2015, 512].

25. **НЫШАНАҒАШ**. Қайсыдур бир қәдемжайды аңлатыў ямаса әрўақларды еске алыў мәнисинде қойылатуғын белги ағаш. Бундай ағашлар кийели саналады. Ол сырық ҳәм сайғақ ағаштан ажыралып турады. Нышанағашқа ҳәрқыйлы тамғалар, белгилер түсирилген.

26. **ОБА**. Әдетте, «оба» деп топырақ яки өрметас пенен үйип бастырылған қәбирлерге айтылады. Қызылқум далаларында усындай себеп пенен аталған «Қособа», «Үшоба», «Қароба» ҳәм т.б. ески зиярат орынлары ушырасады. Аңызларда Едигениң қаны тамған жер сыпатында «Созақтың қара обасы» деген сөз жийи есленеди. Қарақалпақ тилиниң түсиндирме сөзлигинде «оба» сөзиниң «аўыл, ел, жай, үй» деген мәнилери ҳәм жуқпалы кеселликтиң түри екенлиги көрсетилген [ҚТТС_4: 1992, 9]. *«...обалардың үлкен-киши болып салыныўы, жәмийеттеги класслық бөлиниўшиликти де аңлатыўы мүмкин»* [Есбергенов: 1993, 83].

27. **САЙҒАҚ**. Қарақалпақ халқының аўызеки сөйлеў тилинде «сайғақ» сөзиниң бирнеше мәнилери сақланған. Әдетте кийиктиң тумсығы дөңес болған ақ қуйрықлы түрлери усылай аталады. Жаўынгерлердиң жуўан ағаштан жонылған жарағы «сайғақ» делинген. Сондай-ақ, әўлийели жерлердеги бийик төбеликке шаншылатуғын узын ҳәм беккем сырықты да «сайғақ» дейди.

28. **САҚАНА**. Марқумды жерлемей «аты» менен жер бетине қойып, соның үстине орнатылған бесик тәризли естелик усылай аталады. Айырым орынларда сақананы

«сағана» деп те атайды. *«... көрсетилген сақана, айшық, қулпытас, бесиктасларды жергиликли естеликлер иретинде дизимге алыў керек»* [Есбергенов: 1993, 82].

29. **СЫРЫҚ**. Көпшилик зиярат орынларда халыққа сыйлы инсанлардың басына сырық орнатылады. Сырықты «сырғаўыл» деп те атайды. Марқумның әрўағына сыйыныўшылар, оны зияратлаўшылар сырыққа шүберек байлап кеткен. Аты умытылған айырым қойымшылықлар усындай сырықларға байланыслы жаңа атамалар алған: *Сырықлы, Қуўсырық*.

30. **ТАМ**. Қарақалпақ әдебий тилинде «там» сөзи тийкарынан «имарат» мәнисин ҳәм «өжире» мәнилерин билдиреди. Айырым сөйлесимлерде бул сөз «мазар басына салынған жай» мәнилеринде де ислетиледи.

31. **ТАМҒА**. Қәбир басына қойылған қазықтаслар менен қулпытасларға, басқа да естеликлерге марқумның тегин еслетиў ушын салынған белги. Тамға – әўлад ийелериниң бирден-бир баслы нышаны. Усыған байланыслы ата-бабалар: «Тамағыңа бола тамғаңды жойытпа», - деп ескерткен [Саза: 2020, 8].

32. **ТИЛЕЎХАНА**. Әўлийели орынлар басына салынған сыйыныў ханасы. Әдетте, тилеўханаларда әўлийе-әнбиялардан перзент тилеген ҳаяллар түнеген ҳәм сол жерде садақа тарқатқан.

33. **ТӨРТҚУЛАҚ**. Марқумлардың қәбири үстине салынатуғын қурылыстың кең тараған түри.

34. **ҮЙМЕТАС**. Ески диний исенимлерге байланыслы айырым орынларда қойымшылықтағы тасларды бир жерге жыйнаў дәстүри бар. Бундай тасларды халық «үйметас» деп атайды. Хожели қаласындағы тарийхый төбеликте жайласқан қойымшылықлар әтирапында усындай үйметасларды ушыратыўға болады.

Улыўма алғанда, қарақалпақ тилинде тарийхый-мәдений естеликлер менен байланыслы бирқанша терминлер бар болып, келешекте олардың ҳәрбириниң анықламасын бериў зәрүр болады. Бул өз нәўбетинде, илимий терминологиямызды байытып баратуғынлығы тақыйық.

## ӘДЕБИЯТ


Андрианов Б.В. Этническая территория каракалпаков в северном Хорезме // ТХАЭЭ, том. III, М., 1958. [Andrianov B.V. The ethnic territory of the Karakalpaks in northern Khorezm // PKAEE, vol. III, M., 1958.].

Есбергенов Х. Қоңырат: тарийхый ҳәм мәдений естеликлери. Нөкис: Билим, 1993. [Esbergenov H. Konyrat: historical and cultural monuments. Nukus: Bilim, 1993.].

ИДЖ – Изертлеўшиниң дала жазыўлары. Таўелибай, 2011. Дәпт. № 4. [RFR – Researcher's field records. Tauelibay, 2011. Noteb. No: 4.].

ҚТТС_1 – Қарақалпақ тилиниң түсиндирме сөзлиги. I том. Нөкис: Қарақалпақстан, 1982. [EDKL – Explanatory dictionary of the Karakalpak language. I vol. Nukus: Karakalpakstan, 1992].

ҚТТС_2 – Қарақалпақ тилиниң түсиндирме сөзлиги. II том. Нөкис: Қарақалпақстан, 1984. [EDKL – Explanatory dictionary of the Karakalpak language. II vol. Nukus: Karakalpakstan, 1992.].

ҚТТС_3 – Қарақалпақ тилиниң түсиндирме сөзлиги. III том. Нөкис: Қарақалпақстан, 1988. [EDKL – Explanatory dictionary of the Karakalpak language. III vol. Nukus: Karakalpakstan, 1992].

ҚТТС_4 – Қарақалпақ тилиниң түсиндирме сөзлиги. IV том. Нөкис: Қарақалпақстан, 1992. [EDKL – Explanatory dictionary of the Karakalpak language. IV vol. Nukus: Karakalpakstan, 1992].

ҚФ – Қарақалпақ фольклоры /көптомлық/. Нөкис, 2014. [KF – Karagalpak folklore / мultivolume/. Nukus: Ilim, 2015].

ҚФ – Қарақалпақ фольклоры /көптомлық/. Нөкис, 2015. [KF – Karagalpak folklore / мultivolume/. – Nukus: Ilim, 2015.].

Насыров Д., Доспанов О. Қарақалпақ диалектологиясы. Нөкис: Қарақалпақстан, 1995. [Nasyrov D., Dospanov O. Karakalpak dialectology. Nökis: Karakalpakstan, 1995.]

«Саза» журналы. Нөкис, 2020. №3 (120). [Journal «Saza». Nukus, 2020. №3 (120)].

Хожаниязов Ғ., Юсупов О. Қарақалпақстандағы муқаддес орынлар. Нөкис: Полиграфист, 1994. [Khozhaniyazov G., Yusupov O. Holy places in Karakalpakstan. Nukus: Poligrafist, 1994].

**Г.Ф. КАЮМОВА**
Казан федераль университеты, Казан

## ТАТАР ДРАМАТУРГИЯСЕНДӘ ЯУЧЫ ОБРАЗЫНЫҢ БИРЕЛЕШЕ

**Г.Ф. КАЮМОВА**
Казанский федеральный университет, Казань

## ОБРАЗ СВАХИ В ТАТАРСКОЙ ДРАМАТУРГИИ

**Аннотация.** Образ свахи является одним из ключевых в дореволюционной татарской драматургии, что связано с традиционно-обрядовой культурой татар. Сватовство являлось традиционным предсвадебным этапом свадебного обряда. В предлагаемой статье на основе анализа положительных и отрицательных образов свах в татарской дореволюционной драматургии анализируется их обязанности и роль в создании семьи, делается вывод о том, что труд свахи достаточно трудоёмкий, требующий не только профессионализма, но и определённых личностных качеств, в том числе чувство такта, изворотливости, умение анализировать информацию и даже обладания знаниями психологии. Резко отрицательно драматургами оцениваются свахи, рассматривающих своё дело исключительно как источник прибыли.

**Abstract.** The image of the matchmaker is one of the key in pre-revolutionary Tatar drama due to the traditional ritual culture of the Tatars. Matchmaking was a traditional pre-wedding stage of the wedding ceremony. The article analyzes positive and negative images of matchmakers in the Tatar pre-revolutionary drama and highlights their responsibilities and role in creating a family. The author comes to the conclusion that the matchmakers' labor is quite hard and requires not only professionalism, but also certain personal qualities, including sense of delicacy, resourcefulness, the ability to analyze information and even possess knowledge of psychology. Matchmakers who view their business exclusively as a source of profit are strongly criticized by playwrights.

**Ключевые слова:** традиционные ценности, сваха, сватовство, драма, положительный образ, отрицательный образ.

**Keywords:** traditional values, matchmaker, matchmaking, drama, positive image, negative image.

Татар халкының тирән мәгънәле, әмма төрле сәбәпләр белән онытылуга дучар ителгән, һәм яңа гасырда яңадан торгызыла башлаган күркәм гадәтләре, традицияләре

бар. Гомумән, соңгы елларда, галимнәр ассызыклаганча, традицион – рухи, гаилә, дини һ.б. – кыйммәтләр белән кызыксыну арта, һәм әлеге күренешне мәдәни яңарыш буларак та бәяләргә мөмкин” [Азизова, 2009: 3]. Әлеге мәкалә кысаларында безне гаилә кыйммәтләре, туй йоласы белән бәйләнгән, аның беренче – туй алды традицияләренең берсе булган яучылык күренеше кызыксындыра. Инкыйлабтан соңгы тарихыбызда иҗтимагый-сәяси үзгәрешләр белән бәйле рәвештә яучылык үзе дә, яучылар да көлү объектына әверелсәләр дә, бүгенге көндә бу күренеш яңадан таралыш ала башлый. Интернет челтәрендә егет-кызларны кавыштыручы махсус сайтлар булдырыла, әлеге эшчәнлек махсус клубларда тормышка ашырыла, вакытлы матбугатта профессиональ яучылык турындагы игъланнар да еш очрый. Бүгенге көн реалияләре инкыйлабка кадәрге тормыштан җитди аерылса да, яучылыкның асылы үзгәрми: ул егет-кызларга (әлбәттә, егет, кыз сүзләре бу очракта шартлы рәвештә кулланыла, яучылар төрле яшь категорияләренә караган кешеләр белән эшлиләр) потенциаль ярлары турында объектив, гадел мәгълүмат бирү, аларны таныштыру, кавыштыру һәм шушы хезмәт өчен матди бүләк алу белән характерлана. Татар драма әсәрләрендә яучы образларының бирелешен, яңа гаилә тууда яучыларның ролен өйрәнү дә кызыклы булыр, дип уйлыйбыз.

Инкыйлабка кадәрге татар гаиләләрендә, бигрәк тә кызлы гаиләләрдә яучы – көтелгән кадерле кунак. Шуңа күрә мәхәббәт, өйләнешү темасы күтәрелгән әсәрләрдә яучы образы еш очрый. Татар әдәбияты әсәрләрен күзәтү күрсәткәнчә, әдәби образлар галереясында яучыларның капма-каршы ике тибы урын ала: яки бу үз эшен яхшы белгән, яшьләрне кавыштыру һәм тигез, бәхетле гаилә кору серләренә яхшы төшенгән, эшчәнлеген тиң парларны кавыштыруга юнәлдергән яучы карчык, яки яучылыкны акча эшләү кәсебенә әверелдергән принципсыз герой. Күренгәнчә, сәрләрдә бу образ беркайчан да урталыкта бирелми. Мәкаләбез кысаларында һәр ике типка да тәфсилле тукталырбыз.

Уңай яучы карчык образы Ф.Халидинең “Рәдде бичара кыз”, Г.Камалның “Каениш”, М.Фәйзинең “Галиябану” кебек әсәрләрендә урын ала. Ешрак болар автор тарафыннан “мәшһүр яучы карчык” буларак тәкъдим ителәләр. Болар эшләренә җаваплы караулары, ялган мәгълүмат белән эш итмәүләре белән аерылып торалар. Аңлашылганча, тормышта мондый типлар кадер-хөрмәткә лаек кешеләр буларак кабул ителәләр, чөнки ата-ананың йөрәк парәләре – балаларны яхшы гаилә, әхлакый яктан бөтен булган яр белән кавыштырырга ярдәм итәләр. Шул ук вакытта драма әсәрләрендә мондый яучыларның ниятләре һәрвакытта да тормыша ашмый, һәм бу аларның профессиональлык дәрәҗәләре белән түгел, ә бәлки әсәрләрнең жанр үзенчәлекләре белән аңлатыла: “кискен конфликтлы үзара мөнәсәбәтләрне диалоглар аркылы сурәтләгән киеренке сюжетлы сәхнә әсәрләрен драма дип атыйлар” [Хатипов, 2000: 237]. Аңлашылганча, бу очракта яучы карчыкларның хезмәтләре, изге ниятләре яки башка геройларның әхлак сыйфатлары (ешрак көнчелек, саранлык) белән бәрелешкә керә, яки әсәрдә социаль планда тигез булмаган геройларны (мәсәлән, урта хәлле крестьян кызы Галиябану һәм ярлы егет Хәлил) кавыштырудагы каршылыклар сурәтләнә.

Ф.Халиди язган “Рәдде бичара кыз” драмасында яучы карчык буларак Биби әби тәкъдим ителә. Бай тормыш тәҗрибәсе булган, яше 76 га җиткән әлеге карчык салмак хәрәкәтләре, башкарган эшен Аллаһыга тапшырып башкаруы, кыз һәм егет өйләре арасында арадашчы, киңәшче, үгет-нәсихәт бирүче булуы белән аерылып тора. Приказчик Закирның шактый бай, ә Мирза белән Сәлимәләрнең ярлы тормышта торуларын белгән хәлдә, туй чыгымнарының кияү тарафыннан тотылачагын белдерергә

дә ашыга ул. Мәгълүм, элек яшьләр еш кына бер-берсен күрмичә, белмичә өйләнешкәннәр, Биби әби егеткә кызны күрсәтү җаен да таба: “Закир тәрәзәдән карар, Сәлимә тәрәзә яныннан узып китәр” [Драма. – URL: http://www.kitap.net.ru/halidi.php; мөрәҗәгать итү вакыты: 23.09.2019]. Бу очракта драматург кызның матурлыгын егетләрне җәлеп итүче төп критерий буларак бәяли, Закир да, соңрак бай улы Әптем дә иң элек кызның матурлыгына гашыйк булалар. Биби әбинең Закир белән Хәлимәне кавыштыру эше уңышлы барып чыкмавының сәбәбе – Закирның шәхес буларак бөтен булмавында, Биби әбигә түгел, көнче Мәхүпкә ышануында. Яучы Бибинең үгет-нәсихәтенә игътибарлы булган очракта, Закирның тормышы бәхетле гаилә кору белән тәмамланыр иде, көнче Мәхүпнең ялган димләвенә ышанган егет тормышы трагик үлем белән тәмамлана.

Татар әдипләре яучыларның хәйләкәр булуын да ассызыклап китәләр, әмма бу хәйлә яшьләргә файда китергән очракта гына аклана. М.Фәйзинең “Галиябану” атаклы татар музыкаль драмасындагы яучы Бәдиганы гына искә төшерик: ул йомшак теле белән Бәдри һәм Галимәне шулкадәр җәлеп итә, булачак кияне шулкадәр мактый ки, кызның ата-анасы аны Исмәгыйль байдан килгән яучы дип кабул итәләр. Т.Гыйлаҗев ассызыклаганча, шушы вакыйганы тасвирлаган “икенче пәрдәдә төп каршылыкның беренче адымы – төенләнеш ясала: әсәрне композицион яктан оештыруда, геройларның холык-фигылен, күңел кичерешләрен ачуда зур роль уйнаган аңлашылмаучылык аркасында Бәдри белән Галимә, яучы Бәдиганы Исмәгыйльдән дип белеп, шатланып Галиябануны кияүгә бирергә ризалык белдерәләр” [Гыйлаҗев, 2011: 52-53].

Г.Камалның “Каениш” драмасында “шәһәрнең мәшһүр яучы карчыгы” Хәмидә, эпизодик рольне башкарса да, яучыларның хезмәте турында күп кенә мәгълүмат алырга ярдәм итә. Уңай герой буларак кабул ителгән әлеге яучы ике гаилә арасында арадашчы буларак төп эшенә күчкәнче, төрле яклап мәгълүмат җыя. Хисами Хәйрулласы, аңлашылганча, аны төп героиняның сеңлесенә яучы буларак җибәрә. Хәмидә исә иң башта төрле кешеләрдән иң мөһим сорауларга җавап эзли: “Төскә-биткә чибәрме? Яхшы, булган нәрсә микән? Кулыннан эш киләме икән?” [Камал, 1978: 263]. Хәмидәнең бу сорауларны бер генә кешегә түгел, төп героиня Зәйнәпләр гаиләсен күреп белгән күпләргә бирүе аңлашыла. Дөрес, драматург әлеге яучы образын Зәйнәпнең каенанасы Бәдигыльҗамалның чын йөзен тагын да тулырак ачу өчен куллана, әмма эшебез кысаларында ул яучылык эшенең четерекле якларын, дөрес һәм ялган мәгълүматны анализлый белергә тиешлекләрен дә асссызыклавы белән кыйммәт.

Татар драматургиясе сатирик яучы образларына да бай. Галимнәр ассызыклавынча, “мөгаен, яучылык бик төшемле, акчалы кәсеп булгандыр. Чит кешеләрдән яучы буларак кемнең өйләнергә, кемнең кыз бирергә җыенуы турында хәбәрдар булган карчыкларны чакырганнар. Бер якны икенче як алдында мактап, алар эшне никах белән тәмамларга тырышканнар, моның өчен бүләкләнгәннәр” [Азизова, 2009: 27]. Әгәр яучы өчен төп максат ничек кенә булса да яшьләрне өйләндереп, бүләкле булуга кайтып кала икән, яңа гаиләнең бәхете зур сорау астында кала, әлбәттә. Бу очракта комсыз һәм алдакчы яучы образы драматурглар тарафыннан көлкегә калдырыла, тәнкыйтьләнә. Г.Камалның “Бүләк өчен” комедиясендә яучы Мәхүп карчык образы – шундыйлардан. Егетнең байлыкка кызыккан анасының Габдуллаҗанны ямьсез, надан бай кызына димләүләре иң элек аның тарафыннан әйттерелә: “бу җүләр дә инде, минем шикелле, бүләккә кызыгып, кызның начар икәнен белән торып, бергәләшеп мактый”, – ди ул [Камал, 1978: 92].

Шунысы кызык: татар драматургиясендә яучы образлары нигездә шактый олы яшьтәге карчыклар буларак урын алалар. Бары Г.Камалның “Безнең шәһәрнең серләре” драмасында гына яучы “аңа (Себер баена – искәрмә безнеке) кыз димләргә йөрүче, маклер сымак бер ысул кадимче” буларак тәкъдим ителә [Камал, 1978: 172]. Дөрес, драмада бу образ яучы буларак түгел, кадими Казанны фаш итүче, кадими Казанны бер өлеше буларак күрсәтелә.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк: татар драматургиясенә яучы образлары шактый еш урын алалар. Аларның төп эшләре буларак потенциаль кияү һәм кәләш турында тулы һәм төпле мәгълүмат җыю, әдәп-әхлак кысаларыннан чыкмыйча, яшьләрне бер-берсенә күрсәтү, гаиләләр арасында арадашчы булу, шул исәптән четерекле булган акча, бүләк бирү турындагы мәгълүматны җыю-җиткерү, хәтта яшьләргә үгет-нәсихәт бирү буларак аңлашыла. Яучылык вазифасы – гаять җаваплы, яңа гаиләнең тигез-имин булуы яучы эшчәнлегенә дә күп кенә дәрәҗәдә бәйле, шуңа күрә әлеге хезмәт тиешле рәвештә бүләкләнгән дә. Яучылыкны бүләк, акча алу, моның өчен ялганнан да тайчынмаган яучылар драматурглар тарафыннан кискен тәнкыйтьләнә.

## ӘДӘБИЯТ


Азизова Н.Р. Традиционно-обрядовая культура локальных этнических групп в современной России (на примере юртовских татар): автореф. дис. д-ра культурологи. Краснодар, 2009. – 41 с.

Гыйлаҗев Т.Ш. Мирхәйдәр Фәйзи. Тормыш юлы һәм иҗаты. Уку-укыту әсбабы. Казан: Казан (Идел буе) федераль ун-ты. 2011. – 80 б.

Камал Г. Әсәрләр. Өч томда. 1 нче т.: пьесалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – 407 б.

Халиди Ф. Рәдде бичара кыз. Драма // URL: http://www.kitap.net.ru/halidi.php (дата обращения: 23.09.2019)

Хатипов Ф. Әдәбият теориясе: югары уку йортлары, педагогия училищелары, колледж студентлары өчен кулланма. Казан: Мәгариф, 2000. – 351 б.



**З.Н. КИРИЛЛОВА**
Казан федераль университеты, Казан


# КЕРӘШЕН ТАТАРЛАРЫНЫҢ ТЕЛЕ, ТАРИХЫ ҺӘМ МӘДӘНИЯТЕ: ТӨРЕК ТЕЛЕНДӘГЕ ХЕЗМӘТ


**З.Н. КИРИЛЛОВА**
Казанский федеральный университет, Казань


# ЯЗЫК, ИСТОРИЯ И КУЛЬТУРА КРЕЩЕНЫХ ТАТАР: МОНОГРАФИЯ НА ТУРЕЦКОМ ЯЗЫКЕ


**Аннотация.** Данная работа представляет собой обзор монографии на турецком языке, посвященной исследованию языка, истории и культуры крещеных татар.

**Abstract.** This work is an overview of a monograph in Turkish on the study of the language, history and culture of Christian Tatars.



**Ключевые слова:** кряшены, крещеные татары, языковые особенности, история, культура

**Keywords:** Kryashens, Christian Tatars, language features, history, culture

Чыгышыбыз керәшен татарларының теле, тарихы һәм мәдәни үзенчәлекләре турындагы хезмәткә күзәтү ясауга багышлана. Әлеге китап 2018 елның ахырында Төркиянең Истанбул шәһәре “Кәсит” нәшриятендә дөнья күрде. Хезмәтнең авторлары – Төркиянең Фырат университеты хәзерге төрки телләр һәм әдәбиятлар кафедрасы мөдире, профессор, доктор Әрҗан Алкая һәм Казан федераль университетының гомуми тел белеме һәм тюркология кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты Зоя Кириллова.

Әрҗан Алкая – тюркология һәм татаристика өлкәсендә зур белгеч, хәзерге төрки телләрне тикшерүгә багышланган күп санлы хезмәтләр авторы. Бигрәк тә төрки телләрнең кыпчак төркемен, аерым алганда, татар теле һәм аның диалектларын җентекләп тикшереп, 2008 елда – мишәр, ә 2014 елда Себер татарлары диалектының тел үзенчәлекләре турында саллы хезмәтләрен бастыра. Әлеге тикшеренүләрдән соң аның керәшен татарлары сөйләшләренә мөрәҗәгать итүе табигый.

Монографиянең беренче өлешендә керәшеннәрнең тарихи һәм мәдәни үзенчәлекләре киң яктыртыла. Мәсәлән, алар яшәгән җирләр, төркемнәре, дини үзенчәлекләре, тарихы һәм хәзергесе, халык саны, килеп чыгышы мәсьәләсе, “керәшен” атамасы, XX гасыр башы һәм ахырында керәшен сәяси-иҗтимагый хәрәкәте, керәшен татарларын өйрәнүгә багышланган хезмәтләр, керәшеннәрнең йола һәм бәйрәмнәре, күренекле шәхесләре һ.б. бик күп темалар тикшерелә.

Хезмәтнең аерым бер бүлеге керәшен татар сөйләшләренең фонетик үзенчәлекләрен ачыклауга багышлана, аерым алганда, сузык һәм тартык авазлар, аларның ясалу урыны һәм әйтелеше ягыннан үзенчәлекләре, сөйләм барышында барлыкка килгән аваз үзгәрешләре һ.б. күп мәсьәләләр карала. Сөйләшләрнең авазлар системасын тасвирлау, иске төрки телне нигез итеп алып, чагыштырма-тарихи алым белән татар әдәби теле, башка төрки телләр, бигрәк тә кыпчак телләре, аларның тарихы белән тыгыз бәйләнештә алып барыла.

Алдагы бүлектә керәшен сөйләшләренең морфологик һәм сүз ясалышы ягыннан аерымлыкларын билгеләүгә зур урын бирелә. Әлеге өлештә һәр сүз төркеме белдергән категорияләре, сүз ясагыч кушымчалары белән бергә җентекләп анализлана. Сөйләшләрдә кулланыла торган төрле кушымчалар һәм структур элементларның элекке һәм хәзерге төрки телләр, татар әдәби теле белән булган якынлыгы һәм бәйләнеше билгеләнә, керәшен татарларының төрле сөйләшләренә хас булган уртак һәм аермалы якларга бәя бирелә.

Хезмәт ахырында керәшеннәрнең төрле төркемнәренә караган сөйләм текстлары, кайбер фотографияләр тәкъдим ителә. Әлеге текстлар керәшен сөйләшләренең тел үзенчәлекләрен төрле яклап ачыклау өчен нигез булып тора һәм анализ вакытында аерым номерлар белән күрсәтелеп барыла.

Хәзер исә монографиядә чагылыш тапкан кайбер төп моментларны карап үтәргә телибез. Керәшеннәр – Идел һәм Урал буйларында яшәүче татарларның үзенчәлекле бер төркеме. Алар христиан диненең православие юнәлешен тоталар. Тел һәм гореф-гадәтләре ягыннан да аерымлыклар күзәтелә. “Керәшен” атамасы рус телендәге “крещён” (“чукындырылган”) сүзеннән килеп чыккан дип карала, шулай ук тарихчы Максим Глухов тарафыннан санскрит телендәге кер (тау) һәм кытай телендәге чин (кеше) сүзләреннән ясалып, “тау кешесе” мәгънәсен белдерүе хакындагы фикер дә урын ала.

Керәшен татарларының саны буенча беренче мәгълүматлар XVIII гасыр башыннан гына сакланып калган. Совет чоры статистикасында аларны мөстәкыйль төркем буларак соңгы тапкыр 1926 елда саныйлар, бу вакытта 121 меңгә якын кеше үзен

керәшен дип күрсәтә. 2002 елгы халык санын алуда Россиядә яшәүче керәшеннәрнең саны 25 меңләп, ә 2010 елда 35 меңгә якын дип билгеләнә.

Керәшен татарларының күпчелеге Татарстанда яши, шулай ук аерым төркемнәре күрше республика һәм өлкәләрдә дә урын ала. Аларны, яшәгән территорияләренә һәм тел үзенчәлекләренә нигезләнеп, 5 төркемгә бүлеп карыйлар: Казан арты (Казан-татар), Түбән Кама (Алабуга), Нагайбәк, Тау ягы (Мәлки) һәм Чистай керәшеннәре.

Казан арты төркеменә Татарстанның төньяк-көнбатыш районнарында һәм Киров өлкәсендә яшәүче керәшеннәр керә. Бу төркем чагыштырмача борынгырак булып исәпләнә һәм, күп санлы галимнәр фикеренчә, элек-электән шушы территориядә яшәгән җирле халыкны тәшкил итә. Этник составы ягыннан аны ике катламга бүлергә мөмкин: төрки чыгышлы һәм фин-угыр катламнары.

Түбән Кама яки Алабуга төркеменә Татарстанның көнчыгыш районнарында, күрше Башкортостан һәм Удмуртия республикаларында яшәүче керәшеннәр керә. Галимнәр фикеренчә, әлеге төркем оешуда ногайлар, угырлар, татарлашкан удмурт һәм марилар катнашкан. Башкортостандагы керәшеннәр исә рус, чуаш, мари, мордва һәм удмурт авыллары чолганышында яши, кайбер авыллары татар телендә сөйләшүче, әмма христиан динендәге мари һәм чуашлардан формалашкан.

Керәшеннәрнең өченче төркеменә Чиләбе өлкәсендә гомер итүче нагайбәкләр керә. Алар да этник тамырларының катлаулы булуы белән аерылып тора. Күп кенә документлар буенча, бу төркемнең нигезен Казан арты татарлары һәм ногайлар тәшкил итә, шулай ук аларга мәҗүси фин-угыр һәм Урта Азиядән килгән халыклар да кушылган. Нагайбәкләр күп гасырлар дәвамында казак гаскәрләрендә хезмәт иткәннәр һәм башка татарлардан аерылып яшәгәннәр, нәтиҗәдә үзенчәлекле төркем барлыкка килгән.

Керәшеннәрнең дүртенче төркеме – Тау ягы яки Мәлки керәшеннәре – Татарстанның Чуашстан белән чиктәш булган районнарында яшиләр. Бу төркем формалашуда чуашлар да катнашкан. Николай Воробьев фикеренчә, әлеге керәшеннәр татар һәм чуашлар өчен уртак булган гомуми болгар тамырыннан бу ике этнос әле аерылмаган вакытта формалашкан. Матди мәдәнияттә һәм тел үзенчәлекләрендә чуашлар белән дә, мишәрләр белән дә уртаклыклар күп.

Керәшеннәрнең соңгы төркеме – Чистай керәшеннәре – Татарстанның үзәк, көньяк һәм көньяк-көнчыгыш районнарында һәм Самара өлкәсендә яшиләр. Бу төркем христиан динен кабул иткән мишәрләрдән формалашкан, шунлыктан аларны мишәр керәшеннәре дип тә атыйлар. Шул ук вакытта кайбер авылларның чуашлар белән катнаш булуын, төркем оешуда Каманың уң ягында һәм Казан артында яшәүче керәшеннәрнең дә катнашуын әйтеп узарга кирәк.

Керәшен сөйләшләре аваз составы ягыннан татар әдәби теленнән аерылмый. Төп фонетик үзенчәлекләрдән исә кайбер авазларның башкача әйтелүен, аваз тәңгәллекләрен, ассимиляция, диссимиляция, аваз төшереп калдыру, борынгы төрки фонетик вариантларның саклануы кебек күренешләрне аерып күрсәтергә мөмкин.

Керәшен татарларының **лексик үзенчәлекләре** христиан дине белән кергән йола атамаларында, рухи һәм матди мәдәнияткә кагылышлы сүзләрдә ачык күренеп тора, шул ук вакытта хәзерге татар телендә кулланылмаган борынгы төрки нигезле сүзләрнең сакланып калуы, рус, чуаш, удмурт һ.б. телләрдән кабул ителгән алынма сүзләр дә игътибарга лаек. Керәшен татарларының һәр сөйләшендә дә төрки нигезле сүзләр төп урынны алып тора. Ләкин мөселман татарларыннан күпмедер дәрәҗәдә аерымланып яшәгәнлектән, сөйләшләрдә, татар әдәби теле белән тәңгәл килгән сүзләрдән тыш, язма

истәлекләрдә урын алган һәм хәзерге төрки телләрнең кайберсендә кулланыла торган сүзләр дә сакланып калган. Мәсәлән: ару (яхшы, чиста; изге), ардаклы (хөрмәтле), күз (утлы күмер), печү / пычу (кисү) һ.б. Тау ягы яки Мәлки керәшеннәрендә чуаш теленнән кергән алынмалар да күзәтелә: тунди кен – дүшәмбе, утлари кен – сишәмбе, җекрәс – игез, чапле – яхшы, матур һ.б.

Керәшен сөйләшләрендә татар әдәби теле, аның урта һәм мишәр диалектлары белән шактый зур уртаклык күрсәткән **грамматик үзенчәлекләр** дә чагылыш таба. Морфологик үзенчәлекләр беренче чиратта фигыль сүз төркемендә күренә. Аерым алганда, керәшен сөйләшләрендә боерык фигыльнең II зат берлек санда борынгы **-гын/-ген, -ың/-ең** (баргын / барың (бар)); хәл фигыльнең **-гачын/-гәчен**, **-гынчы/-генче** (килгәчен (килгәч), килгенче (килгәнче)), инфинитивның **-ма/-мә, -мага/-мәгә, -маллы/-мәлле** кушымчалары (алма / алмага (алырга), җырламаллы (җырларга)), сыйфат фигыльнең башка төрки телләрдә дә (мәсәлән, төрек, гагауз, азәрбайҗан, кырым татарлары, төрекмән, чуаш һ.б.) кулланылган **-малы/-мәле** (җөрмәле (йөрерлек)) формасы сакланып калган. Керәшен сөйләшләрендә шулай ук килешләрнең борынгы формалары да күзәтелә. Мәсәлән, тартымлы исемнәрнең юнәлеш килеше формасы **-ңа/-ңә, -ңар/-ңәр, -ңгар/-ңгәр** кушымчалары ярдәмендә формалаша: тегесеңә (тегесенә), барысыңар (барысына), куҗаныкыңгар (хуҗаныкына) һ.б. Чыгыш килеше өчен керәшен сөйләшләрендә хәзерге вакытта -дан/-дән, -тан/-тән кушымчалары кулланыла, бары җырларда гына борынгы **-дыйн/-дин, -тыйн/-тин** формалары сакланып калган.

Йомгаклап әйткәндә, керәшен татарлары хакында татар һәм рус телләрендә хезмәтләр нәшер ителсә дә, башка төрки телләрдә бары берничә мәкалә генә барлыгы мәгълүм. Без күзәтү ясаган хезмәтнең төрек телендә басылып чыгуы һәм төрки дөнья җәмәгатчелеге тарафыннан бик хуплап кабул ителүе татар халкының үзенчәлекле төркемен тәшкил итүче керәшеннәрне өйрәнү һәм башка халыкларга таныту ихтыяҗының булуы хакында сөйли.

## ӘДӘБИЯТ

Ercan Alkaya, Zoya Kirillova. Kreşin Tatar Türkçesi (Dil, Tarih, Kültür). İstanbul: Kesit Yay., 2018. – 670 s.

**Қ.Р. КЕМЕҢГЕР**
Л.Н. Гумилев атындағы Еуразия ұлттық университеті, Нұр-Сұлтан

## АБАЙ МҰРАСЫ – МАҒЖАН ЖҰМАБАЙҰЛЫНЫҢ «ПЕДАГОГИКА» ЕҢБЕГІНДЕ

**К.Р.КЕМЕНГЕР**
Евразийский национальный университет имени Л.Н. Гумилева, Нур-Сулан

## НАСЛЕДИЕ АБАЯ В ТРУДЕ МАГЖАНА ЖУМАБАЕВА «ПЕДАГОГИКА»

**Аннотация.** Статья посвящена научно-методическому наследию казахского поэта, выдающегося просветителя плеяды «Алаш» М.Жумабаева. В ней рассматриваются стихотворения великого казахского поэта Абая в научно-просветительской работе М.Жумабаева «Педагогика» (1922). Исследуется художественное наследие Абая в данной

книге. Интерпретируются идейно-нравственые, художественно-воспитательные черты стихотворения Абая. Автор видит духовно-нравственную, художественно-эстетическую связь между двумя поэтами.

**Abstract.** The article is devoted to the scientific and methodological heritage of the Kazakh poet, outstanding educator of the "Alash" pleiad M. Zhumabayev. It examines the poems of the great Kazakh poet Abay in the scientific and educational work of M. Zhumabayev "Pedagogy" (1922). This book explores the artistic heritage of Abay. The author interprets the ideological and moral, artistic and educational features of Abay's poem. The author sees a spiritual, moral, artistic and aesthetic connection between the two poets.

**Ключевые слова:** казахская литература, Абай, Магжан Жумабаев, литератруное наследие, педагогика, преемственность.

**Keywords:** Kazakh literature, Abay, Magzhan Zhumabayev, literary heritage, pedagogy, continuity.

Ұлт-азаттық Алаш қозғалысы саяси күш ретінде тарих сахнасына шыққан ХХ ғасыр басында халықтың рухани өміріне серпіліс әкеліп, оны қараңғылық ұйқысынан оятқан бірнеше айтулы жағдай орын алғаны белгілі. Ұлттық баспасөздің тууы, кітап шығару ісінің артуы, сауда капиталының көбеюі, жазба әдебиеттің дамуы, әдебиетте жаңа жанрлардың пайда болуы, театр өнерінің өмірге келе бастауы сынды маңызды оқиғалар  халық өмірінде елеулі орын алды. Солардың қатарында Абай кітабының баспадан жарық көргені – қазақ қоғамында айтулы мәдени жаңалық болып саналды. Ұлы ақын сөзі ХХ ғасыр басында қалың бұқараға тарап, қазақ жұртының санасына сәуле төгіп, мәдениетті жұрттар қатарына ұмтылуға жұмылдырды.

Қалам ұстаған оқыған қазақ кемел ақын мұрасымен танысқаннан кейін, сөзін мысал етпей, тағылымынан тәлім алмай, даналығын ескермей өлең де, мақала да, зерттеу еңбек те жазбады. Абай туындыларымен танысқан ескі сүрлеумен өлең жазатын ақындар шығармашылыққа сыни көзбен, жазғанына биік талғаммен қарады. Шын мәнінде, Абайдың ұлы даналық қағидалары ХХ ғасыр басындағы қазақ мәдени өмірінде айрықша сипатқа ие болды. Аталған уақытта, әсіресе алғашқы ұлттық басылымдардың беттерінде ұлы ақын есімін, шығармаларынан үзіндіні үнемі оқымасақ та, кемеңгерлік ой-тұжырымдарын, философиялық, гуманистік пікірлерін аңғара аламыз. Абайды қазақ жұртына алғаш таныткан алаш оқығандары болды. Сол арқылы олар Алаш қозғалысының рухани негіздемесіне ақынның терең философиялық, ұлы гуманистік, елді бірлікке шақырған саяси-әлеуметтік ойларын негізге алды.

Алаштың көрнекті ақыны Мағжан Жұмабайұлына (1893-1938) шығармашылық тұрғыдан қалыптасып кемелденуіне, көркемдік-эстетикалық қуаты жоғары туындыларды жазуға, поэзияның көркемдік биігіне шығуына Абайдың асыл мұрасы зор ықпал етті. «Шолпан» атты алғашқы жинағында «Атақты ақын – сөзі алтын хакім Абайға» деп өлең арнаған он тоғыз жасар жас ақын:

«Көз ашып, жұртың ояу болған сайын,
Хакім ата, тыныш бол, қадірің артар» [М.Жұмабаев, 2005. 2 т.: 12], –

деп Абайдың асыл мұрасына қызығушылық жыл озып, қазақ халқының санасы жоғарылаған сайын арта береді деп әулиелік танытты. Абай өлеңінің көркем дәстүрі Мағжан шығармашылығында жалғасты. Ұлы ақынның «Жазғытұры» өлеңіндегі:

«Күн – күйеу, жер – қалыңдық сағынышты,
Құмары екеуінің сондай күшті» [Абай, 1995, 1 т.: 161], –

деген кейіптеудің айшықты үлгісі Мағжанның «Батыр Баян» поэмасында:

«Алтын Күн алыстағы арайланған,

Жарқырап шығып жерге сәлем берді» [М.Жұмабаев, 2005, 1 т.: 150], –
деп бейнелі метафорамен қайталанғанын байқаймыз. Екі ақын туындыларын зейін қойып зерделегенде, дәстүр сабақтастығын көрсететін мұндай көркем мысалды молынан келтіруге болады.

М.Жұмабайұлының «Педагогика» ғылыми еңбегінде Абай өлеңдерінен мысал алынып, оларға талдау жасалған. Еңбек 1922 жылы Орынбор қаласында жеке кітап күйінде жарық көрген. «Кітапты бір орыс кітабынан тура тәржіма деуге болмайды. Алдыма бір кітапты жайып қойып, бұрылмастан желе бергенім жоқ. Тәрбие ғалымдарының пікірлерін таңдап алуға ұмтылдым. Шамам келгенше қазақ қанына қабыстыруға тырыстым» [М.Жұмабаев, 2005, 3 т.: 97], – деп автор өзі ескерткендей, еңбек орыстың педагогика саласындағы кітаптарынан аударма болып саналмайды, ол қазақ ұғымына, болмысына жақын етіп жазылған. Қазақ халқының түсінігіне ыңғайлап жазуда Мағжан туған халқының ауыз әдебиеті үлгілерін, соның ішінде тұрмыс-салт жырларды, аңыз әңгімелерді, батырлар жырын, мақал-мәтелдерді пайдаланған. Ойын айшықты, сөзін дәлелді ету үшін жазба әдебиеттен де көркем үзінді берген. Төл туындыларынан мысал келтірген. Ш.Бөкейұлы, А.Байтұрсынұлы, М.Дулатұлы есімдерін атап, олардың өлеңдерін ұсынған. «Педагогика» кітабында Абайдың көркем сөзі мен философиялық ойлары бірнеше рет мысалға алынған.

Зерттеуші адамның жан тұрмысының бірлігін талдағанда, оның үш тапқа бөлінетінін айтады да, пікірін дәйектеу үшін Абайды еске алады: «Жан көріністері қанша түрлі болғанымен, оларды түп негіздері бойынша үш тапқа бөлуге болады: білу яки ақыл көріністері, ішкі сезім көріністері һәм қайрат көріністері. Қазақтың данышпаны Абай бұл үш тапты ақыл, жүрек, қайрат деп атайды» [М.Жұмабаев, 2005, 3 т.: 122]. Адам бойында осы үш тап жан көрінісі тең болмаса, ол өзін бақытты жан сезінбейді. Бірі артық, бірі кем болмауына тәрбиеші міндетті деп Абайдың көлемі шағын болса да, бірақ мағынасы терең философиялық «Әуелде бір суық мұз – ақыл зерек» деп басталатын өлеңін мысалға алады:

«Әуелде бір суық мұз – ақыл зерек,
Жылытқан тұла бойды ыстық жүрек.
Тоқтаулылық, қалыпты, шыдамдылық,
Бұл – қайраттан шығады, білсең керек.

Ақыл, қайрат, жүректі бірдей ұста,
Сонда толық боласың елден бөлек.
Жеке-жеке біреуі жарытпайды,
Жол да жоқ жарыместі жақсы демек.

Ақыл да, ашу да жоқ, күлкі де жоқ,
Тулап, қайнап бір жүрек қылады әлек.
Біреуінің күні жоқ біреуінсіз,
Ғылым сол үшеуінің жөнін білмек» [М.Жұмабаев, 2005, 3 т.: 123].

Алаш білімпазы мысалға алынған өлеңге «данышпан Абайдың төмендегі сөзі шын дұрыс сөз» деп баға берген. Байқасақ, жан тұрмысының бірлігін зерттегенде Абайды екі рет мысалға келтіріп, оны үнемі данышпан деп атаған.

Ғылыми еңбектің «Есту сезімінің жан тұрмысына керектігі» тақырыбында адамның жаратылыс әуенін есту қабілеті түсіндірілген. Көз нәрсенің сыртын, құлақ

оның ішін, жанын шешіп береді, бейтаныс адамның жанын ұқтыратын – есту сезімі, есту қабілетіміз болмаса, қоршаған дүние мылқау, жансыз көрінер еді дейді автор. «Кәне, сөйлеші. Мен сені көрейін» деген көне грек данышпанының терең мағыналы сөзін мысал еткен. Адамның жан дүниесін тәрбиелейтін, гуманизмге бойлататын, эстетикалық ләззатқа бөлейтін әсем ән, әдемі күй екенін түсіндіріп, олардың құдыретіне тәнті болады: «Адамның әділеттілікті сүю сезімін тереңдететін де осы есту сезімі. Әдемі ән, сұлу күй бойды билеп, денені балқытып, адамға терең ой салмай ма?» [М.Жұмабаев, 2005, 3 т.: 135]. Адамның есту сезімінің ғылыми сипатын қарапайым мысалдар арқылы түсіндіріп:

«Құлақтан кіріп, бойды алар
Тәтті ән мен мұңды күй.
Жүрекке терең ой салар
Әнді сүйсең, менше сүй» [М.Жұмабаев, 2005, 3 т.: 134], –

деген Абай өлеңінің бір шумағын ән мен күйдің тәрбиелік-эстетикалық сипатын ашуға ұсынған. Кейде осы өлеңнің екінші тармағы баспасөзде, әлеуметтік желіде «Әсем ән мен тәтті күй» деп те беріледі. Ұлы ақынның 1995 жылы жарық көрген «Шығармаларының екі томдық толық жинағында» келтірілген шумақтың екінші тармағы «Жақсы ән мен тәтті күй», үшінші тармағы «Көңілге түрлі ой салар» деп жазылған [Шонанұлы Т., 4 т., 36]. Яғни Лермонтовтың «Звуки» атты өлеңінен еркін аударма жасаған Абайдың нұсқасын Мағжан кітабында ауыстырып берген. «Педагогика» еңбегінде «ән» – «тәтті», «күй» – «мұңды» болып айшықталған, сондай-ақ түпнұсқадағы «көңілге» – «жүрекке» деп, «түрлі ой» – «терең ой» деп ауысқан. «Шығармаларының екі томдық толық жинағында» бұл өлең Абайдың 1909 жылғы нұсқасы бойынша дайындалғаны айтылған. Ұлы ақын шығармаларын текстологиялық тұрғыдан зерттеу жұмысы жалғаса беретінін білеміз. Осы орайда Мағжан кітабындағы келтірілген нұсқаны да қаперде ұстау керек деп есептейміз.

Алаш білімпазы «Педагогика» еңбегінде адам бойындағы жұмбақ нәрсенің бірі – мінез деп санайды. Бір адамның іс-әрекетін басқа адамдікінен айыратын да мінез дейді. Мінездің жасалуы, темперамент түрлері, мінездің тәрбиесі жайында ұзақ талдау жасайды. Балада дұрыс мінез қалыптастыру үшін тәрбиеші көп күш жұмсау керектінін айтады: «Ерінбей, жалықпай балаға әрбір істің себебін ұқтыра беру керек. Мәні-жайын ұқтырмай, құр бұйрық беруші адам – тәрбиеші емес. Данышпан Абай айтқандай, «ұстаздық қылған жалықпас үйретуден балаға», тәрбиеші баланың қаһарлы қожасы болмасын, жұмсақ жолдасы болсын» [М.Жұмабаев, 2005, 3 т.: 185], – деп ойын пысықтау үшін Абай өлеңінен мысал алады. Ұлы ақынның ұстаздық қасиетін айшықтаған дана сөзімен Мағжан «Педагогика» зерттеу еңбегін қорытындылаған. «Данышпан Абайдың төмендегі сөзімен біз кітабымызды тамамдаймыз» [М.Жұмабаев, 2005, 3 т.: 186], – деп, ақын өлеңімен ойын түйіндейді. М.Жұмабайұлының «Педагогика» кітабы Абайдың «Әсемпаз болма әрнеге» деп басталатын өлеңнің екі тармағымен тұжырымдалған.

Қазақ мұғаліміне құнды ғылыми-әдістемелік оқу құралы ретінде ұсынылған «Педагогика» еңбегінде данышпан Абайдың дидактикалық-философиялық ойлары анық байқалады. Ақынның асыл сөзі, өлеңдерінің тұтас шумақтары тақырыпты ашуға көмектеседі.

**ӘДЕБИЕТ**

Абай (Ибраһим) Құнанбайұлы. Шығармаларының екі томдық толық жинағы. Т. 1: Өлеңдер мен аудармалар. Алматы: Жазушы, 1995. – 336 б.

Жұмабаев М. Көп томдық шығармалар жинағы. 2-том. Өлеңдер, дастандар, аудармалар. Алматы: Жазушы, 2005. – 208 б.

Жұмабаев М. Көп томдық шығармалар жинағы. 1-том. Өлеңдер, дастандар, әңгіме. Алматы: Жазушы, 2005. – 208 б.

Жұмабаев М. Көп томдық шығармалар жинағы. 3-том. Аудармалар, ғылыми еңбек, мақалалар. Алматы: Жазушы, 2005. – 232 б.

Шонанұлы Телжан. Бес томдық шығармалар жинағы. 4-том. / Құрастырып, түсініктерін жазған – филология ғылымдарының докторы О.Жұбаева. Алматы: Мемлекеттік тілді дамыту институты, 2017. Т.4: – 256 б.

**Х.Х. КУЗЬМИНА**

Казан федераль университеты, Казан

## МӘКТӘПКӘЧӘ ЯШЬТӘГЕ ТАТАР БАЛАЛАРЫНЫҢ СҮЗ БАЙЛЫГЫ ТУПЛАНУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

**Х.Х. КУЗЬМИНА**

Казанский федеральный университет, Казань

## ФОРМИРОВАНИЕ ЛЕКСИКИ У ДЕТЕЙ-ТАТАР ДОШКОЛЬНОГО ВОЗРАСТА

**Аннотация**. Изучение особенностей формирования детской речи (онтолингвистика) считается одной из сравнительно новых, активно развивающихся научных дисциплин. В данной статье были рассмотрены проблемы формирования лексикона детей-татар дошкольного возраста.

В сознании ребенка, достигшего возраста одного года, слово представляет собой фонетически организованную и смысловую единицу. В возрасте одного года лексикон ребенка состоит примерно из десяти слов, в полтора года – из 30 слов, в 3 года – из 300 слов. По достижении 3-4летнего возраста, слова в детской речи начинают составлять активную лексику; в 4-5 лет дети практически полностью усваивают все морфологические элементы. В возрасте 6-7 лет ребенок осваивает логическую последовательность, монологическую речь, в которой уже четко и в должном смысле используются слова, выраженные предметами.

**Abstracts**. The study of the formation of children's speech (ontolinguistics) is considered one of the relatively new, actively developing scientific disciplines. This article deals with the problems of forming the vocabulary of preschool Tatar children.

In the mind of a child who has reached the age of one year, a word is a phonetically organized and semantic unit. At the age of one year, the child's vocabulary consists of about ten words, at one and a half years – 30 words, at 3 years – 300 words. Upon reaching the age of 3-4 years, words in children's speech begin to form an active vocabulary; in 4-5 years, children almost completely assimilate all morphological elements. At the age of 6-7 years, the child learns a logical sequence, monologue speech, in which words expressed by objects are already clearly and in the proper sense used.

**Ключевые слова:** онтолингвистика, детская речь, татарский язык, лексика

**Keywords:** ontolinguistics, the first language acquisition, child speech, the Tatar language, vocabulary

Тел белемендә балалар сөйләмен һәм, гомумән, сөйләм онтогенезын өйрәнә торган фән онтолингвистика дип атала. Ул лингвистиканың һәм, аерым алганда, психолингвистиканың бер бүлеге буларак баланың сөйләм сәләтләрен формалашуын, индивидуаль телнең барлыкка килүен һәм алга таба үсешен, һәм теге яки бу бала телендә яшь үзенчәлекләренә бәйле рәвештә барлыкка килә торган үзгәрешләрне өйрәнә.

Рус онтолингвистикасыннан аермалы буларак, татар телле балаларның сөйләм үсеше мәсьәләләре өйрәнелмәгән диярлек. Дөрес, XX йөз башында ук М.Фазлулла бу мәсьәләгә карата фикерләрен үзенең «Баланың теле ничек ачыла?» хезмәтендә тәкъдим итә [Фазулла, 1922]. XX йөз ахырында балалар сөйләмен өйрәнүгә кагылышлы фикерләрне И.Низамовның «Уем – тел очында» исемле хезмәтендә очратабыз [Низамов, 1995]. Шулай ук Ф.Ю. Юсупов хезмәтләрендә дә балалар сөйләм мәсьәләләре күтәрелә [Юсупов, 2002].

Беренче сүзләрне кечкенә балалар, кагыйдә буларак, бер яшь тулганда әйтәләр. Ул сүзләр, гадәттә, барлык балалар сөйләмендә дә чагыла. Баланың әйткән үз сүзләре актив сүзлек составын тәшкил итә. Аңлап та, әйтә алмаган сүзләр пассив сүзләргә кертеләләр. Баланың аңлап әйткән беренче сүзләре нигезендә реаль лексикон оеша. Сүзлек составына кергән сүзләр баланың ничә яшьтә булуы, нинди җенескә караганлыгы, гаилә шартларына, баланың уенны ничек кабул итүе һәм практик яктан аларны үзләштерүе, ата-аналарының биргән тәрбиясенә дә бәйле. Ике яшьтән алып кулланышка кереп киткән сүзләр конкрет мәгънәгә ия булалар, аларны инде оешкан, индивидуаль, стандартлашкан төшенчәләр кебек кабул итәргә була.

Предметны белдергән сүзләрне куллана башлау балада аны чолгап алган дөнья, ягъни еш кабатлана торган кеше исемнәре, хайван, кош - корт атамалары, уенчык, азык-төлек өлкәсенә караган сүзләр белән бәйләнгән. «Янә балалар табигатенең ике аерымлыгын истә тоту кирәк. Берсе – балаларның һәрдаим уен-көлкегә, шуклыкка омтылулары. Икенчесе – аларның тыелгысыз хәрәкәтчәнлеге һәм, әнә шул нигездә, һәрвакыт искиткеч маҗараларга ташланырга ыргылып торулары», – дип яза И.М. Низамов [Низамов, 1995: 287]. Предметлык төшенчәсе киң мәгънәдә кулланылырга мөмкин. Ул затны, конкрет предметны, күренеш һәм вакыйгаларны, абстракт төшенчәләрне белдереп килә ала, ләкин бала сөйләмендә нинди мәгънәдә кулланылуы баланың үзеннән генә тора. Мәсәлән, 1-3 яшькә кадәр предметны белдергән сүзләрне үзләштерү дигәндә без, *әннә, әттә, әббә* (әби*), авау* (эт) кебек сүзләр кулланышта булуын күрәбез. Бала еш кына бер ситуациядә бер үк сүзне төрле мәгънәдә кулланырга мөмкин. 1,5 яшьлек бала предмет белдергән сүзләрне ешрак файдалана башлый, чөнки психологлар фикеренчә, бала үзен чолгап алган предметлар дөньясы белән тизрәк танышып, аларны үзләштерергә өлгерә. 2-2,5 яшьтә бала бакчадагы тәрбиячеләрнең исемнәрен, мәсәлән: *Унна – Резеда Сәмигулловна*, яисә *Итя Фанна*, соңрак *Елена Итяфанна – Елена Вячеславовна* дип кешенең исем-фамилиясен атаучы сүзләрне үз лексиконына кертеп сөйләшә башлый. Яисә бала сөйләмендә, бөтенләй аңлашылмый торган һәм логик эзлеклелеккә сыймаган сүзләр кулланыла: *тану – помидор* (“Белмим, ник алай дип атаган. Кызык” – дип җавап бирә әнисе) (Динә, 2 яшь).

Нәтиҗәдә, бер яшькә җиткән бала предметларны белдерүче сүзләрдән – 10 сүз, 1,5 – 30, 3 яшькә – 300 сүз өйрәнә. 3-4 яшьлек бала сөйләмен күзәтик: Мәсәлән,

– *Нәрсә ашадың?*
– *Ас, сылок, сок.*
– *Рәсемдә кемне ясыйсын?*

– *Апаны, сине, әтине, дәүәнине.*

– *Камиләнең нәрсәләр ашыйсы килә? ( Камилә, 3 яшь)*

– *Мәмиләр, кәнфит* (конфет)*, аписин* (апильсин)*, сок, банан, винанад* (виноград), *тупатупс* ( чупа-чупс)*, абус* (арбуз*).*

Сүзләрдәге хәрефләрне бутап, ялгыш авазларны куллану дәвам итә. Мәсәлән: *ундырык* (урындык), *тевелизор* (телевизор), *тәргәчмәч* (тәгәрмәч), *кандараш* (карандаш). (Динә, 3,5 яшь).

Күренгәнчә, 3-4 яшькә җиткәндә, балалар сөйләмендәге сүзләр актив лексиканы тәшкил итә башлый, предметны белдергән сүзләр конкретлашып, сөйләмдә еш кабатлана. Морфологик яктан якын килгәндә, исем сүз төркеменә кергән сүзләр баланың беренчел дәрәҗәдәге сүзлек составын тәшкил итәләр. 4- яшьләрдә балалар практик яктан бөтен морфологик элементларны, исемнәрдәге сан категорияләрен бик тиз үзләштереп бетерәләр. Мәсәлән, күрсәтелгән мисалларда предметны белдергән сүзләрдә кайбер очракларда гына [р] һәм [л], яңгырау [с] һәм [з], саңгырау [ж] һәм [ш] һәм тартык авазларның сүзләрдә янәшә килүе бала өчен кыенлык тудырырга мөмкин. 6-7 яшьтә бала логик эзлекле, монологик сөйләмне үзләштереп бетерә, анда инде предмет белдергән сүзләр төгәл, тиешле мәгънәсендә кулланыла. Беренче җөмләләре дә гади булуга карамастан, аңлаешлы һәм тел закончалыкларына буйсынган була. Мәсәлән,

– *Бүген өйдә нишләдең?*

– *Бүген мин Линатка (Ринатка), Булатка бүләк эсләдем (эшләдем), аннан уламга (урамга), кибеткә сыктым (Алсу, 2,5 яшь)*.

Предметны белдергән сүз, 3 яшьлек бала тарафыннан дөрес әйтелә, шул ук вакытта баланың психо-физиологик халәте кызыксыну, фикерләү рәвешен һәм белемгә омтылышны дәлилләп тора:

*Караңгы. Автобуста: «Кояш» тукталышы.*

*Динә: – Әнием, ә кояш кая? Ник ул юк? (Динә, 3 яшь).*

1-2 яшьлек бала бөтен сорауларга җавапны төгәл һәм тулы итеп бирә алмый, ләкин вакыт үтү белән, эш-хәрәкәтне белдергән сүзләрне куллана башлау баланың лексиконын баета бара. Элементар сүзләрне ул 2 яшькә үзләштереп бетерә. Баланы тәрбияләү өчен олылар тарафыннан эшкә өндәү, хәрәкәткә, авазларны тиешенчә кушып, дөрес сүз формалаштырылырга тиеш. Андый сөйләм хәрәкәткә нигезләнә, бала инде ул сүзләрне куллана гына түгел, ә хәрәкәтне үзе дә башкара башлый: *тол* (тор), *утыл* (утыр), *ят* һ.б. Эш-хәрәкәтне белдергән сүзләрне куллану өчен балада төрле характердагы күнегүләр белән кызыксындыру мөһим. Мәсәлән, олылар сөйләме эшкә өндәргә тиеш, бары шул очракта гына ул бала тарафыннан кабул ителәчәк. Яшь үзенчәлеген исәпкә алып, без эш-хәрәкәт белдергән сүзләрне ни дәрәҗәдә актив кулланылуын аңлый алабыз. Мәсәлән, 2 яшькә кадәр фигыль лексемаларын ул «бала сөйләме» белән әйтә: *уп иту* (егылу), *тютю* (югалу, качу). Инде 3-4 яшьтә баланың сүзлек составындагы лексемалар арта һәм ул җөмлә төзү өчен төрле конструкцияләрне файдалана башлый: *Эт сяба* (эт чаба); *кита лята* (китап ята). 5-6 яшьләрдә бала эш-хәрәкәт белдергән сүзләрнең мәгънә төсмерләрен аера башлый һәм 7 яшьтә аларны тиешенчә файдалана.

Баланың эш-хәрәкәтне белдергән сүзләр арасыннан иң еш кулланыла торганнарыннан *балмадым* (бармадым), *асыйм* (ашыйм), *адым* (алдым), *каламадым* (карамадым), *зылыйм* (җылыйм), *оссаттым* (ошаттым), *эсләгә тылысам* (эшләргә тырышам), *әннә белән саубулластым* (әни белән саубуллаштым) һ.б.

Санап үтелгән мисаллардан балаларның физиологик һәм психологик аерымлыкларын истә тотып балаларның тел үзенчәлекләре туплануын билгелибез. Аралашу барышында аларны истә тоту әһәмиятле. Баланың эш-хәрәкәтне белдергән үз сүзләрен сөйләмгә кертеп җибәрергә дә мөмкин: *эннә* (әни), *мәм-мәм* (мими), *тәпи-тәпи, өфәй булган, тәти иткән* һ.б.

Г. Тукай әсәрләрен фәнни нәшерен һәм аның «академик басма»сын әзерләү юнәлешендә берничә омтылыш ясала. Аларның һәркайсы фән күзлегеннән караганда да, классик әсәрләрне популярлаштыру ягыннан да шактый зур адым булып тора. XX гасыр ахырында илебезнең иҗтимагый тормышында килеп чыккан кискен үзгәрешләр әдәбиятыбызның үткәнен бернинди чикләүләрсез өйрәнү, әдәби мирасыбызны тулы рәвештә халыкка кайтару мөмкинлеген бирде.

1939 нчы елда оешкан Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты (хәзер: Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һм сәнгать ) фәнни-тикшеренү институты классикларның мирасын җыйнап, фәнни-текстологик яктан өйрәнү, ягъни күптомлыклар әзерләү эшен башлап җибәрә. Беренче эш итеп, Тукай әсәрләрен күптомлы Академик басма итеп әзерләүгә керешелә.

Г. Тукайнын вафатына 25 ел тулу көнен билгеләп үтү максатында, Татарстан хөкүмәте комиссиясе Татгосиздатка "Татарстан Язучылар союзы белән берлектә кыска вакыт эчендә Г.Тукай әсәрләренең академик басмасын чыгару эшен тапшырырга» дигән карар чыгарганнан соң, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү институты шагыйрьнең икетомлык академик басмасын төзүне планга кертә [URL: http://gabdullatukay.ru/works/poem/6-tomlygy-turynda/zofer-remiev-shagyjrnen-kuptomly-basmalary/ (мөрәҗәгать итү вакыты: 13.09.2020)]. Әмма әлеге эшкә тиешле әзерлек җитмәү сәбәпле, бу басма Академик басма дәрәҗәсендә эшләнә алмый. Җыентык ике томлы булып, 1943 нче һәм 1948 нче елларда басылып чыга.

Ике томлык җыентыкны әзерләү эше Якуб Агишев һәм Хәй Хисмәтуллинга тапшырыла. Сугыш елларында дөнья күргән 1 нче томда (1943) Габдулла Тукайның барлык шигъри әсәрләре хронологик тәртиптә бирелә һәм балалар өчен язылган текстлар махсус бүлектә тәкъдим ителә.

1948 нче елда басылган томда проза әсәрләре 4 бүлеккә тупланып бирелә:

1) автобиографик очерклар, истәлекләр һәм хатлар (китапта барлыгы 13 хат);
2) иҗтимагый-политик һәм әдәби-критик мәкаләләр;
3) хикәяләр, фельетоннар һәм памфлетлар;
4) мәсәлләр һәм дидактик материаллар.

Ике томлык «Габдулла Тукай. Академик басма» дип атала. Әлеге ике томлыкка әлеге исемне бирү турында төрле бәхәсләр куба. Әдәбият тармагы галимнәренең китапның төзелеше, тулылыгы, әсәрләрнең һәм комментарийларының бирелеше ягыннан караганда, "Габдулла Тукай. Академик басма" исеменә туры килерлек материаллар бирелгәнме дигән сораугa җавап эзлиләр. Бу турыда дәлилле фикерне «Әдәбият чыганаклары белеме» (1998) дигән монографиясендәге «Ике томлыкның үзенчәлекләре» исемле мәкаләсендә Нил Юзиев язып чыга. Ул, архив материалларын да өйрәнеп, әлеге басманың төзелү, редакцияләнү тарихын ачыклый һәм «Тукайның ике томлыгы «академик тулы җыентык» дип аталса да, чынында, ул будәрәҗәгә күтәрелә алмый. Моның өченәле Тукай әсәрләренең текстологиясе өстендә фәнни эшләрнең җитәрлек дәрәҗәдә алып барылмавы комачаулый. Шуңа да ул гадәти фәнни басма дәрәҗәсендә кала. Бу басма тибы да Институт галимнәре өчен әһәмиятл еказаныш булуын әйтергә кирәк. Шушы басма белән Институтта классикларны текстологик әзерләү буенча фәнни традицияләр салына башлый» [Юзиев, 1998: 61] дигән нәтиҗә

чыгара. Алга таба, 1955–56 нчы елларда – беренче дүрт томлыгы, 1975–77 нче елларда икенче дүрт томлыгы дөнья күрә. Тукайның 100 еллык юбилее уңае белән биш томлы итеп әзерләнә.

XX гасырның 90 нчы елларыннан соң башланган үзгәрешләр нәтиҗәсендә, классикларның күптомлыкларын яңадан барларга, билгеле яки ниндидер сәбәпләр аркасында кыскартуларга дучар булган, яки бөтенләй төшерелеп калдырылган әсәрләрне торгызырга, аларны һәртөрле идеологиядән азат итеп, обьектив бәя бирергә мөмкинлек туа. Беренче Академик басма әзерләү эше дә Габдулла Тукай томлыкларыннан башлана. Тукайның әлеге басмасын алтытомлы итеп әзерләү һәм Академик басма дәрәҗәсендә эшләү максат итеп куела. Габдулла Тукайның 125 еллыгына 1–2 томнары, 130 еллыгына 3–5 томнары дөнья күрәләр. Бу томнар Академик басма таләпләре нигезендә эшләнә. Текстлар шул чорга хас язылышлар, тел-стиль үзенчәлекләре сакланган хәлдә урнаштырыла. Текстлар сакланган хәлдә, тел һәм стиль, шулай ук язылышның шул чор өчен хас булган үзенчәлекләрен саклап урнаштырыла. Барлык әсәрләре, бернинди идеологик чикләүләргә буйсынмыйча, бергә тупланып бирелә. Ул төзегән җыентыклар, аңа кагылышлы материаллар шулай ук аерым том буларак лаеклы урын алалар. Нәтиҗәдә, шагыйрьнең 6–7 шигыре, 45ләп мәкаләсе, 2 хикәясе һәм ул төзегән бер җыентыгы да күптомлыкларда беренче мәртәбә дөнья күрәләр.

Габдулла Тукай «Әсәрләр»енең алты томлы Академик басмасының алтынчы томын эшләү барышында табылган берничә әсәр «Өстәмә материаллар» бүлегенә урнаштырыла. Шуларның арасыннан «Кәфәштатыюш» имзасы белән язылган «Казандан Думага телеграм» мәкаләсе икетомлык «Габдулла Тукай. Академик басма»сының икенче томына (1948) һәм беренче дүрт томлык «Габдулла Тукай. Әсәрләр»енең өченче томына (1956) берникадәр кыскартылып урнаштырылса, «Бичура» имзасы белән басылган «Нәҗип Ломовой шигырьләре» исемле мәкаләсе беренче дүрт томлыкның өченче томына (1956) кертелә. Әлеге мәкаләләр 1975–1977 нче һәм 1985–1986 нчы елгы басмалардан чыгарылган. Ә менә өч әсәре Тукай томлыкларына беренче мәртәбә урнаштырыла. Беренчесе – «Дүнә вә Мишә» исемле мәкалә. Язма «Фикер» газетасының 1907 елгы 2 апрель (13 нче) саны кушымтасында «Күрдегезме? шигыре белән бергә урнаштырылган. «Шүрәле» имзасы шигырьдән соң куелган. Бу мәкалә Тукайныкы булуына бер дә шик тудырмый. Беренчедән, шагыйрьнең ике әсәрен янәшә куеп, бер имза белән имзалау очраклары бар. Икенчедән, Тукайның «Дин вә мәгыйшәт» журналын мыскыллап «Дүнә вә Мишә» дип атавы аның «Гөмберрт» имзасы белән басылган «Динчеләр куаныштылар» исемле мәкаләсендә дә күзәтелә [Сәйфи-Казанлы, 1929: 235]. Өченчедән, мәкаләдән соң урнаштырылган «Күрдегезме?» шигырендә дә «Дин вә мәгыйшәт» журналы телгә алына. Кызганычка каршы, алтынчы томны әзерләү барышында, «Фикер» газетасының 13 саны кушымтасы табылмый.

Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана торган Габдулла Тукай фондында әлеге мәкаләнең 1953 елдаХ. Хисмәтуллин күчергән кулъязмасы саклана [Габдулла Тукай и тюркский мир, 2016: 123]. Ни өчендер Х. Хисмәтуллин һәм Я. Агишевлар төзегән беренче дүрт томлыкның 1 нче томына (1955) бары тик «Күрдегезме?» шигыре генә урнаштырылган. Мәкалә кыскартылып күчерелүгә карамастан, фикер бөтенлеген югалтмаган. Шуңа күрә дә мәкаләнең текстын томга бирергә кирәк дип табыла.

Йомгак ясап әйткәндә, Габдулла Тукай иҗатын өйрәнү төрле яссылыктан алып барыла. Әлеге теманы күп татар галимнәре үзләренең фәнни эшчәнлекләрендә яктырта. Габдулла Тукай тормышы белән бәйле булган истәлекле көннәр уңаеннан уздырылган фәнни-гамәли чыгышларның җыентыклары ел саен диярлек басыла.

## ӘДӘБИЯТ


Габдулла Тукай и тюркский мир: материалы международной конференции, посвященной 130-летию со дня рождения Г.Тукая / сост. Ф.Х. Миннуллина, А.Ф. Ганиева. Казань: ИЯЛИ, 2016. – 484 с.

Г. Тукай әсәрләре. 1 том / төзүчесе Ф. Сәйфи-Казанлы. Казан: Яңалиф, 1929. – 176 б.

Юзиев Н. Источники по татарской литературе: (Обзор лит. наследия, исслед. теорет. и практ. проблем) / Акад. наук Татарстана, Ин-т яз., лит. и истории им. Г. Ибрагимова. Казань: Мысль, 1998. – 175 с.

URL: http://gabdullatukay.ru/works/poem/6-tomlygy-turynda/zofer-remiev-shagyjrnen-kuptomly-basmalary/ (мөрәҗәгать итү вакыты: 13.09.2020).



**Х.Й. МИҢНЕГУЛОВ**
Казан федераль университеты, Казан


## ФИН ИЛЕНДӘ КӘРӘКӘШЛЕ КЫЗЫ (ГӘҮҺӘР ТУГАНАЙ)


**Х.Ю. МИННЕГУЛОВ**
Казанский федеральный университет, Казань


## О ПОЭТИЧЕСКОМ ТВОРЧЕСТВЕ ГАУХАРА ТУГАНАЙ (ФИНЛЯНДИЯ)


**Аннотация.** Татарское словесное искусство XX века существовала и развивалась не только в России, СССР, но и в Зарубежье, в том числе в Финляндии. Одним из представителей татарской эмигрантской литературы является Гаухар Туганай (1911—1998). В статье профессора Х.Ю. Миннегулова освещаются жизненный путь и творчество этой поэтессы.

**Annotation.** Tatar verbal art of the twentieth century existed and developed not only in Russia, the USSR, but also abroad, including Finland. One of the representatives of Tatar emigrant literature is Gaukhar Tuganay (1911-1998). The article by Professor H.Y. Minnegulov highlights the life and work of this poetess.



**Ключевые слова**: татарские эмигранты в Суоми и их литература; Гаухар Туганай — уроженка деревни Каракашле Ютазинского района; автор поэтических сборников; ностальгия по родине; доминирование татарской тематики; поэтический мир автора.

**Keywords:** Tatar emigrants to Suomi and their literature; Gaukhar Tuganay — a native of the village of Karakashle in the Yutazinsky district; author of poetry collections; nostalgia for the Motherland; the dominance of Tatar themes; the author's poetic world.


...Чит илләрдә яшәү читен хәл ул,
Йөзләрне саргайтты сагышы
Туган илем калды бик еракта,
Алсуланып кояш чыккан якта [Туганай, 1970: 68]

Мөһаҗәрәттәге милләттәшләребез, чит мәмләкәтләрдәге татар әдәбияты һәм матбугаты хакында сүз чыкканда күпләр иң әүвәл Финляндияне атый. Моның үзенә күрә ныклы нигезе дә бар. Бердән, бу ил — йөз елдан артык Рәчәй империясе составында яшәп, Октябрь инкыйлабыннан соң бәйсезлек алган күрше дәүләт. Ул элек-электән үк татарлар чагыштырмача оешып яшәгән Мәскәү, Петербург, Нижгар, Касыйм төбәкләре белән аралашып тора. Балтыйк флотында милләттәшләребезнең хезмәт итүе дә мәгълүм. Финляндиядәге татарлар хакында Гәүһәр Туганайның «Безнең тормыш корылышы» [1: 72] әсәрендә дә кайбер мәгълүматлар бар: «Моннан берәр гасыр элек мишәр бу җиргә килгән. Төрле  кием-салымлыклар» метрлап сатып йөргән; Тора-бара юллар табып, гаиләләре дә килгән». Икенчедән, бу мәмләкәттә кавемдәшләребезнең төпләнеп гомер итә башлауларына инде ярты гасыр ярымнан артык вакыт узып китте. Алар, гәрчә сан ягыннан  бик аз булсалар да, милли үзлекне саклауда башка илләрдәге һәм төбәкләрдәге милләттәшләребезгә үрнәк рәвешендә дә карала. Моңа биредәге татарлар, иң беренче чиратта, телне, динне, моңны, гореф-гадәтләрне саклау, чагыштырмача бердәмлек, шактый гына китаплар, гәҗит-журналлар чыгару аша ирешәләр. Татар дөньясының мәркәзе Казан белән дә традицион бәйләнешләре көчле.

Финляндиядәге (Суомидагы) кавемдәшләребезнең иң зур  күпчелеге үзләренең килеп чыгышы, нәсел-нәсәбләре белән Нижгар (Сергач) яклары, тагын да төгәлрәк әйткәндә, Яңапар (Актук) авылы белән бәйле. Бу хакта аларның бик күп язмалары бар. Үзе дә шушы авылда туып үскән, 15 яшендә Суомига күчеп килгән Хәсән Хәмидуллланың (1900—1988) «Яңапар тарихы» китабында (1954) [Хәмидулла, 1954] Финляндиядәге милләттәшләребез, аларның асыл ватаннары хакында шактый тулы мәгълүматлар бәян ителә. Биредәге каләм әһелләренең дә зур өлеше еш кына үзләрен «Нижгар мишәре» дип саный. Әмма моннан чыгармалар да бар. Шундыйларның берсе Гәүһәр Туганай (15. 10. 1911 — 4. 02. 1998)*. Ул чыгышы белән исеме җырларда яңгыраган, берничә билгеле затны (Мирфатыйх Зәкиев, Фәһимә Хисамова, Әнвәр Шәрипов һ. б.) биргән, атаклы Кәрәкәшледән. Элек Самара губернасының Бөгелмә өязенә кергән бу авыл хәзер Татарстанның Ютазы районы составында.

Истәлекләрдән булачак шагыйрәнең әтисе Нигъ мәтулла һәм әнисе Гайниҗамалның уртача хәлле, чагыштырмача укымышлы, абруйлы кешеләр булуы күренә. Гаиләдә китап үзенә лаеклы урынны били. Авылда электән үк билгеле мәдрәсә эшли. Гәүһәр шул уку йортында, бераздан аның нигезендә ачылган мәктәптә белем ала. Бу — бик тә катлаулы, болгавыр еллар: инкыйлаб дулкыннары, аклар-кызыллар, илдәшләр сугышлары... Тормыш кырмыска оясы кебек кайный. Тиз арада боларга коточкыч ачлык афәтләре килеп кушыла. Ул безнең әдәбиятта, аеруча Г. Ибраһимов, М. Гафури, Ф. Әмирхан әсәрләрендә шактый калку гәүдәләнеш тапкан. Соңрак булса да, аларга Гәүһәр Туганай да килеп кушыла. Аның «Бала вакытымдагы хакыйкый хатирә»  исемле язмасында [Туганай, 1970: 76—80] ачлык чорның шактый гына аянычлы күренешләре тасвирлана. Шагыйрә аны үз язмышы, үз гаиләсе, үз төбәге мисалында сурәтли («Бу хәсрәтне, ди ул, — мин дә күрдем...»), «Газраил гел янымда... торды...», «Үлән орлыклары белән туену» да телгә алына. Ризык эзләп авылдан авылга хәерчеләр йөри. «Илдә эт, мачы калмады»,— ди автор.  Әсәрдә Американың азык-төлек белән ярдәм итүе дә искәртелә. Әмма барыбер халык кырыла, «унбишәр» мәетне

* Кабер ташында шагыйрәнең туу вакыты 1907 ел дип күрсәтелгән.

бер кабергә күмәләр. Әсәр ахырында күрше авылдагы дүрт балалы бер гаиләдә кечкенә кызларын пешереп ашау кебек коточкыч хәл дә сурәтләнә...

Мәгълүм ки, 20 нче еллардагы ачлыктан берничә йөз мең милләттәшебез кырыла. Башка җирләргә, илләргә күчеп, качып китүчеләрнең саны да гаять күп. Болар арасында Кәрәкәшленең үсмер кызы Гәүһәр дә бар. Кайбер язмаларда аның туган төбәгеннән Төркиягә килүе искәртелә. Бу мәкаләне язганда без фәкыйрегезгә күренекле милләттәшебез, күптәнге танышыбыз, Хельсинки университеты мөгаллиме Окан әфәнде Таһир белән берничә мәртәбә элемтәгә керергә туры килде**. Аның һәм Гәүһәр апаның кызы Гүзәл ханымның әйтүенчә, булачак шагыйрә этисенең туганы, заманында Буби мәдрәсәсендә укыган Рәйхана ханымның чакыруы буенча әүвәл Финляндиягә килә. Аның бу «һиҗрәте», чикләрне үтүе бик тә авыр булгандыр. Әдибәнең 1962 елда иҗат ителгән «Бала вакытым» шигырендә [Туганай, 1970: 10-13] мондый юллар бар:

*Илле яшем үтеп киттем, сагынам туган илне көн дә,*
*Гомер буе читтә адашсам да, татлы уйлар калды күңелдә.*

Бу әсәрдәге сан һәм кайбер башка өстәмә мәгълүматлар Гәүһәрнең Суомига 1922-1923 еллардан да иртә килмәвенә ишарә ясый. Биредә ул берара яшәгәч, Рәйхана апасы һәм җизнәсе белән Төркиягә китә. Кайда яшәве, укуы бик билгеле түгел. Бу мәмләкәттә 3-4 ел торгач, Финляндиягә әйләнеп кайталар. Әүвәл Тирйоки да (Зеленоград. 1939 елдан ул — СССР составында), аннан ил башкаласында гомер кичерә. 1933 елда чыгышы белән Касыйм татарларыннан булган Хәким (1907—1989) исемле кешегә кияүгә чыга. Окан әфәнде аңлатуынча, аның фамилиясе Тәкәнә исеменә нигезләнгән Текенаев рәвешендә була. Финляндиядә ул аны «Туганай» дип үзгәртә. Гәүһәр апабыз үзенә тәхәллүс итеп шул исемне ала. Аларның берничә баласы булуы мәгълүм. Исемнәре бик мәгънәле, үзебезчә, милли: Хәтфә (1934 елгы), Тугры, Гүзәл (1939 елгы, минем яшьтәш), Якты, Зирәк... Боларның кайберләре белән шәхсән үземә дә күреп сөйләшергә туры килде. «Ислам җәмгыяте»ндә секретарь вазыйфаларын башкаручы, ачык күңелле, ярдәмчел Зирәк миңа гыйльми-тикшеренү өчен кирәкле материалларны табуда шактый булышты.

Туганайлар, нигездә, мех сәүдәсе белән шөгыльләнә. Гәүһәр апа да кибеттә эшли. Бу аның шигырьләрендә дә берничә мәртәбә телгә алына. «Үтте еллар» парчасында (1967) ул сату, кибет эшенең авырлыгын да искәртеп куя:

*Уен-көлкегә, җырларга калмый һич форсат, вакыт,*
*Кибеттә утырып торабыз үләксә тиресе сатып.*
*Кич белән өйгә кайтабыз кара тузанга батып,*
*Көн буена арып талгач, йоклыйбыз инде ятып* [Туганай, 1970: 70]

Миңа 1990 елда Финляндиягә өч айлык гыйльми командировка вакытында Гәүһәр апа, аның гаилә әгъзалары белән берничә мәртәбә сөйләшергә, аларның Хельсинки мәркәзендәге «Туганай» дип исемләнгән мех кибетләрен дә күрергә туры килде. Беренче очрашу, ничектер, күңелдә ныграк уелып калган. Хельсинкига килеп, берничә көн үткәч, Гәүһәр апаның кызы Хәтфә ханым үзенең елык-елык килеп торган машинасында кунакка алып китте: тору урыныннары шактый зур, иркен. Мул тормышта яшәүләре сизелеп тора. Мине бөтен кыяфәтеннән, үз-үзен тотышыннан ук татар икәнлеге сизелеп торган бер хатын каршы алды. Ул Гәүһәр апа булып чыкты. Мул итеп чын милли табын әзерләнгән. Самовар да гөрләп тора. Утырдык. Мин артык

** Биргән мәгълүматлары, җибәргән фотолары өчен мин бу игелекле затларга янә рәхмәтләр укыйм.

ачылып китмичә, үземне рәсмирәк тотам. Имеш, Совет кешесе. Шунда Гәүһәр апабыз, үземнең әнкәй кебек аркадан сөеп: «Хатыйп улым, читенсенеп утырма»,— дип йомшак кына әйтеп куймасынмы. Шуннан телләр ачылып, сөйләшеп киттек. Мин аның матур сөйләменә, тормышны, кешеләрне, әдәбиятны, халкыбызны белүенә сокланып утырдым. Үз туган теленнән тыш, ул төрек, фин, швед һәм кайбер башка телләрдән дә яхшы хәбәрдар. Гәүһәр апа минем лекцияләргә дә иң алдан килеп утыра иде. Милләттәшләребезнең аны хөрмәт итүен мин үз күзләрем белән күрдем. Ул милли чараларда актив катнаша, халкыбызның гореф-гадәтләрен, традицияләрен саклауга үзеннән зур өлеш кертә. Туган якларына да кайтып килгәләве, туган-тумачалары белән бәйләнештә торуы да мәгълүм***.

Финляндиядән мин мөһаҗирлектәге татар китапларына шактый баеп кайттым. Ул басмаларның зур өлешен үзебезнең китапханә-музейларга тапшырдым. Аларның бит шактый өлешен миңа Гәүһәр апа бүләк иткән иде! Бу гамәле өчен генә дә ул олуг рәхмәтләргә лаек. 1990 елның апрель аенда Хельсинкиның тимер юл вокзалында мине озатырга, башка күп кенә милләттәшләребез белән бергә, Гәүһәр апа да килгән иде. Шәхсән миңа һәм үзенең кардәше һәм авылдашы Фәһимә ханым Хисамовага күчтәнәчләрен биреп: «Исән-сау йөр Хатыйп улым»,— дип мине озатып калды. Ул җибәргән тәм-томнар белән өйдәгеләрне генә түгел, эштәгеләрне дә сыйладым. Үзенә күп рәхмәтләр укыдылар. Яңадан Суомига баруларымда инде ачык йөзле Гәүһәр апабыз якты дөньяда юк иде. Аның һәм кайбер башка милләттәшләребезнең каберләрен генә зиярәт кылырга, рухларына дога кылырга гына туры килде.

XX йөздә Суомида яшәгән кавемдәшләребез мең тирәсе генә булса да, алардан чыккан каләм әһелләренең саны дистәдән артып китә: Хәсән Хәмидулла (1900-1988), Садрый Хәмид (1905-1987), Садыйк Хөсәен (1906-1971), Гайсә Хәкимҗан (1896-1972) һ.б. Болар арасында Гәүһәр Туганай да мөһим урынны били. Аның әдәби иҗат белән кайчаннан бирле шөгыльләнүе төгәл билгеле түгел. Шигырьләре аркылы без аның яшьтән үк әдәбиятны яратуын, сүз сәнгатенә тартылуын күрәбез. Әмма Кәрәкәшле кызы әдәби иҗат белән ныклап чагыштырмача соңрак — 50-60 нчы елларда гына шөгыльләнә башлаган булса кирәк. 1968 нчы елның 16 нчы апрелендә язылган шигырендә ул болай ди:

*Кайвакыт күкрәгемдә кайный хисле илһам чишмәсе,*
*Тупланып килгәч күңелгә, язмыйча соң нишләсе.*
*Ярты гомрем үтте язарга вакыт таба алмыйча,*
*Бәлки дустлар уйлый торгандыр бу «саташкан» диеп.*
*Мин үз-үземне таныйм да, бакмыйм аларга кыек.*
*Укысаң әүвәлге шагыйрьләр тарихын — нәкъ шулай,*
*Тиле исмен күтәреп йөрүе булмаган уңай* [Туганай, 1970: 72].

Шагыйрә безгә мәгълүм әсәрләренең башында ук язылу вакытын көне, ае, елы белән күрсәтеп бара. Аларның иң зур күпчелеге нәкъ менә 60 нчы елларга карый. Арада, сирәк кенә булса да, 50 нче елларда иҗат ителгән парчалар да күзгә ташлана.

---

*** Туган якларына Гәүһәр Туганай берничә дистә елдан соң гына кайтып килгән бугай. «Әнкәм үлгәндән соң» дип исемләнгән шигырендә (15. 07. 1956) ул әнисе белән очрашуны озак көтүен искәртә. Әмма барыбер бу теләгенә ирешә алмый: «Мин утыз ике ел көттем әнкәй белән күрешүне», «Күрмичә калдым еракта әнкәйдән мин ятим» [Туганай, 1970: 2].

Гәүһәр Туганайның аерым язмалары мөһаҗәрәттәге төрле җыентыкларда, гәҗит-журналларда басылып килә. Мәсәлән, 1986 елның 25 октябрендә Хельсинкида Г. Тукайның тууына 100 ел тулу уңае белән зур кичә оештырыла. Аның җыентык рәвешендәге махсус программасы да бар. Анда шагыйрьнең берничә әсәре дә («Пар ат», «Яз галәмәтләре», «Туган авылым», «Көз» һ. б.) урнаштырылган. Шунысы мөһим: латин хәрефләре белән басылган бу мәҗмуга Гәүһәр Туганайның Тукайга багышланган шигырьләре белән ачыла һәм ябыла. Аларда автор шагыйрьнең бөеклегенә, «мәңгелегенә» басым ясый. «Аның исеме, шигырьләре мәшһүр, Җаныбызга —аш, күңелгә — нур»,— ди. Җыентык ахырындагы «Тукайны сагыну» парчасы мондый строфа белән тәгәлләнә:

*Ничә еллар көттек сиңа тиң торганны,*
*Белеп булмый синең мислең туармы?*
*Һәр ел зурлап хөрмәтлибез бу көнеңне,*
*Вакытсыз ташлап киттең — әрнетә күңелне.*

Илдәге басмаларда шагыйрәнең иҗатының аерым үрнәкләре, гәрчә бик сирәк булса да, күзгә ташлана. Күзәтү характерындагы язмаларда, шул исәптән без фәкыйрегезнең хезмәтләрендә дә Гәүһәр Туганай хакында аерым белешмә-мәгълүматлар бар. Шагыйрәнең безгә мәгълүм тәүге [Туганай, 1970] җыентыгы ике китап («бүлек». — 99 б.; 104 б.) рәвешендә 1970 елда дөнья күрә. Гарәп хәрефләре белән басылган бу «Шигырьләр мәҗмугасы» «Тампере Ислам мәхәлләсе имамы» Хәбибрахман Шакир матбагасында нәшер ителә. Кызганыч ки, бу китапларның «беренче бүлеге» генә кулыбызда бар. Шуңа күрә хәзерге вакытта шагыйрә иҗаты хакында сүз әнә шул басмага таянып алып барыла, мисал-өзекләр дә шул «Беренче бүлек»тән китерелә. Кәрәкәшле кызы үзенең иҗатын, әлбәттә, 1970 елдан соң да дәвам иттерә. Әмма бу чор әсәрләренең аерым туплам рәвешендә нәшер ителүе бу юлларның авторына хәзергә мәгълүм түгел.

1970 елда дөнья күргән «Шигырьләр мәҗмугасы»нда (төгәлрәге аның «беренче бүлеге»ндә) авторның 87 шигыре урнаштырылган. Алар, нигездә, 60 нчы елларда иҗат ителгән. Әлеге китап, гомумән, лирик-эмоциональ характерда; эпиклык-вакыйгалылык азчылык урынны били. Әсәрләре аркылы авторның шигъри дөньясы, рухи халәте, күңел биографиясе шактый тулы күзаллана. Шәхси уй-кичерешләр, хатын-кыз психологиясе аркылы иҗтимагый, фәлсәфи, милли, тарихи мәсьәләләргә шактый урын бирелә. Туган ил һәм җир, газиз халкың, ата-ана, туганнар һәм кардәшләр, якташлар һәркем өчен бик тә якын, үз. Алардан аерылу адәм баласын, аеруча иҗат әһелләрен, кайгы-сагышка, сагыну диңгезенә сала. Мондый халәт, мондый хис Гәүһәр Туганай парчаларында бигрәк тә ачык гәүдәләнә. Аның күп кенә шигырьләре туган ягына мөнәсәбәттә язылган. Җыентыкның тәүге битләрендә үк без 1956 елда иҗат ителгән шундый юллар белән очрашабыз:

*Мин бик яшьдән айрылдым туган илдән,*
*«Илем» дигәч күңлем нәзек нечкә кылдан.*
*Шуның өчен төшерә алмыйм сине телдән,*
*Иген үсә иде уңып башдан, билдән*
*Беркайчан да туймас идем туган илдән,*
*Аны мәшһүр итәр идем, килсә кулдан.*
*Авылыбызның исеме дә Кәрәкәшле,*
*Тирә-ягы биек таулар һәм бурташлы*

*Анда үскән кызлар матур, кара кашлы,*

*Җегетләрдә — кара мыек, кара чәчле...* [1: 2]

Автор кайвакыт тормыш, гомер агышы хакында уйлана. Аның фикерләвенчә, бу дөньяда рәхәт-шатлыкка караганда, газап-михнәт хәддин ашкан. Лирик герой әнә шул капма-каршы төшенчәләр арасында бәргәләнә: «Хәсрәт ялкыны эчендә тарсынып җаным талашты, Бер туктамый яна йөрәк, янмаган көне бик сирәк» [Туганай, 1970: 46]; «Дөнья кыса, тормыш авыр, сызыла күңлем тарсына, Ямь таба алмый, тәм таба алмый, нигә болай ярсына?!.»; «Җан яна урын таба алмый, михнәт эчендә иртә-кич» (63 б.). Татар шигърияtendә «күңел»гә мөрәҗәгать итеп, аны хәтта рәдиф итеп (юл ахырында кабатлап) язу күптәннән килә. Гәүһәр Туганай да бу традициягә тугры кала. Газәл жанрына тартым бер шигырендә автор лирик герой күңеленең бәргәләнүен, сызлану-әрнүләрен, яну-көюләрен шактый үтемле тасвирлый:

*Әй күңел, ялкыны юк янган күңел,*

*Су сибеп сүндерергә мөмкин түгел.*

*<…>Дөнья золмәтендә изелгән күңел,*

*Һәр явызлыкларга түзә алган күңел.*

*Шагыйрә мондый халәтнең үзенә күрә сәбәбе булуын да искәртә:*

*Дөнья ерткыч булмаса, янмас идек,*

*Хөр яшәр, йончымас, интекмәс идек...* [Туганай, 1970: 38]

Кәрәкәшле, туган илнең бер символы, коды буларак, шагыйрәнең кайбер башка әсәрләрендә дә очрый. Бу тирәдәге халыкның яшәеше билгеле бер дәрәҗәдә Ык белән дә бәйле. Гәүһәр Туганай шигырьләрендә дә бу елга телгә алына. Аның «Ык буе хатирәсе» дигән махсус шигыре дә бар [Туганай, 1970: 44-45]. Бу әсәр берничә яктан игътибарга лаек. Беренчедән, бу елга, аның кешеләре автор өчен бик тә кадерле:

«*Ык буенда үскән кызлар — ул тирәдә мактаулы:*

*Йөзе кояш, кашы кыйгач, эшчән, армый-талмый...*

*<...> Бала чагымда ук таныйм: ямьлелә ул Ык буе,*

*Кара бөрлегән, карлыган куаклары бик куе.*

*Чиләкләп җыйсаң да бетми — халык җыя җәй буе,*

*Җәтмә, кармакка эләкде зур җәен балыклары...*

Икенчедән, бу шигырь авторның нәсел-нәсәбенә, тәрҗемәи хәленә дә билгеле бер ачыклык кертә:

*Каразирек авылында әнкәем туып үскән,*

*Буе кыз булгач, Кәрәкәшлегә яшь килен булып киткән*

*<...> Әнкәй Вилдан нәселендән — Әхмәдҗан бабам кызы*

*Ерак әбием Сәхибкәмал — сөлекче иде үзе.*

Җыентыкта «Крым»ны мактаган бер шигырь дә күзгә ташлана [Туганай, 1970: 19]. Ул көньяктагы Кырым түгел, ә Ык тирәсендәге Крым — Сарай. Автор аның гүзәллеген генә түгел, ә үзе өчен бер «ватан» булуын да искәртә. Күрәсең, аның берәр бик якын кешесе бу авыл белән бәйледер.

Гәүһәр Туганай шигырьләрендә туган төбәгенең гореф-гадәтләре, шөгыль-яшәү рәвешләре дә гәүдәләнеш тапкан.

Кәрәкәшле кызы әсәрләрендә туган як, бала һәм үсмерчак хатирәләре зур урынны били. Әмма аның иҗаты алар белән генә чикләнми. Шагыйрәнең тугыз дистәгә диярлек сузылган гомер юлының иң зур өлеше иленнән читтә — Финляндиядә уза. Биредә ул балигълык яшенә керә, гаилә кора, балалар үстерә, эшли, кешеләргә, бигрәк тә үз

халкына булдыра алган кадәр хезмәт күрсәтә. Шунда ук бакый дөньяга да китеп бара. Мондый чынбарлык, яшәешнең реаль вазгыяте, әлбәттә. аның иҗатына да сизелерлек йогынты ясый. Шагыйрә, гомумән, табигать, ел фасыллары, аларга хас сыйфатлар турында язарга ярата. Аның аерым шигырьләрендә Финляндиянең урман-сулары, кош-кортлары, озакка сузылган карлы, «кара» кышлары хакында шактый юллар бар.

*Финляндиядә шулай инде, җәйне көтеп гомер үтә,*

*Елы көнгә туеп булмый — өч айдан җәй үтеп китә* [Туганай, 1970: 14].

Гәүһәр Туганай Суомидагы тормышның көйле, халкының тырыш, эшчән булуын да искәртә. Мәгълүм ки, бу мәмләкәттә милләттәшләребезгә шактый уңай мөнәсәбәт урнашкан. Бу хакта Кәрәкәшле кызы да язып үтә:

*Рәхмәт төшсен бу милләткә: безне яхшы тоталар,*

*Кимсетмичә, тигез карап, бөек хөрмәт итәләр.*

*Фин халкы инсаниятле, исеме танулы, мәшһүр,*

*Меңләрчә тәшәккер* (рәхмәт. — Х. М.) *белән рәхәт яшибез,*

*мәсрур* (шат. — Х. М.) [Туганай, 1970: 73]

Әмма матди яктан ничек кенә мул, «рәхәт» яшәсә дә, мөстәкыйль дәүләте булмаган халыкка, бигрәк тә чит мәмләкәтләрдә гомер кичерүче кавемнәргә үзләренең тел-моңнарын, гореф-гадәтләрен саклау һәм киләчәк буыннарга тапшыру гаять кыен... Монда төп шартларның бик мөһиме булып халыкның бердәмлеге тора. Мөһаҗәрәттәге башка каләм әһелләре кебек, Гәүһәр апабыз да бу мәсьәләгә кат-кат басым ясый:

*Бер-береңдән аерылмый дусча бергә берләшик,*

*Бергә татлы сүзләр сөйләп, күгәрчендәй гөрләшик.*

*Бергә уйнап, бергә көлсәк, бергә җырлап, бергә торсак, —*

*Ахырда үкенмәбез, авырлыклар күрмәбез* [Туганай, 1970: 84].

*Фин илендә торабыз — әз монда безнең халык.*

*Көч куеп тырышабыз — тормаска артка калып.*

*Кирәк бергә яшәргә, таралмыйча бер булып.*

*Аерылмыйча яшәсәк — капламас кара болыт* [Туганай, 1970: 54].

Билгеле ки, дәүләтчелеген җуйган халкыбыз коточкыч колониаль изелү елларында да, зур югалтулар бәрабәренә булса да, үзенең телен, милли барлыгын саклап, алдагы буыннарга тапшыра килгән. Бу юлда аның даими һәм ышанычлы юлдашы, таянычы ислам дине булган. Бу тарихи тәҗрибәне, реаль хакыйкатьне тирәнтен аңлаган шагыйрә дә кавемдәшләрен иманлы булырга чакыра, Ураза, Корбан бәйрәмнәре уңае белән махсус шигырьләр дә иҗат итә. Автор өчен дин, тел, миллият — аерылмас төшенчәләр.

Узган гасыр урталарында Финляндиядә яшәүче, болай да оешып, бердәм булып җитмәгән милләттәшләребез арасында төрекчелек хәрәкәте, Истанбулга йөз тоту көчәя. Хәтта төрек телендә басмалар да дөнья күрә. Әмма күпчелек, Төркиягә, төреккә һич тә каршы килмичә, үзенең элек-электән килгән милли барлыгын сакларга омтыла. Гомәр ага Таһир оештырган «Тукай җәмгыяте» бу юнәлештә нәтиҗәле генә эшли. Хәсән ага Хәмидулла халкыбызның тарихын яктырткан хезмәтләр яза, милли рухлы шигырьләр иҗат итә. Мондый татарпәрвәрләр арасында Гәүһәр Туганай да бар. Аның берничә әсәре турыдан-туры шушы бәхәскә бәйле:

*Берсе әйтә: татар түгел, мин төрек, — ди,*

*Икенчесе ди: мин татар,— сөйлисең ни?* [Туганай, 1970: 22].

Башка күп кенә татар зыялылары кебек, Кәрәкәшле кызы да Истанбулны, төрекләрне үз һәм якын итә, зурлый, укучыларын да бу халыкка дустанә карарга чакыра. Әмма бер үк вакытта, тарихи хакыйкатькә тугры калып, татарлыкны да кискен яклап чыга. Строфаларының төгәлләнеше белән Шәмседдин Зәкинең (1821-1865) «булгай – булмагай» шигырен хәтерләткән парчасында (1962) Гәүһәр Туганай болай ди:

*Һичбер заман татар төрек булмай-булмай,*

*Ул юл белән киткән эшләр уңмай-уңмай.*

*Шивә башка — туган телгә килмәй-килмәй,*

*Халкыбызның күңеленә сеңмәй-сеңмәй...* [Туганай, 1970: 29].

«Төрек-татар» мәсьәләсе «Татар без!» шигыренең дә [Туганай, 1970: 28] төп мотивы. Менә андагы аерым юллар: «Әллә нәрсә дисәләр дә, татар булгач – татар без», «Бездә бар да бар» («сүзе» дә, «көе» дә, җыры» да)

*Туган телебез булып торсын — төрекчәне дә өйрән»,*

*Фин кызларына өйләнмә — татар кызларын* (кызына. — Х. М.) *өйлән.*

*Кияүләр дә татар булсын, татар белән зал тулсын,*

*Төрек кардәшләребез дә хөрмәтле кунак булсын.*

Шагыйрәнең «Дәрдләрем», «Милләтем», «Татар», «Идел суы» һәм кайбер башка әсәрләрендә дә татар тематикасы шактый тулы яктыртыла. Автор фикеренчә, халкыбыз уңган, булган, озын тарихлы («Татарлыкны әзсенмәгез, татар — Чыңгыз баласы»; аның «теле матур», җыр көе моңлы). Урыны белән, мөгаен, артык яратканга, үз халкын тәнкыйтьләп тә ала. Идел, Казан — Кәрәкәшле кызының төп кыйбласы.

Мөһаҗәрәттәге милли әдәбиятыбызда «Татарстан» атамасы, аның белән бәйләнешле тематика сирәк очрый. Татар дөньясы, элеккеге тарихка нисбәтән, киң планда карала, еш кына «Идел-йорт», «Идел-Урал», «Казан» төшенчәләре рәвешендә күзаллана. Гәүһәр Туганай исә бу юнәлештә кыю гына эш итә. Аның хәтта республикабызга багышланган махсус әсәре дә бар. Ул «Бүгенге Татарстан» дип атала [Туганай, 1970: 42-43]. 1966 елда иҗат ителгән бу шигырьне җөмһүриятебезнең билгеле бер дәрәҗәдә идеаллатырылган картинасы дип тә атарга мөмкин. Анда муллык, алга китеш, тәртип, рәхәтлек...; «мәктәпләр гөрләп тора — бар да татар телендә»... Автор Татарстанны «зур гөлбостан» белән тиңли. Элеккеге әдәбиятта касыйдә, мәдхия жанрлары бик актив кулланыла. Аларда, гадәттә, авторлар үзләре күрергә теләгәнне бар, булган рәвешендә тасвирларга ярата. Кәрәкәшле кызы да билгеле бер дәрәҗәдә шул традицияне дәвам иттерә. Әмма аның шигырендәге төп төшенчә-сурәтләр реаль чынбарлыктан артык ерак китми. 2020 елда Татарстанның төзелүенә 100 ел тулды. Аның тарихы, үткән юлы хакында сүз барганда Кәрәкәшле кызының да бу шигыре бер гыйбрәтле мисал була ала.

XX йөздә мөһаҗәрәттә иҗат ителгән күп кенә язмаларда илдәге хакимиятне, Кремльне, совет системасын тәнкыйтьләү очрый. Мондый хәл исә Гәүһәр Туганай иҗатында күзәтелми.

Вәзен-кафиядә, поэтик стильдә, сүз-гыйбарәләр сайланышында аерым төгәлсезлекләр, бәхәсле яклар булуга да карамастан, Гәүһәр туганай иҗаты мөһаҗирлек әдәбиятында гына түгел, ә гомумән татар сүз сәнгатендә дә билгеле бер игътибарга лаек. Ул татар мәнфәгатьләре өчен көрәшүче, чын милли шагыйрә. Аның уй-кичерешләре, сагыну-сагышлары укучыларны битараф калдырырлык түгел. Шунысын да искә төшерик: соңгы берничә дистә елда илдән китеп, чит мәмләкәтләрдә яшәүче милләттәшләребез шактый. Әмма, ни кызганыч, алар арасында Сания Гыйффәт, Хөсәен

Габдүш, Әхмәд Гәрәй, Гәүһәр Туганай... кебек татарым, телем, моңым дип янучылар, фидакарьләрчә тырышучылар бик аз шул . Ә инде Рөстәм Сүлти, Чулпан Зарифтан... кала, татарча иҗат итүчеләр бөтенләй юк диярлек.

Гәүһәр Туганайның «Иртә чиркәү кыңгыравы тәэсире астында» баш исеме белән 1968 елның 6 нчы декабрендә язылган бер шигыре бар [Туганай, 1970: 96].Чит илдә яшәве җайсыз.

| | |
|---|---|
| *Торам гүя ярты җансыз.*<br>*Кая барсам да ят тоям,*<br>*Бу әрнүне язып куям.*<br>*Иртәдән үк кага чиркәү.*<br>*Күңел белән без тик икәү.*<br>*Туганлар, туган ил калган,*<br>*Язмышны белмисең алдан.*<br>*Көн-төн үз (ул. — Х. М.) илне сагынам,* | *Сары яфракдай саргаям,*<br>*Канатсыз кош кебек яшим,*<br>*Итләрен мәҗбүрдән ашыйм*<br>*Ничек аңлатырлык әйтим,*<br>*Сизәм үземне гел ятим.*<br>*Сагынам моңлы азанны,*<br>*Моңайган шәһрем Казанны.*<br>*Йөрәк төптән сагынмасам,*<br>*Бу сүзләрне язаммы?!* |

Игътибар итегез: бу юлларны бит ярты гасырдан артык чит илдә яшәгән, шунда гаилә корган, балалар үстергән, тамырланган, мул тормышлы кеше яза! Никадәр әрнү-сагыш, никадәр сагыну-юксыну!

«Безнең мирас» журналын укучыларга Гәүһәр Туганайның тормышы һәм иҗаты турындагы мәкалә һәм аның аерым шигырьләрен тәкъдим итәбез. Аларны сайлап алу шактый кыен, шартлы булды. Чөнки җыентыктагы 100ләп шигырьнең һәрберсенең үз кыйммәте бар. Бәлкем киләчәктә Кәрәкәшле кызының махсус шигырьләр җыентыгын әзерләп бастыручы булыр. Ютазылы-баулылар үз якташларын ни дәрәҗәдә беләләр, Гәүһәр апаларын ни рәвешле искә алалар микән – күңелдә бу төр сораулар да туып тора.

## ӘДӘБИЯТ


Гәүһәр Туганай. Шигырь мәҗмугасы. Беренче бүлек. Тампере, 1970. – 99 б. (гарәп язуында).

Хәсән Хәмидулла. Яңапар тарихы. Хельсинки, 1954. – 85 б. (гарәп язуында).

Хатыйп Миңнегулов. а) Фин илендә Кәрәкәшле кызы; б) Гәүһәр Туганай шигырьләре // Безнең мирас, 2020. № 9-10.



**А.И. МИННУЛЛИНА**

Казанский федеральный университет, Казань


# СКАЗКИ НАРОДОВ ПОВОЛЖЬЯ
## (На примере татарских и чувашских сказок)


**Аннотация.** Цель данного исследования – на основе структурно-семантического анализа выявит сходства и различия татарских и чувашских сказок.

**Annotation.** The purpose of the study – based on structural-semantic analysis will reveal similarities and distinctions of the Tatar and Chuvash fairy tales.



**Ключевые слова:**сказка, чувашский и татарский фольклор.

**Keywords:** fairy tale, Chuvash and Tatar folklore.


Сказка – это яркое проявление народной культуры каждой нации. Она содержит в себе такие сюжеты, образы, ситуации, которые специфичны для определенного этноса,

что находит выражение в именах действующих лиц, названиях животных и растений, месте действия, в самобытных традиционных языковых формулах. Национальный характер сказки каждого народа определяется его бытом, обрядами, условиями труда, фольклорными традициями, особым поэтическим взглядом на мир и т.д. [Тришакина, 2011: 28-29].

Многие сказки чувашского и татарского фольклора сопоставляются с аналогичными произведениями других народов. Это помогает во многих случаях полнее раскрыть смысл сказок, дает возможность делать интересные заключения. Сходство сказок часто объясняется не заимствованием, а одинаковыми условиями жизни трудовых слоев населения разных национальностей. Но, в то же время нельзя отвергать и культурное взаимовлияние и заимствования. Всказка во многих тюркских народов имеется древнее общее ядро, а в отличных друг от друга вариантах отражаются специфические черты национальной жизни. В переводах чувашских сказок на русский язык по возможности сохранено национальное своеобразие оригинала. Желание находить эквивалент сказок в татарском языке не всегда выполнимо, так как не каждый раз можно подобрать в татарском фольклоре сказки, полностью передающую содержание и стиль чувашской.

*СКАЗКА* 1, -и, ж. 1. Повествовательное, обычно народно-поэтическое произведение о вымышленных лицах и событиях, преимущ. с участием волшебных, фантастических сил. Русские народные сказки. Сказки Пушкина. 2. Выдумка, ложь (разговорное). Бабьи сказки (пустые слухи, сплетни; пре-небр.). 3. сказка. То же, что чудо (в 3 значение) (разговорное). Костюм получился — сказка! Ни всказке сказать, ни пером описать — в народной словесности: о ком-чём-нибудь очень хорошем, красивом. || уменъш. сказочка, -и, ж. (к 1 значение). || прил. сказочный, -ая, -ое (к 1 значение). С. жанр. Сказочные герои [Ожегов, 1996: 412 ]

Смысл сказок народов Поволжья - возвышении человека, вооруженного разумом и знаниями, способного побеждать враждебные силы, строить жизнь без помощи и вмешательства сверхъестественных сил. В сказках утверждается мысль о том, что житейский опыт является основой человеческого познания и что практика проверяет достоверность наших знаний. В обоих языках существуют сказки на одну и ту же тематику: семья, хозяйство, правда и ложь, труд. А для того чтобы передать тонкий смысл сказок и в татарском, и в чувашском языках используются схожие предметы, схожие ситуации. Соответственно и смысл в данных сказок тоже одинаковы.

Рассмотрим вышеуказанные подходы на примерах.

1. Рос Иван не по дням, а по часам (Иван-батыр) – Камырмалай ай үсәсен көн үсә, ел үсәсен ай үсә (Камыр батыр).

2. Пошли они вместе. Шли-шли, порожний мешок нашли. Опять идут путем-дорогой, нашли голову волка, положили ее в мешок (Козёл и Баран) – Икәү чыгып сызалар болар. Баралар – баралар, бара торгач бер бүре башы табалар да: «Кирәк булыр әле!» - дип, бүре башын капчыкка салып алып китәләр болар (Кәҗә белән сарык).

3. Сам берет мешок и вытаскивает из него голову волка. Вытащил, поглядел, обратно положил и снова вытащил: делает вид, что выбирает (Козёл и Баран) – Бер бүре башы, ике бүре башы, өч бүре башы, - дип, шул бер бүре башын әйләндерә дә саный, әйләндерә дә саный(Кәҗә белән сарык).

4. Бабушка отвечает:

- Что вы мелете? Нету у нас никакой дочки (Зухра) – Әби әйтә: Ни сөйлисез, безнең кызыбыз юк ич, - ди (Зөһрә).

5. И отправился тот малец по свету бродить. Шел он день, шел он ночь, месяц минул, год прошел, от деревни он ушел на один вершок. И попал в дремучий лес. Повстречался ему в этом лесу человек стреноженный (Иван – батыр) – Чыгыпкитә малай дөнья гизәргә. Көн китә, атна китә, ай китә, ел китә, бер саплап җир китә. Барып керә, ди, бер карурманга (Камыр батыр).

Итак, изучив татарские и чувашские сказки можно, во-первых, сделать вывод, что в языке разных народов существуют много общих и сходных явлений. Многие сказки народов мира изобилуют похожими сюжетами. Герои могут видоизменяться в соответствии с особенностями и привычками определенного народа, в котором эта сказка бытует.

Изучая татарские и чувашские сказки, мы видим в них схожее содержание, выраженное в сказочных сюжетах, героях и их испытаниях, но форма повествования может быть различной. Отличие сказок часто связано с особенностями другой культуры, природы и обычаев другой страны. Сказки сближают разные народы и помогают им лучше понимать друг друга.

## ЛИТЕРАТУРА

Ожегов С.И., Шведов Н.Ю. Толковый словарь русского языка. М.: Российская академия наук. – 4 – е изд., дополненное, 1999. – 944 с.

Тришакина Е.С. Народная сказка как фольклорный жанр и как специфичкое культурное явление. Ростов-на-Дону, 2011. – 28-29.

Татар халык әкиятләре: Әкиятләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989.- 480 б.

**Ф.Х. МИҢНУЛЛИНА**
Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясе
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Казан

## Р. ЗӘЙДУЛЛАНЫҢ «ҮЛЕП ЯРАТТЫ» ДРАМАСЫНДА ШӘХЕС ФАҖИГАСЕ

**Ф.Х. МИННУЛЛИНА**
Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова
Академии наук Республики Татарстан, Казань

## ТРАГЕДИЯ ИЧНОСТИ В ДРАМЕ Р. ЗАЙДУЛЛЫ «ЛЮБОВЬ БЕССМЕРТНАЯ»

**Аннотация.** Статья посвящена изучению драмы Р. Зайдуллы «Любовь бессмертная», где показана драма человека, на долю которого выпали суровые жизненные испытания. Анализ трагического конфликта раскрывает неразрывную связь судьбы героев и судьбу татарского народа. Писатель не только изобразили на страницах своих произведений исторические события, но также смогли отразить трансформацию мировосприятия и ценностных ориентиров человека под влиянием диктатуры.

**Annotation.** The article is devoted to the study of R. Zaydulla's drama «Immortal love», which shows the drama of a person who has experienced difficult life trials. Analysis of the tragic conflict

reveals an indissoluble connection between the fate of the heroes and the fate of the Tatar people. The writer not only depicted historical events on the pages of his works,but also managed to reflect the transformation of a person's worldview and value orientations under the influence of the dictatorship.
**Ключевые слова:** драма, пьеса, герой, личноть, заблуждение.
**Keywords:** drama, play, hero, personality, delusion.

Татар драматургиясе иҗтимагый яңарыш һәм тетрәнүләр чорын үтеп, XXI гасыр башында җитди үзгәрешләр дәвренә керде. Каләм ияләре тарафыннан гомумкешелек кыйммәтләре, кеше гомере аның яшәеше, шәхес иреге мәсьәләләре алга куела. Тоталитар режимны, бюрократик системаны фаш иткән пьесалар аеруча күп иҗат итлелә. Т. Миңнуллинның «Баҗа мал түгел, кәҗә туган түгел», З. Хәкимнең «Телсез күке», «Легионер», Р. Батулланың «Җимерелгән бәхет», Р. Зәйдулланың «Үлеп яратты» кебек пьесалары шундыйлардан. Чынбарлыкны чагылдыруда драматурглар төрле алым-чаралар эзлиләр, яңа тормыш моделен төзиләр. Мәсәлән, соңгы еллар татар драматургиясендә фаҗигалелек категориясенәдәби алым буларак та, сурәтләү объекты рәвешендә дә кулланылган әсәрләрне еш очратырга була.

Билгеле булганча, Сталин чорында мәдәниятебез зур югалтулар кичерә: меңләгән татар зыялылары, әдәбиятчылары, фән вәкилләре, җәмәгать эшлекләре, дин әһелләре юк ителәләр. Мәсәлән, Р. Зәйдулланың «Үлеп яратты» исемле драмасында XX гасырның 20-30 елларында татар зыялыларына кагылган эзәрлекләүләр Дини идарәдә хезмәт иткән өлкән яшьтәге Мөхлисә ханымны да читләтеп үтми. Пьесада Мөхлиса Буби нәселенең гаять аянычлы язмышлары бәян ителә. Мөхлиса гаиләсең юк ителүе совет хакимияте алып барган сәясәткә барып тоташуы ачык текст белән әйтелә.Мисал итеп, бердәнбер кызы Мөнҗия 1919 елда кызыддар тарафыннан үтерелә. Геройлар бирелешендә кеше күңеленең катлаулы һәм бай булуына да игъибар ителә. Шундыйларның берсе Россиянең мөселман дөньясында хатын-кызлар өчен иң беренче мәдрәсәгә нигез салучы һәм беренче хатын-кыз казый Мөхлисә Бубый язмышы. Ә. Закирҗанов сүзләре белән әйткәндә: «Сәхнә кануннары таләп иткәнчә, аворның игътибар үзәгекндә М. Бубыйның төрмәдәге соңгы көннәре һәм хатирәләр рәвешендә ггомеренең аерым эпизодлары гына укучы-тамашачы күз алдыннан үткәрелә» [Закирҗанов, 2020: 132]. Яшәү һәм үлем, олы җанлылык һәм намуссызлык, бөеклек һәм түбәнлек төшенчәләрен дөнья, ил язмышы белән рәттән куела. Драматург ретроспекция ярдәмендә, ягъни Мөхлиса Буби карчыкның хәтерендәге хәл-ситуацияләрне искә төшерү аша шәфкәтьсезлек, имансызлык кебек сыйфатларга кагыла, «яңа» җәмгытьнең, иделогиянең кешенең дөньяга карашын да, әхлагында, үз-үзен тотышында үзгәртүен күрсәтә. Ата-ана кызлары бәхетле булыр, мул тормышта яшәр дип өметләнеп Мөхлисаны өлкән яшьтәге муллага яшьли кияүгә бирәләр. Кыз исә ире белән бергә авыл халкын мәгърифәтле итү турында хыяллана. Кызганыч ки, дуамал, каты күңелле хәзрәт яшь абыстайның кызлар укыту теләгенә каршы килгән. Аның ике кечкенә кыз - ире сүзенә карамастан тәрбиягә алган ятимә (баладан үлгән хезмәтче хатынның кызы) Нажия һәм үз кызы Мөнҗия генә юаныч булган. Мөхлисәнең авыр тормышын күргән абыйсы һәм энесе аны үзләре белән алып китәләр. Мөхлисә, ир туганнарын авыл капкасына кадәр озатабыз, дигән хәйлә белән чыга һәм, ике кызын алып, аларның чанасына утырып китә. Драматург Мөхлиса Буби образы ярдәмендә татар зыялылары тормышын, теләк-омтылышларын, шул чорның иҗтимагый-мәдәни, сәяси халәтен бәян итә.Ул бөтен гомерен татар халкын белемле итүгә багышлый. Әмма тотлитар режим

шартлары бу фидакарь шәхесне аямый. Пьесада Мөхлисә ханымның Мәккәгә хаҗ кылу ниятеннән җыеп килгән барлык «байлыгы» тартып алынуы, кулга алынуы сурәтләнә.

Корбанов сүзләрендә Мөхлисаның революциягә каршы милләтчел эшчәнлек алып баруы, чит ил разведкасы белән элемтәдә торуы,совет хөкүмәтенә каршы фетнә күтәрүдә, бәйсез татар дәүләте төзергә җыенуда гаепләнүе бирелә. Драмаург Мөхлиса Бубиның төрмәдәге соңгы көннәрен һәм хатирәләр аша гомеренең аерым күренешләрен үзәккә куя. Төрмә авырлыкларын кичергән шәхес кансыз тикшерүчеләрне кызганырга, сатлык дусларын кичерергә көч таба. Тормыш юлында күптөрле золым кичергән Мөхлиса олы гуманист буларак сурәтләнә. Җаны-тәне белән явызлыкка каршы торучы бу образ күңелендә үзен кайгы-хәсрәткә дучар иткән кешеләргә карата нәфрәт-хисе юк. Үзенә нахак гаеп тапкан Вәлиулла Макаевны да кичерергә көч таба. Яңа идеология адаштырган Кобанов, Дәүләтов кебекләрне Аллаһка мөрәҗәгать итеп, аңардан ярдәм сорарга чакыра. Язалауларга карамастан, гомеренең соңгы сәгатенә кадәр Мөхлисә Бубый үзенең рухи көченә таяна, сайлаган юлына тугры кала.«Бетешкән бер карчыкны сындыра алмадык бит, ә?» [Зәйдула, 2014: 152], ди бу турыда Дәүләтов. Бу системаны саклап торучылар буларак сурәтләнгән тикшерүчеләр – Корбанов һәм Галияне– үзләре дә хокуксыз, яңа хөкүмәт корбаннары дип әйтергә мөмкин. Яңа җәмгыять тәрбияләп үстергән, авыл хәзрәте улы Корбанов әхлак кануннарын санга сукмыйча, максатына кыйнап, куркытып, кан коепирешергә өйрәнгән. Корбанов кебекләр исә мыскылланмас өчен, Дәүләтов кулында корал булырга ризалашкан. Ул башкалар теләгенә буйсынучы, заман тәртипләренәҗайлашып, үз шәхесен югалтучы булып күзаллана.мӘмма вакыйгалар үстерелешендә ул Мөхлисә Бубыйның ныклыгы, сабырлыгы каршында җиңелүен, ялгышуын таный, чарасызлыктан, сайлаган юлының ялгыш булуына төшенеп, үз-үенә кул сала. Мөхлиса Буби мәктәбендә белем алган, яңа власть өчен җанын көрәшкән комиссар Галия дә яңа идеология корбаны, адашкан геройларның берсе. Ул үзенең ни өчен төрмәгә ябылуын, халык дошманы буларак гаепләнүен аңламауга кармастан үлемгә алып киткәндә дә: «Яшәсен Сталин!» [Зәйдулла, 2014: 146], - ди. Пьесада Галиянең улы Мэлсның анасыннан халык дошманы дип баш тартуы, дөресрәге кадерле кешеләрен югалтуы, яшьлегеннән мәхрүм ителүе аша ялгызлык мотивы, яңа идеологиянең рәхимсез, аяусыз булуы тергезелә. Шул рәвешле әсәрдә идеология китереп чыгарган фаҗигаләрне яктырту, югалтуларны советчыл иделогиянең кешегә кыйммәт итеп каравы, шуны тәнкыйтьләү килеп керә.Корбанов та, Галия дә, яшәешнең кырыс шартлары нәтиҗәсендә авыр хәлдә калган шәхес фаҗигасен социаль-фәлсәфи планда чагылдыралар. Әлеге образларнәкъ менә катлаулы, каршылыклы булуы белән игътибарны җәлеп итәләр. Язучы моның өчен тарихи-иҗтимагый, сәяси проблематикага мөрәҗәгать итә, геройларын хата-ялгышулар аша уздыра. Тикшерүче Дәүләтов исә Галия белән Корбановтан аермалы буларак эш-гамәле белән алардан аерылып тора, нәрсә өчен хезмәт итүен яхшы белә. Үз макстатына ирешүдә ул кулга алынган кешенең рухын сындыра. Бередә совет урнаштырган кешелексез җәмгыятьнең куркытуга нигезләнгән булуын ассызыклый. Ләкин Мөхлиса бирешми. Көчле шәхес булып кала, бу явызлар алдында башын ими. НКВД төрмәләрендә җәзаланса да, атылуга хөкем ителсә дә халкына һәм диненә хыянәт итми.Ятим калып, ләкин Мөхлисә ханым тарафыннан тәрбияләнгән Наҗия ханым да Дәүләтов тарафыннан төрле газаплауларга дучар ителүгә карамастан, рухи яктан көчле, авырлыклар каршында баш имәс шәхес буларак ачыла. Драмада Мөхлиса ханым күптөрле вакыйгалары шаһиты буларак кына түгел, ә тирән фикерле, татар жанлы, көчле рухлы, зыялы, милләтпәрвәр

шәхе буларак ачыла. Аның рухи ныклыгы Аллаһы Тәгаләне, әти-әнисен, милләтен, тормышны яратуда. «Мин дөньяны үлеп яраттым» [Зәйдулла, 2014: 153], – ди ул. Шуңа да әлеге герой кешелекле кеше булып кала һәм шул сыйфатлары, эш-гамәлләре белән системага каршы чыга, аның гадел булмаган принципларны җимерә. Ул Коръәннән килә торган сабырлык һәм түземлеккә таянып яши.Бу очракта шәхес язмышы – милләт язмышы, гаилә, ил, Ватан язмышы белән тыгыз бәйләнештә булуын күрәбез. Шул рәвешле Р. Зәйдулла заманның милли, әхлакый, сәяси һ.б. проблемаларын күтәреп, милли характерлар тудыра.

Яшәешнең җитди мәсьәләләрен үзәккә куйган пьеса үзара мөнәсәбәттәге ярату һәм нәфрәт, өмет һәм өметсезлек, ышану һәм ышанмау, горурлык һәм курку кебек төшенчәләрне иңләп үтә, аларның асылы турында уйланырга этәрә.


**ӘДӘБИЯТ**

Закирҗанов Ә. Дөньяны ярату // Мәйдан, 2020. № 4. – Б. 127-134.

Зәйдулла Р. Үлеп яратты // Ркаил Зәйдулла. Саташкан сандугач һәм башка пьесалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 146 б.



**Р.Ф. МИРХАЕВ**

Институт языка, литературы и искусства им. Г.Ибрагимова

Академии наук Республики Татарстан, Казань


## О СОЦИАЛЬНО МАРКИРОВАННЫХ СТИЛИСТИЧЕСКИХ СРЕДСТВАХ В ЯЗЫКЕ ТАТАРСКОЙ ПРОСВЕТИТЕЛЬСКОЙ ПРОЗЫ КОНЦА XIX – НАЧАЛА XX ВЕКОВ


**Аннотация.** В статье рассматривается проблема изучения истории татарского литературного языка, ее отдельных синхронных срезов в социолингвистическом аспекте, а именно вопрос социально маркированных языковых единиц. Теоретическая ценность и актуальность исследования определяется социальной обусловленностью развития языка, а также недостаточной разработанностью проблемы в татарском языкознании.

**Abstract.** The article deals with the problem of studying the history of the Tatar literary language, its separate synchronous sections in the sociolinguistic aspect, namely the issue of socially marked language units. The theoretical value and relevance of the research is determined by the social conditionality of language development, as well as the lack of development of the problem in Tatar linguistics.



**Ключевые слова:** социолингвистика, подсистема, язык, татарская просветительская проза, маркированные языковые средства, стилистические средства.

**Keywords:** sociolinguistics, subsystem, language, Tatar educational prose, marked linguistic means, stylistic means.


На современном этапе влияние социальных факторов на развитие языков у научного сообщества не вызывает каких-либо сомнений. Возникаемая при этом дифференциация внутри каждого из них, по мнению специалистов, находит свое выражение «1) в виде социально обусловленных подсистем (таких, как местные диалекты, городские койне, социальные и профессиональные жаргоны, литературный язык) и 2) в виде социально маркированных языковых средств, используемых говорящими, которые принадлежат к тем или иным общественным слоям и группам, в

зависимости от условий коммуникации, от функционально-стилистических характеристик речи» [Современный русский язык…, 2003: 29].

Как показывает обзор работ татарских ученых, отдельные формы существования татарского языка, такие как литературный язык и диалекты, в структурном и функциональном аспектах исследованы досконально. Однако этого нельзя сказать об их социальной природе. Другие же его подсистемы и вовсе оказались вне поля зрения. Что касается изученности второго вида социальной дифференциации языка, являющегося предметом нашего исследования, здесь к примеру можно привести труды И.Б. Башировой [Баширова, 2008], [Баширова, 2012] (относительно литературного языка) и Ф.Ю. Юсупова [Юсупов, 2004] (относительно диалектов), в которых структурные элементы (фонетические, грамматические, лексические) указанных форм существования татарского языка в определенной степени рассматриваются и как социально маркированные единицы. В частности, их употребление в речи соотносится с жизнедеятельностью представителей отдельных слоев и групп общества. В первом случае это духовенство, поэты и писатели, которые в силу своего статуса самой образованной и ученой прослойки в течение многих веков выступали в качестве, если не единственных, то основных носителей письменно-литературных норм и традиций, а во втором – сельские жители, практикующие в своей повседневной жизни диалектный язык.

Учитывая сказанное выше, язык татарской просветительской прозы конца XIX – начала XX веков, который выступает объектом нашего исследования, мы выделяем его как историческую социально обусловленную функциональную подсистему татарского языка. Его формирование было обусловлено деятельностью писателей-просветителей – представителей светской интеллигенции, возникшей в указанный период и объединившей в себе выходцев из различных социальных слоев. Общественно-социальные предпосылки и факторы его появления нами были рассмотрены в предыдущих работах [Мирхаев, 2016: 141-143; Мирхаев, 2017: 127-130].

Социальная обусловленность языка татарской просветительской прозы конца XIX – начала XX веков в свою очередь определяет актуальность исследования уровней и степени отражения социальной дифференциации в элементах разных языковых уровней (фонетических, грамматических, лексических, стилистических). Необходимость рассмотрения языковых средств всех уровней на предмет их социальной обусловленности продиктована тем, что она «<…> проявляется не на всем пространстве языка, а лишь на некоторых его участках» [Современный русский язык…, 2003: 79], а также избирательностью социального влияния относительно их. По мнению ученых, «<…> ему подвержены лишь определенные участки, те или иные группы единиц, а также отдельные единицы, в то время как другие участки и группы единиц остаются относительно устойчивы к социальному воздействию» [Современный русский язык…, 2003: 79].

В рамках данного исследования на материале, извлеченного из произведений татарской просветительской прозы, в частности из романов и повестей М. Акъегета, З. Бигиева, Р. Фахретдина, на предмет социальной маркированности рассматриваются стилистические средства. В этом плане язык указанных авторов от их предшественников отличается употреблением художественных фигур, образованных на основе имен собственных, таких как сравнительных конструкций *Ғаббас меллабу қарйәйә күрә Дамустин улуб*‘ Габбас мела по меркам этого села был своего рода Дамустином’, *Наполеон ғаскәрендән зийадә* ‘больше чем войско Наполена’,метафоры

*Дарвин мәймүнләре*‘обезьяны Дарвина’, гиберболы *Рочильдләр байлыкы моқаwәмәт идә алмаз*‘не хватит богатств Ротшильда’ и т.д.

Конечно такого рода стилистические средства встречаются и на более ранних этапах развития старотатарского письменно-литературного языка. Однако здесь социально маркированным является употребление в художественных целях имен древнегреческих философов, европейских ученых и государственных деятелей, американских миллионеров. В сферу художественного словоупотребления, в которой до этого традиционно доминировали имена восточных писателей и поэтов, они проникли именно посредством творчества писателей-просветителей. Сюда же можно отнести и градации, возникшие на основе использования в одном ряду названий стран мира: *Қырым, Қытай, Иран, Һиндстан, Әфғанстан, Тунис, Мисырда*‘в Крыму, Китае, Иране, Индии, Афганистане, Тунисе, Египте’,*Йапун, Қорә, Сиам, Бразилия әхwәлләрендән* ‘о состоянии дел в Японии, Корее, Сиаме, Бразилии’ и т.д.

Далее социально маркированными по нашему мнению являются также и те стилистические средства, которые возникли на основе семантического переосмысления традиционных для старотатарского письменно-литературного языка слов и употребления их в новых контекстах, в частности публицистического характера. Здесь к примеру можно привести метафорическую конструкцию *наданлық wә һөнәрсезлек кеби олуғ wә ғаддар ике дошманлық әленә*‘в руки таких двух больших и вероломных врагов как невежество и бездеятельность’. В данном случае значения слов *олуғ* и ‘большой’ *ғаддар*‘вероломный’ в силу их употребления в одном ряду с лексическими единицами *наданлық* ‘невежество’ и *һөнәрсезлек*‘бездеятельность, отсутствие профессий, ремесл’, выражающими общественные понятия, обогащаются новыми коннотациями и приобретают функцию эпитетов.

Сюда же можно отнести оксюмороны *ғақылсыз дәлилләр* ‘неразумные доказательства’, *ғақыллы ишәкләр*‘умные ослы’, образные конструкции *җинайәт wә мәхкәмә мәғыйшәтендән* ‘из жизни криминала и правосудия’,*бәхетләре түбән кидеб*‘счастье их покинуло’, *бәхет wә байлық ишеге*‘двери счастья и богатства’, эпитеты *қара* ‘черный’, *үткен* ‘острый’, *йиңел* ‘легкий’, *ғали* ‘высокий, возвышенный’, зарегистрированные в составае таких словосочетаний как *қара бәхетемең очқыны*‘искра моего черного счастья’, *үткен фикерле* ‘остроумный’, *йиңел фикерле*‘легкомысленный’, *ғали фикерле* ‘с возвышенными идеями’ и т.д.

Таким образом, в языке татарской просветительской прозы конца XIX – начала XX веков в качестве социально маркированных стилистических средств выделяются новые художественные фигуры, привнесенные самими авторами, а также переосмысленные ими в семантическом плане в силу необходимости употребления в новых контестах традиционные для старотатарского языка единицы.

## ЛИТЕРАТУРА

Бәширова И.Б. XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар әдәби теле: жанр-стильләре, аерым грамматик категорияләрдә норма һәм вариантлылык. Казан: ИЯЛИ, 2008. – 340 б.

Бәширова И.Б. Татар әдәби теле тарихы. Гомумтеоретик мәсьәләләр. Казан: ИЯЛИ, 2012. – 255 б.

Мирхаев Р.Ф. Языковая ситуация в татарском обществе конца XIX – начала XX века // Филологические науки. Вопросы теории и практики, 2016. № 12. Ч. 3. – С. 141-143.

Мирхаев Р.Ф. Старотатарский литературный язык и социальная структура татарского общества в конце XIX – начале XX вв. // Гуманитарные науки и образование, 2017. – № 1 (29) (январь-март). – С. 127-130.

Современный русский язык: Социальная и функциональная дифференциация / А. В. Занадворова, Е. В. Какорина, М. В. Китайгородская и др./ Отв. ред. Л. П. Крысин. – М.: Языки славян.культуры, 2003. – 565 с.

Юсупов Ф.Ю. Морфология татарского диалектного языка: категории глагола. Казань: Фэн, 2004. – 592 с.

**Г.Р. МӨГЪТӘСИМОВА**
Казан федераль университеты, Казан

## РУС ТЕЛЕНДӘГЕ ТӨС АТАМАЛАРЫН ТАТАР ТЕЛЕНӘ ТӘРҖЕМӘ ИТКӘНДӘ БАРЛЫККА КИЛГӘН ТРАНСФОРМАЦИЯЛӘР

**Г.Р. МУГТАСИМОВА**
Казанский федеральный университет, Казань

## ТРАНСФОРМАЦИИ ПРИ ПЕРЕВОДЕ РУССКИХ КОЛОРАТИВОВ НА ТАТАРСКИЙ ЯЗЫК

**Аннотация.** В статье рассматриваются проблемы перевода колоративной лексики. Приводится подробный переводческий анализ оригинальных примеров. Делается вывод об использовании переводческие преобразования, применяющиеся для адекватной передачи семантики русских колоративов при переводе на татарский язык.

**Abstract.** The article deals with the problems of translation of colorative vocabulary. A detailed translation analysis of the original examples is provided. The conclusion is made about the use of translation transformations that are used to adequately convey the semantics of Russian colorants when translating into the Tatar language.

**Ключевые слова:** колоратив, семантика колоратива, переводческие трансформации.

**Keywords:** colorative, colorative semantics, translation transformations.

Телара лексик тәңгәллекләр турындагы мәсьәлә тәрҗемә белемендә мөһим урын алып тора. Телнең лексик берәмлекләре һәм тәрҗемә арасындагы телара тәңгәллекләрне классификацияләү мәсьәләләре Я.И. Рецкер, Л.С. Бархударов, В.С. Виноградов һәм башка галимнәрнең хезмәтләрендә билгеләнгән. Без З.О. Давидян классификациясен нигез итеп алабыз.

Тәрҗемә белеменең заманча парадигмасы күзлегеннән караганда, чыганак текстка коммуникатив бердәй кыйммәтле, укучыда чыганак текст кебек үк фикерләү эшчәнлеге уята торган тәрҗемә тексты адекват дип танылa [Богин, 1989: 6]. Әдәби, бигрәк тә ритмик һәм мелодик үзенчәлекле шигъри текстларны адекват тәрҗемә итүгә ирешү өчен, чыганак берәмлекләрендә төрле трансформацияләр булуы котылгысыз.

Тәрҗемә трансформацияләренә түбәндәгеләрне кертеп карыйлар: а) төшереп калдыру (семантик яктан артык булган сүзләр тәрҗемә ителми); б) алмаштыру; в) тәрҗемә туры килмәү (хәрефкә-хәреф тәрҗемә иткәндә барлыкка килә, ул калька рәвешендә була).

Тәрҗемә трансформацияләренең чынбарлыкта реальләшүен тәфсилләбрәк рус әдәбияты классиклары Н.Некрасов, С.Есенин һәм М.Лермонтов әсәрләренең татарчага тәрҗемәләренә таянып күзәтәчәкбез.

Шигъри әсәрләрдәге төс атамаларын татарчага тәрҗемә иткәндә, атама тәрҗемә ителмичә төшеп калырга яки тәрҗемәгә өстәлергә мөмкин. Мәсәлән, С.А. Есенинның «Анна Снегина» әсәрендә мондый юллар бар: *Свобода взметнулась неистово. // И в* ***розово-смрадном*** *огне....*Г. Рәхим болай дип тәрҗемә иткән: *Тыелгысыз ирек иде анда //* ***Алсу-соры*** *утлар эчендә...*Розово-смрадный – катлаулы сыйфат. Төс тасвирламасы ис тасвирламасы белән бергә үрелеп бирелгән. Алсу төстәге ут смрадный (сасы исле, әшәке исле) лексемасы аша тискәре характеристикага ия була. Барлык дүртьюллык экспрессия белән сугарылган һәм геройның ачуын, аның тискәре хис-кичерешләрен чагылдыра. Тәрҗемәче исә утны алсу итеп кенә тәрҗемә итеп калмый, алсу төскә соры сыйфатын да кушып җибәрә дә утлар алсу-соры төскә әйләнә. Шулай итеп, С. Есенин әсәрендәге смрадный (сасы исле, әшәке исле) татарчага тәрҗемәдә искә алынмый, тәрҗемәче аны төшереп калдыра. Тәрҗемәдә чыганакның экспрессив үзенчәлеге югала.

С.А. Есенинның «В Хороссане есть такие двери» шигырендәге *В Хороссане есть такие двери, // Где обсыпан* ***розами*** *порог. // Там живет задумчивая пери. // В Хороссане есть такие двери, // Но открыть те двери я не мог.*юллары Зөлфәт тәрҗемәсендә болай яңгырый: *Шундый ишекләр бар бу Һарсанда, //* ***Кызыл гөлгә*** *чумган юллары. // Уйчан әкият кызы яши анда. // Шундый ишекләр бар бу Һарсанда, // Аларны тик ачып булмады.* Роза чәчәге русча-татарча сүзлектә гөлчәчәк дип бирелә [Русско-татарский словарь 1984: 544]. Күргәнегезчә, Зөлфәт бу чәчәкне кызыл гөл дип тәрҗемә иткән. Гәрчә, роза төрле төстә булса да, тәрҗемәче аны кызыл итеп кенә күрә. Яңа төс атамалары өстәү текстның төсләр палитрасында уңышсыз чагылыш табарга мөмкин.

Иң киң таралган тәрҗемә трансформацияләренең тагын бер үрнәге – сүз төркемнәрен алыштыру. Бу очракта бер сүз төркемен башка бер яки берничә сүз төркеме белән алмаштырыла. Тәрҗемә процессында сүз формалары, сүз төркемнәре, җөмлә кисәкләре дә алмашырга мөмкин. Шунлыктан, грамматик һәм лексик алмаштыруларны аерып карарга кирәк. Мәсәлән, М.Ю. Лермонтовның «Парус» шигыренең татарчага тәрҗемәсендә кызыклы шундый очракны күзәтәбез: *Кояш сибә матур* ***алтын*** *нур, // Ә түбәндә* ***зәңгәр*** *дулкыннар. // Ул тынгысыз, давыл тели ул, // Гүя тынычлык бар давылда!* Татарчага Ә. Ерикәй 1941 елда тәрҗемә иткән. Чыганак текст болай яңгырый: *Под ним струя светлей* ***лазури****, // Над ним луч солнца* ***золотой****... // А он, мятежный, просит бури, // Как будто в бурях есть покой!* Бу мисалда да без тәрҗемәченең грамматик алмаштыруга мөрәҗәгать иткәнен күрәбез. «Лазурь» берәмлеге рус телендә морфологик яктан исем сүз төркеменә карый. Тәрҗемәләрдә ул сыйфат белән алмаштырылган. Русча-татарча сүзлектә «лазурь» берәмлегенә мондый тәрҗемә бирелгән: «лазурь – 1. (светло-синий цвет) аксыл-зәңгәр төс, зәңгәрсу төс 2. ( синева) зәңгәрлек 3. ( краска) лазурь — зәңгәрсу [төстәге] буяу» [Русско-татарский словарь 1984: 242]. Безнеңчә, М.Ю. Лермонтовның «Парус» шигырендә «лазурь» сүзе беренче мәгънәсендә кулланылган. Әлеге сүзне тәрҗемәче Әхмәт Ерикәй 1934 елгы тәрҗемәдә «иң якты зәңгәр су» дип тәрҗемә кылган: Asta a **in jaqtь zəngər su**, // Өste – qojaş, **ytken çiz nurlar**, // Ə ul anda davьl teli ul, // Davьllarda gyjə tьnlьq bar!

Шушы ук өзектә икенче бер төс атамасы да бар. «Золотой» сүзе төп мәгънәсе буенча предметның физик, химик чималын аңлатса да, еш кына төс атамасы буларак та кулланыла. Биредә без нәкъ менә шуны күзәтәбез. Яңалиф вариантында тәрҗемәче

шигырь тукымасына яңа сурәт, образ кертеп, күтелмәгәндә җиз (медный) сүзе кулланган. Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә әлеге сүзгә мондый аңлатма биргәннәр: «җиз – 1. Бакырга төрле металлар (цинк, кургаш, аккургаш, тимер һ.б.) кушып коелган эретмә. 2. с. мәгъ. 1) Шундый эретмәдән эшләнгән. 2) Шул эретмә төсендәге, сары, җирән» [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге 2005: 776]. Шулай итеп, җизнең төсен искә төшергәндә, бик уңышсыз вариант булып күзаллана. М.Ю. Лермонтов шигыренең карала торган строфасындагы дәһшәтле күренешне аерым бер күренешләрне (алтын кояш нурлары, сыек зәңгәр төстәге дулкыннар давыл көтүгә каршы куела) капма-каршы куеп сурәтләү алымы тасвирны үтә киеренке итә, шигырьнең тәэсир көчен арттыра. Җиз төсе монда бөтенләй урынсыз тоела.

Гомумән, М.Ю. Лермонтов иҗаты төсләргә гаять бай. Шагыйрь төс атамаларын бик уңышлы куллана, алар сурәт тәэсирен көчәйтү, сурәтләү катламыннан тыш символик, психологик, хисси катламнарга да үтеп керәләр.

Әйтергә кирәк, төс атамасын тәрҗемәдә тасвирлана торган реалиягә башка бәя бирә торган лексема белән алмаштырырга яки аның мәгънәсен компенсацияләмичә калдырырга мөмкин. Мондый хәл ике мәдәният вәкилләренең аңында төсле образлар белән беркетелгән тотрыклы ассоциацияләргә ия булган реалияләр очрагында күзәтелә. Мәсәлән, бу Н.А Некрасовның «Выбор» шигырен татарча биргәндә, ачык чагылыш таба: *Только красивее дам я наряд: // В белом венке голова засияет // Завтра, чуть* ***красное*** *солнце взойдет.* Татар теленә Ә.Ерикәй тәрҗемә иткән: *Иң матур киемне кызганмам: // Кидерермен ак таҗ, нур сибәр ул // Иртәгә,* ***көн балкып туганда.***Күргәнегезчә, “красное солнце” сүзтезмәсе тәрҗемәдә, гомумән, “төзсез” кала, ягъни тәрҗемәче аны “көн балкып туганда” дип процесс алды алмаштыру ысулы белән тәрҗемә итә. Димәк, укучыда тәрҗемә белән танышканда, шулай ук күзаллау тудырылырга тиеш: көн туганда, барлык җиһан кызыл төскә керә. Безнеңчә, бу очракта тәрҗемәченең букваль, ягъни калькалаштырып тәрҗемә итмәве дөрес, чөнки “кызыл таң” – татар халкы өчен үзгә күренеш. Татарларда таң, гадәттә, Муса Җәлилдәге кебек алсу итеп сурәтләнә.

Тикшеренүләрдән күренгәнчә, тәрҗемә әсәрләрендә кайбер төгәлсезлекләр дә бар. Тик бу кимчелекләр чыганагын бозарлык кимчелекләр түгел, ә рус теленең кайбер специфик үзенчәлекләрен саф татарча биреп булмау һәм татар телендәге төс атамаларының саны рус телендәгегә караганда күпкә ким булуга кайтып кала.

Һәрбер телнең төсләрне сайлауда үз юлы булган кебек, шагыйрьләрнең дә үз юлы, үзенең рухына, психологиясенә, халәтенә туры китереп, төсләрне белдергән сыйфатларны файдалану ысулы бар. Әлеге катлаулы процессларны аңлау, төшенү иҗат кешеләренең психологиясен аңларга, шуның белән милләтебезнең лингвомәдәни кыйммәтләрен ачыкларга, дөнья сурәтен тасвирларга ярдәм итәчәк.

## ӘДӘБИЯТ

Богин Г.И. Критика перевода в свете современных представлений о рефлексии // Перевод как процесс и как результат: язык, культура, психология: Сб. научн. тр. Калинин: Изд-во КГУ, 1989. – С. 6-14.

Есенин С. Анна Снегина: поэма / Г.Рәхим тәрҗ. Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 63 б.

Есенин С. “Шундый ишекләр бар бу Һарсанда...”; “Зәгъфран төсе сеңгән кичке нурга...” / Зөлфәт тәрҗ. // Казан утлары, 1985. – № 10. – Б.141-142.

Лермонтов М. Ю. Сочинения: В 2-х томах. М., 1992. – Т. 2. – 488 с.

Некрасов Н.А. Поэмалар. Казан, Татгосиздат, 1953. – 63 б.
Русско-татарский словарь. Казань, 1984. – 734 с.
Татар теленең аңлатмалы сүзлеге / Баш редактор проф.Ф.Ә.Ганиев. Казан: “Матбугат йорты” нәшр., 2005. – 848 б.

**Г.Н. МӨХӘРЛӘМОВА**
Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясе
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Казан

## 1920-1930 ЕЛЛАР ТАТАР ПРОЗАСЫНДА ТӨН ХРОНОТОБЫ БИРЕЛЕШЕ

**Г.Н. МУХАРЛЯМОВА**
Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова
Академии наук Республики Татарстан, Казань

## ХРОНОТОП НОЧИ В ПРОИЗВЕДЕНИЯХ ТАТАРСКОЙ ПРОЗЫ 1920-1930-х гг.

**Аннотация.** В данной статье рассматривается хронотоп ночи в татарских прозаических произведениях 20-30-х годов XX века. Хронотопический образ ночи, приобретающий символическое значение дает возможность охарактеризовать историческое время, изображенное в произведениях данного периода.

**Abstract.** This article examines the chronotope of the night in Tatar prose works of the 20-30s of the XX century. The chronotopic image of the night, which acquires a symbolic meaning, makes it possible to characterize the historical time depicted in the works of this period.

**Ключевые слова:** хронотоп, историческое время, пространство, хронотоп ночи, бинарная оппозиция.

**Keywords:** chronotope, historical time, space, chronotope of night, binary opposition.

XX гасырның 20-30 нчы еллары татар прозасында тасвирланган тарих вакыт тормышта туктаусыз хәрәкәтне, аның үзгәрүен һәм яңаруын белдерүче «кояш баю – төн – таң – көн» циклик вакыт та билгеләп тора. 1920-1930 еллар татар проза әсәрләрен күзәтү барышында тәүлекнең күрсәтелгән дүрт вакыты да еш кына символик мәгънәләргә ия булуы ачыклана.

Әлеге чор әсәрләрендә сурәтләнгән төп вакыйгалар, характерларына карап, башлыча тәүлекнең төн вакытында туры килә. Төн образы XX гасыр башы татар әдәбиятында күпчелек очракта ирреаль мифологик пространство функциясен үтәсә, XX гасырның 20-30 нчы еллар прозасында ул, киресенчә, аерым иҗтимагый мәсьәләләр хәл итә торган социальләшкән пространствоны тәгаенли. Биредә төн – таң, туачак көн алдыннан революция белән бәйле яңа планнар кору, геройларның очрашулары, төрле мәсьәләләрне хәл итү вакыты буларак күзаллана. Шул рәвешле, әлеге чорга караган әсәрләрдә төн хронотобы билгеләнә.

Билгеле булганча, әдәби хронотоп, иң элек, сюжет мәгънәсенә ия, автор тарафыннан сурәтләнгән вакыйгаларның төп оештыру үзәге булып тора. Хронотоп эчендә сюжет вакыйгалары конкретлаша, вакыт белән урын исә хисси һәм күрсәтмәле характерга ия була. Моннан тыш «әдәби урын һәм вакыт бирелеше дә билгеле бер эпохадагы көнкүрештә, диндә, фәлсәфәдә, фәндә кабул ителгән урын-вакыт турындагы күзаллауга бәйле була» [Әминева, 2005: 52].

Әлеге чор әсәрләрендә төн хронотобы әдәби геройлар яшәгән пространствоны билгели. Геройларның күбесенә яшерен эшләрен башкаларга белдермәс өчен конспиратив рәвештә төнлә башкарырга туры килә. Боларны эшләргә аларга төнге караңгылык булышлык итә. Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр» романында да җыелышлар, план корулар башлыча төнлә уздырыла. Шәһәр буйлап та геройлар төнлә хәрәкәт итә: Булат «Гәүһәрне капка төбенә чаклы озатып, кулын кысты, аның караңгы төндә, чат башында югалганын карап калды да тиз-тиз бүлмәсенә керде» [Ибраһимов, 2018: 28], яки «Шул кала читендә, соңгы, салкын көзнең караңгы төнендә, пычрак урамнардан ялгыз уйлана-уйлана, каенлы йортка таба кызуланып атлады» [Ибраһимов, 2018: 54]. Ләкин геройлар, күптән ияләшкән булып, төнге урам пространствосында чагыштырмача яхшы ориентлашырга да өйрәнәнеп өлгерәләр: «Төн караңгы. Шулай да күп тапталган таныш урамнардан бару артык кыен булмады» [Ибраһимов, 2018: 73].

К. Нәҗминең «Язгы җилләр» әсәре геройларына да күбесенчә төнлә йөрергә туры килә. Әсәрдән Хәсән Айвазов кешеләр арасында кичке сәгатьләрдә генә күренүен беләбез. Геройлар төнлә, кешеләр инде йокларга ятып беткәч, «бистә урамында буран улап», «ниндидер суккан тавышлар ишетелгән, караңгы вакытта» очрашырга тырышалар.

Әсәрләрдән геройларны кулга алулар, сөргенгә җибәрүләр яки аларның аннан кайтулары шулай ук тәүлекнең төн вакытына туры килүен күрәбез. Мәсәлән, «Язгы җилләр»дә Адмиралтейство бистәсе кичке караңгылык белән әйләндереп алынган вакытта пристань ягына конвой астында бер төркем арестантларны Себергә озату күренеше бирелә. Шул ук романда Мостафаның әтисе – Сәүбәннең дә каторгадан «караңгы көзге төндә» кайтып төшүе турында әйтелә.

Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр» романында төнлә тагы бик күп яңа тоткыннар, яңа материаллар алынуы турында искәртелә. Качкын Хәбип Мансуровны да төнлә тоталар һәм төнге сәгать бердә жандарм агентлары аны бишенче полиция участогына алып килә. Романның тагын бер төп герое – Булат Зарифны көзге төндә винтовкалар тоткан кешеләр, өйне астан өскә әйләндереп атып, үзләре белән алып китәләр. К. Нәҗминең «Язгы җилләр» романы герое Мостафа фатирында прокламация табу нияте белән, тентүне шулай ук төнлә үткәрәләр. Күргәнебезчә, төн тентүләр үткәрү өчен дә уңайлы вакыт була.

Төн вакытының характерын әдәби геройлар пространствосы да ачыклый ала. Мәсәлән, төрмәдәге төн «зинданда гына була торган авыр, озын, ел буенча сузылгандай озын кара төн» [Ибраһимов, 2018: 387] булуы белән аерылып тора. «Зиндан тыштан тын, тыныч, авыр, басынкы караңгылык эчендә чолганып утыра» [Ибраһимов, 2018: 393], шулай да төн булуына карамастан «тоткыннар йоклый алмыйлар», нидер сизгәндәй көтәләр. Алар бу юлы ялгышмый – шушы «төннең тын караңгылыгында» Гәрәй Солтановны асып үтерәләр.

Төн шулай ук иректә булган геройлар өчен дә күп очракта тынгысыз була. «Безнең көннәр» герое Баязит, үзенең хәле турында уйланып, тынычсыз төн үткәрә. Иртән, бик озак уйланып ятканнан соң, үзе өчен бик мөһим һәм шул ук вакытта коточкыч бер карар кабул итә – авылга кайтып атасын үтерергә була. Шулай итеп, төн – катлаулы карарлар кабул итү вакыты буларак та билгеләнә.

Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романында күп вакыйгалар шулай ук төнлә бара. Роман үзе үк төнге вакыйгаларны тасвирлаудан башлана: «Майның караңгы төне иде». Төннең мәңгелек юлдашы – караңгылык. Монда исә караңгы төн, өстәвенә «кичтән башланган яңгыр туктамады, каты җил иде, дөньяны ялтыратып яшен яшьнәде,

тау-таш җимерелгәндәй гөрелдәтеп, күк күкрәп үтте» [Ибраһимов, 2018: 168]. Автор, төнне шул рәвешле тасвирлап, геройлары белән булган хәлләрнең драматизмын тагын да көчәйтә төшә кебек. Әйтергә кирәк, бу әсәрдә төн хронотобы берничә мәгънәви функция башкара. Беренчедән, романтик хис белән сугарылып геройларның очрашу хронотобын билгели. Мәсәлән, төн төп геройлар булган Фәхри белән Гайшәгә бер-берсенә мәхәббәтләрен аңлату мөмкинлеген бирә, аларны яңа өметләр белән канатландыра. Нәкъ шул төнне Гайшә туган йортыннан сөйгәне янына качып китәргә карар кыла. Димәк, бу очракта төн хронотобы тупса хронотобына туры килеп, геройларның тормышында борылыш, үзгәреш буларак аңлашыла.

Романның тагын бер героинясы Нәгыймәгә төн, киресенчә, тынычлану китерми. Ул өеннән төнлә, ирен төрмәдән чыгару нияте белән аның иптәшләрен табарга дип чыгып китә: «Көн кич иде. Кара-соры болытлар, менә хәзер коеп яварга әзерләгән кебек, кала өстенә капланганнар иде. Хатын боларны шәйләмәде. Ашыгып барышында очраган әйберләргә тиргәнә-тиргәнә, үз юлы белән чапты» [Ибраһимов, 2018: 214]. Әсәрдә Нәгыймәнең юлы күптөрле киртәләрдән гыйбарәт булуга карамастан, иренә ярдәм итү теләге көчле булганга, юлында очраган бер генә каршылык та аны туктата алмавы күрсәтелә

Төн, үлем символы буларак, тәүлекнең бу вакытында үтерүләр, һөҗүм итүләр, җәзалаулар күп башкарылуын күрсәтеп тора. Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романында Фәхрине, Вәли бай Хәсәнов боерыгы буенча, төнлә үтерәләр. Вәли Хәсәнов үзе дә җәзасын тәүлекнең караңгы вакытында ала, аны төнлә урманда атып үтерәләр. Г. Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр» геройлары Гыйлаҗи һәм тагын берничә комсомол егет шулай ук кояш баер алдыннан, караңгы төшкәндә, җәзалап үтерелә. Шулай итеп, әсәрләрдә төн күп очракта геройларга үлем, яки бәхетсезлек китерүче куркыныч явызлык белән тәңгәлләштерелә.

1920-1930 еллар татар прозасында сурәтләнгән тарихи вакыт һәм урын Көн/Төн бинар оппозициясе белән тәгаенләнә. Төн геройларларның үткәне яки караңгы хәзергесе, көн якты киләчәге буларак күзаллана. Булатның Гәрәй Солтановка язган хатында: «Караңгы авыр төннең иң авыр сәгатьләре үтә инде 〈...〉, бу караңгы төннәр мәңге булмас, ышан, озакламас, безнең көннәр яңадан килерләр!» [Ибраһимов, 2018: 392], дип әйтелә. Шул рәвешле, Көн/Төн оппозициясе бу очракта Үткән/Киләчәк оппозициясе белән кисешә.

Көн/Төн бинар оппозициясе илнең хәзерге вакытындагы хәлен ачыклый. Геройлар яңа тормыш символы булган яңа көннең җитүенә әле тәгаен ышанып та бетмиләр.

Шул рәвешле, көн – ил тормышындагы якты, төн – караңгы полоса буларак аңлашыла. Бу чорда язылган әсәрләрдә геройлар авыр, караңгы, куркыныч төннән соң «кызарып таң аткан»ны көтеп яшиләр.

## ӘДӘБИЯТ

Әминева В.Р. Әдәби әсәрдә хронотопны билгеләү // Әдәби әсәргә анализ ясау: Урта гомуми белем бирү мәктәбе укучылары, укытучылар, педагогика колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма. Казан: Мәгариф, 2005. – Б. 52-71.

Ибраһимов Г. Безнең көннәр // Әсәрләр: 15 томда. 5 т.: роман. – Академик басма. Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. – 423 б.

Ибраһимов Г. Кызыл чәчәкләр // Әсәрләр: 15 томда. 3 т.: хикәя повестьлар, роман, драма. – Академик басма. Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. – Б. 9-102.

Ибраһимов Г. Тирән тамырлар // Әсәрләр: 15 томда. 3 т.: хикәя, повестьлар, роман, драма – Академик басма. Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. – Б. 168-388.
Нәҗми К. Язгы җилләр. Казан: Татгосиздат, 1949. – 412 б.

**Г.Н. МӨХӘРЛӘМОВА**
Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясе
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Казан

## ТУГАН ТЕЛ ҺӘМ ӘДӘБИЯТНЫ ДИСТАНЦИОН УКЫТУ ШАРТЛАРЫНДА УКУЧЫЛАРДА ТАНЫП БЕЛҮ УНИВЕРСАЛЬ УКУ ГАМӘЛЛӘРЕН ФОРМАЛАШТЫРУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

**Г.Н. МУХАРЛЯМОВА**
Институт языка, литературы и искуства им. Г. Ибрагимова
Академии наук Республики Татарстан, Казань

## ОСОБЕННОСТИ ФОРМИРОВАНИЯ У УЧАЩИХСЯ ПОЗНАВАТЕЛЬНЫХ УНИВЕРСАЛЬНЫХ УЧЕБНЫХ ДЕЙСТВИЙ НА УРОКАХ РОДНОГО ЯЗЫКА И ЛИТЕРАТУРЫ В УСЛОВИЯХ ДИСТАНЦИОННОГО ОБУЧЕНИЯ

**Аннотация.** В статье рассматриваются особенности формирования познавательных учебных действий на уроках родного языка и литературы в условиях дистанционного обучения. Получившее в последнее время широкое распространение дистанционное обучение способствует формированию у учащихся универсальных учебных действий, связанных с самостоятельной деятельностью. Познавательные универсальные учебные действия формируются на уроках родного языка и литературы при самостоятельном изучении, систематизации, обобщении учебного материала.

**Annotation.** The article deals with the features of forming cognitive educational actions in the lessons of the native language and literature in the conditions of distance learning. Distance learning, which has recently become widespread, contributes to the formation of students ' universal learning activities related to independent activities. Cognitive universal educational actions are formed at the lessons of the native language and literature with independent study, systematization, generalization of educational material.

**Ключевые слова:** дистанционное обучение, Федеральные государственные образовательные стандарты, познавательные учебные действия, родной язык, родная литература.

**Keywords:** distance learning, Federal state educational standards, cognitive learning activities, independent activity, native language, native literature.

Бүген мәктәптә укытуның төп максатларының берсе – алдагы тормышында һәм эшчәнлегендә белем алырга әзер булган, инициативалы, мөстәкыйль, үз позициясе формалашкан шәхес тәрбияләү. Әлеге фикер Федераль дәүләт белем бирү стандартлары белән билгеләнеп, уку-укыту барышында шуңа бәйле шартларны тудыру төп мәсьәлә булып санала. Билгеле, моңа ирешүдә төрле заманча белем бирүнең төрле технологияләрен, ысул-алымнарын, укыту формаларын исәпкә алып эшләү алгы планга чыга. Үз чиратында укучы алдына да аерым бер таләпләр куела. Шуларның берсе – мөстәкыйль укый, эшли белү. Әлеге гамәлне формалаштыру юнәлешендә башка формалар белән беррәттән дистанцион укыту формасы ярдәмгә килә.

Дистанцион, яки онлайн уку формасы моңарчы да билгеле бер категория укучыларны (сәламәтлек мөмкинлекләре чикле булган балаларны, сәләтле балаларны, гаилә белеме алучы балаларны) укыту, өстәмә белем алу мәйданында дәрестән тыш эшләү өчен кулай булып саналып, үткән уку елының соңгы айларында, күпчелек уку йортларында пандемия белән бәйле рәвештә билгеле бер вакытка төп укыту формасына әйләнде. Әйтергә кирәк, нәкъ шул вакытта дистанционуку-укытуның уңай һәм тискәре яклары да күренде: моңа билгеле бер күләмдә техник сәбәпләр дә, эшләү процессын тиешенчә оештырмау, дистанцион укытуның таләпләрен белмәү, укучыларның бу шартларда уку максатларын аңлап бетермәведә һ.б. да керә. Шулай да уңай яклары да бар, әлеге форманы киң масштабта куллану Федераль дәүләт белем бирү стандартлары билгеләгән таләпләрнең берсе – универсаль уку гамәлләрен формалаштыру мөмкинлеге һәм зарурлыгын ачык күрсәтте.

Укытучы дәресне планлаштыра башлаганда ук укучыда кайсы УУГларны формалаштыру дөрес һәм отышлы булуын уйлана башлый. Эшләү барышындааны универсаль уку гамәлләрен формалаштыруда нинди үзенчәлекләр күзәтелә, кайсы якларга аерым игътибар бирү таләп ителә кебек сораулар да борчый.

Билгеле булганча, универсаль уку гамәлләре яңа социаль тәҗрибәне аңлы һәм актив үзләштерү юлы белән укучының үз-үзен үстерү һәм камилләштерүен, аның әлеге процессны оештыру сәләтен дә исәпкә алып, яңа белемнәрне һәм күнекмәләрне мөстәкыйль үзләштерүен тәэмин итүче гамәлләр җыелмасы буларак аңлашыла. Иң беренче чиратта, алар укучыларга уку эшчәнлеген мөстәкыйль рәвештә гамәлгә ашыру, уку максатларын кую, аларга ирешүдә кирәкле чаралар һәм алымнарны куллану, уку эшчәнлеген һәм аның нәтиҗәләрен күзәтү, контрольдә тоту һәм бәяләү мөмкинлеген бирә.

Әдәбият дәресләрендә метапредмет нәтиҗәләргә ирешү юнәлешендә танып белү универсаль уку гамәлләренең әһәмияте бик зур. Әлеге гамәлләр әйләнә-тирә дөньяны танып-белү юлларын, эзләнү барышын мөстәкыйль рәвештә төзү, алынган мәгълүматны эшкәртү, системалаштыру, гомумиләштерү һәм куллану буенча тикшеренүләр системасы буларак аңлашыла. Алар үз эчендә гомумуку, логик гамәлләр һәм проблема куеп, аны хәл итү кебек гамәлләргә төркемләнә.

Гомумуку гамәлләренә танып белү максатын мөстәкыйль рәвештә билгеләү һәм тәгъбир итү; кирәкле информацияне эзләү һәм билгеләү; мәгълүмати эзләнү ысулларын куллану; белемне структуралаштыру; фикерләрне аңлы һәм ирекле рәвештә телдән һәм язма формада төзү; конкрет шартлардан чыгып мәсьәләләрне хәл итүнең нәтиҗәле юлларын билгеләү; төп максаттан чыгып уку максатларына төшенү һәм уку төрен сайлау буларак аңлап уку; төрле жанрдагы текстлардан кирәкле информацияне аерып чыгару керә.

Логик уку гамәлләре билгеләрне аерып чыгару максаты белән объектларны анализлау; синтезлау – өлешләрдән бөтен төзү; объектларны чагыштыру, классификацияләү критерийларын сайлау;төшенчә итеп чыгару; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен билгеләү; фикер йөртүнең логик чылбырын төзү; дәлилләү; гипотезаларны чыгару һәм аларны нигезләү гамәлләрен билгели.

Проблеманы кую һәм хәл итү үз эченә проблеманы тәгъбир итү, иҗади һәм эзләнү характерындагы проблемаларны хәл итү чараларын мөстәкыйль башкару кебек гамәлләрне ала.

Шулай итеп танып белү универсаль уку гамәлләрен формалаштыру юнәлешендә укучы эзләнүнең барышын мөстәкыйль рәвештә төзүгә ирешә ала, үзләштерелгән

белемнәрне эшкәртү, системалаштыру, гомумиләштерү һәм белем алу процессында куллануны тормышка ашыра. Иң әһәмиятлесе – укучының танып белү максатын мөстәкыйль рәвештә билгели һәм тәгъбир итә алуы. Укучы кирәкле мәгълүматны төрле чыганаклардан таба, билгели, бу вакытта аңа компьютер ярдәмгә килә ала. Танып белү уку гамәлләре мәсьәләне чишүнең нәтиҗәле юлларын табарга өйрәнүдә ярдәм итә. Укучы шулай ук проблеманы куя, аны тәгъбир итә, иҗади һәм эзләнү характерындагы проблемаларны чишүдә эшчәнлек алгоритмнарын мөстәкыйль рәвештә төзергә өйрәнә. Дистанцион уку вакытында боларны башлыча укучыга нәкъ менә үзенә мөстәкыйль рәвештә башкарырга туры килә.

Тел-әдәбият дәресләрендә логик универсаль уку гамәлләрен формалаштыру да әһәмиятле санала. Әдәби әсәрне мөстәкыйль анализлаган вакытта укучы сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен урнаштыру күнекмәсенә ия була. Билгеләрне аерып чыгару максаты белән объектларны анализлау, ягъни әсәр, вакыйга, образ һ.б. шундый объектларга характеристика бирү гамәленә дә өйрәнә. Туган тел дәресләрендә кагыйдәне чыгару барышында синтезлый белү, ягъни өлештән бөтен төзү гамәлен формалаштыру алгы планга чыга. Әдәбият дәресләрендә эчтәлеге буенча капма-каршы ике гамәл булган анализлау һәм синтезлау бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә торып, һәрвакытта диярлек бергә башкарыла. Бу гамәлләрне формалаштыру максаты белән укучылардан әсәрдә сөйләнелгән предметның (детальнең) яки әдәби геройның билгеләрен күрсәткән таблица төзетергә мөмкин. Әлеге таблицаны дистанцион уку шартларында укучы әсәргә нигезләнеп мөстәкыйль рәвештә тутыра. Чагыштыру гамәле ике әдәби геройны, вакыйганы, ситуацияне һ.б. чагыштырып өйрәнү рәвешен ала. Шулай ук таблицаны баганалап, әйтик, һәр баганада аерым герой билгеләрен күрсәтү рәвешендә эшләтеп була. Укучы бу вакытта объектларны анализлау, аларның төп һәм икенчел билгеләрен гомумиләштерү, нәтиҗәне тәгъбир итү, мәсьәләне аңлап хәл итү алгоритмын эзлекле рәвештә мөстәкыйль төзеп эшли.

Шулай ук тел-әдәбият дәресләрендә уку материалын өйрәнүдә фикерләүнең логик чылбырын төзү дә әһәмиятле санала. Әйтик, түбән сыйныфларда әсәр буенча рәсем-иллюстрацияләрне, өлкәнрәк сыйныфларда вакыйгаларны тиешле эзлеклелектә урнаштыру була ала. Тагын бер мөһим гамәл – укучы үз фикерләрен аңлап дәлилләргә өйрәнүе.

Онлайн укыганда, текстны укуның максатына төшенү буларак аңлап уку да тел-әдәбият дәресләрендә аерым урын алып тора. Шул юнәлештә тагын бер гамәл – уку төрен мөстәкыйль рәвештә сайлап ала белү формалаштырыла. Тексттан кирәкле мәгълүматны табып алып күрсәтү гамәленә, укучы теге яки бу фикерне дәлилләү өчен әсәр текстыннан мисаллар китерү аша өйрәнә.

Дистанцион уку-укыту вакытында укучыга үзендә танып белү универсаль уку гамәлләрен мөстәкыйль рәвештә формалаштыру мөмкинлеге бирелә. Әлбәттә, укучыга әлеге эш җиңел бирелмәячәк, бигрәк тә түбән сыйныфларда. Әлеге гамәлләр теге яки бу дәрәҗәдә укучыларда формалаштырылган булып, алга таба мөстәкыйль эшләүдә тулысынча файдаланыла ала.

Шулай итеп, дистанцион уку-укыту укучыларны мөстәкыйль эшли белүгә өйрәтү, аларда билгеле бер универсаль уку гамәлләрен формалаштыру өчен зур мөмкинлекләр ача. Шул ук вакытта онлайн уку-укыту хәзер кулланыла торган традицион мәктәптә уку формасын тулаем алыштыра алмавын да аңларга кирәк. Аерым очракларда, ихтыяҗ туганда бу төрле укыту ярдәмгә килеп, уку-укыту процессына тоткарлык килмәү, аны өзмәү юнәлешендә файдалы була ала. Шулай да кайчан һәм нинди максат белән генә

файдаланылмасын дистанцион уку-укыту укучыларның белем алуга ихтыяҗларын канәгатьләндерү эшенә хезмәт итәргә тиеш.


## ӘДӘБИЯТ

Крылова О.Н., Муштавинская И.В. Новая дидактика современного урока в условиях введения ФГОС ООО: методическое пособие. Санкт-Петербург: КАРО, 2015. – 144 с.

Поташник М.М., Левит М.В. Как помочь учителю в освоении ФГОС. Методическое пособие. М.: Педагогическое общество России, 2015. – 320 с.



**Л.Р. НАДЫРШИНА, Г.М. ХАННАНОВА**

Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясе

Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Казан


## ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ КАЗАН ЧОРЫ ИҖАТЫНДА ҮТКӘННЕ САГЫНУ МОТИВЫ


**Л.Р. НАДЫРШИНА, Г.М. ХАННАНОВА**

Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова

Академии наук Республики Татарстан, Казань


## МОТИВ ТОСКИ ПО ПРОШЛОМУ В КАЗАНСКОМ ПЕРИОДЕ ТВОРЧЕСТВА ГАБДУЛЛЫ ТУКАЯ


**Аннотация.** Статья посвящена анализу мотива тоски в лирике Габдуллы Тукая. На примере ряда стихотворений авторами выявляются семантические особенности изучаемого мотива, определяется взаимосвязь с другими мотивами творчества поэта.В статье сделан вывод о том, что данный мотив взаимосвязан с романтическим и экзистенциальным мировосприятиями, характерными для многих произведений Казанского периода творчества Тукая. Подобная семантика, в свою очередь, определяет эмоионально-психологическое состояние лирического героя, осознавшего истинную суть бытия: время быстротечно и прошлое не вернуть.

**Abstract.** The article is devoted to the analysis of the motif of longing in the of GabdullaTukay'slyrics. On the example of a number of poems, the authors identify the semantic features of the studied motive and determine the relationship with other motives of the poet's work. The article concludes that this motif is interrelated with the romantic and existential worldviews characteristic of many works of the Kazan period of Tukay's creativity. Such semantics, in turn, determine the emotional and psychological state of the lyrical hero, who realized the true essence of being: time is fleeting and the past cannot be returned.



**Ключевые слова**: татарская поэзия, Габдулла Тукай, мотив, лирика, лирический герой.

**Keywords:** Tatar poetry GabdullaTukay, the motive, the lyrics, the lyrical hero.


1907 елда «Монда хикмәт, мәгърифәт һәм монда гыйрфан, монда нур» [Тукай, 2011: 172] дип ашкынулы өметләр белән Казанга килгән Габдулла Тукай шигърияте сизелерлек үзгәреш кичерә: шагыйрнең иҗат дөньясы лирик, романтик аһәңнәр хисабына киңәя, катлаулана, Г. Халит сүзләре белән әйтсәк, «публицистик рух лирик-психологик сурәткә урын бирә» [Халит, 1962: 79]. Бер яктан, иҗтимагый проблемаларны лирик геройның сызлану-ачыну сәбәбе иткән романтик әсәрләр әдәби

мәйданга чыкса («Көзге җилләр», 1911; «Тәләһһеф», 1910 һ.б.), икенче яктан, лирик-романтик, эмоциональ-сентименталь кичерешләр бәйләме төсендә күзалланган күңел лирикасы үрнәкләре күпләп иҗат ителә башлый: туган авыл, туган тел, ана образлары үзәктә торган әсәрләр әдәби мәйданга чыга.Үз чиратында, туган җир, туган авыл темасы туган якны сагыну белән алшартланган хәтер мотивын калкыта. Лирик геройның ретроспектив рухтагы уйлану-хатирәләре үткәндә калган хөр чакларны уйлап юану идеясен алга чыгара. Мәсәлән, «Туган авыл» (1909) шигырендәтуган авыл – кешенең нәсел чишмәсе башланган, аның дөньяга күзе ачылган урын булуы турындагы күзаллау дини эчтәлектәге образлар аша гәүдәләнә:

*Ходай шунда җан биргән, мин шунда туган,*
*Шунда әүвәл Коръән аятен укыган;*
*Шунда белдем рәсүлемез Мөхәммәдне,*
*Ничек михнәт, җәфа күргән, ничек торган* [Тукай, 2011: 55].

Туган җирдә үткән гамьсез-вафасыз сабыйлык елларын сагынухисе шигырьне иңләп уза:

*Истән чыкмый монда минем күргәннәрем,*
*Шатлык белән уйнап гомер сөргәннәрем;*
*Абый белән бергәләшеп кара җирне*
*Сука белән ертып-ертып йөргәннәрем* [Шунда ук].

Соңгы строфада *тәкъдир* төшенчәсе аша ачылган яшәеш фәлсәфәсе урын ала: язмыш юллары кая гына илтсә дә, туган як, балачак турындагы истәлек-хатирәләр кешене юатучы төп көч булып калачак:

*Бу дөньяда, бәлки, күп-күп эшләр күрем,*
*Билгесездер – кая ташлар бу тәкъдирем;*
*Кая барсам, кайда торсам, нишләсәм дә,*
*Хәтеремдә мәңге калыр туган җирем* [Шунда ук].

Гомумән, шагыйрьнең лирик герое еш кына күңел юанычын нәкъ менә үткәннәрдән таба, «үткәнне искә төшереп сагышлану, идеалны үткәннән эзләү мотивы шагыйрьнең романтик иҗатын, фәлсәфи шигырьләрен әйдәп бара» [Заһидуллина, 2006: 74-75]. Бу әсәрләрдә моңлы-сызланулы хатирәләр дулкынында калган, иң бәхетле чагы – сабыйлык елларын сагынган лирик герой үзәктә тора. Мәсәлән, «Исемдә» (1909) шигырендә өлкәнәйгән лирик герой үзенең иң матур хатирәләр белән күңелендә калган бала чагын юксынып моңлана:

*Исемдә курка-курка төрле уйлар уйлаган чаклар,*
*Гафифанә вә мәгъсуманә көлгән, уйнаган чаклар;*
*Исемдә һәм эчемнән көткәнем якты бәхетләрне,*
*Теләп яшьрен генә рәхәт, сәгадәтле вакытларны* [Тукай, 2011: 17].

Гомернең узучанлыгы, вакыт агышы кебек фәлсәфи мотивлар бу табигый агышны туктатып булмаганлыгын аңлауга алып килә:

*Тыныч калды йөрәк, шау-шу вә гаугадан тәмам тынды;*
*Моңаеп тибрәнә тик бер тәхаттырдан гына инде* [Тукай, 2011: 17].

«Сагыныр вакытлар» шигырендә беренче строфаларда ук лирик кичерешләр катламында әйдәп барачак төп хис – үкенеч катыш сагыну хисе аерымлана, бу исә, үз чиратында, әсәрне сентименталь укылышка көйли:

*Туйса Иблис тормышыннан, яд итә оҗмахларын, –*
*Яд итәм, бизсәм үземнән, мин сабыйлык чакларын.*

*И күңелнең шаулап аккан чишмәдән сафрак чагы!*

*И гомернең нурланып үскән яшел яфрак чагы!* [Тукай, 2011: 239].

Әсәрнең шуннан соңгы өлешендә шагыйрь балачак хатирәләрен детальләп торгыза, һәр строфада санап барылган эмоциональ-сентименталь истәлекләр, мәгънәви яктан бер-берсен тулыландырып, сабыйлык дәверенең гаҗәеп җылы, нурлы манзарасын тудыра һәм шигырьдә кызыл җеп булып сузылган төп идеяне – балачакның кешенең иң авыр вакытларында күңелен җылыткан дәвер булуы турындагы фикерне раслауга буйсындырыла.

Өлкән лирик геройның балачак истәлекләреннән рухи җылылык алуы белән бәйле мотив шагыйрьнең башка әсәрләрендә дә урын ала. Әйтик, яшь буынга мөрәҗәгать кебек иҗат ителгән «Гомер юлына керүчеләргә» (1910) шигырендә лирик герой түбәндәге нәтиҗәгә килә:

*Нигә, – дим, – изге мәктәптән, сабый чаклардан айрылдым?*

*Нигә мин кечкенә Апуш түгел, зуп-зур Тукай булдым ?*[Тукай, 2011: 130].

Шул рәвешле, Тукайның Казан чорында үткәнне сагыну мотивы гомернең үтүчәнлеге, үткәнне кайтарып булмавы, әмма шул гүзәл-гамьсез чакларның гомер буе күңелне җылытып торуы хакындагы фәлсәфи идеяне нигезли.

## ЛИТЕРАТУРА

Заһидуллина Д.Ф. Дөнья сурәте үзгәрү: XX йөз башы татар әдәбиятында фәлсәфи әсәрләр: Монография. Казан: Мәгариф, 2006. –191 б.

Тукай Г. Әсәрләр: 6 томда. Академик басма. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – 2 т.: шигъри әсәрләр (1909–1913).

Халит Г. Тукай үткән юл (Габдулла Тукайның тормышы һәм иҗаты турында очерк). Казан: Тат. кит. нәшр., 1962. – 230 б.

**Г.Р. НАСИБУЛЛОВА**

Казанский федеральный университет, Казань

## ПЕРЕВОД МИФОЛОГИЧЕСКИХ ФРАЗЕОЛОГИЗМОВ С ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА НА АНГЛИЙСКИЙ ЯЗЫК

**Аннотация.** В статье рассматриваются особенности перевода мифологических фразеологизмов с татарского языка на английский язык, которые составляют особый пласт в фразеологической системе языка. Основываясь на «Татарско-русско-английский словарь фразеологизмов», автор выделяет эффективные способы их перевода.

**Abstract.** The article discusses the features of the translation of mythological phraseological units from the Tatar language into English, which constitute a special layer in the phraseological system of the language. Based on the "Tatar-Russian-English dictionary of phraseological units", the author identifies effective ways to translate them.

**Ключевые слова:** фразеологизм, мифологема, мифоним, культура, перевод, лингвокультурология.

**Keywords:** phraseologism, mythologem, mythonym, culture, translation, linguoculturology.

Фразеологизмы несут в себе ценнейшие сведения об истории, образе жизни, менталитете, мировоззрении, культуре народа. Они играют важную роль в сохранении и перевода с поколения в поколение знания о выработанной в обществе системе

обычаев, традиций, законов и обыденных представлений о мире. Фразеологизмы не только называют то или иное явление объективной действительности, но и указывают на определённое отношение говоряшего к этому явлению.

В фразеологической системе языка значительное место составляют фразеологизмы, компонентами которых являются мифологизмы. Эти компоненты называются мифологемами. По мнению исследователя К.Г.Юнга, мифологема – термин, обозначающийчто-либо, связанное с мифологией, например, образ, сюжет или конкретное событие [Юнг, 1996: 107]. Как правило, мифологема носит глобальный характер иявляется широко распространенной в мифологии многих народов икультур.

Исследования показывают, что перевод и трансформация такого типа фразеологизмов с одного языка на другой является сложным процессом. Настоящее исследование посвящено изучению перевода фразеологизмов с татарского языка на английский язык, в составе которых есть мифологизмы. Заметное влияние на восприятие и освоение фразеологических единиц оказывают межкультурные различия, несоответствия на этно-культурологическом уровне, разные мифологии, религии. Экстралингвистические факторы, участвующие в формировании стилистико – коммуникативных средств выразительности английского языка, включают особенности общественно – экономической, политической, культурной жизни народа, и это оставляет свой след в фразеологизмах. «Наименования» предметов, явлений материальной и духовной культуры, отражающие образ жизни и специфику мировосприятия определенного культурно – языкового сообщества мы называем реалиями. Будучи носителями национального (локального) или исторического колорита, реалии не имеют точных соответствий в других языках и поэтому требуют особого подхода при переводе» [Винокуров, 2011: 413].

Следует отметить, что в последние два-три десятилетия в отечественном языкознании наблюдается повышение интереса к проблеме мифологической лексики и ее функционирования. Это связано, по нашему мнению, как повышением значения науки лингвокультурологии в целом, так и поиском нового в научно-практических исследованиях. Объектом нашего исследования является «Татарско-русско-английский словарь», составленный С.Ф. Гарифуллиным [Татарско-русско-английский фразеологический словарь, 2010]. При переводе фразеологизмов с татарского на английский язык в основном используется метод выбора возможного эквивалента, а при отсутствии эквивалента автор передает его близким по значению фразеологизма в качестве эквивалента. Также применяется описательный метод.

Основной пласт фразеологизмов с мифологемами составляют фразеологизмы в составе которых присутствуют такие компоненты как «иблис», «җен», «шайтан», «пәри», которые используются при отрицательной оценки того или иного явления. Мифологемы «иблис» и «шайтан» в словаре в большинстве случаев на английский язык передаются мифологемой «devil», который в английском языке также выражает отрицательную оценку: иблис вәсвәсәсе - devil's temptation, иблис токымы - the devil's spawn, шайтан оясы - it's the devil of a mess, пәри котырган – raise the devil.

Фразеологизмы, которые имеют одинаковые значения, но отличающиеся мифологемами переводятся единым фразеологической единицей, которая передает их содержание в целом: пәри алыштырган, җен алыштырган, шайтан алыштырган - it's thedevil's work.

При переводе фразеологизмов, в составе которых присутствуют мифонимы, автор обращается к широкому спектру переводческих методов, наряду с выбором эквивалента в английском языке, описательным переводом используются транслитерация и транскрипция, которые являются основными трансформациями при переводе имен собственных: Гали батыр дөлделе – Pegasus; Нух заманыннан калган – sincedaysofold; Нух көймәсе - Noah'sArk; Нух пәйгамбәр заманыннан башлау – beginatthebeginning; Нухтан калган – sincedaysofold.

В большинстве случаев при переводе татарских фразеологизмов на английский язык теряется их мифологический компонент:

пәри башка, җен башка – tell one from another;

дию йокысы белән йоклау – sound sleep;

каф тау артында – at the back of beyond;

күздә шайтан бию - playful eyes

шайтан суы – alcoholic drink (конкретизация);

юхаелан – snake in the grass;

Несмотря на то, что татарский и английский народ относится разным культурам, в их мифологии встречаются общие образы, общие сюжеты, которые идут от древних истоков, культур и являются общими для всего человечества. К примеру, можно привести цифру семь, которая и в английской, и в татарской лингвокультурологии имеет мифологическое, волшебное значение. Это ярко проявляется и в фразеологизмах двух языков:

Җиде йозак астында – undersevenseals;

Күкнең җиденче катында булу - to be in seventh heaven.

Таким образом, мы можем сказать, что перевод фразеологизмов, в состав которых входят мифологизмы, должно основываться на правильном понимании соответствующих понятий, верного толкования их метафорических значений. В результате исследования выяснилось, что значительная часть татарских мифологических фразеологизмов имеет стилистико-семантические эквиваленты в английском языке. В случае отсутствия эквивалентов самым эффективным методом их перевода является описательный метод.

## ЛИТЕРАТУРА

1. Винокуров А.М.Англо-русский словарь идиом. М.: Мартин, 2011. – 352 с.

2. Кунин А.А.Фразеология современного английского языка/ А.А.Кунин. – М.: Международные отношения, 1972. – 288 с.

3. Татарско-русско-английский фразеологический словарь. Казань: Татарское республиканское издательство “ХЭТЕР”, 2010. – 296 с.

4. Юнг К.Г. Душа и миф: шесть архетипов. Киев: Государственная библиотека Украины для юношества, 1996. – 384.

**И.С. НАСИПОВ, А.А. ТИМАШЕВА**

Башкирский государственный педагогический университет им. М.Акмуллы, Уфа

## ПРАЗДНИЧНАЯ КУЛЬТУРА КРЕЩЁННЫХ ТАТАР с. НОВЫЕ МАТЫ БАКАЛИНСКИЙ РАЙОН РБ

**Аннотация.** Праздничная культура в жизни кряшен играет важную роль. В данной статье раскрывается праздничная культура кряшенского народа, а именно подробно повествуется об одном из распространенных и актуальных праздников – Раштуа (Рождество) на примере традиций крещеных татар с. Новые Маты Баклаинского района Башкортостана.

**Abstract.**Festive culture plays an important role in the life of Kryashen. This article reveals the festive culture of the Kryashen people, namely, it tells in detail about one of the most common and relevant holidays – Rashtua (Christmas) on the example of the traditions of the baptized Tatars. New Mats Baklinskogo district of Bashkortostan.

**Ключевые слова:** Праздничнаякультура, кряшены, Раштуа (Рождество).

**Keywords:** Festive culture, Kryashens, Rasta (Christmas).

Село Новые Маты расположено в Бакалинском районе Республики Башкортостан. Его история берёт начало с конца 18 века. Удалённость села от районного центра составляет 21 км. Преобладающую часть населения составляют кряшены.

Кряшены, кряшенский народ, крященные татары (керәшеннәр) – это поволжские тюрки, близкие по языку и культуре татарам, но при этом обладающие рядом этнокультурных и антропологических особенностей. Уникальностью данного народа являются синтез православного вероисповедания и татарской культуры. Их язык является говором относящимся среднему диалекту татарского языка. Особенности кряшен, которые свойственны только им: языковые особенности, историю, традиции, национальную одежду, украшения изучали такие ученые, как Ф. Баязитова, В. Витебский, С. Матвеев, А. Можаровский, Н. Фирсов.

Укрепление религиозного самосознания, актуализация этнической идентичности, взаимодействие с другими народами являются важнейшими условиями современной народной культуры. Перечисленные факторы особенно полно и конкретно отражаются в праздничной культуре. Кряшены в настоящее время уделяют значительное внимание празднованию народных праздников, также своим этнокультурным особенностям, традициям.

Праздничная культура кряшенского народа довольна разнообразна и многогранна. Она включает себя государственные, народные и религиозные праздники.

Для определения частоты значимости и определения более распространеных и почитаемых праздников для жителей села Новые Маты, мы обратились к населению с просьбой перечислить кряшенские праздники, значимые для них и их семьи. По переписи населения 2018 года в селе зарегистрировано 294 человека, задействовано 157 человек.

| Праздники | Всего, человек |
|---|---|
| *Раштуа* (Рождество Христово) | 157 |
| *Олы көн* (Пасха) | 155 |
| *Кач ману* (Крещение) | 149 |
| *Питрау* (Петров день) | 99 |
| *Покрау* (Покров день) | 90 |
| *Бәрмәнчек* (Вербное воскресенье) | 68 |
| *Май чабу* (Масленица) | 57 |
| Другие – *Энҗел көн* (жемчужный день), *Үле чыгу көне* (Родительский день), *Кош ияр типмәскөн* (Благовещение Пресвятой Богородицы) и др. | 45 |

По итогам опроса следует, что многие опрашиваемые отметили, что в селе Новые Маты широко отмечают праздник *Раштуа*, который проводится 7 января каждого года. Аналогичное у русского народа Рождество Христово, но у кряшен свои особенности его празднования. Он определяется как День рождения пророка Иисуса Христа, посланного на Землю, чтобы наставить людей на истинный путь. Этот день с давних времен является одним из главных праздников для кряшен. Перед Рождеством люди в течение шести недель воздерживаются от употребления мясных, молочных, яичных продуктов, постятся. Большим праздником считается ночь перед Рождеством. В народе его называют *«авыз ачу»* (дословно переводится как *«открытие рта»*, т.е. разрешение на принятие обыденной пищи). К великому празднику стремились прийти чистыми душой и телом: шла уборка в домах, топилась баня, все надевали чистую одежду.

По случаю праздника православные в ночь на 6 января в церквях до утра молились и зажигали свечи за своих покойных родственников, просили прощения за свои грехи.

На Рождество каждый православный христианин обязан посещать церковь. Верующие верят, что свет и запах свечей, зажженных в этот день в домах, очищают жилище и душу.

В праздничный день с утра дом наполняется запахами разных угощений: пироги с разными начинками, чак-чак, блины, треуголники, перемячи с картошкой, с мясом и т.д. Как и в один из великих праздников кряшен – *Олы көн* (Пасха), утром дети начинают ходить по домам, собирать сладости или же деньги. Этот праздник длится неделю до Старого Нового года, т.е. 13 января. Улицы полны веселья, катания на санках, игр на улице. Главное, что в эту неделю нельзя начинать что-то новое, всё это заранее обречено на неудачу.

Самым интересным элементом праздника является *«бабайга чыгу»* дословно переводится как *«выходить как дедушка».* Вечерами в разных до неузнаваемости одеяних односельчане, гости из других сел, регионов по несколько человек ходят по домам и развлекают всех стихами, частушками, песнями, плясками, прибаутками. И стараются максимум приложить усилия, чтобы оставаться неузнаваемыми. Хозяевам дома в новом году желают здоровья, благополучия и счастья.

Исходя из многолетних наблюдений, к Рождеству в народе ходили различные приметы. Вот некоторые из них: *1) Если в этот день выпадет снег, то урожай будет обильным. 2) Если снег метет, то это к приходу богатства и изобилия. 3) На крыше дома лежит снег, то рожь и сено вырастут высокими. 4) Если на Рождество на деревьях иней, то зерновые культуры дадут хороший урожай, если ночь будет ясной* - *горох, если санный путь гладкий* - *гречиха и т.д.*

Праздник *Раштуа* (Рождество Христово) довольно масштабна и значима для населения кряшен села Новые Маты, как и для всего кряшенского народа. Со временем каждый из праздников усовершенствуется, приобретают новую окраску, преображаются, но суть передаваемая из поколения в поколения сохраняется. Очень интересна и самобытна праздничная культура кряшен. Прослеживаюся связи как с религиозными православными традициями, так и с мусульманскими корнями. Необходимо отметить, что все праздники, не только *Раштуа* (Рождество Христово) свято соблюдается как старшим поколением, так и молодежью.

Традиционная праздничная культура кряшен является важнейшим видом древней культуры татарского народа, сохранившая память нескольких поколений и

передаваемых будущему поколению. Они хранят традиции своего народа, соединив его с правослаными истоками. Христианство для них стало неотъемлемой частью жизни.

## ЛИТЕРАТУРА

Волков Н.П. Историко-культурное наследие кряшен, проживающих на реке Матинка: взаимосвязь и влияние языков друг на друга. Нижнекамск, 2001. – С. 284.

Волков Н.П. Яңа Маты авылы тарихы (Бакалы районы, БР) // Туганайлар, 2004. – С. 14.

Воробьев Н.И. Кряшёны и татары (некоторые данные по сравнительной характеристике быта). // Труд и хозяйство. № 5. Казань, 1959. – С. 76.

Гарипов М. Яңа Маты – Әрнәш җире. Новые Маты – Земля Арняшская / М. Яковлев, Н. Яковлева // Очерки о людях и истории деревни. Октябрьский, 2009. – С. 165.

Мухаметшин Ю.Г. Татары-кряшены: Историко-этнографическое исследование материальной культуры. М., 1977. – 183 с.

Тимашева А. Башкортостан республикасы Бакалы районы Яңа Маты авылы милли бәйрәмнәре һәм гореф-гадәтләре / А. Тимашева, С. Тимашева // Сборник материалов Фестиваля-конкурса «Буыннар сабагы» («Уроки поколений»), посвященного 50-летию БГПУ им. М.Акмуллы [Текст]: Уфа: Издательство БГПУ, 2017. – С. 104-108.

**Н.Ш. НАСЫЙБУЛЛИНА**
Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясе
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Казан

## ЭСТӘРЛЕБАШ МӘДРӘСӘСЕНЕҢ МӘГЪРИФӘТ ҮСЕШЕНӘ КЕРТКӘН ӨЛЕШЕ

**Н.Ш. НАСИБУЛЛИНА**
Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова
Академии наук Республики Татарстан, Казань

## РОЛЬ СТЕРЛИБАШЕВСКОГО МЕДРЕСЕ В РАЗВИТИИ МУСУЛЬМАНСКОГО ОБРАЗОВАНИЯ

**Аннотация**: Целью данной работы является анализ культурно- просветительской, образовательной деятельности медресе и трудов преподавателей конфессионального учебного заведения села Стерлибашево. Особое внимание уделяется анализу благотворительного, педагогического наследия династии Тукаевых (Нигматуллиных) и осознанию исторической роли медресе в общественно-духовном развитии татарского, башкирского, киргизского и казахского общества.

**Abstract.** The aim of this research is analysis of cultural and educational practice of medrese and teachers of confessional educational institution of Sterlibashevo village. The special attention is paid to analysis of the Tukaevs (the Nigmatullins) heritage and perception of historical role of medrese in social and religious development of tatar, bashkir, kirgiz. and kazakh society in the early 18th and 19th centuries.

**Ключевые слова**: образование, медресе, религия, ислам, методическая деятельность, выдающиеся личности.

**Keywords:** confessional education, medrese, religio, islam, educational and methodical work, outstanding persons.

Эстәрлебаш төбәге борынгыдан мәгърифәтле як булганы тарихыбызга яхшы мәгълүм. Мөсеман халкының мәгърифәтен үстерүдә мәчетләр зур роль уйнаган. Алар халыкның аң-белем дәрәҗәсен үстерүгә, тормыштагы үзгәрешләрне күзалларга ярдәм иткән. Эстәрлебаш мәчет-мәдрәсәләре XVII-XIX гасырда дөньякүләм мөселман халыкларын агартуда мөһим урын тота һәм иң данлыклы, иң мәшһүр уку йортлары буларак танылу ала.

Унтугызынчы гасырга кадәр ике мең кешесе булган авылда кырыкка якын мәдрәсә эшли. Тирә-якта яшәгән халыкларның аң-белемен үстерүгә шагыйрьләр, җәмәгать эшлеклеләре, руханилар Утыз Имәни (1754–1836), Хөснетдин Жданов (1767-1869), Әбелмәних Каргалы (1782 –1833), Һибәтулла Салихов (1794-1869), Зәйнулла ишан Хосраушир улы Галикәй, Әхмәтгали (казакъ мәдрәсәсе хәлфәсе), Гали Чалатай (казакъ мәдрәсәсе хәлфәсе), Шәмсетдин Зәки (1822–1865), Мөхәммәтъяр хәлфә, Мөхәммәтхафиз хәлфә, Халиулла хәлфә, Гали Чокрый (1826-1889), Мифтахетдин Акмулла (1831–1895), мулла һәм таш язу остасы Габдулла Тукаев, Мирсәет Солтангалиев (1892-1940), Гали Рафикый (1890-1944), Төхфәт Янәби (1894–1938) һ.б. көчле йогынты ясый.

Эстәрлебаш авылының иң беренче имамы – Монасыйп мулла, чукындырудан качып, Казан ягыннан килә. Авылда беренче мәчет һәм мәдрәсә 1724 елда төзелә дип фараз ителә.

Эстәрлебаш мәдрәсәсеннән белем алып чыккан шәхесләр бөтен тирә-якта мөгаллимлек итәләр. Гыйлем учагы буларак танылган мәдрәсәнең зур үсеш чоры 1800 елларга туры килә.

Бохарага барып укып кайтканнан соң Нигъмәтулла Биктимеров (Тукаев) 1812 елда мөдәррис итеп тәгаенләнә һәм гомеренең соңгы көненә кадәр (1842) шушы вазифаны үти. Нигъмәтулла мәдрәсәнең абруен күтәрү өчен зур тырышлык куя. Ул иң беренче чиратта хәлфәләрне һәм шәкертләрне һәртөрле дәреслекләр, уку китаплары белән тәэмин итәргә тырыша. Мәсәлән, җәмәгать эшлеклесе, педагог, «Тарихи Эстәрлебаш» китабының авторы Мөхәммәтшакир Тукаев: «Нигъмәтулланың үз кулы белән язылган мәҗмугаләре бар...Эстәрлебашта язылган һәм Бохарадан алдырылган күп кулъязма китаплар бүгенге көнгә кадәр саклана», – дип яза [Тукаев, 1899: 3].

«Нигъмәтулла хәзрәт китап туплауга зур игътибар биргән, үзе дә күчереп язган, кешеләрдән дә яздырган, Бохарадан да алдырган: «Китаплар хасил итү өчен, күп иҗтиһад вә маллар сарыф әйләгән» Эстәрлебаш мәдрәсәсе аның вакытында Казан, Оренбург, Уфа, Әстерхан, Урта Азия якларында үзенең кулъязма һәм басма китапларының күплеге белән данлыклы булган», – дип язды күренекле замандашыбыз Зәки Зәйнуллин [Зәйнуллин, 1990: 1].

Нигъмәтулла үлгәннән соң мөдәррислек вазифасы аның өлкән улы Мөхәммәтхариска (1810–1870) күчә[1]. Бу чорда шәкертләргә белем бирү күзгә күренеп яхшыра. Ул мәдрәсә тормышына тәүге карашка бик сәер, мөселман схоластикасы белән бик үк ярашмаган яңалыкларны кертә. Мөхәммәтхарисның хәлфәләр һәм шәкертләр арасында абруе шул кадәр көчле була, ул керткән үзгәрешләргә фанатик дин әһелләре дә каршылык күрсәтергә батырчылык итмиләр.

---

[1] Мухаметхарис Нигаметуллин (Тукаев), по архивному источнику, имам-хатыпом и мударрисом Стерлибашевской мечети стал по указу Оренбургского губернского правления за № 14816 от 20 октября 1845 г. См.: ЦГИА РБ. Ф. И-295. Оп. 10. Д. 66. Л. 106

Мөхәммәтхарис Тукаев: «Россия мөселманнары өчен дәүләт телен белү лазим», – дип, мәдрәсәдә рус телен укыту өчен аерым мөгаллим тота, шәкертләргә русча газета уку да бик кирәклеген аңлап, «Голос» газетасын алдыра һәм анда язылганнарны махсус тәрҗемәче ярдәмендә шәкертләргә җиткерә [Харисов, 1965: 7].

Мәдрәсә мөдәррисе заманы өчен атаклы булган язучы-шагыйрьләрне, шәкертләрне укытырга җәлеп итәргә тырыша. Мәсәлән, күренекле суфый шагыйрь Шәмсетдин Зәки (1825–1865) үзенең туган авылы Зәк Ишмәттән (Оренбург өязе) бөтен шәкертләрен ияртеп, Эстәрлебашка күчеп килә һәм гомеренең соңгы көненә кадәр шунда укытучы булып эшли. Бөре өязенең Иске Чокыр авылында туган шагыйрь Гали Чокрый да (1826-1889) 1849 елда Эстәрлебашка килеп, мәдрәсәдә белем ала һәм шунда ук Шәмсетдин Зәки белән хәлфәлек тә итә.

Бу шәхесләр Көнчыгыш һәм Европаның алдынгы язучылары, галимнәре белән якын бәйләнештә булалар. Шиһабетдин Мәрҗани үзенең «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» дигән китабында түбәндәгеләрне яза: «Мелла Нигъмәтулла бине Биктимер бине Тукай бине Урманай әл–Эстәрлебаш чыгышы белән Казан иленең Малмыж өязе Салавыч карьясеннән... Дөньясы киң, шәкертләре күп була. Үз илендә чиктән тыш шөһрәт казана. Габделнасыйр әл-Курсави карашларын яклаучылардан һәм аның дусларыннан була» [Мәрҗани, 1989: 2].

Риза Фәхретдинов үзенең «Асар» исемле хезмәтендә: « Нигъмәтулла хәзрәтнең дөньясы иркен, шәкертләре күп, якыннары хисапсыз, абруе югары, үзе чиксез диндар, дин юлындагы тугрылыгы белән көчле, данлыклы, атаклы, шөһрәтле булдыгыннан моның заманасында Эстәрлебаш карьясе дәрелгыйлем, ягъни, югары белем бирү урыны булды», – дип яза [Фәхретдинев, 1904: 5].

Нигъмәтулланың ике улы (Мөхәммәтхарис белән Мөхәммәтхаррас) булып, шуларның икенчесенең улы Мөхәммәтшакир (1862–1933) Тукаев II-III Дәүләт Думасына әгъза итеп сайлана [Тукаев, 1899: 3]. Халкыбыз галимне беренче чиратта тарихчы буларак кабул иткән. Аның китапларында Эстәрлебаш төбәгенә кергән авыллар, алардагы мәчетләр, мәдрәсәләр, анда укыткан шәхесләр, аларның нәсел шәҗәрәләре тарихларына караган мәгълүматлар урын алган. Бу безнең өчен әйтеп бетергесез хәзинә, Эстәрлебаш тарихы нәкъ менә аның 1899 елда Казанда нәшер ителгән «Тарихи Эстәрлебаш» исемле хезмәтенә таянып языла.

Мәдрәсәнең китап фонды да заманы өчен ифрат бай була. Анда көнчыгыш илләрдән килгән кулъязма һәм басма китаплар күп тупланган. Аларның байтагы сәяхәт, хаҗ сәфәрләре, кәрванчылар аша килгән булса, күпчелеге күчереп алынган, һибә кылынган (бүләк ителгән) китаплардан гыйбарәт булган. Моның шулай икәнлеге хакында Рәмиевләр тырышлыгы белән чыга башлаган «Вакыт» газетасының 1913 ел, 9 июнь санында академик В.В. Бартольдның Оренбургтан Уфага сәяхәте хакында язылган мәкаләдән укып белергә мөмкин. В.В. Бартольд мәдрәсә китапханәсен актарып, 200-300, хәтта 500 ел элек язылган кулъязма китапларны дикъкать вә ләззәт белән караган», – дип яза газета [Харисов, 1965: 7].

«...Эстәрлебаш Рәсәй Европасындагы мөселман фәненең иң төп үзәкләренең берсе, – дип яза азактан В.В.Бартольд үзе. – Мәдрәсә китапханәсеннән тыш, кулъязмалар XIII гасырга карый. Миңа Шаһрух солтанның (1407-1447) мөһере басылган кулъязмасын күрсәттеләр» [Умняков, Туманович, 1976: 4].

Эстәрлебаш мәдрәсәсендә күп тапкырлар булган Ризаэтдин бине Фәхретдин, Нигъмәтулла хаҗи китапханәсендә һиҗри 787, икенчесе 785 елда язылган кулъязма китаплар бар иде, ди. Ягъни алар XIV гасырга караган китаплар [Усманов, 2000: 5].

Нигъмәтулла гарәп-фарсы телләрен, грамматика нигезләрен өйрәнү барышында күнекмә, нәхү, сарыф буенча да кулъязма китаплар язган, сүзлекләр төзегән. 1794 елда аның тарафыннан төзелгән гарәпчә-төрекчә чагыштырма грамматика бик әһәмиятле лингвистик язма байлык булып санала. Шулай ук Нигъмәтулла фарсы телендәге тарих китабын төркиләштергән.

Кулъязма китаплар арасында шәҗәрә китаплары да бар, шуларның берсе Эстәрлебаш мәдрәсәсендәге хәлфә Гали Чалатай тарафыннан язылган. Әлеге зур шәҗәрәдә имам Һибәтулла Каргалыйның нәселе (шагыйрь Һибәтулла Салихов) Мөхәммәт пәйгамбәрдән үк башланып язылган. Әлеге көндә бу коллекция Башкортстан Фәннәр академиясендә саклана.

1921елда Эстәрлебаш мәдрәсәсе эшләүдән туктатылгач, мәдрәсәнең соңгы мөдәррисе Мөхәммәтшакир Тукаев китапларны авылның укымышлы кешеләренә алырга рөхсәт итә. 1923 елда Оренбургка күченгән вакытында, үзе дә әлеге китапларның күпмедер өлешен алып киткән булырга мөмкин. 1928 елда ГПУ махсус операция үткәреп, авылның иң затлы 87 кешесен кулга алып, төрмәгә озаталар, китапханәдә калган китапларның бер өлешен конфисковать итеп, Уфага алып китеп яндыралар.

Авыл аксакаллары тарафыннан яшереп саклап калынган китапларның 150 дән артыгы Абдрахман Айдабуловта (1876-1969) сакланган. Алар күн тышлы бик калын китаплар була. Канлы елларда Абдрахман Айдабулов аларны тирескә күмеп яшереп кала. Шул китапларның унсигезе Гайсә Хөсәенов тарафыннан Уфага Тел, әдәбият һәм тарих институтының кулъязма һәм иске басма китаплар фондына кайтарыла. Калган китапларның язмышы билгеле түгел.

Берничә китапханә һәм мәдрәсә урнашкан йортларның сызымнары, Эстәрлебаш тарихына нигезләнеп авыл музее төзегән һәм шунда эшләгән Галиев Владимир Лотфрахман улында саклана. Бу сызымнарны заманында шушы мәдрәсәдә укыган Габдерәхим Галиев (1866-1966) ясаган. Габдерәхим бабайның атасы Гали Чалатаев, Казахстаннан килеп, биредә гыйлем эстәгән, соңыннан шунда хәлфәлек иткән – казах балаларын укыткан. Үзе дә язу-сызу эше белән шөгыльләнгән. Гали Чалатаевның XIX гасырның уртасында язылган берничә кулъязма китабы Уфада Әхмәтзәки Вәлиди исемендәге Милли китапханә фондында саклана.

Берничә генә данә калган мирас китаплар буенча да Эстәрлебаш мәдрәсәсендәге укылган китапларның, дәреслек әсбабларының характерын күпмедер чамалап күз алдына китереп була. XI гасырда яшәгән бөек шагыйрь Йосыф Баласагунлы:

Җыйган дөнья байлыклары таралыр, язылган сүз җиһанда мәңге калыр, – дип язган. Эстәрлебаш хәттатларының эшчәнлеге дә шушы сүзләргә дәлил булып тора. Ата-бабаларыбыз үз тырышлыклары белән тапкан табышлары, мал-мөлкәтләре, белемнәре белән киләчәк буыннарны, милләтебезне аң-белемле итәр өчен тырышканнар, дөньякүләм мөселман халыкларын агартуга зур өлеш керткәннәр. Үткәннәрне белмәсәк, бүгенгенең дә, киләчәкнең дә кызыгы булмас. Тукаевларның, гомумән Эстәрлебаш мәдрәсәсе тарихына зур өлеш керткән зыялыларның көнкүреш-яшәешен, аларның иҗтимагый фазыйләтен өйрәнү сорала. Һәр шәхес – үзе бер дөнья. Аны ачу исә безнең мөкатдәс бурычларыбызның берсе булып кала.

## ӘДӘБИЯТ

Зәйнуллин З. Эстәрлебаш мәдрәсәләре // Казан утлары, 1990. № 6. – 178 б.

Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. – Казан, 1989. Б. 245.

Тукаев Ш. Тарихи Эстәрлебаш. Казан, 1899.

Умняков И.И., Туманович Н.Н. Аннотированная библиография трудов В.В. Бартольда. Описание архива В.В. Бартольда. М., 1976. С. 327.

Усманов В. Эстәрлебаш төбәгендә тарихи истәлекләр // Өмет, 2000. 7 июль.

Фәхретдинев Р. Асар. 2 т. 9 җөзьә. Оренбург, 1904.

Харисов Ә. Башкорт халкының әдәби мирасы. Уфа, 1965.



**Г.Ә. НӘБИУЛЛИНА**

Казан федераль университеты, Казан


## ӨСТӘЛМӘЛӘРНЕҢ ЭКСПРЕССИВ-СТИЛИСТИК КУЛЛАНЫЛЫШЫ


**Г.А. НАБИУЛЛИНА**

Казанский федеральный университет, Казань


## ЭКСПРЕССИВНО-СТИЛИСТИЧЕСКОЕ УПОТРЕБЛЕНИЕ ПРИСОЕДИНИТЕЛЬНЫХ КОНСТРУКЦИЙ


**Аннотация**. В данной статье рассматривается экспрессивное употребление присоединительных конструкций в татарском языке. Дается краткий обзор исследования данных конструкции в татарском языкознании. На материале литературных произведений выявляются семантические функции присоединительных конструкции.

**Annotation**. This article examines the features expressiv use of connecting structures in the Tatar language. A brief review of the research of these constructions in Tatar linguistics is given. The material of literary works reveals the semantic functions of the connecting constructions.



**Ключевые слова:** татарский язык, синтаксис, татарское языкознание, экспрессивный синтаксис, присоединительные конструкции.

**Keywords:** Tatar language, syntax, Tatar linguistics, expressive syntax, connecting constructions.


Сөйләмдә, хис-тойгы белдерү өчен, поэтик синтаксик чаралар куллануны системалы рәвештә өйрәнү татар синтаксисының актуаль мәсьәләләреннән санала. Тел белемендә өстәлмә конструкцияләр XX гасыр урталарыннан башлап өйрәнеләләр. Бу юнәлештә рус галимнәре В.В. Виноградов, С.Е. Крючков, Н.В. Черемисина, Н.С. Валгина, Г.С. Шалимова, тюрколог-галимнәр Н.П.Петров, Б.Т.Турсунов, М.З. Зәкиев, Ф.С. Сафиуллина һ.б. хезмәтләре игътибарга лаек [Валгина, 1964; Виноградов, 1981; Закиев, 1963; Сабиров, 1956; Сафиуллина, 1990].

Тел гыйлемендә “өстәмә бәйләнеш” терминын беренчеләрдән булып Л.В.Щерба тәкъдим итә, өстәлмә конструкцияләрнең матур әдәбият әсәрләрендә экспрессив-стилистик кулланылыш үзенчәлекләрен җентекләп тикшерүче, аларга нигезле билгеләмә бирүче буларак В.В.Виноградов санала [Виноградов, 1981]. Өстәлмә конструкцияләр дип галим “бер мәгънәви яссылыкка сыешмаган, ләкин бер ассоциатив чылбыр төзегән фразалар җыелмасын” атый һәм аларның эмоциональ-экспрессив төркемчәләрен аерып чыгара [Виноградов, 1981: 286].

Татар телендә өстәлмә конструкцияләргә беренчеләрдән булып К.Сабиров игътибар итә. “Татар телендә тыныш билгеләре” хезмәтендә галим әлеге синтаксик күренешне тиңдәш кисәкләр рәтендә тикшерә һәм, рус галимнәренә ияреп, аларны “өстәмә бәйләнеш” (“присоединительная связь”) дигән термин белән атый [Сабиров, 1956: 44] Галим, өстәлмә конструкцияләргә аңлатма биргәндә, “өстәлгән элементның теге яки бу экспрессив төсмер белән әйтелүенә” басым ясый [Сабиров, 1956: 104]. М.Зәкиев 50-60 нчы елларда язылган хезмәтләрендә өстәлмә конструкцияләргә игътибар итә һәм аларны ким җөмләләр рәтендә өйрәнә. Соңрак чыккан хезмәтләрдә галим бу төзелмәләрне аерым синтаксик күренеш итеп таный һәм “өстәлмә” дигән термин белән атап тикшерә [Закиев, 1963]. Татар тел белемендә өстәлмә конструкцияләрне җентекләп өйрәнүче галимә Ф.С.Сафиуллина “Татар әдәби телендә өстәлмә конструкцияләр” (1972) дигән мәкаләсендә өстәлмә конструкцияләрне, өйрәнү тарихы, аларның ритмик-мелодик яңгырашы, грамматик-структур һәм стилистик кулланылыш үзенчәлекләре ягыннан тикшереп, аларны синтаксик берәмлек итеп аерып чыгара. “Татар тел телендә сүз тәртибе” (1974) хезмәтендә галимә өстәлмә конструкцияләрне парцелляция күренеше белән тәңгәлләштерә һәм экспрессив синтаксик чара булуын күрсәтә. “Синтаксис татарской разговорной речи” (1978) дигән монографиясендә өстәлмә конструкцияләрнең җанлы сөйләмдә туган төзелмәләр булуы ассызыклана [Сафиуллина, 1990].

Өстәлмә конструкцияләр – тел белемендә күпьяклы күренеш. Кайбер телче галимнәр аларны синтаксик берәмлек буларак тикшерә, стилистиканы өйрәнүче галимнәр аларны поэтик синтаксис кысаларында стилистик алым итеп билгелиләр, экспрессив синтаксиста исә өстәлмә конструкцияләр хис-тойгы белдерү чарасы буларак карала. Термин мәсьәләсендә дә галимнәр уртак фикердә түгел: рус тел белемендә өстәлмә конструкцияләрне «присоединительная связь», «открытые или сдвинутые конструкции», «присоединительные конструкции», «присоединение»; татар тел белемендә «өстәмә бәйләнеш», «өстәлмә», «өстәлмә конструкцияләр» дип атау очрый. Безнеңчә, экспрессив синтаксик чара буларак әлеге күренешкә карата күпчелек галимнәр тарафыннан кабул ителгән өстәлмә конструкцияләр терминын куллану төгәл булыр.

Тикшеренүләрдән күренгәнчә, экстралингвистик һәм психофизиологик факторларга бәйле булган өстәлмә конструкцияләр тел белемендә иң элек җанлы сөйләмгә хас синтаксик үзенчәлек буларак билгеләнә. Соңрак аларны матур әдәбият, публицистика телендә әһәмиятле стилистик чара, яки синтаксик экспрессия чарасы буларак тикшерү үзәккә куела. Өстәлмә конструкцияләр структур-грамматик (Н.С.Валгина, Н.П.Петров) һәм стилистик (В.В.Виноградов, Г.С.Шалимова, Ф.С.Сафиуллина) яктан өйрәнеләләр, аларның төркемчәләре билгеләнә.

Өстәлмә конструкцияләр язма телгә җанлы сөйләм теленнән үтеп керә. Өстәлмә конструкцияләрнең җанлы сөйләм телендә киң кулланылышы анық алдан уйланмаган, язма тел законнары буенча формалашмаган булуы белән бәйле. Алар нәрсәнедер ачыклап килергә, аныклык кертергә, алда әйтелгәннәргә өстәмә мәгълүмат бирергә мөмкиннәр.

Теоретик тикшеренүләргә нигезләнеп, хәзерге татар әдәбиятыннан, аерым алганда, М.Мәһдиев, Т.Галиуллин, А.Хәлим, Н.Гыйматдинова, Р.Зәйдулла әсәрләреннән тупланган фактик материаллар өстәлмә конструкцияләрнең түбәндәге мәгънәви төркемчәләрен аерып күрсәтергә мөмкинлек бирде.

1. Билгеле бер деталь, факт, күренешләрне аерып күрсәтү, шуның ярдәмендә хисне тирәнәйтү: *Хәйруш кесәсеннән ак өстенә алсу шакмаклар төшкән кульяулыкны алып*

*борын төбенә китерде. Иснәде. Кульяулыктан җиңелчә генә хушбуй исе килә иде. Тагын нindидер ис. Ләйсән исе.* (Р.Зәйдулла) җөмләсендә язучы бер детальне (бу очракта – ис) өстәлмә конструкция итеп аерып чыгару ярдәмендә геройның сагыну хисен тагын да үтемлерәк итеп тасвирлый. Түбәндәге мисалда исә өстәлмә конструкцияләр ярдәмендә автор-хикәяүләүченең ярату, якын итү хисе тирәнәйтелә: *Каш өстендәге бәләкәй миңе яшь Габдерәхимнеке... Борыны да аныкы... Кабарынкы иреннәре дә.* (Н.Гыйматдинова).

2. Хиснең төрле төсмерләрен белдерү (борчылу, кайгыру, шатлану, гаҗәпләнү, аптырау, күрәлмау, шикләнү, икеләнү, түбәнсетү, ирония, кисәтү, шелтә, ышану, соклану, курку, кот очу, ачулану, кызгану, ярату, иркәләү, хуплау, мактау һ.б.): *Шулчак малайның кылган чәчкәләрен кемгәдер бик тә якын, бик тә якын кешесенә бүләк итәсе килеп китте. Әнисенә! Әнисенә, әлбәттә!* (А.Хәлим); *Авылда сугыш ордены икәү булган кеше бер Исламгали агай гына иде, көннәрдән бер көнне "Кызыл Йолдыз" орденын кайда, ничек алуын сораша башладылар.*

*– Монысын Жуков үзе бирде, күкрәккә адъютанты такты, – диде ул. Украинаны азат иткәндә. Тел алып кайттык. Шәп күркә эләкте. Офицер.* (М.Мәһдиев).

3. Кешегә хас сыйфатларга, аның үз-үзен тотышына тискәре яки уңай бәя бирү: *Сәет йөртүчесен машинаны күрше өй артына куярга өйрәткән иде. Гавамны борчымас өчен.*(Т.Галиуллин); *Энҗе шәһәр клиникасында палата врачы. Дәрәҗәле...*(М.Мәһдиев).

4. Логик яктан бер-берсенә капма-каршы булган төшенчәләрне, фикерләрне ассызыклау: *Борынга яңа сауган сөт исе килеп бәрелгәндәй булды. Нигәдер... Югыйсә Нәфисәнең сыеры юк бит дип аптырап уйланды ул...*(Р.Зәйдулла).

5. Сөйләүченең сөйләмгә карата мөнәсәбәтен чагылдыру: *Нәрсә булган – үткән, һәм аны берничек тә кире кайтарып булмый. Кирәкми дә.* (Р.Зәйдулла).

6. Вакыйга-күренешләрне төгәлләштереп килү: *Хәйрүшнең шунда гына башына барып җитте – бу Шамил Басаевның йорты икән. Булган...* (Р.Зәйдулла).

7. Билгенең, процессларның үсүен, зураюын, артуын күрсәтү: *Чәйнәргә, аңкауларда, теш төпләрендәге селәгәй безләрен актык чутына кадәр эшләтеп, чылатып, тамак юлын тутырып бер тапкыр ипи йотарга иде, юк, ике тапкыр... Юк, өч тапкыр, дүрт тапкыр...* (М.Мәһдиев).

Тикшеренүләрдән күренгәнчә, өстәлмәләр экспрессив синтаксик алым буларак татар әдәбиятында, бигрәк тә язучылар М.Мәһдиев, Т.Галиуллин, А.Хәлим, Н.Гыйматдинова, Р.Зәйдулла тарафыннан гаять оста файдаланылалар. Өстәлмә конструкцияләр билгеле бер деталь, факт, күренешләрне аерып күрсәтү, шуның ярдәмендә хисне тирәнәйтү өчен кулланылалар, хиснең төрле төсмерләрен белдерәләр, кешегә хас сыйфатларны, аның үз-үзен тотышына тискәре яки уңай бәя бирәләр. Шулай ук капма-каршы фикерләрне ассызыклау, сөйләүченең сөйләмгә карата мөнәсәбәтенең кинәт үзгәрүен чагылдыру өчен кулланылалар, вакыйгаларның кинәт үзгәрүен белдереп киләләр, билгенең, процессларның үсүен, артуын күрсәтәләр.

## ӘДӘБИЯТ


Валгина Н.С. Присоединительные конструкции в современном русском литературном языке. М., 1964. – 32 с.

Виноградов В.В. Проблемы русской стилистики. М.: Высшая школа, 1981. – 320 с.

Закиев М.З. Синтаксический строй татарского языка. Казань: Изд-во Казанского университета, 1963. – 464 с.

Сабиров К. Татар телендә тыныш билгеләре. Казан: Таткнигоиздат, 1956. – 184 б.

Сафиуллина Ф.С. Развитие синтаксического строя татарского литературного языка (XX век): Автореф. дис. ... д-ра филол. наук. Казань, 2000. – 119 с.

Сафиуллина Ф.С. Развитие синтаксического строя татарского литературного языка в советский период (простое предложение). Казань: КГУ, 1990. – 230 с.

## ЧЫГАНАКЛАР

Галиуллин Т. Төнге юллар. Казан: Матбугат йорты, 2003. – 318 б.

Гыйматдинова Н. Бер тамчы ярату. Казан: Тат. кит. нәшр., 2006. – 351 б.

Зәйдулла Р. Ташка ордым башны. Казан: Тат. кит. нәшр., 2008. – 399 б.

Мәһдиев М. Бәхилләшү. Казан: Тат. кит. нәшр., 1999. – 256 б.

Хәлим А. Кыйбла. Казан: Тат. кит. нәшр., 2005. – 382 б.

**А.Ф. НӘГЫЙМОВА, Т. Ш.ГЫЙЛАҖЕВ**

Казан федераль университеты, Казан

## Г.ИСХАКЫЙНЫҢ “ТАҢЧЫ”ЛЫК ЧОРЫ ПЬЕСАЛАРЫНДА КОНФЛИКТ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ

**А.Ф.НАГИМОВА, Т.Ш. ГИЛАЗОВ**

Казанский федеральный университет, Казань

## ОСОБЕННОСТИ КОНФЛИКТА В ПЬЕСАХ «ТАНГИТСКОГО» ПЕРИОДА Г.ИСХАКИ

**Аннотация:** Творчество Г. Исхаки является плодотворной площадкой для изучения различных историко-литературоведческих проблем. В данной статье рассмотрены и проанализорованы пьесы “тангитского” периода писателя. Предмет исследования работы - особенности конфликта в драматических произведениях данного периода.

**Abstract:** The work of G. Iskhaki is a fruitful platform for the study of various historical and literary problems. This article examines and analyzes the dramas of the "tangit" period of the writer. The subject of the study is the originality of the conflict in the dramatic works of this period.

**Ключевые слова:** Драма, комедия, конфликт, характер.

**Keywords:** Drama, Comedy, conflict, character.

Яңа реалистик татар әдәбиятына нигез салучы Гаяз Исхакыйның 1917 елгы Октябрь инкыйлабына кадәрге иҗатын язучының дөньяга карашы, җәмгыятьтәге үзгәрешләргә мөнәсәбәте, әдәби-эстетик зәвыгы, сәнгатьчә фикерләве, әсәрләренең идея юнәлеше, язу стилеягыннан фәндә өч чорга бүлеп тикшерү гадәткә кергән:

1. Мәгърифәтчелек дәвере (1898-1904);
2. “Таң”чылык чоры (1905-1910);
3. Милләтчелек дәвере (1911-1918) [Гыйлаҗев, 2007: 18-19].

Һәр чор иҗатының үзәгендә язучының шушы дәвердәге иҗтимагый, әдәби-эстетик карашларын гәүдәләндергән үзенчәлекле герой, проблемалар тора.

“Таңчы”лык чоры дип аталган иҗатының бик уңдырышлы, көчле этабында Гаяз Исхакый өч драма иҗат итә – “Тартышу”, “Алдым-бирдем”, “Мөгаллим”. Аларда татар җәмгыятендә милләт үсешенә каршы торучы көчләрне фаш итү үзәктә тора. Мондый көчләр рәвешендә иске карашлы кешеләр, бигрәк тә дин әһелләре күрсәтелә. Драматург аларның тормышта табигый яңарышка агымына каршы торырга тырышуларының мәгънәсезлеген күрсәтә, бер үк вакытта, кире кагылган иске тормыш моделе белән янәшә, милләтне үсешкә, яктыга алып чыгачак юл да, яңалыкка йөз тоткан иҗтимагый үсеш моделе дә билгеләп куела. Әсәрләрдәге иҗтимагый-сәяси эчтәлекле публицистик код татар укучысын, тамашачысын милләт мәнфәгатьләрен кайгыртып көрәшкә чакыру, өндәү төсендә кала.

Әдипнең “Алдым-бирдем” драмасы 1907 елда Казан төрмәсендә утырганда язылуы белән билгеле. “Әсәрдә төп фикер буларак, мәхәббәт, никах, кеше хокукы проблемалары куелган, бу мәсьәләгә караштa “аталар”һәм “балалар”, кадимчеләр белән җәдитчеләр, консерваторлар белән европалашкан зыялылар арасындагы тартыш-көрәш күрсәтелгән” [Галимова, 2018: 123].

“Алдым-бирдем” драмасы исә гомумән “аталар һәм балалар” проблемасын ачуга буйсындырылган. Драманың героинясе заманчарак тәрбия алган Галия ачынып “*бер яктан тегесе кыса, бер яктан болары кыса, менә юлын тап инде, гәзитә әйткәнчә менә болар белән тартыш инде! Әмма тартышам! Актыгына кадәр тартышам*” Исхакый, 2003: 398], - ди.

Дөрес, бу әсәрдә яңалык белән искелекнең көрәше әле яшьләрнең шәхси бәхетләре өчен көрәше рәвешендә гәүдәләндерелә, ул искелекнең гәүдәләнеше булган “аксак хатыннар” дөньясының җиңелүе һәм мәхәббәтнең тантанасы белән тәмамлана.

Ә “Тартышу” тарихи-инкыйлабый драмасында исә искелек белән яңалыкның көрәше киңрәк планда алына, татар тормышын һәрьяклап колачлый, халыкның ихтыярын басып торган караңгылык, тәгассыблык күренешләренә каршы юнәлдерелә. *“Без,* — дип белдерә драма геройларының берсе, — *рус шәкертләре кебек мәктәп балалары гына түгел, без иске гадәт, иске тормыш белән тартышучылар, иске дөнья белән сугышучылар, безнең укуыбыз, безнең киләчәк хезмәткә хәзерләнүебез — һәммәсе иске тормышны ватар өчен, бетерер өчен, без үзебезнең һәрбер адымыбыз, һәрбер хәрәкәтебез белән иске тормышның нигезен җимерәбез... Без — яңа тормышның алдагы гаскәре. Безгә һәр минутта, һәр секундта иске тормыш белән сугышырга туры килми хәл юк”* [Исхакый, 2003: 440].

Бу пьесада татар җәмгыятен тамырдан үзгәртеп кору бөтен Россия күләмендәге революция аша гына, илдә гадел, демократик тәртипләр урнаштыру нәтиҗәсендә генә мөмкин булыр дигән фикер үткәрелә. Драмада “тартышу” күптөрле мәгънәләрдә килеп, аеруча киң яңгыраш алганнары түбәндәгеләр: патша самодержавиесе белән тартышу; искелек-яңалык тартышуы; аталар һәм балалар тартышуы; ирек өчен тартышу; партияләр арасындагы тартышу; ике сыйныф арасындагы тартышу; геройның эчке дөньясындагы тартышу һ.б.

“Мөгаллим” (1907) драмасында гади халыкка аң-белем таратуга, яңарышка өндәүгә нигезләнгән әлеге күренеш үзәк мәсьәлә буларак урын ала. Төп герой – мөгаллим Салих милләткә хезмәт итү идеалы белән яшәсә дә, максатына ирешә алмаганга, рухи газап кичереп яши. Ул авыл халкын әдәп-әхлакка, белем-мәгърифәткә тартып, аларны авыр тормыштан коткарырга тели. Автор Салихның уй-фикерләрен, эш-гамәлләрен авыл крестьяннарының каршылыклы тормышы белән үреп бара. Моңа

төрле социаль катлаулар арасындагыкаршылык-бәхәсләр килеп кушыла. Ә инде гаилә кору, балалар туу белән Салих күңелендәге каршылык тагы да арта. Күренекле галимә Р.Ганиева билгеләп үткәнчә, “өйләнү, гаиләле булу ир кешенең җәмгыять эшчәнлегенә аяк чала дигән толстойчылык карашлары”на [Ганиева, 1998: 67] барып тоташа. Салих, яшәвенең мәгънәсе, иң зур теләк-хыялы халкына хезмәт итүдә, дигән фикергә килә. Нәтиҗәдә бертөрле генә бәяләнми торган адым ясый – хатынын, балаларын калдырып китә. Гаилә “тышавы”ннан арынып, үзен тулысынча халкына хезмәт итүгә багышлый.

Драманың төп образы мөгаллим Салих милләткә хезмәт итү идеалы белән яшәсә дә, максатына ирешә алмаганы өчен һәрдаим үзе белән эчке диссонанс кичереп яши. Ул авыл халкын әдәп-әхлакка, белем-мәгърифәткә тартып, аларны авыр тормыштан коткарырга тели. Автор Салихның уй-фикерләрен, эш-гамәлләрен авыл крестьяннарының каршылыклы тормышы белән үреп бара. Салих характерына автор милли көрәшче, мәгърифәтче чалымнарын йөкли.

Гаяз Исхакыйның “таң”чылык чорына караган комедияләре – икәү. Язучының “Җәмгыять” (1909) һәм “Кыямәт” (1909) комедияләре искелек-артталыкны фаш итү пафосы белән сугарылган. Әдип “Җәмгыять”тә һәртөр наданнардан, бушкуыклардан, үзләрен җирнең кендеге дип санап та берни эшли белмәүче икейөзлеләрдән ачы итеп көлә. Мохтаж-ятимнәргә ярдәм итәргә тиешле хәйрия җәмгыяте оештырырырга йөреп тә, сүзләре һәм эш-гамәлләре кеше тикшерүдән, мактанышудан узмаган кара йөзләрне автор татар җәмгыятенең эчке хәленә нисбәтле сурәтли. Комедия геройлары (араларында Муса мирза аерылып тора) зур булмаган штрихлар белән генә бирелсә дә, драматург үз чорының социаль йөзен, тулы образын тудыра. Шул рәвешле, әдәп-әхлак, дини мәсьәләләр белән үрелгән хәлдә чынбарлыкның җитди социаль-иҗтимагый проблемалары калкып чыга, аларга җавап эзләнә.

“Кыямәт” сатирик комедиясе –халыкчан, карнавал рәвешендәге көлүгә йөз тоткан пьеса. Автор “алтын язулы күкәй”не образ-символ дәрәҗәсенә күтәреп, яңалык дошманнарының ялган битлеген салдыра һәм чын йөзләрен ача.

“Җәмгыять” һәм “Кыямәт” комедияләренең эчтәлеген татар дөньясындагы вакыйгалар тәшкил итеп, каһарманнары милли типлар булсалар да, күтәрелгән проблемалар, идея-эстетик мәгънәсе, пафосы гомумкешелек әһәмияткә ия. Ул әсәрләрдә, милли аерымлыкларга карамастан, гомумән кешеләргә хас булган тискәре сыйфатлар – саранлык, тупаслык, комсызлык һ.б. көчле сатира уты астына алына.

Комедияләрдә дә көлкеле каршылык холык-фигыльләрнең төрлелеген ача. “Ләкин, драма һәм трагедиядән аермалы буларак, комик каһарманның табигате үзгәрми, үсештә күрсәтелми. Комик геройның мәгънәсезлеген, кимчелекләрен күрсәтү, шуны юмор яки сатира дәрәҗәсендә кире кагу комедиянең төп юнәлешен билгели” [Заһидуллина, 2004: 140].

Шулай итеп, Г. Исхакыйның 1917 елгы революцияләргә кадәр язылган драма әсәрләренә зур булмаган күзәтү дә әдипнең татар сәхнә әдәбиятын формалаштыру, аякка бастыруда мөһим, хәтта хәлиткеч роль уйнавын күрсәтә. Ул драматургиябезне яңа тема-мотивлар белән баета, җитди мәсьәләләрне алгы планга чыгарып, күпсанлы укучы-тамашачыларны үз артыннан ияртә, яңа жанрларга, сәнгати чара-алымнарга нигез сала. XX йөз башы драматурглары, аның «Ике йөз елдан соң инкыйраз»ы белән бергә, без югарыда искә алган күпсанлы пьесаларындагы табыш-яңалыкларга да даими мөрәҗәгать итә, иярә, бәхәскә керә һәм яңа тормыш материалында аларны үстерә, баета һәм алдагы чор сәхнә әдәбиятына китереп ялгый.

**ӘДӘБИЯТ**

Ахмадуллин А.Г. Драматургия // История татарской литературы нового времени (XIX – начало XX в.). Казань: Фикер, 2003. – С. 406-428.

Галимова Э.М. Г.Исхакый әсәрләренең Г.Камал театры куелышында музыкаль бизәлеш үзенчәлеге // Гаяз Исхаки и национальное возрождение татар в начале XX века: материалы международной конференции, посвященной 140-летию со днярождения Г. Исхаки / сост.: Ф.Х. Миннуллина, А.Ф. Ганиева, Л.Р. Надыршина. Казань: ИЯЛИ, 2018. – Б. 121-125.

Ганиева Р.К. Исхакый иҗаты // Мирас, 1998. №5. – Б. 63-78.

Гыйлаҗев Т.Ш. Татар әдәбияты. XX гасыр башы: Лекцияләр, гамәли дәресләр, тестлар: Югары уку йортлары өчен уку әсбабы. Казан: Мәгариф, 2007. – 239 б.

Заһидуллина Д.Ф. Мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – Яңадан эшләнгән һәм тулыландырылган икенче басма. Казан: Мәгариф, 2004. – 367 б.

Исхакый Г. Әсәрләр. 15 томда. Т.4. Пьесалар (1900–1918). Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 496 б.

**Б.Х. НУРАБУЛЛАЕВ**

Бердақ атындағы Қарақалпақ Мәмлекетлик университети, Нөкис

## МЕМУАРЛЫҚ ШЫҒАРМАЛАРДА ДӘЎИР КӨРИНИСИ
## (Т.Алланазаровтың «Заман гәрдиши» мемуары мысалында)

**Б.Х. НУРАБУЛЛАЕВ**

Каракалпакский государственный университет им. Бердаха, Нукус

## ОТРАЖЕНИЕ ОБЛИКА ВЕКА В МЕМУАРАХ
## (на примере мемуаров Т.Алланазарова «Картина времени»)

**Аннотация:** В данной статье рассматривается вопрос отражения картины времени (эпохи) в мемуарах Т.Алланазарова «Картина времени»). Цель статьи – анализ отражения действительности отражаемого периода, историко-социальных проблем в анализируемом произведении; выявление значимости такого рода произведений в отражении исторической реальности. Данная проблема доказывается примерами из названного труда.

**Abstract.** This article discusses the issue of reflecting the picture of time (era) in T. Allanazarov's memoirs "Picture of Time"). The purpose of the article is to analyze the reflection of the reality of the period being reflected, historical and social problems in the analyzed work; identifying the significance of this kind of works in the reflection of historical reality. This problem is proved by examples from the named work.

**Ключевые слова**: мемуар, отражение времени, данные, исторические факты

**Keywords:** memoir, reflection of time, data, historical facts

Илим ҳәм техникалық, жәмийетлик-сиясий процесслердиң дүньяға жаңа көзқарасларды пайда етиўи әдебияттың да идея-тематикалық, мазмунлық, көркемлик-стиллик жақтан жаңа сапалық басқышқа көтерилиўине тийкар жаратты. Әсиресе, тарийхқа болған көзқарастың өзгеше түс алыўы, яғный тарийхты үйрениўдеги дурыс бағдарды табыў, ҳақыйқатты билиўге деген қызығыўшылық көркем ҳүжжетли (мемуарлық) әдебиятты жеделлестирип, бурмаланған тарийхый ҳақыйқатлықларды жүзеге шығарыў

ҳәм китап оқыўшыларының көркем-эстетикалық талабын қанаатландырыўда мемуарлық үлгиде жазылған шығармалардың әҳмийети арта баслады.

Мемуарда өткен ўақыт ҳаққында мағлыўматлар жазылады, демек, ол сол дәўирдиң көриниси болып, бәрҳама адамлардың өзи ҳәм заманы ҳаққында гүўалық бериўши, бир адам турмысының кең көлемли, ямаса пүткил бир әўлад өмириниң тарийхый ҳақыйқатлары сүўретленеди.

«Мемуар – бир жағынан тарийхый ҳүжжет, екинши жағынан жазыўшының өзи туўралы пикир беретуғын, тийкарынан оның ишки дүньясын ҳүжжетлестиретуғын көркем текст. Оның мазмуны узақ яки жақын өтмиштиң (индивидуаль) жекке бөлеклери болып, мемуар текстлери мәлим бир шахс, ўақыялар, ҳәдийселер арқалы өтмиш ўақыяларының тарийхый анықлығын қайта тиклеўге жәрдем береди» [Георгиева, 2012: 3]. Мемуарист тек ўақыяларды сүўретлеп қоймайды, бәлки, бир нәрселерди анықластырады, қайсыдур ўақыяларды қайта ой елегинен өткизеди ҳәм баҳа береди. Сонлықтан да көбинесе мемуарлық шығармалардың жазылыў мақсети: «…тарийхый материал қалдырыў ҳәм болып өткен ўақыяларды ҳәр тәреплеме тексерип көриў» ден ибарат [Холбоев, 1998: 4].

Қарақалпақ әдебиятында Т.Алланазаровтың «Заман гәрдиши» (1991), Ж.Аймурзаевтың «Қара бултлар» (1993), Х.Сейтовтың «Ызалы әрман излери» (1993) сыяқлы мемуарлық шығармалары да тарийхый дәреклерде көмескиленген айырым гүмилжи, гүңгирт ўақыяларды еслеў, баҳа бериў арқалы тарийхый ядты қайта жаңғыртыў, дәўир шынлығын келешек әўладқа жеткизиў ҳәм китап оқыўшыларын өтмишти талқылап, ҳәзирги ўақыт ҳәм келешек туўралы түсиникке ийе болыўында үлкен әҳмийетке ийе.

Бизиң мақаламыз қарақалпақ миллий театрын қәлиплестириўге, театр мәдениятын раўажландырыўға драматург, режиссер, аўдармашы, театр көркем өнерин изертлеўши ҳәм театр сыншысы сыпатында салмақлы үлес қосқан көп қырлы талант ийеси Т.Алланазаров (1916-2000ж.ж.) «Заман гәрдиши» мемуарлық шығармасында дәўир көринисиниң сүўретлениўин талқылаўға арналады.

«Заман гәрдиши» мемуарлық дөретпеси композициялық жақтан кирис сөз, қысқаша жуўмақтан тысқары «Жаңа заман, дәслепки тәсирлер», «Қатарға қосылыў жолындағы ҳәрекетлерим», «Тәлим берген Москва», «Сынақлы күнлер», «Илим жолындағы қәдемлерим», «Сүрингенде сүйеген Ташкент», «Ат айланып үйирин табар» деген темалар менен аталған үлкен сегиз бөлимге бөлинип сүўретленген. Мемуар жазыўшы алдына қойған мақсетин, шығарманың идеясын анық көрсетип, өзи гүўасы болған, есинде қалған ўақыяларды өз бақлаўлары ҳәм талқылаўлары тийкарында баян етеди.

Т.Алланазаровтың сол дәўирдеги әдебиятқа, көркем өнерге деген халықтың көзқарасын С.Мәжийтов, Х.Ахметовтың дөретиўшиликлери мысалында бериўи «халықтың жалпыламай садалықтан саналылық дәўирге өте баслағаны» ҳәм орта мағлыўматлы халық санының көбейиўи ҳаққындағы мағлыўматлар оқыўшыға халықтың көркем-ой санасындағы өзгерислер менен бирге заман, дәўир руўхын айқын сезиниўи ушын әҳмийетли. Сондай-ақ, шығармада мемуар авторының қарақалпақтың белгили зиялылары менен танысыў эпизодының сүўретлениўиниң әҳмийетли мазмуны сонда: Қарақалпақстанда жаңа ҳәкимиятты дүзиўши, жаңа мәдениятты қәлиплестириўши миллий шахслардың образы, олардың сол дәўирдеги халық ушын күни-түни ислеген пидайы мийнетлери, уллы мақсетлери туўралы оқыўшыға толығырақ ҳәм тәсирли мағлыўмат береди.

Бул шығармада XX әсирдиң басындағы халықтың жәмийетлик-социаллық турмыс көринислеринен хабар беретуғын нақлы фактлер ҳәм дәреклерге де айрықша дыққат аўдарылғанын көриў мүмкин. Т.Алланазаровтың Төрткүл қаласында билим алған оқыўшылық дәўири Қарақалпақстанда Кеңес ҳүкиметиниң қыйсынсыз қарарларының ҳәўижге минген, сондай-ақ, жаңа ҳүкиметтиң ағзалары болған, бурын ҳешқашан ҳеш жерде ҳеш ел басқарып көрмеген уқыпсыз бадырақлардың (*батрак Н.Б*) себебинен елдиң ашаршылыққа гириптар болған дәўирине туўра келеди. Сол ўақытлардағы халықтың ашынарлы аўҳалын ҳәм дәўирдиң тарийхый, жәмийетлик-социаллық картинасын автор өзи гүўасы болған ҳәдийсени мысал келтириў ҳәм анық дәреклер менен оқыўшы көз алдында сәўлелендиреди:

*«...Мен жағаға жақын жердеги көл ишине кирип бир жал қамыслықтан өте бергенимде суўынлап қойған бир шоқат баўлы қамысларға көзим түсти. Қамыс орыўға еринип, усы суўынлап қойған шоқат қамыстан еки баў қамыс алмақшы болып қасына жуўырып барғаным, бириниң үстине бирин текшелеп қойған көп өли адамларға көзим түсип қорыққанымнан тас есимди жоғалтып қоя жазладым. ... Булар усы жыллары ашлыққа ушырап Қазақстаннан посып келген ағайинлер еди. Мәжбүрий колхозласыў мапазының аўыр ақыбетине гириптар болған бул бахытсыз адамларға жәрдем қолын созыўға жергиликли халықтың өзлери де әззи еди»...*

*Және бир қызық жери өзлериниң қолы менен еккен дақылынан жан сақлаў ушын баў алып ишиў қадаған. **1932-жылдың 7-август** қарары бойынша: «Кимде-ким колхоздың орталық атызынан масақ терип, дән урласа, яки болмаса колхоздың мал фермасына қыянет қылса, өзи атыў жазасына буйырылады, мал-мүлки конфискацияланады» деген статьялар көрсетилген. Халық бул қарарды күйгенинен «Масақшылар» қарары деп атаған. Себеби, сол қарарда көрсетилген жазаға **6** дана буўдай масағы менен қолға түссе жетерли болған. Соңғы жыллары баспасөзде жәрияланып атырған ески тарийхый документлерге қарағанда, сол жыллары усы қарар менен Советлер Союзында **55 мың** адам жазаланған, соның **2100** адамы атыў жазасына, **52** мың адамы **10 жыл** қамақ жазасына тартылған».* [Алланазаров, 1993: 1]

Өзиниң жеке тәжирийбесине сүйене отырып автордың бурын болған ўақыяларды яды арқалы жеткизе билиўи оқырманның санасына емес, оның сезимлерине де күшли тәсир етеди. Сол көзқарастан алғанда, мемуарлық шығармалар оқыўшыға әлемди өткен менен бүгинниң кесилиспесинде қабыллаўға мүмкиншилик береди. Жоқарыдағы таллаўларда мемуардың жанрлық тәбиятына тән еки бағыт көзге тасланады: 1) ***сыртқы*** (оқыўшыға қатнаслы) және 2) ***ишки*** (автордың өзине белгили жағдайларды тәртипке келтирип, тағы бир рет сезиниўи). Мине, усы бағдарда мемуар авторы сол жыллардағы ашаршылық, Кеңес ҳүкиметиниң «Халық жаўы» деген түсиник пенен елдиң бетке тутар азаматларын қырғынға ушыратқан сиясий терроршылық ҳәрекетлерин, дәўирдиң ашшы шынлығын жанр талабына сай тартымлы сүўретлеген.

Бул жерде бизиң айрықша дыққат қаратыў керек мәселемиздиң бири: үйренилип атырған дөретпеде дәрек-мағлыўматлардың толықлылығы ҳәм исенимлилиги, факт ҳәм мағлыўматлардың сүўретлениў усылларының өзине тән өзгешелигин де анықлаў болып табылады. Мәселен орыс илимпазы А.Галич украин жазыўшыларының мемуарлық дөретпелерин изертлеў тийкарында ол мемуарлардың төмендеги белгилерин көрсетеди:

«Субъективлик ямаса жеке баслама, өтмишти еслеў, ҳүжжетлилик, еки ўақытлы жобаның болыўы, ўақыяларға автордың еки тәреплеме көзқарасының берилиўи (шығарманың авторы ҳәм оның қаҳарманы сыпатында) … автор баянлаўды тек бир

ўақытлық өлшемге орналастырмайды, ўақыялар ҳәрдайым мемуаршының белгили бир бирлеспелерге ийе болыўына себеп болады, сонлықтан ҳәзирги ҳәм өткен ўақыт бәрҳа болады» [Галич,1991: 2].

Биз жумысымызда таллаўға тартқан «Заман гәрдиши» мемуарлық шығармасында *дәўир турмысы, социаллық-мәдений қатнаслар, келтирилген фактлердиң бири-бирин толықтырыўы, мағлыўматлардың исенимлилиги, шығармада автордың бирде қаҳарман, бирде автор позицияларын ийелеп отырыўы, ўақыяларға еки тәреплеме көзқарастан жантасыўы, естеликлердиң ҳәзирги ҳәм өткен ўақыт формасында баян етилиўи* сыяқлы илимпаз тәрепинен көрсетилген **улыўмалық белгилердиң болыўы** мемуар авторының жанрдың баслы көркемлик талапларына әмел еткенин көрсетеди.

Растительные коды используются в свадебных диалогах и как олицетворение отрицательных черт невесты. Родственницы жениха при встрече свадебного поезда поют невесте корильные песни: *Нупониить, пангоить, / Кияк лангозот эзь ванно. / Нупонеть сатыть ташто кудонь подробамс, / Пангот сатыть кудань-андань каванямс* [Село Шугурово, 2018: 34] («Замшела, грибами заросла, Никому ты не нужна была, / Мха твоего хватит старый дом проконопатить, / Грибов хватит всех поезжан накормить») (перев. авт.). В ответ на эти укоры невеста вступает в экспрессивный диалог с родней жениха, где звучат *сильдей* «осока», *раужо вирь* «черный лес», *керязь вирь* «срубленный лес»:

*Сильдей* потмонь ватракштне,

*Раужо вирень* раужо гуйть,

*Керязь вирень* коткудавт.

Неть монь сэрень покордыцян?! [Село Шугурово, 2018: 35].

(Заросшего осокой болота лягушки, Темного леса черные змеи, Срубленного леса муравьи. Вам ли мою стать оскорблять?! (перев. авт.).

Родственницы жениха в полемическом задоре стремились «поставить на место» не только род невесты, но и ее подруг, которые держали «оборону» девичьего городка, и в своих припевках остро злословили в адрес поезжан. Родственницы жениха, подбирая наиболее язвительные и бьющие в цель слова, среди которых есть дендрологические обозначения *эрьба* «ивняк», *нар* «луговина», *берянь пангт* «грибы поганки», пели:

Кодат Матрянь ялганзо?

Покштнэ – задкат-передкат,

Вишкинетне – цёрашкат,

*Эрьбань* поре барякат,

*Наронь* гади тулякат

Навоз лангонь *берянь пангт* [Село Шугурово, 2018: 36].

(А какие у Матрены подруги? Большие – задки-передки, Маленькие – как взрослые парни, Вербу грызущие овцы, Луговину портящие поросята, Нечистоты жрущие поросята, Навозной кучи бледные поганки (перев. авт.).

В острых уничижительных стихах использовались и другие коды с характерной семантикой. Характеризуя жизнь в доме свекрови невеста причитает:

Ятонь кедьсэ эрямось,

Чужоень мелень ваномась –

*Чурькадояк* чапамо,

*Кшуманьдеяк* противна [Село Шугурово, 2018: 50].

(Жить в чужом доме, Угождать чужим людям. Это горше лука, Хуже хрена (пер. авт.).

В приведенном случае активно используются наиболее меткие выражения *чурькадояк чапамо, кшумандеяк противна*. Среди них встречаются иноязычные заимствования. К примеру, слово *м. кушмань kuљman', э. kљuman'* «редька» восходит к чувашскому *кушам* «брюква». Свадебная поэзия включает разнообразие и других иноязычных растительных кодов, например: м. комля koml'a э.комоля komol'a «хмель» < чув. хамла «хмель». Во время проводов невеста, обращясь к подругам, говорит им:

Шожда *комолякс* лиседе,

Кевери *ксновкс* кевереде [Село Шугурово, 2018: 95].

(Легким хмелем выйдите, Круглым горохом катитесь (перев. авт.).

Набор языковых средств в причетах невесты разнообразен. Встречаются коды-олицетворения в виде цветов:

Бояравaт, ялгинеть!

*Пиже лугань горнипов цецят*, ялгинеть,

*Парина паксянь мазы цецят*, ялакскеть! [Село Шугурово, 2018: 99].

(Боярышни, мои подружки! Зеленого луга купальницы, подружки, Зеленых паров красивые цветы, подруженьки! (перев. авт.).

В вышеприведенном случае растительные коды представлены словами из языка соседних народов. Так, примеру, эрзянское *цеця* с'ес'а «цветок» восходит к татарскому *чэчэк, чэчкэ* «цветок».

Важным свойством мордовской свадебной поэзии является то, что встречаются целые сцены, в которых употребляются растительные коды. Так, к примеру, приезда сватов за невестой девушки со стороны жениха поют:

Сватонть кустема песэнзэ

*Пижень* мазый *лугине,*

*Тусто килейбулыне.*

А узерьсэ керяви,

А пилязьгак пиляви [Село Шугурово, 2018: 81].

(Перед крыльцом свата, Зеленый красивый лужок, Густая березовая роща. Ее и топором не срубить, Ее и пилой не спилить (перев. авт.).

В свадебных текстах упоминаются и такие символы-олицетворения, как *куз цецёвкат, мак, груша*: *Куз цюцёвкат монь сурнэм, Мако лопань кондят турвинем* [Село Шугурово, 2018: 81], («Словно еловые шишечки мои пальчики», / «Как маковы лепестки губы мои») (перев. авт.); *Почкинешка эчкинем, / Грушинешка лицинем* [Село Шугурово, 2018: 84], («С веретено моя толщина, / Как грушица мое личико») (перев. авт.).

Среди растительных кодов встречаются довольно экзотические растительные коды. Во время прощания с девичеством невеста говорит о том, что она вместо себя в родительском доме оставляла дерево *кипарис*, которую срубила сваха-пчелиная матка:

Сыреждинь толгась мекшавась,

*Кипарис* чувтонть керизе,

*Кипарис* чувткенть янгизе [Село Шугурово, 2018: 85].

Растительные коды можно выделить в причетах невесты, посвященных отцу, где упоминается ряд дендрологических образов *(выделено курсивом)*:

Монь кастомдо-трямодо,

Молевлить лучше, тетякай,

*Вирьга-укшторга* ютавлить,

*Пиче вирне* саевлить, [Село Шугурово, 2018: 91].

*Тумо вирне* саевлить,

*Ёлганя тумот* керявлить.

Покш ки лангс, корьмакай

Лисьмине теевлить [Село Шугурово, 2018: 92].

(Вместо того, чтобы вырастить меня, Пошел бы ты тятенька, Лесом кленовым прошел, Лес сосновый (делянку) купил бы, Дубовый лес (делянку) приобрел бы, Стройные дубы срубил бы. На большой дороги, кормилец, Родниковый сруб изготовил (перев. авт.).

Растительный код, используемый в народной культуре, отражает мировоззренческие представления, опыт культурно-символического и мифологического освоения мира. Он тесно связан с местной ландшафтной зоной, природно-климатическими особенностями края, с его растительным миром, хозяйственными и промысловыми занятиями.

## ЛИТЕРАТУРА

Бакиров М.Х. Татарский фольклор. Казань: Ихлас, 2012. – 400 с.

Зеленин Д.К. Тотемический культ деревьев у русских и у белорусов // Известия АН СССР. Серия VII, 1933. № 8. – С. 591–629.

Миннуллин К. М. Растительная символика в песенной поэзии народов Поволжья и Приуралья // Ядкар, 2008. № 2. – С. 107–109.

Рогачев В.И. Свадьба мордвы Поволжья: обряд и фольклор (историко-этнографические, мифологические, региональные и языковые аспекты). Саранск: Мордов. кн. изд-во, 2004. – 384 с.

Рыбаков Б.А. Язычество древних славян. – изд. 2-е. М.: Наука, 1994. – 608 с.

Село Шугурово: история, люди, культура (историко-этнографические и филологические заметки) / сост. В.И. Рогачев. Саранск, 2018. – 198 с.

Чувашев М.И. Духовное наследие народов Поволжья: живые истоки

Чувашев М.И., Касьянова И.А., Шуляев А.Д. Самара: Изд-во СамГПУ, 2001. – 536 с.

Центральный государственный архив Республики Мордовия, фонд рукописный – 267, оп. 1, д. 26; д. 27; д. 28; д. 48; д. 65; д. 67; (в тексте – ЦГА РМ ФР).

**Д.Р. САБИРҖАНОВА**
Казан федераль университеты, Казан

# Ф. ХӨСНИ ӘДӘБИ-ТӘНКЫЙДИ ЭШЧӘНЛЕГЕНДӘ Г. ТУКАЙ ИҖАТЫ

**Д.Р. САБИРЗЯНОВА**
Казанский федеральный университет, Казань

# ТВОРЧЕСТВО Г. ТУКАЯ В ЛИТЕРАТУРНО-КРИТИЧЕСКОЙ ДЕЯТЕЛЬНОСТИ Ф. ХУСНИ

**Аннотация.** В данной научной статье рассматриваются литературно-критические статьи Ф. Хусни, посвященные творчеству Г. Тукая. Ф.Хусни – ученый, критик, писатель, оставивший глубокий след в истории татарской литературы и критики. Известно, Ф. Хусни не мог не высказаться о великом поэте. Статьи *«Во время открытия памятника Г. Тукаю» (1956), «Мысли о Тукае» (1966), «Трагедии Тукая» (1076-1977)* посвящены психологии творчества поэта. При анализе Ф. Хусни руководствуется творческим, национальным и моральным принципами.

**Abstract.** This scientific article examines literary and critical articles by F. Husni devoted to the work of G. Tukai. F. Husni is a scholar, critic, and writer who left a deep mark on the history of Tatar literature and criticism. It is known that F. Husni left own opinion about the great poet. The articles "*During the opening of G. Tukai'smonument*"(1956),"*Thoughts about Tukai* "(1966),"Tragedies of Tukai" (1076-1977) are devoted to the psychology of the poet's work. In the analysis, F. Husni is guided by creative, national and moral principles.

**Ключевые слова:** Литературная критика, Фатих Хөсни, Габдулла Тукай, поэт, психология творчества.

**Keywords:** Literary criticism, HatihHusni, poet GabdillaTukai, Tatar poetry, critical activity, creativity of GabdullaTukai.

Ф. Хөснинең иҗат портретына характеристика биргәндә, Р. Сверигин аның үзенчәлеген яратып куллана торган тел әйләнмәләрендә, чагыштыруларда, детальләрдә һәм башка сәнгать бизәкләрендә күрә. Әлеге иҗат принцибы язучының проза өлкәсенә генә карамый, ә әдәби-тәнкыйди эшчәнлегендә дә киң кулланыла. Г. Тукай иҗаты Ф. Хөснинең тәнкыйди призмасында традицион, схематик бәя бирүдән азат ителә. Тәнкыйтьче, Г. Тукайның иҗат итү принципларын, алшартларын тикшерә, анализлый. Шагыйрьгә генә хас фикерләүне, тормышны үзенчә сурәтләүне, кешеләргә мөнәсәбәтен ачырга тырыша. Билгеле, Ф. Хөсни бер мәкаләдә язучының иҗади юлын һәр яктан җентекләп тикшерүне мөмкин дип санамый. Шуңа бәйле, тәнкыйтьче Г. Тукайга өч мәкалә багышлый. Мәкаләләрнең язылу вакытлары төрле, димәк тәнкыйтьче шагыйрьгә төрле вакыт, тәҗрибә күзлегеннән карый. Моннан тыш, Г. Тукай исеме өстән генә башка мәкаләләрдә дә күренгәли.

И. Нуруллин «*Шагыйрьне өйрәнү юлында* »мәкаләсендә болай дип яза: «*Г. Халит китапларын, аеруча «Тукай үткән юл» монографиясен искә алмаганда, соңгы 10-15 ел эчендә Тукай иҗатын өйрәнүдә берьяклылык, фактларны алдан уйланган тезиска туры китереп җыю, шагыйрьне берниңди икеләнү һәм шикләнүне белми торган фикер иясе итеп күрсәтү тенденциясе гаять көчәеп китте»* [Нуруллин, 1966: 124].Ф.Хөсни дә Тукай турында йөргән стереотип фикерләрне җимерергә тели. *«Тукай турында уйлану» (1966)*мәкаләсендә болай яза: «Тукайның биографлары, аның замандашлары һәм гомумән Тукай турында язучы әдипләр һәм шагыйрьләр моңа хәтле мәсьәләнең күбрәк шул ягына басым ясый килделәр (изелгән, җәбер-золым күргән)». Ф. Хөсни шагыйрьнең тормышында, иҗатында күз яше, өзгәләнүләр барын раслый, ләкин шул ук вакытта талпынып-талпынып сөюләр, туган телгә мәдхия җырлаулар азмыни дигән сорау куя. Моннан тыш, тәнкыйтьче Тукайны хөрмәт итү, ярату сәбәбен аның аянычлы язмышында күрми, әлеге фактор – башлыча сәбәп тә түгел икәнен ассызыклый. Мәкалә барышында, Ф. Хөсни тарихилык принцибына таянып, шагыйрьнең “күз яше, пессимистик ноталар”дан “мәхәббәт, күңел бәйрәме”нә күчеп-күчеп алуларны аңлатырга тырыша. Бер караганда, Г. Тукай:

*Әсирмен, ычкыналмам инде мәңге,*
*Күңелсез һәр ягым, нурсыз, караңгы,*-[Тукай, 1910 ].

дигән булса, икенче яктан:

*Файдасыз бер ит кисәгеннән гыйбарәттер йөрәк,*
*Парә-парә кисмәсә гыйшык, мәхәббәт кайчысы,*-[Тукай, 2011, 1 т.: 265].

Ф. Хөсни мондый каршылыклы позицияләрне шигырь мисалларында күрсәтә. Хәтта, кайвакыт шигырьләр бинар оппозиция барлыкка китерәләр (“Дусларга бер сүз” - “Хөрмәтле Хөсәен ядкәре”; “Бәйрәм бүген” - “Нәрсәдән?”, “Авыл халкына ни җитми?” – “Васыятем”). Шул ук вакытта, Ф. Хөсни мөһим ремарка ясый: “*Әйе, Тукайда каршылыклар бар, ләкин шул ук вакытта бөек Тукайда яхшыны - яхшы, яманны – яман дип әйтә белү, үз чорының, үз халкының шатлыгын, өметләрен, киләчәген җырлау чагыштыргысыз көчлерәк*” [Хөсни, 1966: 148]. Тәнкыйтьче каршылыкларны күрмәскә тырышу да яхшылыкка алып бармауны аңлата. Шулай, күз йому аркасында Тукайга

“динне яклаучы шагыйрь”, “милләтче шагыйрь”, “вак буржуа шагыйре” кебек исемнәр тагыла. Шагыйрьнең тормыш юлын, иҗат этапларын анализлаганнан соң, Ф.Хөсни каршылыкларга аңлатма бирә, аларның асылын, килеп чыгышын билгели: “*Монда күптән исбат ителгән бер закон килә: әдәбият тормышны чагылдыра. Бәс шулай икән, Г. Тукайның иҗаты, үзенең барлык шул эчке каршылыкларында чагылдырмыймы? Ә Тукай яшәгән чор – әйтеп бетергесез каршылыклар белән чәбәләнгән чор. Контрастлар чоры*” [Хөсни, 1966: 149].

“*Г. Тукай һәйкәлен ачканда*” (1956) исемле мәкаләсендә Ф. Хөсни шагыйрь феноменына якын килергә тырыша, әлеге профессиянең фәлсәфәсенә аңлатма биреп карый: “*Дөньяда шагыйрь булып яшәүнең җиңел булмаганлыгын син белеп киттең, Габдулла! Шул ук вакытта дөньяда шагыйрь булып яшәүнең никадәр ләззәтле булганлыгын да, шәт, белгәнсеңдер син*” [Хөсни, 1956: 127]. Тәнкыйтьче бер сорау куя: татар халкы өчен кем иде соң ул Тукай?

Беренче нәүбәттә, Тукайны ул лидер буларак билгели. Чөнки шагыйрь халыкның тирән мәхәббәтен, хөрмәтен яулап һәм ничә гасырлар буена саклап калдыра алучы кеше. Әлеге дәрәҗәгә Тукай бары тик үзенең иҗаты, үтемле сүзе, олы җанлылыгы белән ирешә дип әйтә Ф. Хөсни. “*Бүген ачыла торган бу һәйкәл ташының ныклыгында без, барыннан да элек, Г. Тукайның халык массаларына булган ышанычының ныклыгын һәм камиллеген күрәбез”.*

*Кузгатмакчы булсаң халык күңелләрен,*
*Тибрәтмәкче булсаң иң нечкә кылларын,*
*Көйләү тиеш, әлбәт, ачы хәсрәт көен,*
*Кирәк түгел мәгънәсе юк көлке, уен...*- [Тукай, 2011, 2 т.: 67].

Икенче нәүбәттә, Ф. Хөсни Тукайны тел ачучы буларак билгели: “*Әгәр бүген без язма әдәбиятыбызда, йөрәкнең иң нечкә кылларын тибрәтүче лирик талпынышларны үз ана телебездә аңлатып бирә алабыз икән, бу кодрәтле телебез өчен шактый зур дәрәҗәдә без Тукайга бурычлыбыз. Тукай безнең әдәби телебезне ачучы булып кына калмады, ул аны күп төрле синонимнар, әйтеп бетергесез күп мәгънә бизәкләре, музыкаль авазлар белән баетты”* [Хөсни, 1956: 128].Ф. Хөсни язучының татар әдәбиятына гына түгел, ә татар теленә керткән биниһая зур өлешен ассызыклый. Ул Тукайда тагын башка сыйфатлар да табарга мөмкин ди, ләкин иң мөһиме әлеге икесен күрсәтә.

*Туган тел, и матур тел, әткәм, әнкәмнең теле!*
*Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы,* [Тукай, 2011, 2 т.: 69].

Ф. Хөснинең Тукайга багышланган соңгы мәкаләсе *«Тукайның фаҗигаләре» (1076-1977)* дип исемләнә. Әлеге мәкаләдә тәнкыйтьче Тукайга күбрәк шагыйрьгә кебек түгел, ә гади җир кешесенә кебек карый. Ул халык шагыйре турында болайрак яза: *“Беренче фаҗигасе – шагыйрьнең кыска гомерле булуы”* [Хөсни, 1976-1977: 71]. Ф. Хөсни шагыйрьнең егерме җиде яшендә дөнья куюын авыр кичерә. Шушы яшьтә дә татар тормышының бик күп сәхифәләрен ачып өлгерүе белән соклана. Әгәр озаграк яшәсә, әлбәттә, ул күбрәк мирас калдырыр иде дип сыкрана. *“Тукайның икенче фаҗигәсе – мәхәббәт хисе белән бәйле. Элеккерәк елларны кайбер ялган тукайчылар раслаганча, Г. Тукай мәхәббәттән качучы, мәхәббәт хисенең тәмен-ләззәтен белмәүче бер яклы шагыйрь түгел. Ул сөя, көчле итеп сөя белгән ”* [Хөсни, 1976-1977: 71] дип дәлилли. Шундый юнәлештәге бәяләүләрне, Ф. Хөсни бары тик шагыйрьнең иҗадияте гаять киң кырлы, масштаблы булуга карамастан, мәхәббәт темасына киң тукталмау белән бәйләп аңлата. Тәнкыйтьче Тукай фаҗигасенең бер чагылышын шунда күрә.

Ф. Хөснинең Тукайга мөнәсәбәте анын биограф булырга тырышу да, яңалык эзләү дә, ниндидер бер ачыш ясау да түгел. Тәнкыйтьче үзенә олырак миссия үтәүне максат итеп куйган: Габдулла Тукайның тормыш, яшәү, иҗат, шәхес фәлсәфен күрсәтү. Әлеге өч мәкаләдә, тәнкыйтьче шушы миссияне тулы килеш үти.

## ӘДӘБИЯТ


Нуруллин И.З. Шагыйрьне өйрәнү юлында // Казан утлары, 1966. №3. – 120-127 б.

Сверигин Р. Х. Фатих Хөсни: тормыш юлы һәм иҗаты. Казан: Татар. кит. нәшр., 1968. - 150 б.

Тукай Г.М. Әсәрләр: 6 томда: 1 т.: шигъри әсәрләр (1904-1908). Академик басма / төз., текст.. иск. һәм аңл. әзерл., Р.М. Кадыйров, З.Г. Мөхәммәтшин; кереш сүз авт. Н.Ш. Хисамов, З.З. Рәмиев. Казан: Татар.кит.нәшр., 2011. – 407 б.

Тукай Г.М. Әсәрләр: 6 томда: 2 т.: шигъри әсәрләр (1909-1913). Академик басма / төз., текст.. иск. һәм аңл. әзерл., З.Р. Шәйхелисламов, Г.А. Хөснетдинова, Э.М. Галимҗанова, З.З. Рәмиев. Казан: Татар.кит.нәшр., 2011. – 407 б.

Хөсни Ф. Уйланулар. Казан: Татар. кит.нәшр., 1961. - 221 б.

Хөсни Ф. Карурманга керәм. Казан: Татар.кит.нәшр., 1985. – 71 б.

Хөсни Ф. Ни әйтергә? Ничек әйтергә? Казан: Татар.кит.нәшр., 1969. – 145 б.

http://karaakkosh.com/tukay-stih_tt169.html (мөрәҗәгать итү вакыты: 02.09.2020).



**Н.Ш. САЙФУЛИНА**

Казанский федеральный университет, Казань


## ЭКСПРЕССИВНАЯ ФУНКЦИЯ ХУДОЖЕСТВЕННОГО ТЕКСТА


**Аннотация:** Данная статья предлагает посмотреть с другого ракурса на один из эффективных средств передачи чувств и мысли говорящего, как экспрессивность. Она является одной из важнейщих движущих сил в развитии языка, ибо наряду с другими категориями, экспрессивность служит не толькодля эффективной реализации намерений говорящего, но и воплощением в речи самой его личности, что особенно важно для художественного текста.

**Abstract:** This article suggests looking from a different perspective to one of the effective means of conveying the feelings and thoughts of the speaker, as expressiveness. It is one of the most important driving forces in thedevelopment of language, for along with other categories, expressiveness serves not only to effectively realize the speaker's intentions, but also the embodiment of his personality in speech, which is especially important for an artistic text.



**Ключевые слова:** Экспрессивность, художественный текст, речемыслительная деятельность, языковая природа.

**Keywords:** expressiveness, artistic text, speech activity, linguistic nature.


Художественный текст как одна из форм речемыслительной деятельности обусловлен потребностями общения и сообщения, и,следовательно, представляет собой вербализованную мысль субъекта (автора) о каком-либо фрагменте реальной действительности, предназначенную для передачи адресату (читателю). Такой подход позволяет рассматривать художественный текст как один из типов высказывания (наряду, к примеру, с высказываниями-предложениями, нечленимыми высказываниями и т.д.). Иными словами, текст, в том числе ихудожественный, есть завершённый, цельнооформленный, объективизированный в виде письменного произведения, продукт

речемыслительной деятельности людей, возникающий в процессе познания окружающей действительности, и в процессе непосредственной илиопосредованной коммуникации. [Нелюбин, 1981: 96]. Экспрессивность является одной из важнейщих движущих сил вразвитии языка, ибо способствует созданию новых средств, которые, в своюочередь, служат для наиболее ёмкой передачи мыслей и чувств говорящего.

Наряду с другими категориями, экспрессивность служит не толькодля эффективной реализации намерений говорящего, но и воплощением вречи самой его личности, что особенно важно для художественного текста.

*Миньяр-Белоручев Р. К.* отмечал возможностьсуществования многочисленных средстви способов выражения одного и того же эмоционального содержания.Наличие многочисленных экспрессивных средств он выводил из«ассоциаций, порождённых присутствием в памяти выражений, аналогичныхданному, создающих своего рода бессознательную синонимию» [Миньяр-Белоручев, 1969: 45]. Именно эта множественность выражения чувств и отношенийсоставляет по мнению ученого, проблему экспрессивности. Экспрессивность- это совокупностьсемантико-стилистических признаков языковой единицы,которые обеспечивают её способность выступать в коммуникативном актекак средства субъективного выражения отношения говорящего ксодержанию или адресату речи [Лингвистический…, 2009: 57]

Экспрессивность - это «всё, что делает речь более яркой, сильнодействующей, глубоко впечатляющей» [Виноградов, 1955: 87].

«Всё» - это характеризующиеся экспрессивностью морфологические и синтаксические, фонетические,лексические единицы языка; этоавторские неологизмы, введение просторечной или жаргонной лексики,стилистические фигуры; параллельные конструкции, зевгма, нарастание,всевозможные повторы, аллитерация и т.п.

Экспрессивно окрашенной лексике и её значению уделяется главноезначение в семасиологии (науке о значении слов и выражений и ихмодификаций). С точки зрения этой науки в деле изучения экспрессивностиважно вызывающих эмоциональную (чувственную) реакцию реципиента (читателя) разграничение слов, называющих эмоции.

Последняякатегория слов рассматривается учёными [Виноградов, 1955: 12] сквозь призму системного описания значения и, таким образом, теряеткоммуникативную самостоятельность, становится экспрессивно-синонимической.Таким образом, понятие экспрессивности может быть истолковано по-разному:

1) экспрессивность может быть и стилистической и лексикологической категорией;

2) необходимо учитывать тот факт, что экспрессивность имеетязыковую природу, т. е. действует через механизмы языка, а эффект еепроявляется только в речи (тексте). Отсюда следует, что экспрессивностьимеет двойственную природу.

В целом экспрессивность можно определить как отношение субъекта квысказываемому, как к содержанию коннотативного характера, что помимособственно экспрессивности, предполагает наличие в нем таких факторов, как эмоциональность и оценочность. Категории эмоциональности и экспрессивности тесно переплетаются. Экспрессивность может быть связана со стилистической маркированностью языковой единицы. На экспрессивных свойствах лингвистического средства строится тот или иной стилистический эффектконкретного текста, который конструируется из многообразного комбинирования элементов с различными стилистическими окрасками. Всовременном языкознании выделяются два аспекта стилистической окраски:

эмоционально-оценочный и функционально-стилевой. Они представляютсобой две разные стороны одного явления, так как в процессефункционирования единиц языка происходит взаимодействие обоих типов стилистической окраски.

Для переводческих целей полезно обращать внимание на денотативное значение, состоящее из эмоционального, интенсивного, оценочного, стилистического и диалектного компонентов. Коннотативные компоненты значения слова выражают или способствуют выражению: 1) эмоциональности, например: слово "mom" всравнении с "mother" более эмоционально, т. е. выражает большую близость, любовь, нежность и т. д или слово "toscarf' (ср. русск. жрать) всопоставлении с нейтральным "toeat" также более эмоционально, так какрождает чувство брезгливости, отвращения и пр., 2) экспрессивность (степень выразительности, напряжённость), например: глагол "toabhor" посравнению с "to hate" и "todislike" вызывает более яркое образноеощущение; 3) оценка, например: "cronies" в сравнении с "friends" вопределённом контексте имеет ругательный оттенок; 4) стилистическая окраска, например: "toslay" в соотношении с "tokill" звучит отчётливо формально, книжно или даже поэтически, также как "toscarf в отношении к"to eat" является словом жаргонным и, наконец, 5) диалектнаяпринадлежность или диалект: "a lift" является британским вариантом, в товремя как "anelevator" это американское слово, "toscarf определяетсяносителем британского английского как относящееся к американскомудиалекту, В британском диалекте синонимом глагола "toscarf являетсяглагол "toscoff. В каждодневном использовании все эти значения частичноперекрывают друг друга и разобраться в них становится трудно. Такимобразом, понятия выразительность или, по другому, экспрессивность иэмоциональность словозначения подчас трудно различить, в результате чегоэти понятия рассматриваются, в общем, как эмоционально-экспрессивныйзаряд или попросту говоря экспрессивность словозначения. Приведёмнекоторые примеры: "tolambastesmb" означает яростно нападать илиатаковать кого-либо, например: "He waslambastedinpress" - ср, русск, «Онподвергся яростному нападению со стороны прессы», В русском переводеэкспрессивность передаётся подключением эпитета «яростный». Ещё одинпример: "toslog (away) atsomething" означает работать без перерыва, вособенности, когда работа трудна или монотонна: I'vebeensloggingatthethesisforquiteaperiodoftimebuthaven'tyetfinishedit, - Я уже много днейкорплю над этим тезисом, но всё никак не могу закончить его.

Выразительность в данном случае сохраняется в русском варианте переводаблагодаря использованию разговорного слова «корпеть».

Итак, явление экспрессивности включает в себя следующие категории:

а) эмоциональность, б) оценка, в) интенсивность (экспрессивность), г)диалекты.

При работе над текстом переводчику необходимо помимо денотативногозначения принимать во внимание вышеуказанные коннотативные оттенкизначения слов для наиболее полного и верного выражения замысла автораисходного художественного текста.

Экспрессивность речи означает её необычность, выделение целого текстаили его части на фоне нейтрального языкового окружения путёмиспользования лексических, фонетических, грамматических илистилистических средств и, следовательно, способствующего положительной или отрицательной оценке данного текста (или его части) получателем, ибовоздействует на его эмоциональную сферу. В качестве примера, можно привести использованиенейтрального слова "dirty" в романе У. Фолкнера «Авессалом, Авессалом»,которое повторяясь периодически на протяжении целого

произведения какбы выпячивается, «семантически» раздувается, начиная воздействовать начитателя как некая магическая формула, заклинание, и вызывая у него, такимобразом, ассоциации не связанные с первоначальным предметно-логическимзначением указанной лексической единицы [Faulkner, 2016]. Мы можем предположить, чтонекоторые слова, которые когда-то имели нейтральное, с точки зренияэкспрессивности, предметно-логическое значение (за исключениеммеждометий, несущих эмоционально-экспрессивный заряд), но в ходеисторического развития были выделены человеком, в силу объективных или субъективных причин и, вследствие этого, получили название«эмоционально-окрашенных» или «выразительных».

Экспрессивность, таким образом, может пониматься как категориякоммуникативного плана, обозначающая «воздейственность содержания какой-либо лингвистической единицы в определённом контексте, какокказиональная выразительность», возникает спонтанно, «проявляется в конкретной речевой ситуации (контексте), в свою очередь, придавая этому «окружению» определённый оттенок, и тем самым, усиливая выразительность языковогоотрезка в целом [ Ахманова, 2017: 56].

## ЛИТЕРАТУРА


Ахманова О. С. The principles of Linguistic Confrontation. М.: изд. МГУ, 2017.

Нелюбин Л.Л., Дормидонтов А.А., Васильченко А.А. Учебник-военного перевода. Английский язык. М.: Воениздат, 1981.

Лингвистический энциклопедический словарь. 2009.

Миньяр-Белоручев Р. К. Последовательный перевод. Теория и методы обучения. М.: Воениздат, 1969.

Виноградов В. В. Итоги обсуждения вопросов стилистики // Вопросы языкознания, 1955. № 1. С. 73.

William Faulkner. Absalom, absalom: Polirom, 2016.



**Ф.С. СӘЙФУЛИНА**
Казан федераль университеты, Казан
**З.С. МАМУТОВА**
Февзи Якубов ис. Кырым инженер-педагогика университеы, Симферополь
**З.Р. БАРИЕВА**
МАОУ “30нчы төп гомумбелем бирү мәктәбе”, Казан


## ӘДӘБИЯТТА ТАРИХ ЧАГЫЛЫШЫ
## (К. БИККУЛОВНЫҢ “ТӨРКЕСТАН” ӘСӘРЕ НИГЕЗЕНДӘ)


**Ф.С. САЙФУЛИНА**
Казанский федеральный университет, Казань
**З.С. МАМУТОВА**
Крымский инженерно-педагогический университет имени Февзи Якубова, Симферополь
**З.Р. БАРИЕВА**
МАОУ “Основная общеобразовательная школа №30”, Казань


## ОТРАЖЕНИЕ ИСТОРИЧЕСКИХ СОБЫТИЙ В ЛИТЕРАТУРЕ

## (ПО ПРОИЗВЕДЕНИЮ К. БИККУЛОВА “ТУРКЕСТАН”)

**Аннотация:** Данная статья посвящена анализу исторического романа «Туркистан», писателя начала XX столетия Касима Биккулова, посвященного событиям конца 19 века в Средней Азии. Здесь также раскрываются судьбы Астраханских татар, попавших в плен морским грабителям, работорговцам.

**Abstract:** This article is devoted to the analysis of the historical novel "Turkistan" by the writer of the early 20th century Kasim Bikkulov, dedicated to the events of the late 19th century in Central Asia. It also reveals the fate of the Astrakhan Tatars who were captured by sea robbers and slave traders.

**Ключевые слова:** татарская литература начала XX века, исторический роман, К.Биккулов

**Keywords:** Tatar literature of the early twentieth century, historical novel, K. Bikkulov

XX гасыр башында укытучы, мәгърифәтче язучы булып танылган Касыйм Бикколов әсәрләрендә шул заман чынбарлыгы, көнкүреше кебек замана укучысы өчен кызыклы булган мәгълуматлар белән бергә, шул вакыттагы төрки төрки дөнья бәйләнешләре, тарихи вакыйгаларына да шактый зур урын бирелә. Шундый әсәрләренең берсе - «Төркестан» әсәре. Әлеге әсәрнең беренче варианты «Әсирлек хикәяте» исемле кыйсса рәвешендә К. Бикколовның 1904 елда басылган “Нәмүнәи тәрәкъкый” исемле уку китабына урнаштырылган. Соңрак бу сюжет «Төркестан» әсәре нигезенә ята.

«Төркестан» әсәре – Фәрит Бәшировның “XX йөз башы татар прозасы” хезмәтендә билгеләнгәнчә, татар телендә язылган беренче тарихи романнарның берсе. Галим «...әсәр үзәгенә XIX йөзнең икенче яртысында Россия тарафыннан Урта Азиягә ясалган хәрби поход вакыйгалары алынган» дип язса да, повестьнең шактый өлешен шул заманда Урта Азия халыклары хәятен сурәтләү алып тора.

Әсәр башында автор Төркестан якларындагы XIX гасыр урталары мәдәни-икътисади хәл турында мәгълумат бирә: «Бу көнебездән илле еллар элек улан бер заманда, Төркестан тәмам башка бер галәм иде. Ул вакытлар анда тимер юллар, машина, телеграмм дигән нәрсәләрнең исеме улмадыкы кеби, низам, хаким, гадәләт, мөсавәтнең (тигезлек, бердәйлек) ни идекен белмиләр иде.»

Шул рәвешле, әсәрнең башында ук автор укучыны тәнкыйди юнәлештә сурәтләнгән вакыйгаларны кабул итергә әзерли. Тарихи әсәрләргә хас булганча, Урта Азия якларында шушы заманда вә аннан алда булган вакыйгалар сурәтләнә, аларга авторның мөнәсәбәте белдерелә, Петропавел, Ташкент, Бохара, Әстерхан шәһәрләре телгә алынып, ул яклардагы халыкка карата кылынган башбаштаклыклар, кеше үтереш, кан кою, вәхшилек, хәтта кешеләрне кол итеп сатуның да булуы хакында языла. «...Төркестан төрекмәннәренең золымы илә әсир улып, коллыкка сатылып, хисапсыз мәшәкатьләр күргән мөселман кардәшләребез (кара нугайларның) хикәятен без дә бу китапда күстәрәчәкмез» – дип әсәр башында хәбәр иткән язучы алга таба нугай халыкларының тарихы, килеп чыгышы, яшәгән географик урыннары, халык саны һ.б. хакында кызыклы мәгълүматлар бирә.

Шуның белән бергә әсәр фәкать тарихи фактлар тупланмасы гына булмыйча, чын әдәби әсәр буларак кабул ителә һәм бәяләнә ала. Беренче чиратта әсәренең һәм сюжет-композициясе, һәм сәнгатьлелеге ягыннан камил эшләнгән, тел-сурәтләү чараларына бай булуына басым ясарга кирәк. «Ул вакытларда диңгез читләрендә вә диңгез тармакларында балыкны һич бер җәтмәсез, аусыз, чүмеч илә дә тултырып алмак мөмкин иде. Бу кешеләр (әсәр геройлары – Әстерхан төркиләре) көймәгә ултырган көн

һава бик яхшы, саф, җил бер дә юк, диңгез өсте эскәтер кеби тигез, ифрат хозур, матур иде. Ерактан кош канаты кеби ап-ак фарус (җилкән) читәннәре күренә, зур-зур сазан балыклар чулт-чулт итеп сикерә, уйныйлар иде. Шундый саф һавада аз гына исә торган җил илә, җилкәннәрен күтәрү илә, болар аз вакытта күп җирне сәяхәт кылдылар». Әсәр башында сурәтләнгән хозур табигать күренеше алдагы бүлекләрдә сурәтләгән Урта Азия ягы халкы тормышына вә әхлакый халәтенә каршы куелып, чынбарлыкның реалистик картинасын тудырырга ярдәм итә. Шул рәвешле хәятнең ямьсез яклары контраст күренешләр аша ассызыклана.

Геройлар белән таныштыру да әдәби әсәр кануннары буенча төп вакыйгалар барышында урын ала. Авторның сюжет кору үзенчәлеге, вакыйгаларны укучыларны кызыксындырырлык итеп төзүе, әсәренең мәгълүматлы булу ягына да игътибар итү – әсәрнең бер яктан мәгърифәтчелек традицияләрен дәвам иттерүен, икенче яктан тәнкыйди  реализм юнәлешендә иҗат ителгән булуын раслый һәм бу ике юнәлеш табигый рәвештә бер әсәр кысаларында урын ала.

Роман башында автор укучыларны диңгездә көймәдә йөзүче нугай егетләре һәм бу өлкәдә зур тәҗрибәсе булган Бикмулла карт образы белән таныштыра: «Бу нугайларның эчендә бик күпне күргән, диңгезнең, җилнең хәленә бик гүзәл төшенгән Бикмулла исемле карт улып, боларның күршеләре иде. Мәзкүр Бикмулла һаваның үзгәрдекен күреп: «Егетләр, бу җил безгә хәерле түгел, хәзер Тимер Казыктан киләдер, имди без бик тирәнгә киткәнче якорь ташлап, шунда бераз сабыр итеп тораек. Вә Алла безгә көч бирми тирәнгә алып китеп һәлак итәр, һәр нә көймәне туктатканымыз яхшы улыр,» – дия, якорь салырга кушты. Һәм тиздән егетләр, зур якорь салып, көймәне туктатып, чәй кайнатырга тотындылар.»

Алга таба автор табигатьнең соң чиккә җитеп тынычсызлануын, куркыныч диңгез сурәтен детальләп сурәтләү белән бергә, шушы диңгез уртасында ярдәмсез калган кешеләрнең күңел халәтләре үзгәрешен дә осталарча чагылдыра. Күпне күргән диңгезчеләр баштарак бу давылның вакытлыча гына булуына инанып, көймәне бөтереп йөрткән давылга да исләре китмичә, чәй эчеп, йокларга ятсалар, тәүлектән артык үкереп торган җил-давыл якорьларын өзеп, шушы мәшһәрдә көймәләрен ачык диңгез иркенә ташлагач, чиксез диңгез кочагында йомычка кебек кенә бөтереп йөртелгән көймәдә диңгезчеләрнең тоташ куркуын чагылдырган күренешләргә барып тоташа: «Диңгез өстендә тәмам ак баш илә капланган дулкыннар тау кеби авып, беренә бере тоташып килә, көймә бер югары, бер түбән төшеп китә иде. Төн яртылары улды, аз гына ай яктысы бар иде, бераздан соң ул да юк булып, гаять караңгылык улды. Җил әүвәлгедән ун өлеш артты. Көймәдә аяк өстенә тормак түгел, утырып торырга да мәҗал (көч; мөмкинлек) калмады. Асты өскә килә, тау кеби дулкыннар илә диңгез өстендә кыямәт кыла иде.» Шул рәвешле әсәр барышында һәм табигать сурәте, һәм геройларның күңел халәте алмашынуы да автор тарафыннан шактый осталык белән бирелә.

Сюжет кысасында автор укучы өчен бик кызыклы булган бу як табигатенә хас күренеш хакында да мәгълүмат биреп үтә, шуңа бәйле рәвештә әсәр сюжетында да хәрәкәт башлана: «Әстерхан диңгезенең суы җил илә бер яктан бер якка агып йөридер. Бу яктан җил улса, суны аргы якка чыгара; аргы яктан улса, бирге якка коры улан җиргә суны менгезәдер. Бу диңгезнең читләрендә яр улмадыктан, бик күп җирне су басып, печәнлек, утлык җирләр су астында каладыр. Боларның да көймәләре, үзләре йоклаганда, су кайтып беттекеннән, кырыйда – балчык эчендә калмыш иде».

Яңа гына диңгез кочагында үлем көткән һәм моннан Ходай кодрәте белән исән-имин котылган диңгезчеләр язмышы өчен җиңел сулап та өлгермәгән укучыны яңа тетрәнүләр көтә: бер мәхшәрдән котылган геройлар аннан да яманыны – утлы-кылычлы диңгез басучылар, кеше талаучылар кулына эләгәләр. Әсәрнең дәвамы – юлбасарлар кулына эләккән нугай егетләренең язмышы, аларны кулга алучылар – кеше сатып, акча табучыларның кансызлыгын сурәтләүгә багышлан. Юлбаларларның мал базарындагы кебек, диңгезчеләрне яшенә, кыяфәтенә, көченә, матурлыгына карап, берничә төркемгә аерып, кайсын нинди бәягә сату мөмкин булуы турында фикер алышулары – мәгърифәтче автор тарафыннан реалистик һәм кискен тәнкыйди пафоста сурәтләнә.

Әсәрнең сюжет-композициясе укучы игътибарын үзендә тотарлык, катлаулы, замана укучысы өчен дә яңа булган вакыйгаларны сурәтләве белән аерылып тора. Кызу көндә, тездән комда, яланаяк, куллары бәйләүле, аякларына колодка кидерелгән бу кадерсез инсаннарның мең җәза, кыен-мәшәкать белән, юлда әлләничә шәһәр һәм базарларга туктап, кайберсен сатып, кайсыларын атка яки дөягә алыштыруларын сурәтләү аша автор XIX гасыр Урта Азия яклары чынбарлыгының никадәр аяныч һәм куркыныч булуын укучыга җиткерә, сатучыларның кансызлыгы, үзләрен кешелек сыйфатларын җуйган кыргыйлар кебек тотулары автор тарафыннан натуралистик тәфсилләү белән тасфир ителә. Сатылырга китерелгән кызларның хәле ирләрнекеннән дә яман булуы сурәтләнә. Шул рәвешле, әсәрдәге вакыйгалар кол итеп сатылган нугай егетләренең язмышын күзәтеп бару рәвешен ала һәм шушы авыр юлдагы күргәннәрен, шул якның табигате, кешеләренең яшәү рәвешен тасвирлау белән бергә сурәтләнә. Алга таба вакыйгалар шушы кәрван белән Бохарага таба юл ала.

Дөньяга мәдәни мәркәз буларак танылган Бохара шәһәренә якынлашкан саен, никадәр озак юл газаплары кичерән булсалар да, кулга алынган нугай егетләренең күңелләрендә азат булуга өмет хисе яңадан уяна, чөнки Бахара кебек мәгърифәт үзәге буларак дан тоткан шәһәрдә кол сату кебек түбән әйбергә юл куелмас, аларның ирекле кешеләр булуын аңларлар, азат итерләр дигән ышаныч туа. Ләкин өметләр акланмый. Язучы бу урында да үзенең мәгърифәтчелек карашларын укучы белән бүлешә: «Әгәр сез Бохарада кол базарын күрсәңез иде, «бу шәһәрдә аслан шәфкать, мәрхәмәт дигән нәрсә юкмы, исламият-инсаниятнең нә ирдекен белмиләрме» дия гаҗәпкә калыр идеңез...»

Авторның Бохара һәм Төркестандагы бу вакыйгаларга, кол сату кебек вәхшилекләргә, кешеләрне кара хезмәтче итеп тотуга кискен каршы мөнәсәбәте әсәр дәвамында ачык чагылыш таба. Бу шартларда Россия дәүләтенең кылган гамәлләре «... бу золымлыкны бетермәк вә һәр адәмне азат идеп, ихтыярында кылмак өчен...»- дип тәкъдим ителә һәм шул рәвешле Бохарага илчеләр килүе вакыйгасына уңай мөнәсәбәт күрсәтелә. Бу илчеләр Бохарада килешү төзү, кол сату, кеше талау кеби вәхшилекләрне бетерүне сорасалар да, әмир моны кабул итми, киресенчә, илчеләрне дә әсир кылды, дип языла. Әлбәттә, эш моның белән төгәлләнмичә, сугыш башлау турында карар кабул ителә. Автор бу очракта да гаскәре, коралы булмаган халыкларны талап йөрү, шуны зур көч вә мәртәбәгә санаган юлбасарлар өчен, сугыш эшенә өйрәтелгән гаскәриләре булган Русия белән сугышының нәтиҗәсе начар булачагын алдан ук кисәтеп куя. Шул рәвешле әсәрнең икенче өлеше Русия һәм Урта Азия арасындагы сугыш вакыйгаларына барып тоташа. Ф.Бәширов билгеләп үткәнчә, К. Бикколов «тарихи материаллардан иркен һәм белеп файдаланганлыгы аңлашыла; Ташкент, Сәмәрканд һ.б. шәһәрләрнең рус гаскәрләре тарафыннан алыну даталары документаль дөрес күрсәтелә. Рус отрядлары

белән әмир армиясенең бәрелеше, сугышның характеры, халыкларның үзара конфликты язучы каләме аша объектив тасвирлана, җанлы ышандыргыч картиналарда сурәтләнә» [Бәширов, 2002: 175-176].

Әсәрдә 1866 елдагы рус армиясенең Төркестанга каршы сугышын сурәтләү барышында тарихи шәхесләр – генерал Черняев, генерал Романовскийлар исемнәре дә телгә алына. Сугышка әзерләнүче әмир гаскәренең бу эшкә җитди карамавы, бу эшне дә коралсыз халыкны, авылларны талап, байлык, коллар, кызлар алып кайту дип кенә кабул итүләрен автор бер үк вакытта ачынып һәм тирән сатира, сарказм белән сурәтли. Мөселман халыкларының оешмаганлыгы, бер-берләрен талап, җәберләп яшәүләренең нәтиҗәсе уңай булмаячагын алдан ук искәртеп куя. «Әмирнең гаскәр дидеке Яуропадагы солдатлар кеби бер сорт вә бер формада улмаеп, каюсы өстенә чапан, башына чалма, аягына башмак кигән. ... Алга таба да әмир гаскәрләренең кораллары, сугышу ысуллары, тәртипкә, сугыш хөнәренә өйрәтелгән рус армиясеннән күпкә кайтыш булуын яза. Алар өчен бу сугыш максаты да дошманның зарарыннан имин булу, дәүләтләрен саклау түгел, ә дошманның малын таламак дип бәяләнә. Дошманга каршы шау-шу килеп, Бохарадан чыгып, берничә көннән бер җиргә туктап, чатырлар корып, пылаулар пешереп рәхәтләнеп ял итүче, «дошман янына барып, изү вә сакаллардан тотышып, аяк чалышып хәйлә илә екмак вә таш илә дошманның башын сугып ярмакны көтеп торучы» мөселманнар, әлбәттә, рус армиясенең беренче туп атуларын ишеткәч үк, «бүредән курыккан куй вә сарыклар кеби кайда керергә җир тапмай, бердән качмага башладылар», дип язуы да әсәрнең тәнкыйди характерда булуын һәм хәтта ачы сарказм белән язылуын раслый.

Автор шул рәвешле бик җиңел генә Сәмәркандны кулдан ычкындырган әмирнең, солых төзергә, Бохарада әсирлекне бетерү, кол сатуны тыю шартына ризалык бирергә мәҗбүр булуы турында бәян иткәндә дә акыл белән эш иткәндә Сәмәрканд, Бохара шәһәрләренең мөстәкыйль кала алулары турында фикер йөртә.

Шул рәвешле, әсәрнең беренче өлешендәге нугай егетләренең кулга алыну тарихы әсәр ахырында шушы солых төзелүгә бәйле рәвештә коллыктан азат ителүләре һәм туган якларына кайтулары белән төгәлләнә. Автор әсәр сюжетындагы вакыйгаларны оста итеп бер-берсенә бәйли, аерым геройлар язмышларын тарихи шартларга куеп, укучыны кызыксындырырлык әсәр тудыра. К. Бикколов мөселман халыкларының бу җиңелүе сәбәбен таркаулыкта, наданлыкта, прогресстан артта калуда күрә, бу да авторның мәгърифәтчелек карашлары тарафдары булуын раслый.

Үз заманының төрле проблемаларын әдәби әсәр югарылыгына күтәреп чагылдыра алган оста прозаик иҗаты, әлбәттә, үзенең өйрәнүчесен, бәяләүчесен, җитди, тирән хезмәтләрне көтә. Гасыр башының катлаулы, күп юнәлешле әдәби барышында К. Бикколов тоткан урынны билгеләү, аның әдәби мирасын шушы контекста җентекләп өйрәнү – яңа эзләнүләргә, ачышларга юл ача.

**ӘДӘБИЯТ**

Бәширов Ф.К. XX йөз башы татар прозасы.  Казан: Фикер, 2002. – Б. 175-176.

**Г.Р. САФИУЛЛИНА**
Казанский федеральный университет, Казань

# ПЕРЕВОД КУЛЬТУРНО-МАРКИРОВАННЫХ ЛЕКСЕМ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА (НА МАТЕРИАЛЕ РАССКАЗА АМИРХАНА ЕНИКИ «МАТУРЛЫК»)

**Аннотация.** В статье рассматривается лексический способперевода культурно-маркированных лексем татарского языка на материале рассказа Амирхана Еники «Матурлык» (Красота). Данный рассказ был переведен автором статьи в 2019 году в рамках мероприятий, посвященных 110 летнему юбилею писателя. Обзору подвергаются лексические единицы, обозначающие лакунарные экстралингвистические реалии, а именно, названия предметов, песен, литературных произведений, понятий религиозного плана, народные песни и традиции, прагматические клише, упомянутые в тексте рассказа. Отмечается наиболее полный тип подачи лексем с фоновыми знаниями для полного восприятия англоязычным читателем. В результате приведенного исследования мы пришли к выводу, что культурно-маркированные лексемы необходимо переводить при помощи монолексемного эквивалента, в обязательном сочетании с развернутой культурно-исторической справкой.

**Abstract.** The article discusses the lexical way of translating culturally-marked lexemes of the Tatar language based on the story of Amirkhan Eniki "Maturlyk" (Beauty). This story was translated by the author of the article in 2019 as part of the events dedicated to the 110th anniversary of the writer. The review examines lexical units denoting lacunar extralinguistic realities, namely, the names of objects, songs, literary works, concepts of a religious nature, folk songs and traditions, pragmatic cliches mentioned in the text of the story. The most complete type of presentation of lexemes with background knowledge for full perception by an English-speaking reader is noted. As a result of the above research, we came to the conclusion that culturally-marked lexemes must be translated using a mono-lexeme equivalent, in a mandatory combination with a detailed cultural and historical reference

**Ключевые слова:** татарский язык, монолексемный перевод, дескриптивный перевод, культурный комментарий

**Keywords:** Tatar language, mono-lexemic translation, descriptive translation, cultural commentary

Рассказ Амирхана Еники «Матурлык» (Красота) был переведен автором статьи, наряду с повестью «Әйтелмәгән васыять» и рассказом «Мәк чәчәге» на английский язык в 2019 году в рамках мероприятий, посвященных 110летнему юбилею писателя. Поскольку данные произведения в конечном итоге представлены на суд англоязычного читателя, задачей, стоящей перед переводчиком, стало сделать текст понятным и удобным для прочтения носителем англоязычной культуры. Текст рассказа перенасыщен культурно-маркированными лексемами, отражающими экстралингвистические реалии, требующие дополнительного пояснения. В начале работы над проектом было принято решение сохранить целостность рассказа и его аутентичную атмосферу татарской культуры начала 20 века.

В.Н. Комиссаров [Комиссаров, 1980], А.В. Кунин [Кунин, 1987], Я.И. Рецкер [Рецкер, 1982], Д.Р. Рахматуллина [Рахматуллина, 1995], В.И. Хайруллин [Хайруллин, 1995], Н.Л. Шадрин [Шадрин, 1991], и др. в своих исследованиях рассматривали языковую картину мира и ее проявления в лексемах, фразах и предложениях [Комиссаров, 1980; Кунин, 1987; Рецкер, 1982; Рахматуллина, 1995; Хайруллин, 1995;Шадрин, 1991]. Три типа переводческих соответствий было выявлено Я.И. Рецкером, как то: 1) эквиваленты; 2) аналоги (вариантные соответствия); 3) адекватные замены [Рецкер, 1982]. В классификации Н.Л. Шадрина предложены варианты: эквиваленты, аналоги, синонимические соответствия, константное лексическое соответствие, контекстуальный аналог, калька, окказиональное

лексическое соответствие, описание как межъязыковые соответствия [Шадрин, 1991]. Данная классификация в рамках данного исследования взята за основу.

Для проведения практической части исследования нами был выбран перевод рассказа классика татарской литературы АмирханаЕники «Матурлык», написанного в 1964 году.

О.Н. Иванищева в своем исследовании, посвященном лексикографированию культуры в двуязычном словаре, отмечает роль фоновых знания в правильном понимании текста. Исследователь проводит черту между когнитивной и коммуникативной характеристиками фоновых знаний. Когнитивная сущность, по мнению О.Н. Иванищевой, реализуется в имплицитности контекста высказывания, а коммуникативная в его эксплицитных характеристиках. [Иванищева, 2006: 13]

О.Н. Иванищева отмечает, что культурно-маркированная лексема в случае отсутствие полного эквивалента «требует использования нескольких типов перевода: перевод при помощи употребляемого в выходном языке, созданного автором или описательного эквивалента». [Иванищева, 2006: 16) и выделяет четыре типа текста, с компонентом культурно-коннотированного слова: нейтрализующий текст, представляющий текст, стимулирующий текст и констатирующий текст [Иванищева, 2006: 16].

По нашему мнению, при переводе текста на татарском языке на английский язык нейтрализующий текст сочетается со стимулирующим текстом. Рассмотрим пример из текста рассказа АмирханаЕники «Матурлык». Слово шакирд переводится нами в виде эквивалента shakird (шәкерт). Внизу страницы дается сноска на фоновую информацию, незнакомую для большинства англоязычных читателей

*Shakirds (шәкерт) [ʃæˈkert] a student at a madrasah-level Muslim school who studies the basics of Islam, Arabic script, religious scholastic disciplines, and calligraphy. The curriculum may include foreign languages, arithmetic, geography, history, etc. (Шакирд (шәкерт) [ʃæˈkert] студент мусульманской школы на уровне медресе, который изучает основы ислама, арабского письма, религиозных дисциплин и каллиграфии. Учебный план может включать в себя иностранные языки, арифметику, географию, историю и т. д.)* [Еники, 2019: 13]

Примером представляющего текста может служить слово верста. Обратимсякпримеруverst (верста) [versˈta] Russian measure of length, equal to 1.06 km. (Русская мера длины, равная 1,06 км). Таким же образом после английского эквивалента приводится его татарский вариант в скобках, затем фонетическаятрансрипция и завершает культурологическую справку определение слова verst [Еники, 2019: 13].

К констатирующему тексту мы можем отнести лексему milletbread, (хлеб из пшена) В данном случае нет поясняющего комментария, читатель понимает значения компонентов выражения, которые описывают новое для него понятие [Еники, 2019: 14].

В нашем исследовании мы придерживаемся мнения, что наиболее удобным в качестве представления татарских культурно-маркированных единиц на английском языке является перевод методом заимствования, так как при этом сохраняется художественная стилистика языка оригинала, читатель погружается в культурную среду, а культурный комментарий позволяет понять этимологию слова и его экстралингвистические характеристики.

К примеру, Ayatal-Kursi. Дается объяснение, что это 255 стих Суры Аль-Бакара, второй суры Корана. Полностью приводится перевод молитвы на английский язык.

В описании обстановки дома шакирдаБадретдинаприсутствуют книги –«Бүзегет», «Тутыйнамә», «ЛәйләбеләнМәҗнүн», «Каһарман Катил». Мы сохраняем свою систему подачи культурно-маркированных лексем через заимствование и культурный комментарий. Рассмотримследующийпример:

*"Buzeget"(Noble Dzhigit) (Бүзегет) Poetic popular romance dastan of Tatar folk art. The widespread distribution of the legend was facilitated by the repeated appeal of Tatar writers Bahawi, Kurmashi to it. (Поэтический популярный романтический дастан татарского народного творчества.Широкому распространению легенды способствовало неоднократное обращение к ней татарских писателей Бахави, Курмаши )* [Еники, 2019: 24]

В английском переводе текста рассказа «Матурлык» мы уделяем внимание также культурному комментарию татарских обычаев. После фразы, что шакирды, выпив чай, перевернули чашки вверх дном, комментируется не втексте рассказа, а в сноске в конце страницы: A Tatartraditiontoturnthecupswiththeirbottomsupwhen a guestdoesn'twanttohaveanymoretea (Татарская традиция поднимать чашки вверх дном, когда гость не хочет больше чая) [Еники, 2019: 24].

